# казан утлары

9
СЕНТЯБРЬ • 1977

**СССР Верховный Советы Президиумының 1977 ел 27 май Указы белән расланды *.**

# СОВЕТ СОЦИАЛИСТИК РЕСПУБЛИКАЛАР СОЮЗЫ ГИМНЫ

С. МИХАЛКОВ, Г. ЭЛЬ-РЕГИСТАН
тексты

А. В. АЛЕКСАНДРОВ
музыкасы

ӘХМӘТ ИСХАК, НУРИ АРСЛАНОВ
тәрҗемәсе

**Республикаларны туплап нык союзга,
Бөек Русь азат, җиңелмәс ил төзде.
Яшә син, халык теләге тудырган ил,
Бердәм, куәтле Советлар Союзы!**

**Дан сиңа, дан, безнең азат Ватаныбыз,
Бар халыклар дуслыгы нигезе!
Ленинчыл партия — син халкыбыз көче,
Син илтәсең коммунизмга безне!**

**Ирек кояшы балкыды давылларда,
Бөек Ленин юл яктыртты көрәштә:
Илне күтәрде хаклыкны дауларга ул,
Бирде рух безгә яуларда һәм эштә.**

**Дан сиңа, дан, безнең азат Ватаныбыз,
Бар халыклар дуслыгы нигезе!
Ленинчыл партия — син халкыбыз көче,
Син илтәсең коммунизмга безне!**

**Күрәбез илнең киләчәк көннәрен без
Сүнмәс коммунизмның җиңүләрендә,
Кызыл байрагына данлы илебезнең
Тугры булырбыз без гомер-гомергә!**

**Дан сиңа, дан, безнең азат Ватаныбыз,
Бар халыклар дуслыгы нигезе!
Ленинчыл партия — син халкыбыз көче,
Син илтәсең коммунизмга безне!**

* Татарча текст Татарстан АССР Верховный Советы Президиумының 1977 ел 4 август карары белән расланды.

# Казан утлары




АЙЛЫК ӘДӘБИ ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ
ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫ ОРГАНЫ
1922 елның май аеннан башлап чыга

**9**

СЕНТЯБРЬ
1977

## Бу санда

Р. ГАТАУЛЛИН. Европада татар шагыйрьләре. Шигырьләр . . . . . . . . . . . . . . . 3
Х. САРЬЯН. Бер ананың биш улы. Повесть . . 10
Г. АХУНОВ. Дәверләр документы . . . . . . 105
Яклыйбыз, хуплыйбыз! . . . . . . . . . . . 108
М. ШОЛОХОВ. Дүртенче баскыч . . . . . . 110
Р. ГӘРӘЙ. Күккә менеп... Шигырьләр . . . . . 112

ОКТЯБРЬНЫҢ 60 ЕЛЛЫГЫНА

Ә. МАЛИКОВ. Мәйдан тоту . . . . . . . . . . 114
С. ШАКИР. Казан Кремле янында . . . . . . 124

К. ТИНЧУРИННЫҢ 90 ЕЛЛЫГЫНА

Р. ИГЪЛАМОВ. Заман көзгесенә куеп . . . . 129
А. ЯХИН. Без кабызган утлар... . . . . . . . 137
Р. ИШМОРАТ. Дус һәм остаз . . . . . . . . 143

СӘНГАТЬ

Д. ВӘЛИЕВА. Борынгы да, бүгенге дә . . . . 149

ХАЛЫК ИҖАТЫ

Р. МӨХӘММӘТҖАНОВ. Эзләсәң — табыла . . . 155

ӘДӘБИЯТ ТАРИХЫНА МАТЕРИАЛЛАР

Р. МӨХӘММӘДИЕВ. Югалмас мирас эзеннән . . 165

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

К. МИҢЛЕБАЕВ. Камиллеккә омтылу . . . . . 175

КПССның
ТАТАРСТАН
ӨЛКӘ
КОМИТЕТЫНЫҢ
ГАЗЕТА ҺӘМ
ЖУРНАЛЛАР
НӘШРИЯТЫ
КАЗАН

КИТАП КҮЗӘТҮ

**Б. КАМАЛОВ.** *Лачын кызлар* . . . . . . . . . 181
**Е. БАЙТУКОВ.** *Әдәбиятларыбыз дуслыгы* . . . . 183

МӘСӘЛЧЕЛӘР МӘҖЛЕСЕ

**Сулхан-Саба Орбелиани** . . . . . . . . . . . 186
**Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары** . . . . . . 189

Редакциянең адресы. Казан, 420066, ул. Декабристов, 2.

Телефоннар: Баш редактор — 3-07-60, җаваплы секретарь — 3-07-09, проза бүлеге — 3-07-69, поэзия бүлеге — 3-07-69, тәнкыйть бүлеге — 3-07-63, сәнгать бүлеге — 3-07-63, очерклар бүлеге — 3-07-61, хатлар бүлеге — 3-07-61, корректорлар — 3-07-65, техник редактор — 3-07-65, машинисткалар — 3-07-60.

Баш редактор: **Зәки Нури**

Редколлегия: **Әхсән Баянов, Хәй Вахит, Шәүкәт Галиев, Аяз Гыйләҗев, Ләбибә Ихсанова** (җаваплы секретарь), **Шәйхи Маннур, Рафыйк Нәфиков, Атилла Расих, Гали Халит, Сибгат Хәким, Нил Юзиев, Мирсәй Әмир**

© «Казан утлары», 1977 ел.

Техник редакторы *Р. Нәбиуллина*
Корректорлары *Р. Сөләйманова, К. Корбангалиева*

Производствога бирелде 1/VI-1977 ел. Басарга кул куелды 10/VIII-1977 ел. ПФ 13256. Кәгазь форматы 70×108¹/₁₆. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12(16,8). Тираж 84544 экз. Заказ Б-229. Бәясе 50 тиен.

КПССның Татарстан өлкә комитеты нәшрияты типографиясе.
Казан, Декабристлар урамы, 2.

**Рәдиф Гатауллин**

# ЕВРОПАДА ТАТАР ШАГЫЙРЬЛӘРЕ

## Ышаныч

ПУБЛИЦИСТИК НОТА

Әйе, ялгышмыйсыз, «азат дөнья»дагы
«дуслар!»
Без — коммунист.
Без җиребезнең матур киләчәгенә ышанабыз,
шул юлга бар гомер багышланган,
без — оптимист.

Пессимизмның ни икәнен беләбез,
беләбез төшенкелеккә бирелгән кешеләрне,
фаҗигагә юлыккан илләрне;
ләкин,
«кеше — кешегә бүре» димәбез.
Ышанабыз: яктылык, хаклык җиңәчәк!
Ышанычыбыз — Эринда,
Палестинада, Чилида —
бар дөньяда күкрәр кызыл чәчәк!
Ышанычыбыз бәхәсләшә Пентагоннар белән,
маоизм белән
(һәм без хаклы, мең кат хаклы юлыбыз, беләм!).
Бездә — коммунистик иман,
ул шигъри сүз белән яктыртылган.
Һәм мин илемә, Партиямә, юлыма
шигъриятькә ышангандай ышанам.
Ышанам Маяковскийча,
Хикмәт,
Нерудача:
яшибезме — һәр сулышта — без коммунист.
Ә шигырьдә —
без оптимист!

## Париждан Казанга, шагыйрь дуска хат

Люксембург бакчасында
нәкъ Алмаздай, Салаваттай — балалар.
Люксембург бакчасында —
чәчәк кебек кызлар, малайлар.
Балалар — кайда да шул:
күбәләктәй җитез, шук.
Алдыңа басалар,
тел күрсәтеп, көлеп,
аннан тагын уенга чабалар...
Балалар күк тату, садә
булса икән дөнья, илләр!
... Парижда, Люксембург бакчасында
уйларым агалар... агалар.

Беләсеңме,
әле хәзер генә Нотр-Дамнан
чыктым «месса тыңлап»...
Гаҗәп матур икән собор, чынлап!
Гәрчә Квазимодоны, Эсмеральданы күрмәдем.
Гөнаһлымын:
бик ошаттым парижанкаларның үзләрен.
Аларга, татарчалап:
— Сез искиткеч гүзәл! — дидем.

... Син фольклор өйрәнәсең бит?
Хәтереңдәме «Рус-француз сугышы бәете»?
Әллә нигә искә төште...
Аннары бер шигырь...
Ишетсен дип Элюар, Аполлинер —
кычкырып сөйлим:
— «Кабан —
Казанның моңлы бер күзе...»

Уйлар — таркау.
Миндә — сагыну катыш бер моңсулык хисе!
Сагындыра Казан.
Читтә нинди генә гүзәллекләр күрмә,
Казанымнан язмыш аермасын!
Безгә шунда язган. Шөкер!
Ә Парижда булу —
тудырсын бер яңа шигырь.

Ә калганы...
Хәер, җитәр.
Кайткач сөйләшербез. Ә бүген син
шигырь тулы бәллүреңне, дустым,
илдә
минем өчен дә бер күтәр!

●

Француз яулык, француз яулык!
Кемнәр йөри икән ябынып?!

Эре чәчәкле иде, әй, яулыгың,
әнкәй, ничек синең саулыгың?
Француз яулык ул әбиләр яулыгымы?
Олыгайгач хәзер син дә ябындыңмы?

Париж.
Эйфель манарасында мин,
яулык болгыйм бүген.
Ул яулыкка —
Эйфель үзе, Версаль,
күперләре белән Сена, —
гүя Париж төшкән.
(Казан сурәте ясалган яулык ник юк?! —
Җилфердәтер идем аны биектән!)

Бүген — минем сагыну көнем.
Бүген — ераклардан күренә миңа илем,
туган җирем, әнием!
Иң татлы хис, ахры —
Ватанга мәхәббәт.
Чит җирләрдә сагынып җирең,
сагынып кешең булу нинди рәхәт!

Әнкәй, ничек анда синең саулыгың?
Кайткач,
күзләреңнән сагыну яшен сөртер
шушы яулык —
француз яулыгым!

●

Турда идек без ул көнне.
Луарада — томан.
Килеп тапты безне монда,
борынгы Тур замогында,
«Нормандия-Неман»!

Атаклы бу дивизиядән
чал полковник — Жюлье,
Экзюпери кук мөлаем,
күз карашы — җылы,
елмаюлы, озын буйлы, —
безнең алга басты.
Тыңладык без дуслык сүзен,
тугры дусның — «ас»ның.

Туган илем күген күргән,
безнең тарафларны,
уйлыйм, һаман биек йөртә
дуслык канатлары!

Тур шәһәре артта калды.
Ә күңелдә һаман
чал ветеранның карашы,
«Нормандия-Неман».

«Нормандия-Неман»!

## Орлеан кызлары

Төш әле атыңнан, Жанна д'Арк!
Күрәмсең,
без Орлеанда.
Һәйкәлең янында
Орлеан кызлары белән
рәсемгә төшәм мин.
Эвелина, Сильвия, Софи... —
Һәммәсенең күңелендә синең сурәт.
Синең символ күзләрендә, синең девиз:
— Францияне коткарырга кирәк!

Һәрчак яңа Жанна туа тора...
Бүген соң коткарырга кемне — нидән?
Кемнән?
Фикер коллыгыннан?
Тук фикердән?
Аек акыл җитмәүләрдән,
түбән төшүдән?
Коткарырга ярый хәтта
үзеңнән-үзеңне!
Жанна д'Арк!
Ә син коткаргансың Францияне, илеңне!
Шул турыда сөйли синең алтын һәйкәл.
Безнең белән ул рәсемгә төште.

Эвелина, Сильвия, Софи...
Алар белән син дә Иделемә —
дуслык лагерена бер килерсең төсле!

## Луврда, Джоконда янында

Венера Милосская!
Каршыңда мин
озак туктап торалмадым, кичер!
Лувр зур шул...

Антик дөнья, хуш әлегә!
«Яңарыш» залында
көтә мине мәшһүр Мона Лиза —
Джоконда.
— Серле ханым,
минме сине аңлый алам?!
Күпме әдип, күпме рәссам
шушы сихри елмаюың серенә
ачкыч табалмаган.
Джоконда, кем син?
Нигә шулай елмаясың?

Син — ана булачак бәхетле бер затмы?
Белмим. Тик үземдә бүген,
Луврда, «Яңарыш» залында
ниндидер бер яңарыш мин сиздем —
шагыйрь буларак, Кеше буларак...
Сәнгать көченә ышанычым зур, какшамас.

Хуш, Джоконда,
тагын бер гашыйгың артты, —
ул ташламас!

●

Ага Сена, ага Сена...
Ниләр әйтим, Париж, сиңа?!

Маяковский әйткәнчә,
«Яшәп синдә үләр идем,
Шундый җир — Мәскәү булмаса»,
Һәм... алтын Казаным минем!

Якын миңа шагыйрьләрең,
хәтта Гаврош-гаменнарың,
Өч бөек революциянең
шаһитлары — урамнарың:
Бастилия мәйданында,
Зират-шәһәр Пер-Лашезда,
Коммунарлар диварында,
Париж халкы, уем — сездә.

Ага Сена, ага Сена,
ниләр әйтим, Париж, сиңа?!

Бөек шәһәр! Манзараңны
укыдым зур китап итеп.
Укучыңның хәтере өчен
кичер — куйсам мин онытып
кайбер битең... Әмма истә
Булыр Мари-Роз урамы:
Ильич торган йорт-музей һәм
якын дус — мосье Лежандр.

Мин аңладым шуны, Париж:
булма син нинди илләрдә,
туган ил ул — үзең белән,
йөрәгең — туган җирләрдә.
Үз Ватаның көтсә генә
читтә рәхәт күңелләргә!

Ага Сена, ага Сена...
— Сау бул,— дидем,— Париж, сиңа!

●

Федерико Гарсиа Лорка!
Кабул ит җырымны минем:
Бүген синең истәлеккә
Ал канәфер мин китердем,
Федерико Гарсиа Лорка!

Романска төрәм хисем,
Нәфрәтемнең кайнар көче —
Һаман канмаган зур үчем —
Синең иртә үлемең өчен,
Федерико Гарсиа Лорка!

Чыклы август иртәсендә
Син егылгач, Гранадада
Апельсиннар — алтын түгел,
Нәкъ кырык ел — кан төсендә,
Траурда испан халкы,
Федерико Гарсиа Лорка!

Дон-Кихотлы Испаниядә,
Син сөйгән Андалузиядә
Үтерелгән шагыйрь җыры.
Шәүләң — кара жандармга,
Инде башсыз франкочыга
Яный көчле дәһшәт булып.

Егерменче гасыр шигыре!
Синең төсең — көрәш төсе.
Синдә инде күпме яра:
Лорка өчен, Җәлил өчен,
Фучик өчен... арта бара,
Көрәш тынмый! Шигырь — байрак!
Ал каннардан ул кызара.
Байракта — синең дә исемең,
Федерико Гарсиа Лорка!

●

Колагымда нигә яңгырый әле
бер җыр димме:
— Европада... татар... шагыйрьләре!

Европада —
Одер, Висла, Влтавада каберләре.
Китермәгән монда дипломатик миссия, вәкаләт тә.
Сорбоннага, Краковка
укырга дип килгән алар бәлки?
Юк.
Хәтта чит илләргә сәяхәткә
сирәк чыга татар шагыйрьләре.
Европада ләкин каберләре.

Сугыш җиле алып килгән дә ирләрне,
Берлин төрмәсеннән
Европага баккан Җәлил.
Атакада чакта кергән анда Кәрим.
Польша аша узган Кутуй. Европада — Баян.
Европа өчен гомерләре янган.

Алар чакыра безне, чакыра истәлеге,
соңгы шигырьләре, каберләре:
— Европада,
Европада татар шагыйрьләре!

Якташларын эзләп шагыйрь менә
бара Гете иленә, Фучик җиренә.
Текә, горур тота шагыйрь башын:
саклый дуслар рухын, бөек хакын.
Ачыла бар дөньяга олы, сабыр җаны.

Колагымда яңгырый, һаман яңгырый:
— Европада татар шагыйрьләре!

1973—1976

**Хәсән Сарьян**

# БЕР АНАНЫҢ БИШ УЛЫ

ПОВЕСТЬ

I



Тимерче булып егерме ел гомерен алачыкта үткәргән этиебез хутның[1] салкын бер көнендә миенә кан савып, сандал төбендә егылып үлә. Боз киткәндә кырык яше туласы булган.

Без этидән биш малай калдык: зурыбызга унҗиде, кечебезгә җиде яшь иде. Бишебез бергә ашарга утырсак, биш минут эчендә олы бер түгәрәк ипидән валчыгы да калмас иде. Шулай да без сугышка чаклы ипидән өзелмәдек — әни эшли, ике абый эшли. Абыйлар эти янында тимергә уралып үскәнлектән, шул юлданрак киттеләр. Этидән соң үзебезнең күрше авылдан килеп яллланган Степан абый белән өчәүләп март башыннан ремонтка керешәләр. Аннары сабан башланып китә. Май беткәндә көчкә буразнадан чыгып, җир башында чабаталарын кагып киенерләр иде дә, туры алачыкка кайтырлар иде: болын җитүгә чапкычы, җыйгычы, башкасы кирәк. Болыны уракка килеп ялгана; һәр көлтәне шпагат белән бәйләп ташлый торган лобогрейкага янә безнең ике абый утырыр иде. Аннары инде кара көзгә кадәр ашлык сугалар...

Очы да, кырые да юк иде колхоз эшенең.

Әни безгә кием генә җиткерә алмады. Абыйлар эшләп туздыра, без уйнап туздырабыз. Йөзәр еллык өянке башында кем атына дисәң — без, тимерче Солтан малайлары. Сатып алырга да юк киемне каян җиткерәсең. Әни башта ике зур абыйны карый, безгә шул кыскарткан да әйләндергән генә кала. Ләкин безнең ай-һайда да юк, язын тау битләре ачылу белән өстән салып атабыз да — көзен җир туңмыйча кимибез. Мунчадан да без, чабынгач карга аунап, ялан аяк, ялан өс, табаннардан ут чәчрәтеп, җилеп кенә кайта идек. Безнең бөтен нәсел җиде ба-

---

[1] Хут — 22 нче февральдән 22 нче мартка хәтле булган вакыт. (Искәрмәнең һәммәсе авторныкы.)

байдан бирле мәйдан тоткан көрәшчеләр булган; безгә карап бары да: «Зат затка, тилчә тамырга»,— дип әйтә торган иде.

Әти мәрхүм безгә кул тигерү түгел, каты сүз дә әйтмәде. Кышкы озын кичләрдә, уйный торгач кызып китеп, сәндерәләрдән сикереп котыра башласак, көндез тимер чыңына мие кайнаган этиебез кара мыегын бөтерә-бөтерә:

— Ай-вай-вай-вай! Җәмәлән җавы [1] да бу төслүк булмагандыр, һай! Өйне күтәреп алып китәсез инде тамансы!..— дип ишек катындагы кече сәкедә, аркасын ястыкка терәгән килеш, рәхәтләнеп ял итәр иде.

Без түгел абыйлар да әле уйнап уеннан туеп җитмәгән бер вакытта этиебезнең үлеп китүе күкрәкләрдә мәңге бетмәс әрнү калдырды. Арабызда иң моңлы бала диелгән Хәвадис абый, зиратка барсак, кабер читенә сыгылыпплар төшеп елый торган иде. Кабер өстеннән алып, түшебезгә әни салган вак ташлар салкыны да бу хәсрәткә дәва түгел иде. Ләкин вакыт үткән саен әкрен генә кайгы да басылып, күз яшьләре кибә барды.Сугыш чыкканда инде әти үлеменә дүрт ел гомер узып, күнелләр дә ятимлеккә күнгән иде. Хәзер бу кайгы ил белән бүтәннәргә килде.

Зур абый Раббани беренче мобилизациягә үк эләкте. Кырык икенче елның көзендә Мирза абыйны да сугышка алдылар. Һәр өй, һәр күңел иртә-кичен «безнеке бәлки исән дә калыр әле» дигән өмет белән каршы ала. Ләкин, ак көннәрнең берендә, хат ташучы гарип Вәкъкас абый, калтырау куллары белән сумкасыннан көчкә алып, калтырап көткән кулларга кара читле кәгазь тоттырып китә иде... Сугыш бер безнең өйгә генә, кем теләкләре кабул булгандыр, үлем кайгысы китермәде. Тик Хәвадис абыйга гына чирен салып узды.

Хәвадис абый бездән бик нык аерылып тора иде. Без дүртебез этигә охшаган: җәенке каш, киңчә борын, коңгырт йөз; хәтта тавышыбыз да бердәй — ачылып ук җитмәгән кук иде. Без гәүдәгә дә бердәй таза, калын җилкәләрдә кайвакыт каннарны язып җибәрәсе килгән ят бер көч бар иде. Хәвадис абый бер үзе әни ягына тартым: зәңгәр күзле, озынча матур йөзле, аксыл җиту чәчле. Ул буйга да Ниязкул камышыдай төз, шунын аркасында, бездән озын булмаса да, безнең янда ничектер калкып торган төсле иде. Әни яклары җырчы да, гармунчы да булып, Хәвадис абый да шулар ягына китте. Клубның сигез телле саратский гармуны бар иде, шуны кай арада өйрәнгәндер, өздереп бер уйнап җибәрсә, бармакларын җен йөртәдер моның, диерләр иде.

Менә шул абый үпкә чиренә сабышты. Үпкә чире нәселдә юк — без кайда үпкә, кайда бавыр икәнен белмибез; күршеләргә килгән башка чир дә безнең өй турыннан кырын-кырын гына карап үтә иде. Салкын тию екты абыйны — салкын тию... Күнеле генә түгел, тәннәре дә йомшак булган икән.

Кырык икенче елның игенен без кырык өченең кышына хәтле суктык. Кыш кыш инде, кары бар, бураны бар,— кибән төпләрен арчып бетерә алмадык: ачканы беренә тигезләп кенә кар салып китә иде. Шулай калдылар. Яз җиткәч шулар буланып ачыла башлады — карты-яше кар өстеннән башакка ябырылды.

Апрель башларына инде үзебезнең басудагы кибән төпләрен чистартып чыгып, аръяктагы күрше колхоз басуына күчтек. Бу аларның юл өзегендә өзелеп кала торган иң ерак басулары, ә безгә буа аша гына иде. Моны белеп, председательләре безнең Тимершәех абыйга хәбәр иттергән: «Тимершәех үзенең ач каргаларын тыйсын, безнең сабыйларның да авызы бар» дип әйткән дип сөйләделәр. Ләкин ничек тыясың инде ул халыкны. Киресенчә, елгага су төшкәнче дип, ябырылып йөрибез. Юкса безнең елга, үзе бәләкәй булса да, язын яман котыра — читтән буйларына өй чаклы бозларын куеп китәр иде.

[1] Җәмәлән җавы — Емельян Пугачев явы дигәннән калган.

Атна эчендә тегермән буасын да җибәрделәр, бозы шартлап ярылып, төбенә төшеп утырды; көндез өстенә су чыгып, иртәләрен качкаг бер вакыт иде. Без таң белән — аяк асты кетердәп торган тунда китә без дә, боз өстенә тездән су чыкканчы кире борылабыз. Тездән генә с безгә су да түгел, без аны чабата белән ярып кына үтәбез. Инде иртәләрен дә тундырмый башлады. Ишетелеп кар эри, сызаларга су төшеп юл өзелде.

Ул көнне без энебез Әдрәнне алмадык, Хәвадис абый белән икәү ге нә киттек. Без башланмаган кибән төбе эзләп бик ерак киткәнбез. Кап чыкларыбызны төя-төя тутырып, авызын бәйләп торганда, кояш төш леккә җитә язган иде инде. Шунда кыйбла тарафтан, инрәп кенә ка эрегәне ишетелеп торган тын һаваны икегә ярып, колагыбызга шомль бер аваз килеп керде. Без беләбез: бу иң усал Ниязкулның ярып тө шүе иде.

Димәк, иртәгә боз да китәчәк. Без бата-чума тизрәк кайту юлына төштек. Ләкин өлгерә алмадык, кара тиргә батып яр буена килеп тук таганда, бер метр биеклеге тоташ ак күбек йомгактай уралып безнең өскә килә иде. Без ихтыярсыз артка чигендек. Ташу кайнап-чәчәп ту рыбыздан үтеп китте — артыннан карлы су җәелеп калды. Без аның буага бәрелеп сынуын көтеп тора башладык. Авылда бер көймә дә юк, булганы Агыйдел буенда. Хәзер чыгып калмасак — эш яман: елга тамагын көймә белән чыгар өчен турыга өч чакрым юлны ун өчкә тутырып, Агыйдел буеннан урап кайтырга туры киләчәк иде.

Каршы якта ташуга ияреп чапкан бала-чага җыела башлады. Кайсыдыр безгә йөгерде булса кирәк: тиздән аркан күтәреп әни белән Әдрән килеп җитте. Якын-тирә апалар да җыелды, кулларында аркан я колга иде.

Ташу безнең буага төртелү белән агым әкренәйде, мәгәр суы күренеп арта башлады. Минут та көтәргә ярамый иде — капчыкларны баш өстенә куйдык та — тәвәккәлләдек. Без агымны туры кистермибез, түбәнгә таба чапрыш кистерәбез. Боз өсте начар, яргаланып беткән, аяк төшеп китәргә генә тора. Уртага җиткәндә су да муенга җитте. Аяк хәзер тигән җиргә тия, тимәгән җиргә — юк. Агым безне тегермәнгә таба агызып бара; аркан ыргытырга әзер торган апалар белән әни дә яр буйлап безгә ияреп баралар. Сизәм: без суда булсак, әни утта иде.

Ярдан:

— Ташлагыз капчыкларыгызны! Мал кыйбатмы сезгә, җанмы!..— дип кычкыра башладылар.

Тик колак ишетсә дә, кул тыңламый: бердән, капчыкта безне юасына, какысына илтеп җиткерәсе ризык булса, икенчедән, су тагы тирәнәя калса әз-мәз ябышып йөзәрлек калкавыч та иде. Ярый әле су муеннан артмады. Инде өч аркан буе җитәрлек иде — яныбызга шап итеп аркан башы килеп төште. Без исән-аман ярга чыктык. Өстебездән шыбырдап су ага. Чирканчык алганда гына өшегән тән хәзер бер ни сизми — кар суына кердекме без, юкмы. Безгә селтәп аркан аткан ирдәүкә Бибинур апа әле һаман күтәреп торган капчыкларыбызны тартып алды.

— Нинди балалар таптың син, Маһисәрвәр җиңгәчәй генәм — бер дә ипкә-сапка килми торган? Җен кауменнәндер болар. Безнең балалар булса, бәгырькәйләрем, тәүбә-тәүбә әстәгъфирулла, инде күптән боз куеннарына уралып, Агыйделгә агып киткән булырлар иде. Әле котылдык дигәч тә, алдагы көнегездә котылмас чирләргә сабышып китәсегез киләмени? Ычкыныгыз җәтрәк өегезгә! Алмаштырыгыз өстегезне. Маһисәрвәр җиңгәй, син дә кайт та, уттай итеп тимер мичеңне ягып җибәр, кызуы җилекләренә җитсен. Капчыкларын үзебез илтербез,— дип безне төрткәләп кузгатып җибәрде.

Без, ниһаять, көчкә кузгалып лач та лоч өйгә чаптык. Әни кайткач сандыктан абыйларның күлмәк-ыштанын алып бирде. Йөзеннән курку

яңа киткән Әдрән салам бәйләп тимер мич ягарга кереште. Тимер мич тиз кыза — өй эче май булды. Чуен чүлмәктәге су да гөбердәп кайнап чыкты. Тәнебез әүвәл утлы кузда яткан тимердәй кызды да, чәнчешеп туңа башлады. Әни, җаны кебек тоткан бөртек чәен сандык төбеннән алып, кераҷ чәйнеккә сары мәтрүшкә белән томалап куйды.

Шулай үтте, авырып-нитеп ятмадык.

Ә көзгә Хәвадис абый йомшак кына итеп йөткерә башлады.

Бер дә басылмагач, врачка күренергә киңәш иттеләр. Больница ерак түгел — биш кенә чакрым. Абый шунда барып ярты литр ютәл даруы алып кайтты. Тәмле икән бу дип, кашыклап кына эчеп бетерде бу моны. Ләкин ютәле бетмәде. Председатель Тимершәех абый әни ягыннан җизни тиешле кеше иде.

— Болай ярамый, апай[1]. Ютәл белән уйнарга ярамый. Ул сиңа иске чабата чире[2] түгел. Иске чабата чире дә айлар буена бер тундырып, бер яндырып йөдәтә,— дип, абыйны яңа ел җитәрәк, атына утыртып, район больницасына алып китте.

Тик юллары уңмаган. «Рингин аппаратлары ватылган» дип кайттылар. Шуннан — калды. Кырык чакрымны көн саен йөреп булмый.

Кырык дүртенче ел башында Хәвадис абый яшендәгеләргә дә чират җитте. Ләкин абыйны сугышка алмадылар. Үзебезнең район комиссиясе яратып җибәрсә дә, Уфа комиссиясе яратмаган — больницаларда йөртә торгач, «открытый форма туберкулез» дип җибәргәннәр.

Кыш өстендә ярты юлын җәяү, ярты юлын ат туры килеп, ярым ач килеш, ике йөз чакрымны кайтып егылды абый. Ябыгып борыны сөягенә төшкән, башлары бәләкәйләнгән иде. Без бу хәлне сугышка китүдән дә авыр кичердек, чөнки ул вакытта үпкә чиреннән дә яман чир юк иде. Шул елны гына безнең күрше агай йөткереп үлде, сугыштан авырып кайткан тагы берәү үлде...

Әти бар чакта ук алган, инде картаеп мөгезе төшкән сыерыбыз бар иде, сөтен абыйга гына тота башладык. Нормадан[3] кысып калдырган күкәй-маен да әни җаен китереп абый алдына куя иде. Тик абыйга бездән өзеп бер ягым май ашату яки бер чи күкәй эчерү — хатын-кызны мәҗбүри урман кисәргә җибәрү белән бер иде.

— Әнкәй, нигә син алай миннән тамак аертасың? Миңа бер йомры[4] яңа сауган сөт булса, шул җиткән. Апайлар да ашасын,— дип маен-күкәен алларыннан этәреп куяр иде.

— Син аша, абый. Аша инде... — дип көчкә ашата идек.

Кыскасы, өендәге бар сөт-майны балаларына да бирмичә йотып бетереп үлгән күрше Хәмәй агай шикелле булмады. Чөнки күңеле тумыштан ук тәрбияле иде. Хәтта без аңардан тамчы шикләнмәсәк тә, чынаягын-иинен үзенә аерым тотты. Кунакка барса да:

— Миңа аерым гына бүлеп бирегез, — дип күмәк ашка кашык та тыртмас иде.

Шулай ике елга якын эшкә чыга алмыйча, өйдә генә ятты да, кинәт тазарып китеп, бит очларына алсу нур йөгерде. Әйтерсең лә сугыш елларында алган чире сугыш елларына уралып калган иде.

Ә кырык бишенче елның Җинүле язында икебез бергә сабанга төштек.

Энебез Әдрән ул елны жиденчесен бетерде. Имтихан биреп йөргән булдылар. Сугыш чорында безне килде-китте генә укыткан япь-яшь

---

[1] Татарстанның Минзәлә, Башкортстанның төньяк-көнбатыш татарлары «апай» дип үзеннән кече яшьтәгеләргә әйтәләр.

[2] Иске чабата чире — бизгәк авыруы. Әүвәле, бизгәк тотканда, тизрәк җибәрсен өчен ишек-тәрәзәдән тышка иске чабата ыргыта торган булганнар.

[3] Норма — ул вакытта һәр хуҗалык дәүләткә бирә торган мәҗбүри налог.

[4] Йомры — чашка, чынаяк: формасының йомры булуыннан телгә кереп киткән.

кызларга килде-китте генә җавап биреп кайта иде дә, калган көннәрен безнең янда сабанда була иде.

Шимбә саен клубта «бичер»[1]. Сугыш чорында да рухы сынмаган халыкның күңеле көр, күтәренке. Клубта да, өйдә дә: «Күтәренке күңел белән үтсен безнең гомерләр» дип җырлыйлар. Гармун — Хәвадис абый кулында. Без килгәнче берәрсе уйнап утырса, без күренү белән:

— Житте, апай, такта ярма, — дип кулыннан шундук гармунын тартып алалар да, абыйга китереп тоттыралар. Ул уйный башлады исә, клубның идәннәрен сыгып, сындыра язып бииләр иде!

## 2

Кырык алтынчы елның алмалар чәчәк койган бер вакытны, хәрби хезмәтләрен дәвам иттергән ике зур абый, бер-берсенә алдан хат язышып, бер-бер артлы гына отпускыга кайтып төштеләр. Берсе старшина, берсе лейтенант. Ярый ул. Киткәндә икесенә ике авыз русча белмәгән малайларга — бик житкән. Дәрәҗәсе нигә аның? Әнә бит, тәннәренә пуля түгел, шырпы да тими кайтканнар бит!

Сугышта кайсының ире, кайсының улы, кайсының улы да, ире дә үлеп, ачы ялгызлыкта шомланып яшәгән апалар безнең абыйлар белән елый-елый күрешкәндә шатлык яшен яулык очы белән генә сөртеп торган әнигә сүз каталар:

— И Мәһисәрвәр җиңгәчәйкәйләр! Берсе-берсе кешенең ике баласына тиң биш балаң да исән бит! Нинди догалар укыдың без белмәгән!?.

— Әйтмә дә инде, әйтмә дә! Аталары Солтан абзый мәрхүмнең әүлиядәй изге җаны — өсләрендә фирештә булып очып йөргәндер инде. Башкайларның исән булуы Сөләйман пәйгамбәр дәүләтеннән дә зуррак байлык шул!.. — диләр.

Кан чирендә[2] карты, сугышта өч улы үлгән, инде үзе дә коры яфрак төсле кипкән Чибәр әби бу дөньяда гамәле беткән бер тавыш белән әйтеп куйды:

— Бәндәләрнең тәкъдире үзләре туганчы ук Ләүхелмәхфүзгә[3] язып куелган. Кырык ел кырылыш булса да, әҗәле житкәннәр генә үлә дигән...

Аның сүзе барысына да бик нык тәэсир итте.

Күкрәгенә, сөлектәй, шатлык ябышкан әни генә:

— Улларымның кулыннан туфрак насыйп иткәндер инде, аллага шөкер! — дип ак яулык очын тагы күзенә китерде.

Май ахыры иде инде. Сабан беткәннең икенче көнендә абыйларга атап куйган бүлтерек тәкәне суеп, туган-тулпы, күрше-күләнне җыйдык.

Сугыш елында нигезләре белән беткән сул як күршебезнең чияләре азып, безнең түр бакчаны басып килә иде инде; тактадан озын өстәл сугып, чия арасына табын корып җибәрдек. Кыстый-кыстый кунак итеш башланып китте. Бер-ике стакан ачы бал эчеп алгач, иткә тотындылар.

Әдрән белән минем алга да өстендә колмак чүбе йөзеп йөргән кызгылт бал куелган иде. Безнең эчми утырганны күреп алган Раббани абый:

— Бәй, сез нишләп эчмисез әле, апайлар? — дип яныбызга килеп житте.

— Эчегез, апкаччайларым, эчегез. Бал гына ул,— дип Мирза абый да безнең иңбашлардан кочып алды.

Без ык-мык килеп баш тартырга итеп карадык, ләкин абыйлар ихтыярга куймады. Өстәл янында әни юк. «Эчкән табынга утырмыйм, ал-

---

[1] Кичә — русчаның «вечер» сүзеннән бозылган.

[2] Көзен җирдә калган башакны язын җыеп ашап, агуланып үлүчеләр күп булды. Кан косып үлгәнлектән, «кан чире» дип атадылар.

[3] Ләүхелмәхфүз — дини сүз: кешеләрнең язмышы язылган такта.

лам сакласын!» дип, өй белән ике арада гына йөри. Зур абый минем янга, Мирза абый Әдрән янына баскан — инде стаканнарны авызга ук китергәннәр. «Ярамый» дип әйтүче юк, һәммәсе ашаудан туктап, дәрт биреп тора:

— Апайларыгыз менә дигән!...

— Эчсеннәр әйдә, эчсеннәр, ул гәүдәгә...

— Мондый шатлыкта да эчмәгәч...

Ахырда председатель Тимершаех абый да:

— Йә, эчсәгез эчегез дә, ялындырмагыз. Эшкә бер дә ялындырып тормыйсыз бит. Баш-күз димәделәр, сугыш чорында бөтен авырлыкны шулар тартты инде. Берне генә эчегез әйдә,— дип эчмәскә урын калдырмады.

Стаканнарны бер кул белән без, бер кул белән абыйлар тоткан — эчереп бетермичә кулларын алмадылар. Без эчү шатлыгыннан кунаклар тагы берне күтәрде. Хәвадис абый сандугач тавышлары белән тальянын уйнатып җибәрде, аңа ике яктан ике абый җыр әйтеп кушылды:

Тальян гармун — моңсу гармун,
Басмый теле ачылмый.
Безнең йөрәк — ярсу йөрәк,
Бер җырламый басылмый...

Көн кичкә авышып көтү кайтканда, инде табындагы ир-ат йомшарып беткән, шулар янында тик безнең абыйлар гына, чибәр генә кызмача булып, имән өрлегедәй басып торалар иде. Көтүеннән аерып, көтүче Талип агайны да чакырып керттеләр. Чыгып киткәндә ул да, яңа туган бозау шикелле, мүкәйләп кенә чыгып китте.

Шулай бәйрәм иттек без абыйларның исән кайту шатлыгын. Гомергә беренче кабат исерткеч нәрсәнең тәмен, бөтен тамырларга йөгергән җылысын шул шатлык-сөенеч көнне татыдык.

Икенче көнне базар көн иде. Тимершаех абый безгә үзенең елан-туры айгыры белән тимер хутын[1] бирде. Әдрән ат тотып ат башына, ә без икешәрләп арбаның ике ягына утырып, күрше авылга базарга киттек. Хәвадис абый яңгыратып тальян уйнап бара — тирләгән бармак битләрен кульяулыгы белән сөртеп ала да, уйный да уйный.

Ызан буйларында күпереп үскән чәчәктәй, юл тулы халык: җинел чабаталы, бәбәй итәкле апалар, күлмәк иңсәләренә мамык теккән кызлар, эссе көндә постау костюм, хром итек кигән хәлле егетләр... Барысы безгә юл сабып, читкә чыгып кала. Көн чалт аяз. Иртәдән үк текәп кыздыра башлады. Без барасы авылның әллә кайлардан күренеп торган ике җил тегермәне дә әйләнми — үләп өстен сыйпап үтәрлек тә җил юк; баш өстендә эленеп торган тургайлар да җил юклыктан селкенмидер сыман иде.

Ике якта да буынга сикергән арыш басуы. Тик аларга карасаң, күцелләргә тургай моңыдай сөенеч агылып керми. Бездә генә түгел, бөтен районда дип әйттеләр, быел арыш бик начар: кыш башында ук ишелеп яуган кар кинәт эреп, башта җир өсте күлдәй су булды, аннары кинәт туңдырып җибәреп, уҗымнарны төбе-тамыры белән йолкып алды. Әнә хәзер кара җирдә, коелып бетмәгән ябага шикелле, утрау-утрау яшькелт арыш уҗымнары утыра. Ел тагын авыр киләчәк. Моны уйласаң, юл тулы халык алдында, шәпле атлар җигеп, гармуннар уйнап барасы да түгел. Ләкин бүгенгедәй шатлыклы көнне эчкә шом саласы килми. Иң авыры инде артта калды, хәзер илдә иминлек — үлмәбез. Халык шулай ди, илдә булсын ди. Шулай булгач, ник ул тикле пошынырга? Без биш туган бишебез дә исән! Сугыштан соң мондый бәхет кайсы өйдә бар иде!

Ничә ел үзебезнең кызларга сусаган, үзебезчә түгелеп бер сөйләшүне тансык иткән ике абый, юлда күзләренә хуш килгән ике сылукайны үре-

[1] Тимер хут — тимерле арба: русчаның «железный ход» дигәненнән алынган.

леп кенә алып, яннарына утырттылар. Ике кыз ике абый кочагында эре. деләр генә — җылы икмәккә май яктылармени! Хәвадис тә күзе төшкәннәргә күз кысып бара, җиде-сигез авыл йөргән бу юлда аны белмәгән бер кыз юк; абый бер кочагын җәйсә, унысы бергә суырылып килергә тора иде. Миңа да унҗиде яшь. Мин түгел инде энекәш тә җитеп килә. Безнең буебызга карап, безгә берәү дә үз яшебезне бирми, ике-өч яшькә зурайтып әйтә; димәк ки, Әдрән дә инде үзеннән ике-өч яшькә олырак кызлар янында бик тиң чуала иде.

Шулай уйнап-көлеп базарлы авылга җиттек. Авыл зур — биш урамга җиде йөз йорт. Базарга үзәк урамнан да, авыл читеннән дә барып була. Без авыл читеннән китмәдек, борак онындай[1] тузан баскан йомшак басу юлыннан чуер ташлы каты юлга менеп, үзәк урамның үзеннән киттек. Атны да без Тимершәех абый үзе төшә торган өй ихатасына кертеп тугардык. Аннары кызлар белән, җидәүләшеп, таш чиркәүле, ике таш кибетле, ашханәле үзәк мәйданнан борылып, ике якка да бердәй агылган халыкны ера-ера, базар эченә кердек. Базар биек койма белән уратып алынган чигенә генә сыймый, давыл килгән Агыйдел өстедәй чайкала, гөжли; эче дә тулы, тышы да тулы кеше иде.

Ике абый, кочаклап килгән кызларына ат тешедәй көнбагыш алып бирделәр дә:

— Инде адашмассыз, үскәнкәйләр. Барыгыз, базар йөрегез,— дип бал эчәргә киттеләр.

Бер буй сузылган такта ларекларда, рәттән, балдыр, аракыдыр саталар иде. Өстендә кәрәз чүбе йөзеп йөргән чын балы да, шикәр балы да, бузасы да күп иде ул базарда.

Раббани абый бал сайлап, берәрне эчеп кенә бетергәндә, безне әти мәрхүмнең дусты, үзебезнең авыл Шәрифулла абзый кычкырып алды.

— Сез нишләп алай, акчалар түләп, ул кешенең череп беткән балын эчеп торасыз? Мин бит моннан бер кая да китмәгән... — дип, исәнләшү урынына үпкәсен әйтте.

— Без туп-туры синең янга киләдериек, бал абзый, — диде Раббани абый.

— Алда әйдә, алда әтәң санлы кешене, — дип Шәрифулла абзый мичкәсеннән бал агыза башлады.

— Апайларга да берәрне сал, — диде Раббани абый.

Шәрифулла абзый мөлдерәмә тутырып биш стаканны бишебез алдына тезеп куйды. Үзенә дә салып тотты.

— Әллә үзең һаман эчәсең инде, бал абзый? — дип шаяртып көлде Мирза абзый.

Шәрифулла абзый корсагын кашый-кашый:

— Нигә, мин үлмәгән бит әле! Ашыйм да, эчәм дә!.. — диде.

Абыйларны ул, авызларыннан өзми, кыстый-кыстый эчерде, үзе шуна куанып бетә алмаган кебек иде.

Аннары без биш туган бергә базар әйләндек. Утыз-кырык авылдан җыелгач, гәүдәгә таза ирләр дә байтак, ләкин безгә җиткәне бик сирәк — бөтен базар өстеннән бер без генә бер-беребезне күреп йөри идек.

Шәрифулла абзыйның балыннан соң бер нәрсәгә гамь салмыйча, таныш-белеш белән күрешеп-сөйләшеп, базарны бер әйләндек тә, чирәмлеккә юнәлдек. Базар икегә аерылып, безгә юл биреп калды. Чирәмле мәйданда үзе бер сабан туй: яр ярны, дус дусны тапкан, биниләр, җырлыйлар... Без кеше азрак җиргә туктадык та, Хәвадис абый тальянын тартып җибәрде. Ул уйный башлагач, берәм-берәм бүтән гармун тавышлары сүнеп, халык безнең янга җыела башлады.

Базары белән беләләр иде шул Хәвадис абыйны!..

---

[1] **Борак оны** — тегермән тартканда стеналарына кунган он тузаны.

## 3

Өч-дүрт көн ара белән кайткан абыйлар — киткәндә бергә киттеләр. Алар китkәч — бишебез бергә өй тулып яшәгәннән соң — өй эче күзгә басудай бушап, идән сайгакларына кадәр боегып-тынып калгандай булды. Аларга да, баскан саен шыгырдатып басар өчен, өчәү генә түгел, биш ир бала кирәк икән!.. Ямансу булса да күңелсезләнмәдек: күрәләтә үлемгә түгел (үлемнән дә исән чыктылар!), ә тыныч вакытның солдат хезмәтенә киттеләр. Дөрес, халык теленә ниндидер Корея сүзе керде. Ләкин Кореямы, бүтәнме,— ул инде Гитлер түгел. Гитлер юк, бетте. Абыйлар да быел булмаса яренгә кайтыр.

Әни аларны озатканда икесенең дә аркасыннан сөеп-сыйпап:

— Улларымның киткәннәренә дә, калганнарына да Локман хәким [1] гомерләре бирсен, минем карт сөякләремне җыеп-тәрбияләп сез күмәргә язсын, йа рабби ходаем!.. — дип теләкләр теләп калды.

Абыйлар да безгә теләк-киңәшнең катысын әйтеп киттеләр: егылатора булса да, өчебезгә дә укырга куштылар. Зур абый җөпләп тора, ә Мирза абый иплəп кенә, купыртмый гына сөйләп тора:

— Үзегез беләсез инде, апайлар: әткәй үлеп, без укый алмый калдык. Раббани абыйның дүрт, минем җиде класс — безнең уку ак өстендә караны аерырлык кына. Сез дә шулай калырсызмени? Җиде класс белем хәзер сабан сөрергә генә ярый. Ике кулыгызга ничек тә бер һөнәр кирәк. Гомер буена колхоз эшендә чиләнерлек булмасын...

Сугышка хәтле колхоз эшен төбенә төшеп эшләгән абыйлардан мондый сүз ишетү миңа бик сәер тоелды. Дөрес булган хәлдә дә бу сүзләрне алар әйтмәскә тиеш иде. Безнең халык көн димәде, төн димәде, колхоз эшен сугыш вакытында да ялмап кына эшләп барды, үзенә тиешенчә тимәсә тимәде, мәгәр дәүләткә бирде — дәүләт алдында безнең йөз ак иде. Тик соңга таба гына, көчле йөрәккә көчсез дәрт төшкәндәй, буш хезмәт көнен тирги башладылар. Ара-тирә корткалар җыелып:

— Заман ахырына таба бәндәләр ел саен җиңеллек көтәр — ел саен авырлык килгәй... — дип бөтен авырлыкны ахыр заманга юрыйлар иде. Тик моңа, корткалардан башка, бер кем ышанмый, киресенчә:

— Менә Гитлер җиңсә, ахыр заман буласые, ә хәзер Гитлер капут — без җиңдек. Яңа заманның башы гына әле бу! — дип сөйлиләр.

Аягыбыз җирдән аерылмаса, йөгенмәбез. Сугышка кадәр бер хезмәт көненә уникешәр кило бүлеп күрсәтте бит колхоз — тагы шул көн килмәсмени?

Мин инде унҗидегә чыккан кеше, шулай уйлыйм. Тик нигә Раббани абый колхоз эшенә шулай сүз тигерде дә, Мирза абый аңа каршы сүз әйтмәде? Мин каршы әйтә алмыйм: артык яшь, ярамый — без шулай тәрбияләнгән. Аннары абыйлар сүзендә дөреслек тә бар: укырга кирәк. Зур укыган кеше ул чакны берничә авылга бер генә иде. Сугыш вакытында уку кайгысы булмады, — кая инде ул каядыр китеп уку! — хәтта кирәк тотарлык балаларын көн саен мәктәпкә йөртү дә аналары өчен авыр йөккә әйләнде. Алтынчы-җиденче класслар болай да сентябрь-октябрь укымадылар, майда инде малайлар сабанга чыга иде. Шулай укылды.

— Менә шулай, апайлар, — диде зур абый ахырда. — Сүз боткасы кәҗәгә азык. Кыскасы, укырга сөйләштек.

— Ишеттегезме? — диде Мирза абый да.

Без өчебез бергә тиз генә баш кактык. Ләкин Раббани абый аның белән генә чикләнмәде:

— Бәлки, апай, быел ук син дәрт итәрсең, ә? — дип күзен батырып

---

[1] Пәйгамбәрләрнең берсе. Мең ел яшәгән имеш.

Хәвадискә карады. — Син иң олысы. Анда бит яшьне дә карыйлар. Соңлап куймагаең.

— Белмим шул. Бер дә уйлаган эш түгел бит әле ул... — дип Хәвадис абый уйга калды.

— Сиңа аны уйлап торасы да юк. Тот та музыкаңа кит. Анда сине дә алмагач кемне алсыннар? Музыкантлар сугышта да бик рәхәт йөрделәр...

Абыйлар китеп, күңел утырыр-утырмастан, Хәвадис абый уку белән җенләнә башлады. Көн тудымы, баруы биш, кайтуы биш чакрым Илләргә чаба. Җиде еллык мәктәп шунда. Үз тиң укытучы кызлар белән шаяра-көлә яңадан сабак өйрәнергә кереште. Әллә кай арада әллә күпме китап табып, өстәл өстен күмеп ташлады. Гаризалары июльдә үк киткән, медицина справкасына туберкулез чире дә язылмаган иде. Тәки дәрт итеп август аенда Уфа музыка училищесына кереп кайтты.

Без аның юлына, ипи карточкалары алганчы-ниткәнче дип, торырына азык юнәтә башладык. Инде ныклап уракка төшкәнбез. Инде эссе парына тыннар каплана-каплана, туйганчы, миҗтән яңа чыккан яшь арыш икмәге ашадык. Без, энем белән икебез дә — абыйлардан мирас булып калган лобогрейкада. Без иртән чык кибү белән эшкә тотынабыз да, көн кызуында атларны ял иттереп, кояш баеганчы эшлибез. Күз бәйләнгәндә кайтырга чыгабыз. Ләкин без турыдан кайтмыйбыз: басу капкасы төбендә көн саен диярлек ревкомиссия кешеләре тикшереп тора — капшалмаган җирең калмый. Шуңа без Әүлиякул саклавы[1] аша урау юлдан китәбез. Башта, әлбәттә, җиденче басудагы ындыр табагына сугылабыз. Анда хәзер әвендәге көшел өеме белән Шәмсетдин бабайдан гайре кеше юк. Ул карттан авылның олысы-кечесе курка, көшел саклап ул торганда бер чакрымнан гына сәлам биреп китәләр иде. Башкаларга кыямәт-дәһшәт күрсәткән шул Шәмсетдин бабай безне якын итә (сәнәк явында әти аны үлемнән алып калган), янына килеп туктау белән:

— Тиз-тиз генә булыгыз да чыжым буена сызыгыз! Әйткәнегез булсын — Хәвадискә сохарилык кына. Мин күрмәдем, — дип күзе булса да күрмәс өчен көшелгә арты белән әйләнә иде.

Әдрән аттан сикереп төшә дә, катыктан бушаган алюмин бидонын көшелгә бер генә батырып ала. Аннары без Шәмсетдин бабай әйткән чыжым буена — җилсез көнне дә чыбыклары чыжлап утырган телеграмм баганалары буена сызабыз. Калдау җиргә чыгу белән Әүлиякул башындагы саклау читеннән — чокыр эчләп кенә үзебезнең ындыр артына кайтып төшәбез. Атларны кешәнләп яланга җибәрәбез. Безне бер кем дә күрмәде, тотмады... дип уйлаган идек тә — Тимершаех абый күреп торган икән. Хәвадис абый белән икәүләп, юлга дип, бер ун кило аванс сорап баргач:

— Менә исем өчен генә биш кило бирәм. Шуны Шәмсетдин абзый көшеленнән атна буе ташып җыйганнарыгызга өстәрсез. И башы да, аягы да шул булсын!.. Әгәр елның-елына колхоз эшенә ябышып ятып эшләмәгән булсагыз, и әгәр дә Хәвадис укырга китәргә булмаса, сезнең юл өстенә дә ревкомиссия чыккан булыр иде. Аңлашылдымы?.. — диде.

Без Шәмсетдин бабай көшеленә бүтән әйләнеп карамадык.

Августның егерме бишләрендә Хәвадис абыйны пристаньга илттек. «Советский полярник» дигән, үзе дә, тавышы да матур бер пароход бар иде, шуңа утырып китте. Түбәбез күкләргә тиеп озатып җибәрдек шулай. Әни, гадәтенчә безгә дә ишеттереп, теләгән теләп калды:

[1] Саклау — дәүләт урманы: «саклана торган» дигән сүз.

— Раббәнә атинә фид-дөнья хәсәнәти, биргән көненә, иткән рәхименә шөкер, ходаем-тәңрем! Инде үзең салган чиренне үзең алып, исән-сау гына укып кайткан сәгатьләрен дә күрергә язсын иде. Амин!..

Тик әнинең теләге кабул булмады. Сентябрьдә Хәвадис абый, үзе торган квартир хуҗаларының мәзәкләрен сөйләп, уйнап-көлеп ике хат язган иде, октябрь азагына таба бик көттереп тагы бер хаты килде. Монысында уен-көлке юк. «Хәлем бик шәптән түгел. Пароход туктаганчы бәрәрегез килеп китә алмассызмы?.. Әзрәк шалкан пешереп алып килегез, бик тә шуны салкын көе ипи белән ашыйсым килә...» дигән.

— Балакаем!..— дип әни тавышсыз гына еларга кереште, күз төбендәге җыерчыкларына яшь тулды.

Без бөтен авыл белән колхоз эшенең якасына ябышканбыз: иген юеш, иген яна — мине дә, Әдрәнне дә Тимершаех абый җибәрмәде. Уфага әни барырга булды. Гомеренә беренче кат шәһәргә барырга җыенуы.

— Каршыларга төшә алмаса, ничек эзләп табарсың икән инде абыкайны? Ичмасам әзрәк русча да сукалый белмисең,— дип Әдрән уфтанып алды. Әйтерсең лә без барсак, без русча беләбез!

— Борчылмагыз, балалар,— диде әни.— Хәвадисем генә исән булсын.

Көзге байлыкта ике катлы тәтәй пароходларга да баржа тага башладылар. Әни утырган «Жан-Жорес»ның да бер ягына иләмсез бер баржа такканнар иде. Аны Кушнаренкода гына ташлап киткән. Шулай итеп Уфага, ике тәүлек урынына, дүрт тәүлек барганнар. Инде пароходларның шулай озак йөрисен санаганда да, әни Октябрь бәйрәменә кайтып җитәргә тиеш иде. Ләкин бәйрәме дә узып китте, безнеке һаман юк. Ике атна дигәндә, кичкә, Дербешка затонына баручы иң соңгы пароход белән кайтып төште әни. Йончыган, битләренә дә, кулларына да ямьсез ак йөгергән иде. Елгалар туңып, Агыйдел өстенә зим чыкты. Хәбәрсезлектән ни уйларга да белмичә аптырауга төштек. Сыерыбызга хәтле, капка ачылган саен башын борып, әнине көтә; саварга дип кергән Вәҗиһә апаны күз кырыена да китерми иде.

Әни, Уфага барып төшкәч, трамвайга утырырга шикләнеп, «шул чикле кеше эченә ничек тыгылып кермәк!» дип, татарга охшаган-бер кешегә конверттагы адресын күрсәтә-күрсәтә җәяү генә киткән.

— Бер урам белән генә туп-туры бардым да бардым. Укыган җирләрен пристаньнан бик ерак дип әйткәннәрие, аша китсә биш чакрым булгандыр. Час арасында барып җиттем. Анда да җайлы туры килде: бик сылу бер татар кызы абыегыз торган фатирга ук илтеп куйды...

Көз керү белән Хәвадис абыйның чире кузгалган. Әни барып кергәндә, салкын да тигереп, бөтенләй яткан ук булган икән. Астына сохаридан бушаган киндер капчык, аның өстенә фуфайка җәйгән, квартир хуҗалары өстенә бер одеал япканнар ди. Моны күргәч әни:

— Замат чигеп, ристан төсле, кеше ишек төпләрендә аунап яткансың икән, балакаем!..— дип елап җибәргән.

Бу хәлендә ташлап китә алмыйча дүрт-биш көнен үткәргән. Ләкин абыйның хәле җиңеләймәгән. Ахырда квартир хуҗалары врач чакыртып, Хәвадис абыйны больницага салганнар. Әни соңгы пароходка чак өлгергән.

— Ходаем! Ул шәһәрләрендә ничек яшиләрдер?.. Урамнары күп. Өй буеннан йөри торган юллары да Актанышныкы төсле такта гына түгел— таш!.. Ул кеше, ул кеше — базар көнмени!.. Ул фатирлары котсыз, салкын. Өемдә булсам, тимер мичләремне ягып җибәрерием диеп, салкын фатирларында туңып яттым. Ходай авылымнан аермасын...— дип җаны өшеп кайткан иде әнинең.

Ул кышны Хәвадис абый Уфа тубдиспансерында үткәрде.

Шулай итеп укуга дип аткан беренче угыбыз ташка тиде.

Ул кышны без өйдә зыян күрдек. Сиерыбыз бозау салды. Инде картаюы да җиткән иде. Карт мал барыбер кеше булмый инде ул дип, бер ай ашаттык та, декабрьнең башы белән суйдык. Якшәмбе саен әни базарга бәләкәй чана тартып ит сатарга бара. Ләкин ит үтми — өч атна рәттән барып, яртысы да сатылмады. Тик яңа ел алды якшәмбесендә генә буш чанасын җилтерәтеп, куанып кайтып керде әни.

— Кайгы сатып шатлык ал дип әйткәннәр борынгылар. Менә бит: кырык тәңкәдән кулга да тигермәделәр! Егерме еллык ачлык килгән мени! «Апа, тагы юкмы» да «тагы юкмы» диеп, бүлнис брачлары тенкәмне корттылар,— дип әни ул көнге базарны сөйләп бетерә алмады.

Ә январь башында акча алмашынды. Акча төште — базар бәяләре төшмәде.

Җитмәсә кинәт җылытып җибәрде. Көнбатыш тарафтан язгы көндәй яшәреп болыт чыкты да, күк күкрәп ләйсәндәй яңгыр ява башлады. Ике көн буена сеңеп яуды яңгыр. Дөньяга су-сөл калкып, юллар билдән измәгә әйләнде. Ярты сыер сатып, тегеңә-моңа тоткалаганнан кимеп калган мең ярым акчаны, авыл советына барып, йөз илле сумга алмаштырып кайттым. Гел кызыл унлык биргәннәр иде. Базар йөреп ит саткан-да һәр тиенен кат-кат санап тоткан әни бу акчаларны санамады да, берберсенә ябышып торган өр-яңа унбиш унлыкларны бер акчадай берьюлы учына куйды да, күзен текәп тик катты. Чоланда җебеп сүле аккан, суытып җибәрү белән кәкрәеп каткан ит ята; әни кулында — күз каргамаслык кына акча — зурларның тәтәй кәгазе. Суяр алдыннан сыер безгә, күзен тутырып, берәм-берәм мөлдерәп карап чыккан иде, шуның яшьләре хәзер әни күзеннән тамды...

Кырык җиденче елга шулай кердек. Колхозның да хәле әйбәт түгел. Иң зур афәт үтте — дошманны җиргә салып күкрәгенә бастык. Инде тыныч дөньяга, ләкин чабата белән оегы да юк өйләргә солдатлар кайта башлады. Базарда ирләр күренеп күбәйде, әмма безнең авылның фронтка киткән йөз алтмыш кешесеннән кайтканы унбишкә дә тулмады. Колхозны бер-ике ел эчендә аякка бастырабыз дип авыз да ачасы юк иде. Өстәвенә сугыш елларында эшне аркылы куйсаң да сөйрәп тарткан кызлар, ирсез калган яшь-яшь хатыннар, ирләр кайтмагач, читкә чыгып китү ягын карый башладылар. Күбесенең телендә «Средний Азия» иде. Безнең Хәвадис абыйга да больницада бездәгечә салкын кышы, начар көзе булмаган җылы якта яшәп карарга киңәш иткәннәр. Уфадан шул өмет белән дәртләнеп кайтты. Үзен бик тә савыктырасы килгәнгә, без аның өметен сүндермәдек; киресенчә, өчебез өч яктан куәтләп, билгесез авыр юлга җибәрергә булдык. Терелсен генә. Сыердан язсак та, безнең әле өч баш сарык, өчесенә биш саулык бәрәне бар иде.

— Кирәкле ташның авыры юк, аллага тапшырдык, — диде әни.

Ике сарыкны аяклы килеш алты йөзгә сатып, бер тиенен тотмыйча, Хәвадис абыйга куйдык. Сөйләүләренә караганда бу акча, юлына гына түгел, баргач бераз тотарына да җитәргә тиеш иде. Базар саен безгә адрес әйтә башладылар: тегенең дә әллә кеме, моның да әллә кеме җылы якта яши икән. Абый язганын язды, язмаганын юк, паспортыние әзер булу белән, басу өсләрендә шашып тургайлар сайраган бер көнне уйнап-көлеп кенә читкә чыгып китте.

Утыртып җибәрүе генә җиңел. Авыры соңыннан башлана икән. Уфадан ничек утырып китәр? Уфасы ярый әле аның — менә Киңилдә нишләр? Анда халык мәхшәр дип сөйлиләр. Баш төртер җай да таба алмыйча, шул Киңилләрдә каңгырып ятар микән? Ә аннан соң?.. Чит, чит диләр дә диюен, читнең дә бит аның бер кырые бардыр: кая барып җитәр дә, кем аяк асларына егылыр? Куллар биреп торгызучы булырмы? Быел кышны болай да үз сәкебез җылысыннан аерылып, боль-

ницаның салкын койкаларында үткәреп кайтты, инде кайчан күрешә алырбыз?.. Шулай көн саен әрнүле кызгану белән Хәвадис абыйны сагынып сөйли идек.

Өч атна дигәндә генә хаты килде. Ут йотып йөргән йөрәкләргә сары май булып ягылды абый язган сүзләр. Уфада поезд кәтеп икене генә кунган. Ә Киңилдә үзебезнең Актаныш кешесе белән танышып, ниндидер юллар белән билетне бик тиз алганнар. Ул кеше Төрекмәнстанның Керки дигән районында укыта икән. «Төрекмән һавасы үпкә өчен самай каймак инде ул» дип, Хәвадис абыйны үзе белән ияртеп алып киткән. «Тирә-якта кайнар сулыш өреп торган ком чүле. Урамда да аяк йөзеннән ком ярып йөриләр. Өстенә йомырка куйсаң, момент пешеп чыга... Их, үзебезнең юеш Агыйдел комнары өстеннән су буйлап кына йөгереп бер үтәсе иде!.. Йөгереп кенә кайтыр җирләр түгел шул...» дигән. Ахырда җыр да язган иде:

Күгәрчен оя кормасын,
Бала да чыгармасын.
Ризык читтә булса булсын,
Туфрак читтә язмасын.

Кан чирендә карты, сугышта өч улы үлгән Чибәр әби дигәнем дә бездә иде. Югалып барган зиһене белән, бездән чыгып киткәч, күршекүләнгә:

— Күгәрченгә оя корырга да кушмаган инде ул, бала да чыгарырга кушмаган... — дип сөйләп йөргән.

Моннан соңгы хатларында да Хәвадис абый гел сагынуны гына язды. Нәрсәне генә сагынмый иде ул! Үз илләребезнең карлыгач канатыдай кара җиркәйләрен, Агыйделнең сөт өстедәй куе томаннарын, яшь мәтрүшкә, яшь карагат исле болыннарын; игеннәрнең буынга сикергән, баш кыскан, сөт тутырган, серкә очырган чакларын; беренче кабат исенә исереп арыш уып ашаган — тел өстенә салып җибәрү белән, тук, төчкелтем тәме каннарга йөгергән минутларны; авылыбызның такта түбәле бүрәнә өйләрен, бәрәңге бакчаларын, шул бакчаларда гына үсә торган, карлыгандай кара карга күзләрен; пары да тын юлларын киңәйтеп җибәргән яшь бәрәңгесен; үзебезнең буа буйларын; тагы әллә ниләрен сагынып, җирсеп ятуларын яза иде...

— Болай булгач терелә алмый инде ул анда, балакаем, — дип көйде әни. — Әйтәм җирле, авыруларын бер дә язмый.

Мәүлет аенда әбиләр безгә җыелып, татарчага охшаган да, охшамаган да бер тел белән мөнәҗәт әйтәләр иде. Әни хәзер шуны мондый көннәрдә дә әйтә торган булып китте. Кичләрен тәрәзә катына утырыр иде дә, авыз эченнән генә көйли башлар иде:

... Тукыз ай күтәреп йөрдем,
Тугач та ак сөтем бирдем;
Ки анага бала татлый,
Идәрди зекер илән ихлас...

Хат алгач, берсендә түзмәде:

— Канаты юк, койрыгы юк бер кош төсле, чит җирләрдә борлыгып ятмасын анда. Үз кояшым үземә — куып җибәрмәдек, кайтсын. Юлына дисә актык сарыкны булса да сатып юнәтербез, — диде.

Сарыкны сатарга туры килмәде. Хәвадис абыйны теге үгелекле Актаныш кешесе үзе укыткан мәктәпкә завхозмы-кемме итеп урнаштырган икән; шунда эшләгән акчасына йөземдер, күрәгәдер ише күчтәнәчләр алып, хәбәрсез генә кайтып төште абый. Тазарасы урынга ямьсез кара төс кунып ябыккан иде.

— Эссе. Һич бир тәгам йиә алмадым,— дип төрекмәнчәләп әйткән булды.

Карап әйләнмәгән җире калмагандыр Хәвадис абыйның!..

Җирсеп сагынуын шулай баскач, өйдә нишләп ятыйм мин дип, кызлар белән бергә салам өяргә йөри башлады. Ындыр табаклары ямьләнеп китте ул эшкә чыккач. Ул юкта, «сыер агачка менгән көй»гә[1] биеп китә алмыйча, чабатаны ышкып кына баскан яшьләр, борып җибәргәндәй, котырып бии башладылар.

Ләкин озак бии алмадылар.

Октябрь бәйрәме чорында халык, гадәттәгечә, көндез басуда ашлык сугып, кичен кунак үткәрде. Инде ничә ел авылдагы бер табын да Хәвадис абыйдан башка узмый иде. Шулай атна буена бәйрәм иткәннән соң бетеп аяктан егылды. Бигрәк тә озынга киткән көзге көннәр ярамады.

Салкын. Юеш. Ноябрьнең соңгы сибәләк яңгырлары, өзлексез, мал йөреп карайткан уҗым өсләрен юа иде.

— Бу яңгыр җиргә түгел, минем үпкәмә генә явадыр инде!..— дип сөзәк тау битендәге шул уҗымнарга тәрәзәдән карап ятар иде. Больницага бер дә барасы килмичә, бер атна чамасы ятты да, бер көн әйтте:

— Булмаса илтеп куегыз инде мине...— диде.

Ат алып Әдрән үзебезнең больницага илтеп куйды. Аннан инде, самолет йөри башлау белән, Уфага җибәрделәр.

Кышның туксан, язның алтмыш көнен ул тагы шулай тубдиспансерда үткәрәчәк иде.

### 5

Кырык сигезенче елның март аенда миңа унсигез тулды.

Кырык сигезнең март аенда солдаттан Раббани абый кайтты.

Авылны инләп карга бураннары уйнап йөргән чак иде. Койма, лапас буйларына көренделәп салган кәрт түбәләре тәтенли. Кәрәр кешесе булмаган өйләр, күзен генә калдырып битен бәйләгән бала сыман, тәрәзәләренең өске өлгесенә чаклы кар эчендә утыра иде. Без көн саен, я Әдрән, я мин барып, Чибәр әбине өеннән казып дөньяга чыгарабыз.

— Гомере бар кешегә ямьле җәйләре дә килер әле...— ди ул.

Безнең бер кат тәрәзәләрнең аскы өлешенә эчтән такта сугылып, җылылык өчен ике арага кибәк салынган; өске өлешләре көн йомшарганлыктан эри, ә үт алгач, яз сулышын сизгән төсле, яшәреп китә иде. Шундый кичләрнең берсендә капка төбендә кемдер «трр!..» дип ат туктатты. Башта Әдрән, аннары мин сәкегә менеп, икебез ике тәрәзәгә капландык. Күз бәйләнгән чак булса да күрдек: колакчын бүрек, бөрмәле тун, ак киез итек кигән бер кеше туп-туры үз өенә кайткандай ат тотып, безнең капкадан кереп килә, чанада толыпны кигән тагы берәү утыра иде. Гел бер төрле кышкы көннәрне кызыксыз гомер кичергән авыл халкы өчен, капкаңны ачып, йортыңа бер ят кеше керү — үзе бер яңалык, хәтта шатлык иде.

Без, кемнәр булыр бу дип, атылып дигәндәй каршыларга чыктык. Чаптар алаша инде күтәрмә төбенә килеп туктаган, чанадагы толыплы кеше дә төшеп, култык таякларын җайлап тора иде. Йөзен күрмәсәк тә, баскач, гәүдәсеннән таныдык:

— Раббани абый!..

Раббани абый тураеп безнең якка борылды:

— Апайлар, сезме?..

Без күтәрмә башыннан туры аның янына сикердек.

— Иплəбрәк, иплəбрәк. Аягыма бик кагылмагыз, — диде ул.

[1] Гармунны белер-белмәс кенә уйнаучыга әйтелә.

— Аягыңа ни булды соң, абыкай?

— Этләрем белсен! Мин түгел врачлар да белеп бетермәде, — дип, инде үзе безне кочаклап алды, култык таяклары икесе ике якка авып китте.

Шул рәвешле, муенябыздан нык итеп кочкан килеш, бер аягы белән генә сикерә-атлый, безнең белән бергә баскычтан менә башлады. Ул арада өйдән, каушап-кабаланып, әни дә килеп чыкты. Ул безне кече як тәрәзәсеннән карап-күреп торган, чыга-чыгышка:

— Хәвадис, аллә синме, улым? — дип куркынып сорады.

— Юк. Мин әле бу. Исәнме, инәй? — диде Раббани абый.

Әни туктап сүз әйткән җирендә катып калды. Ул исенә килгәнче, без аның янына килеп, Раббани абый Әдрәннең иңбашыннан сул кулын алды да, әнине йомшак кына итеп йомшак толыбына кысты. Әни:

— Исән кайттыңмы, балакаем? Исәннәр кайттыңмы? Әллә аяккайларың имгәндеме?.. — дип тулган күңеле, йомшак теле белән такмаклап китте.

— Сорамагыз әле шул йөрмәгән аякны, — дип абый көлеп кенә җавап бирде.

— Ай алла! Нишләп болай тышта торабыз әле? Әйдәгез өйгә керик. Кая, ямчың кирәме? — диде әни.

. — Хәзер, әбекәй, хәзер, — диде абыйны китергән егет.

— Әйдә, энем. Атыңны апайлар үзләре чыгып урнаштырыр, — диде абый аңа.

Ямчы егет, икесе ике таба карап яткан култык таякларын иелеп алып, безнең янга күтәрмәгә менде. Без бер көтү суык иңртеп өйгә кердек. Абыйның өстеннән толыбын, шинелен салдыргач, әни сәке йөзлегенә дога кылырга утырды. Амин тоткач, абыйны китергән егеткә сүз катты:

— Кайсы авылныкы соң үзең, улым? Кемнәрнең игелекле баласы?..

— Идел Эченнән мин, әбекәй. Кырым-Сарайныкы, — диде ямчы егет.

— Ай, бик еракдардан ям чапкансың икән. Ничекләр адашмадыгыз мондый буранда?..

— Без Агыйдел өсләп кенә элдерттек, әбекәй.

— Рәхмәт, балам... Юлга чыккан бәндәләреңне юлдан яздырма, доган хәерләр бир, — дип әни тагы битен сыйпап алды.

Аннары бик кадерле кеше килгәндә генә яндыра торган унлы лампаны кабызып җибәрде, ә сукыр лампаны бәләкәй якка чыгарды. Аннары мондый көннәрне киштәгә тартып куелган киҗеле чаршауны төшереп куйды. Без Әдрән, ямчы егет өчәүләп ат янына чыктык. Атны лапаска кертеп тугарып, бәсләнгән тирләрен сөртеп, печәнгә куштык та, дилбегәсен-камытын өйгә алып кердек. Әни, кулына чыра агачы тоткан килеш, абый белән сөйләшеп тора иде, без керү белән чит кеше алдында сүзне туктаттылар. Әни мине ымлап кына чаршау эченә чакырып алды да, пышылдап кына әйтте:

— Бар, улым, бер киенгән көе Шәрифулла абзыйларыңа барып кайт. Болай гына ярамас бит: китерә килгән егете дә бар. Көтәргә диярсең. Барганда Тимершәех абыйларыңа да сугылып чык, вакыты булса килеп утырсын...

Мин башта Тимершәех абыйларга сугылдым. Өендә юк, идарәдә иде.

— Ярый, апай, нәрәттән соң әбизәтелне барырмын, — диде.

Аннары мин, кире кайтышлый, Шәрифулла абзыйларга кердем. Кызлары да, үзләре дә өйдә. Абый кайту хәбәрен әйткәч, «китче әле!» дип сораштыра башладылар. Иң олы кызлары Рәҗимә апаның тук, алсу йөзеннән нур уйнап үтте. Аннары Шәрифулла абзый минем йомышны үтәде: мышный-мышный мич башына менеп, аннан бер чирек бал алып төшеп бирде.

— Урындагы кешеләр өчен генә койган мичкәдән агызып бирдем. Сата торганы түгел бу, менә күрерсез... — дип сөйләнә-сөйләнә, чирекне тастымалга урап, култык астыма кыстырды.— Раббани иртәгә үз вакыты белән безгә килсен. Ыштубы да килми калмасын, яме. Мужыт, үзем дә барып чыгармын әле, — дип мине өйалды ишегенә кадәр озата чыкты.

Чыннан да күңеле түзмәгән, Тимершәех абыйлар белән табынны башлап кына торганда, тагы бер чирек бал кочаклап үзе дә килеп керде.

Раббани абый сөйләгәннәрдән без шуны аңладык: гөл кебек кенә хезмәт итеп яткан җиреннән сулкылдап кына сул аягы сызлый башлаган. Көндез язылып китә икән дә, иртәнгә тагын оешып ката икән. Подъем булганчы уянып, ике куллап уа-уа гына бераз кеше рәтенә кертә икән. Гомерендә-бер чирнең ни икәнен белгән кеше түгел, үтәр әле дип, кул гына селтәгән. Тик көннәр үтсә дә, авыруы үтмәгән. Ә бер көнне подъемга сикереп торган җиреннән алты потлы гәүдәсе белән гөрселдәп идәнгә ауган. Ике ай буе башта лазарет, аннан госпитальдә яткан, әмма тиз генә аякка басарлык түгел икән. Шулай да оча төбеннән бераз җибәреп, аяк очын гына тидереп баса башлагач, җиде елның дүртесен сугышта үткәргән ветеран буларак, срогы бетер-бетмәстән демобилизацияләгәннәр. Теләсә бүгеннән үк госпитальгә китә, теләмәсә өйдә ятып та дәвалана ала икән. Күбрәк массаж, күбрәк хәрәкәт, илла мәгәр иң файдалысы — эссе мунча дигәннәр. Түзә алган хәтле каен миллеге белән сыйпап-сыйпап чабынырга кушканнар.

— Менә дәвасы шул аның — гел җылы, — дип Раббани абый сүзен тәмам итте.

— Шулай шул, апай: чирне аны килгәндә генә сизмисең, киткәндә ул китә алмый интегә, — диде Тимершәех абый. Аннары һич уенсыз Шәрифулла абзыйга әйтте: — Ишеттеңме инде, бал абзый? Иртәгәдән алып Раббанине үзегезнең бер мунчадан калдырмыйсың...

— Бәй, кем каршы аңа? Әйтелгән — эшләнер, — диде Шәрифулла абзый.

Әни кече якта гына утыра. Абый сөйләгәндә генә, мич буена килеп, чаршау читеннән карап торды. Стаканнар кыймылдый башлап, табын бал җаена агылып киткәч, тагы үз урынына барып утырды.

Кышын без дөньядан киселеп яшибез: иң якын станция Камбарка булып, анысы да безгә җитмеш чакрым кире якта иде. Шуннан абый, авыл саен диярлек ат яллап, өч көн кайткан. Инде шактый юнәя башлаган аягы, чана суыгы тиеп, тагы асылынып калган иде. Ятканда да үзенә аеры нәрсә шикелле күтәреп кенә салдык. Ай-яй авыр икән жансыз аяк!

— Бер дә булмаса Чибәр әбиеңнән имнәтеп карарбыз, — диде әни. — Зиһене йомшарса да, имгә таза әле ул...

— «Раббани улыма ни булган?.. Мөшкәш булган, һау-һау-һау!..» — дип абый яткан җиреннән йомшак кына көлеп алды.— Шулай бит әле, инәй?

Әни бер үпкәсез:

— Анысы аның — бала име, — диде.

— Мирзадан хат бармы? Нилләр яза? — диде абый.

— Синнән хат алмавына бик аптырап язган бер хаты килгән иде, шуннан — юк әле.

— Госпитальдән госпитальгә күчеп — өзелдек шул...

— Аның хезмәте кайчанрак бетәр икән соң, улым? — дип сорады әни дә.

— Озакламас инде. Безнең действительный срогы — икебезнеке бер булырга тиеш, — диде Раббани абый. Тавышында йокы иде инде

Иртәнгә буран басылган, көн аязып, суытып җибәргән иде. Әчкелтем исле җылы өйдән салкынга чыккач, башлар җиңеләеп китте. Без ямчы егетне, иртән тагы бары белән тәрбияләп, әйбәтләп кенә озатып җибәрдек.

Әдрән бер киенеп чыккан җиреннән Чибәр әбинең ишегалдын күрәргә китте. Кыш буена урамга ишеп салган кар өстеннән барганга күрә, безнең энекәш өйләрдән дә биек төсле булып күренә иде.

Раббани абый:

— Төпчек тә бик үскән!.. — дип куйды.

— Инде ике ел сабан туе булды, үз ишеннән бер кемгә бил бирмәде, — дидем мин.

Без урам яктан ишегалдына кердек. Абый, таягына асылынып, бер урында әйләнә-әйләнә, дөньябызны күздән кичерде. Әтидән калган өй дә, абыйлар тергезеп киткән каралты-кура да, сипләп торуга карамастан, искереп килә: кар да күмгәч, әле бөтенләй җиргә ингән сыман иде. Раббани абый, сузып кына «да-а...» дип, кара төк баскан яңагын сыйпап торды. Бу аның сагынуы идеме, әллә бизеп ятсыну авазы идеме — белмәдем.

Аннары ул әкрен генә өйгә кереп китте, мин кар күрәргә калдым. Көнне болай ачып җибәргәч, атна эчендә генә буран булмас — энем белән икебез дә өйдә чакны ишегалларын гөл итеп куярга кирәк иде. Ул арада Әдрән дә Чибәр әбиләрдән кайтып җитте. Без, басылып тыгызланган карны шикәр төсле шакмаклап кисә-кисә, энем бер яктан, мин икенче яктан эшкә тотындык; өсләребезгә көрәк җиленнән борак оныдый кар сара башлады.

Ишегалдын бетереп урам якка күчәргә торганда, өйдән Раббани абый килеп чыкты. Чиста итеп кырынган, шинель төймәләрен самавардай ялтыратып җибәргән, иңбашлары тартып-киереп тора, шинеле җөйдән-җөйгә шытырдап кына сүтелеп китәр кебек иде.

— Әйдә, Сирин апай, мине бал абзыйларга илтеп кенә куй әле, — диде ул миңа. — Мондый карда бу гәүдәне култык таягы гына тота алмас.

Без Шәрифулла абзыйларга киттек. Юл әле тапталмаган — бишалты ат печәнчеләр генә үткән. Мин аягым белән катыны капшый-капшый алдан барам, минем арттан ипләп кенә абый килә. Әледән-әле таягы батып кала да — мин тартып чыгарам. Икебезгә дә рәхәт, күңелле. Безне күреп, ишегалды, капка төпләрен көрәп яткан апалар, бабайлар кул сузып күрешергә киләләр; «бик исәнбез әле» дип кенә узып китеп булмый, бераз сөйләшеп торабыз.

Икәү генә калган бер арада, җаен китереп, Раббани абый Шәрифулла абзыйның кызларын сораштырып алды.

— Түп-түгәрәк битле кара чутыр бер кызлары бар иде, анысы да үскәндер инде?

— Үсте!.. Минем куенда!.. — дидем мин.

Телем әйтте дә качты — кызаруы миңа калды: салкын биткә җылы кан бәрүен тойдым. Абый, башын чөеп, көлеп җибәрде:

— Тиленеке тишек — тотылдың бит, апай!.. Ярый, ярый, киленне күреп кайтырбыз. Ә зурлары кем куенында соң?

— Кем куенында булсын! Рәҗимә апа инде карт — егерме икедә. Ә Тәрҗимә буйлы егетләр бөтен базарында юк. Әле күз генә бер егет шаяртып: «Миңа кияүгә чык әле, баскычым да бар» дип әйткән икән дә, Тәрҗимә аны базар эчендә: «Аяк астында бик чуалып йөрсәң, маңка!» дип, өреп кенә очырган. Күргәннәр сөйләде. Булмас димә! Артыңнан килсә, ат киләме әллә дип артыңа әйләнеп карыйсың...

Шәрифулла абзыйлар безне көтеп торалар иде инде. Ишекләрен ачу белән борынга, ашыйсыларны китереп, каз шулпасы исе килеп бәрелде. Өйләре көндәгечә чиста, һәр җирдә кызлар кулы: идәннәре пычак белән кырып юылган, түр сәкегә буйдан-буйга бизәкле йон палас җәелгән, тәрәзә саен кызыл башлы сөлге, чигүле кашага; ике кат тәрәзәләре буланып-тирләп утыра, — яландай өй эче тулы ямь, муллык иде.

— Шулай картаеп барабыз, Раббани апай. Җилкә бөкрәйгән, бил кәкрәйгән — меңгә ике, йөзгә бер тулмый, — дип Шәрифулла абзый кәефле генә көлеп куйды.

— Каяле сиңа картаю! Карт аю урманда гына була, — диде абый.

Җүәйрә апа бөтерелеп аш җиткерә башлады, әйтерсең лә үзләренең сугышта үлгән уллары кайткан иде.

— Җүәйрәттәй дә бер дә картаймаган.

— Аның — шулай: миннән алда бер картаеп куйды да, хәзер шул көе мине көтеп тик тора.

Җүәйрә апа «с» авазын сакау әйткән теле белән:

— Син! Кунакларны сүз белән сыйлама. Түргә узыгыз дип әйт ичмаса, култык таяклы Раббанине ишек төбендә тотасың,— диде.

— Әүлияләр сүзе әйттен, кортка! — диде Шәрифулла абзый. — Әйдәгез, Раббани, Сирин... Өстәл катына утыраегыз әле.

Без түргә узып өстәл янына утырыштык. Аннары Шәрифулла абзый кече яктан чиреге белән бал алып чыкты. Үзе дә утырып, буяусыз агач кәсаләргә бал коя башлады.

Шул чак тышкы күтәрмә төбеннән дөп-дөп аяк каккан тавышлар ишетелде, кемдер өйалдына буш чиләкләр куйды; күп тә үтмәде, ишек тулып Шәрифулла абзыйның ике зур кызы килеп керде. Башларында иске кама бүрек, өсләрендә кырык ямаулы фуфайка, аякларында катып беткән киез ката иде. Безне күрү белән оялып-кыенсынып мич артына кереп киттеләр.

— Рәҗимә! Тәрҗимә! Нигә сез алай Раббани абыегыз белән килеп күрешмисез? — диде Шәрифулла абзый.

Зур кызлары Рәҗимә дә, Җүәйрә апа кебек, «с» авазын сакау әйтә иде, мич артыннан шул җавап бирде:

— Мал арасында йөргән өс-баш беләнме?

Бераздан аларның сөйләшүе кече яктан килә иде инде.

— Ярар, эшегез бетсә, юынып өсләрегезне алмаштырыгыз, — диде аларга Җүәйрә апа.

— Эшне җимереп эшлиләр анысы, — диде Шәрифулла абзый безгә. — Бармакларына җилен кысарлык көч керү белән сыер сава башладылар. — Шулай дип кулына кәсасен алды: — Әйдәгез алайса, кыстатмый гына эчәегез әле, апайлар. Синең исән-сау кайту бәхетенә инде монысы, Раббани.

Икесе бердәй озаклап-тәмләп эчтеләр. Мин балның туп-туры мигә ярып менгән үткен исенә түзә алмыйча, кәсане кире куйдым.

— Бәй, улым, нишләп алай гына?

— Исе үк башка бәрде әле монын, бал абзый.

— Чынлап та! Бөтен кан тамырларына йөгерде, — дип минем сүзне абый да куәтләп җибәрде.

— Ә-ә, сиздегезме инде! Бу — яшь корт балы шул. Әтиегез мәрхүм дә: «Каяле, Шәрифуллау, теге ниәстәң бармы?» дип, эчсә гел шушындыйны гына сорап эчәрие. Аракының шөйлә тәмен дә белми үлеп китте мәрхүмкәй... Һә-әй дөньялар!.. Үнгәреп бетеп бара инде. Бариемени ул сугышка тикле аракы эчү?.. Күрше авылның Кәҗә Талип кына җиде баласы өчен акча алган көнне бер чүлли эчеп, шуңа исереп кайтырые. Анысы да — елына бер!..

— Шулай иде шул... — диде Раббани абый.
Шунда тагын ишек ачылды. Башта идәнгә ап-ак булып суык җәелеп керде, шуннан соң гына көянтә-чиләге белән Җәзилә күренде. Апалары тәсле мич артына борылмады, йөзеп кенә, чаршау эченә зур яктан үтте. Суын, көянтәсен куйгач кире чыгып, абый белән килеп күреште. Ул, әлбәттә, мин килүен көткән: мал карарга чыкмаган, киенепясанып ерак чишмәгә суга барган. Киеме гел яңадан: мамык шәл, сатин тышлы фуфайка, юка постау күлмәк, биле дә сынмаган киез итек; шәленнән башкасы гел кара — маңгай чәче дә, кашы-күзе дә шомырткара, күперәп торган түм-түгәрәк бите генә алсу янып тора иде.

Ул арада кече яктан да, өсләрен алмаштырып, Рәжимә белән Тәрҗимә килеп чыкты. Икесе дә энәдән-җептән генә төшкән озын җиңле күлмәк кигән, чәчләрен дә кыл урталай ярып, ике толым итеп үргәннәр. Абый белән аллы-артлы күрешеп, бер-ике авыз сүз әйтешкәч, кире кереп киттеләр.

Абый, күзен дә алмыйча, карагайдай озын буйлы Тәрҗимәгә карап калды. Тәрҗимәнең үзе генә түгел, чәче дә озын — тез астына җиткән, атлаган саен елык-елык килеп, койрыктай уйнаклап китә иде.

Шәрифулла абзый кече якка башын борып, Җүәйрә апага дәште:
— Син! Кортка!.. Итең нишли әле анда?
— Хәзер, хәзер... Өстемдә торма.
Җүәйрә апа тирән коштабак тутырып ит чыгарды. Әйләнәсенә бәрәңге тезеп, эре итеп суган туралган иде. Өстәл өсте жырлап җибәргәндәй ямьләнеп китте.

Шәрифулла абзый иркенләп кенә кәсаләргә чиректән бал агызды.
— Әйдәгез, ит алдыннан бер териткә тотаегыз әле. Яше бик җиткән инде бу балның — самый әчәр чагы!
Икесе дә кәса читеннән генә сөзеп эчә башладылар. Раббани абый, эчеп бетергәч, ирен өстенә күбектәй ябышып калган кәрәз чүпләрен уч төбе белән сөртеп алды.
Биш-ун минут үттеме-юкмы, ишекне каерып ачып Тимершәех абый килеп керде. Без урыннарыбыздан торып аны каршы алдык.
— Кунаклар бар икән! Исәннәрмесез барыгыз да!.. Исән йокладыңмы, Раббани?
— Кайда йоклаганымны да белмәдем, — диде Раббани абый.
— Бәхетленең кунагы да бергә килә, әйдүк, Тимершәех!.. —дип Шәрифулла абзый аның бүрегенә үрелде.
— Мин йомыш белән генә, Шәрифулла абзый...
— Йомышны аны табын янында да йомышлап була. Әйдә-әйдә, персидәтел булсаң да, аштан зур түгелсеңдер әле.
— Алайса тукта инде, Шәрифулла абзый, берәр кызыңны атка җибәрик башта. Илләргә барып кайтасым бар иде.
— Тәрҗимә, кызым!..
— Нәрсә? — дип Тәрҗимә килеп чыкты.
— Бик кыенсынмасаң, минем «Туры»ны гына җигеп алып кайт әле, апай, — диде Тимершәех абый.
— Кылыйга ни дип әйтим?
— Илләргә бара дип әйт. Печәнне күбрәк салсын.
Хуш исле печән салып, кермәле чанага утырып кайтасы булгач, Тәрҗимә яхшыдан киенде: өстенә бостон тышлы билле пальтосын, аягына калыптан гына төшкән кара киез итеген киеп, кара шәлъяулыгын бәйләде дә, үзе дә яхшы атлар тәсле башын чөеп атка китте. Абый аңа күзен дә алмыйча карап утырды.
— Ай-һай, «Туры»ң кызлар кулын санлар микән?
— Атыңны түгел, шайтаныңны биетә ул безнең Тәрҗимә! — дип Тимершәех абый өстеннән сала башлады.

Шәрифулла абзый аның күн бүреген, сары бәрән тунын алып, чөйгә элеп куйды.

— Рәҗимә, комганга җылы су сал, кызым, — диде Җуәйрә апа.

Мин Тимершәех абыйга үз урынымны биреп, үзем түбәнгәрәк күчтем. Шәрифулла абзый тагы бер кәса алып чыкты.

— Юк-юк, мин бер капмыйм, Шәрифулла абзый. Син Раббанине сыйла. Минем — эш вакыты. Сириннең дә иртәгә эшкә барасы. Бүген икесен дә нәрәткә кертмәдем инде,— дип кайнар каз шулпасына кашыгын тыкты.

— Әйдә алайса, Раббани, — диде Шәрифулла абзый.

Бер тәлинкә шулпа эчеп, иттән дә авыз иткәч, Тимершәех абый җай гына сүз башлады:

— Яз җитә бит әле, Шәрифулла абзый. Яз! Көздән уйлаган уйлар язга туры килеп бетмәде: менә әле орлыкка дигән бодайны тазартып ятадырыек — бер дә җитәр сыман түгел. Аның әле чәчү өстендә ай буе сабан сөрүчеләрен, тракторчыларын ашатырга кирәк... Менә шундыйшундый хәлләр, Шәрифулла абзыкай гынам...

— Боткасын пешергәч маен да сал инде: миннән ашлык сорарга итәсезме?

— Шулайрак иде. Идарә сүзен әйтәм.

— Аш ташыганда — чүмеч, туфан ташыгында — көймә.

— Андый сүз юк, Шәрифулла абзый. Син һәр вакыт колхозның терәге булдың.

— Йә, салам кыстырма. Әйт: күпме кирәк?

— Бер өч йөз пот бодай биреп тор син колхозга. Яртысын быел, яртысын киләсе ел уңышыннан түләрбез.Үзең теләгән ындырдан сайлап алырсың.

— Өч йөз пот ук булмас, апай Тимершәех.

— Кит әле! Сугыш вакытында да бишәр йөз пот биреп торганны!..

— Әә! Ул чагында минем запас күбрәк иде. Сугыш башланасы елның көзендә дә без, беләсеңме, күпме иген алдык?.. Ике улым — бәгырь кисәкләрем — Гарифуллам, Сәгыйдуллам белән җимереп эшләгән хезмәт көнебезгә төп-төгәл мең пот алдык!.. Ә аннан алдагы елны?.. Син үзең кәнсәләрдә эшли идең бит. Бар иеме колхозда бездән дә күп эшләгән берәр семья? Әлбәттә, башкаларга да тимәде түгел — тиде. Колхоз ике-өч ел рәттән уникешәр кило бүлсен дә — тимәсен! Егетжилән дугаларга кызыл чүпрәк бәйләп өй борынына иген таратып йөридерие бит!.. Соңга табан, урыным юк дип, күпме кеше алмады!.. Ишегалларына бушатып киттеләр. Шулай кош-корт ашап, мал ашап, исраф булды игенкәйләр! Ә мин алай итмәдем — капканы киң ачып кертәдерием олауны. Келәткә саладырием. Базга саладырием. Мунчагы саладырием. Кайда тишек бар, шунда тутырадырием. Сугыш чыгар алдыннан әнә Җәзиләмә җиде яшь тә юк иде — ул да чиләк күтәреп ташыды! Бәләкәй генә уч төпләре чиләнеп чыккание сабыйның... Шуннан нәрсә? Икенче елны сугыш башланып китмәсенме... Синең белән бергә киткән Әкмашны хәтерлисеңме? Шул: «Кышка тикле мимечнең муенын астына китереп кайтмасак, сөйгән хатыннарыбызның куены безгә харам булсын!» дип, башындагы иске кипкеләрен җиргә бәтәрләп аткание. Китте дә югалды, мәрхүм. Авыр туфрагы җиңел булсын — җиңелрәк холыклы иде.

— Озын сурә башладың, Шәрифулла абзый. Беләбез бит инде,— диде Тимершәех абый.

— Хәзер беләсез шул. Белмичә! Ә ул чакны белмәделәр. Көзгә бетә имеш сугыш... Беттеме?.. Кая! — бетәре дә күренми башлады. Елына бишәр-алтышар йөз хезмәт көне эшләгән Гарифуллам белән Сәгыйдулламны да йотты. Колхоз миңа түгел, мин колхозга бирә башладым. Ул самолетка дигән акчалар!.. Бүтәннәр бер мең дә ике мең, аша китсә

биш мең биргәндә, мин бер үзем илле мең бирдем! Елның-елына утыз баш умартадан чыккан дахутым[1] иде ул... Анысы — күз яшедәй ике улыма өстәп инде... — Шәрифулла абзый шулай диде дә, юан бармагы белән, күз төбенә тәгәрәп төшкән ике бөртек кояш нурын сөртеп алды. — Менә шулай ул дөньялар!.. Инде сугыш та юк, ә сез һаман миннән сорыйсыз. Ярый, ике йөз пот бирәм. Артыгын бирә алмыйм, Тимершәех. Кызларым да әнә — өчесе дә җиткән. Гел бер ояда өелеп ятмаслар бит инде алар? Канат катырган кош балалары — очабыз дип әйтерләр. Һәр кайсына сандык әйберсе кирәк. Болай да инде кем кызлары эшкә киндер күлмәк киеп йөрде бу заманда?.. Минекеләр!..

— Иә, кызларың өчен кайгырма әле: башлары кайда, сарайлары шунда. Ике йөз булгач — ике йөз! Анысына да рәхмәт. Сөйләштек!

— Бодай келәттә, любуй бримә төяп алып китә аласыз. Тынчыган, күгәргән түгел, — диде Шәрифулла абзый.

Тәрҗимә ат җигеп кайткач, Тимершәех абый бер минут утырмастан өстәл янынннан торды.

Ә киенгәндә һич уенсыз әйтә куйды:

— Кызлар, менә берегезнең бәхетенә Раббани абыегыз кайтты. Мунча якканда әйтергә онытмагыз: зур врачлар аның аягына гел чабыну кирәк дип җибәргәннәр, — диде.

Абый, кызлардан бигрәк үзе оялып:

— Син алай кызларны оялтма инде, — дигән булды.

— Ничауа, кызлар үзебезнеке! Шулай бит, Шәрифулла абзый?

— Шулай-шулай. Сихәте тиярдәй булса, әйтми калмабыз. Мунчаны без аны кирәк булса көн саен ягабыз,— дип Шәрифулла абзый арттырып ук җибәрде.

Аннары ул, башына мескен бүрек, өстенә иске сырма киеп, Тимершәех абыйны озата чыкты.

Без, иркенләп утырып, өйләдән соң гына кайттык. Ишегалларын әдрән гөл иткән — өр-яңадан көрәп, киңәйтеп куйган. Ап-ак кар өстендә җемелдәп яткан җылы кояш, кыек читеннән тыпылдап тамган беренче тамчы, зәңгәр күктәй иркен яз сулышы — һәммәсе дә Шәрифулла абзыйлар өендә калган ямьле табынның дәвамы кебек иде.

## 7

Икенче көнне Шәрифулла абзый мунчага әйтә килде.

И шул көннән алып абыйны алар бер мунчадан да калдырмый башладылар. Өйдә күбрәк ятып үткәргәнлектән (күп йөрсә, аягы сызлый) абый өчен бу үзе бер бәйрәмгә әйләнә: Шәрифулла абзыйлардан ул, йөзләренә алсу нур йөгереп, кунак булып кайта иде. Тора-бара ул үзе дә бу көн җитүен сабырсызлык белән көтеп ала башлады: мунчадан бигрәк, аяз таңдай балкып, Тәрҗимәне күрергә ашкына иде.

Бер күрүдән яратыштылар алар. Тәрҗимә, минем тиң булып, абыйдан нәкъ тугыз яшькә яшь иде. Ләкин йөрәк аңа карыймени! Безнең абый сыман ир-егеттән ул заманда нинди генә кызкай баш тартыр иде икән!..

Әни сөенеп бетә алмады. Инде бу хакта бөтен авыл сөйләсә дә, үзе белмәмешкә салыша, ләкин ул йөрүләрен, ул талпынып эшкә керешүләрен күрсәң, үзе бер күңелле, әйтерсең лә ул тотасы һәр нәрсәгә бәхет кунып, ак каурыен салып киткән иде. Моның өстенә бер көн, юл өзелер-өзелмәстә, Шәрифулла абзый белән түн өстеннән базарга барып, бер бик матур теше бозау[2] җитәкләп кайтты: чем-кара, янбаш сөякләре кинчә-калку, эче батыбрак тора, маңгаенда тәнкә зурлык кашка-

[1] Доход — керем.
[2] Теше бозау — тана булып җитмәгән яшь (ана) бозау.

сы да бар иде. Шәрифулла абзый үзе сайлап, үзе сатып алып биргән икән. «Җиде ят түгелбез, бер ризалатырсыз әле» дигән.

Алачыкта күмер булмау сәбәпле без эшкә бармаган идек. Әни, тын бер шатлык белән, Әдрәнне шундук Чибәр әбине алмага йөгертте.

Бозауны кыйблага каратып, әни муенчагыннан тоткан, Чибәр әби мөкердәп кенә әфсен укый, безгә аның «әфү-төфү» дигәне генә ишетелеп кала. Шул «әфү-төфү» дигәндә кулындагы дисбесен бозауның әле башына, әле аягына, әле сыртына тигереп ала иде. Аннары ул үзебезнеңчә тел белән:

— Бурадай буралып гөбедәй гөбердәп үс, җиленең тулы май булсын, тоякларыңа тояклар өстәлсен, — диде дә, әни кулыннан муенчагын алып, ишегалдын бер әйләндерде. Шуннан соң гына әни бозауны абзарга кертеп япты.

Инде болар өстенә тагы Раббани абыйның әкренләп кенә савыга килү шатлыгы өстәлде. Җир җылынып үлән калку белән, ул аягын иртәкич кычыткан суында тота башлады. Май аеныкы гына файдалы дигәч, без ул айда ярты авылның читән буен ялмап чыктык. Ләкин иң файдалысы кырмыска оясы булды. Май урталарында Уфа тубдиспансерыннан чыккан Хәвадис абыйны каршыларга баргач, Раббани абый пристаньда бер кеше белән танышып-сөйләшеп киткән. Ул кеше үзебезнең районныкы булып, Казанның бер больницасында баш врач икән. Шул әйткән: кырмыска оясына утыр син, дигән. Абый шуның киңәше белән, май-июнь айларында үзебезнең саклау урманына менеп, җидеме-сигезме кабат кырмыска оясына утырды. Икешәр сәгать буена ничек түзеп утыргандыр инде ул анда! И, әйткәнемчә, шуннан да файдалысы булмады — җиләк өстендә аягын нык итеп җиргә басты.

Бу вакытта инде, алты ай буена больницада ятып, йөзе ак бәздәй агарып кайткан Хәвадис абыйга да юалы болын, какылы басулар җиләндә бераз төс кунды.

Больницада ул үзебезнең Әнәк марие белән бергә яткан. Ул кешене без күптәннән белә идек: бөтен базарга бер фотограф —Юзекаев Асылгәрәй дигән кеше иде ул. Яшьтән үк күксәү булганлыктан, сугышка да бармады. Яз җитеп юл киптеме, базар саен, күләгә җиргә чаршау корып, егет-җилән, кыз-кыркынны «кәртечкегә» төшерә торган иде. Менә шул агай безнең абыйны, больницада бик үз итеп, кайту белән фото эшенә өйрәтергә булган.

Әнәк безгә ерак ил түгел — биш кенә чакрым. Абый, кайтып ике-өч көн уздымы-юкмы, базар көнгә каршы иртә белән шунда китте. Юзекаев аны бер кич кунак итеп, бар кирәк-ярагын салып, «Фотокор» дигән, күгәрчен хәтле генә бер фотоаппарат биреп җибәргән иде. Моның өчен без дә аңа бурычлы калмадык — көзге байлыктан бер капчык бодай бирергә булдык.

И менә хәзер Хәвадис абый, атна саен Әнәккә барып, иләсләнеп карточка төшерергә өйрәнеп йөри иде.

Карточканы тышта төшерсәләр дә, эшләвен караңгыда эшлиләр икән: абый да күрше Нәсих бабайлар мунчасына бикләнеп, ишек-тәрәзәсен юргандыр-нидер белән томалап куя да, түбәтәй чаклы гына бер кызыл пыяла яктысында тик эшләп утыра. Зиһенлегә эшнең сере үзе ачылыр, ди безнең әни. Ай да үтмәгәндер, базар тулы мир алдында, фотога төшәм дип, таяктай басып торырга оялган тутәйләр безгә килеп, чия күләгәсендә рәхәтләнеп «кәртечкегә» төшә башладылар.

Шулай өйрәнеп китте Хәвадис абый. Аның кебек авыру кешегә авыл җирендә уйнап кына эшли торган эш иде бу.

Көннәрнең берендә Мирза абыйдан хат килгәч, уку турында тагы сүз кузгалды. Беребез укый алмагач, мин инде бу сүзне беткәнгә саный идем, Мирза абый бетермәгән икән.

Бу юлы — чират минеке иде.

Ләкин мин көн дә суза киләм: керә аламмы-юкмы дип уйламыйм, абыйның аягы төзәлсен әле дип уйлыйм. Берсе авыру, берсе аяксыз ике олы кешене бер Әдрәнгә калдырып китеп булмый бит инде!

Тимершәех абый да:

— Әкрен барган — куян артыннан җиткән, шәп барган — сыер артыннан да җитмәгән. Ашыкма, вакыт бар, — диде.

Шулай суза торгач, сабаннан соң шөйлә ремонтка китереп җиткергәнмен. Ахырда абый, тәмам ныгып таягын ташлагач, минем өчен председатель янына кергән.

— Эти дә, үзем дә эшләгән алачык — иртәгәдән урынына үзем басам, җибәреп карыйк әле шул Сиринне берәр укуга, — дип үтенгән.

Шуннан соң гына мин документлар әзерли башладым. Документ дигәннән, һич аңламас бер сәбәп белән, минем җидене бетергән таныклык кәгазе югалган булып чыкты. Утка пешкәндәй угаланып, Тимершәех абый янына киңәш сорап кердем.

— Ярый, менә Илләргә барасым бар, мәктәп директоры белән сөйләшеп карармын тагы, — диде.

Кайтышлый ук алачыкка кереп әйтте:

— Директор белән сөйләштем, иртәгә үзең барырсың. Мин җибәрде дип әйтергә онытма, — диде.

Икенче көнне инде алачыкта Раббани абый белән Әдрән эшләп калды, ә мин таныклык юллап Илләргә киттем.

Өч кыш йөреп күпме чабата туздырган авыл! Мәктәбе дә шул ук — мин килгәнне сагынып көткән төсле, тәрәзәләре тулы нур белән миңа карап тора иде. Кыенсынып кына директор ишеген шакыдым. Без укыганда сугышта йөргән, сугыштан соң янә үз урынына кайтып эшли башлаган директорны мин күреп кенә белә идем.

— Мине Тимершәех абый җибәрде...

— Синмени ул таныкламасын югалткан?

Тавышы үтә дә кырыс иде — каушап киттем.

— Әйе, мин...

— Нык эзләдеңме соң?

— Эзләмәгән җир калмады инде, абый. Җен йоткандай булды.

— Җен йотмаган аны — бозау йоткан. Китап эченә тыгып куясыз да — йә энегез утка яга, йә бозау чәйнәп ташлый. Бәлки чәй кәгазе белән бергә стенага ябыштыргансыздыр әле?

— Безнең өйдә кызлар юк, абый.

— Яхшы. Ә син таныкламаны бер кешегә ике кабат бирергә ярамаганлыкны беләсеңме?

Мин бөтенләй коелып төштем. Юк, «укырга китә алмыйм инде болай булгач» дигәннән түгел — беренче тапкыр үз гаебемне үкенеп тоюдан иде.

Шуны сизепме, директор абый кинәт йомшый төште:

— Ярый. Колхозда ничә ел намус белән эшләвеңне исәпкә алып, мин сиңа тагы бер таныклама бирәм, — дип сейфыннан ялтырап торган таныклык кәгазе чыгарды.— Нинди билгеләр алганыңны үзең хәтерләмисеңме?

— Рус теле белән химиядән дүрт, калганнары бишле, — дидем мин.

Монысын мин яхшы хәтерли идем.

Ышандымы-юкмы, исем-фамилиямне тулысынча сорады да, нәзек билле каләмен кат-кат сөртеп, язарга утырды. Үтә дә зурлап, тәмләп язды инде!

— Булды бу, энем. Бу сиңа — без үлем белән якалашып йөргән чакта иген фронтында эшләгәнең өчен. Сакла... — дип урыныннан торып басты.

Кечерәк буйлы, чандыр гына кеше иде.

Мин тиз генә кара тушь белән язылган билгеләргә күз йөгертеп чыктым. Әллә күзем алмашынамы дип торам. Икенче кабатка текәлеп карасам — авып китә яздым: бер дүртле дә юк, рәттән бишле иде!

— Кулың белән аягың гына түгел, башың да эшлидер дип уйлыйм,— диде директор.— Без икәү белгәнне бөтен авыл белергә димәгән.

Аның җыерчык тулы киң маңгаена, тәрәзә буланган төсле, вак кына тир бәреп чыккан иде. Аңа ияреп мин дә маңгайны сөртеп алдым.

— Аңладым, абый, — дидем мин.

— Нинди техникумга соң исәбең?

— Геолого-разведочныйга иде.

— Яхшы. Егет кешегә — йә шул, йә авиационный инде,— дип ул миңа кулын бирде. — Алайса уңышлар телим...

8

Документларны салып җибәрү белән, Хәвадис абый шикелле китап җыеп, әзерләнә башладым. «Гел бишлегә бетергәннәр имтихансыз кабул ителә» дип язсалар да, ышанып булмый: минем ишеләрдән сорап куюлары бар иде. Ул сиңа — алачыкта тимер сугу түгел.

Зиһенем дә кулларым шикелле тупасланган: бик азлап кына кергән белеме дә башны селкү белән чыгып китәргә тора иде. Үзе белгән кадәр Хәвадис абый ярдәм итә — бигрәк тә русчадан зәһәр аңлата иде. (Өйрәнгән больницада ятып!) Ләкин тиздән мин ансыз да калдым: синсез анда ямь юк дип, тальяннары, фотоаппаратлары белән бергә Хәвадис абыйны болынга алып чыгып киттеләр.

Болын, болын... Күңелледер инде хәзер анда. Агыйдел яры өстенә үзе бер урам булып тезелгән куышлар. Бер казаннан барың бер тиң ашаулар. Җәйге төн карасында якты ямь чәчеп, клубтай пароходларның гөжләп узып китүе... Кичке җыр, уен-көлке. Сулкып торган сылу кызлар. Шулар янында җиләктәй Җәзилә...

Кая инде ул авылның болын өстенә житү!..

Мин өйдә дә, тышта да укый алмыйм: кайда укысам да оета башлый. Күзләрем дә елап шешенгән баланыкы төсле — һәр керфеге аерым-аерым чәнчеп тора иде. Ахры түзмәдем, китапларны төреп төйнәдем дә, шунда укырмын дип болынга тайдым. Икенче көнне печән чабучыларга уйнап кына ияргән идем — атна үтүен сизми дә калганмын. Уку исемә төшкәндә болын бетеп килә, ә китаплар куйган җиреннән дә кузгалмаган иде.

Иреннәренә хәтле печән исе сеңгән Җәзилә белән соңгы төнне Агыйдел буенда үткәрдек тә, мин таң ату белән авылга кайтып киттем.

Тагы бер атнадан ипиен, китабын бер бәләкәй капчыкка салып, каеш белән биштәрләп, пристаньга төштем. Көн эссе. Җил юк. Агыйдел өсте таеп егылырдый шома. Суы бик нык кимеп, дебаркадер яр астына ук бәйләнгән иде. Агыйделдә йөргән ике катлы «Тукай» пароходы килеп, мине Уфага алып китте.

Үзебезнең болын турыннан үткәндә мин, кайтмас җирләргә киткән бер кешедәй, җирсеп, җандай якын ярларыма текәлдем. Әле төш житмәгән, куыш тирәләре буш, бер читтәге казан тирәсендә генә Шәмсениса түти кайнашып йөри; яр башына тезелеп баскан бала-чага, корсакларын киереп, пароходны тамаша итә иде. Барысы да артта калып, инде маякчы турына якынлашканда, әллә кайдан гына яр өстенә Җәзилә калкып чыкты. Йөзен аермасам да — гәүдәсеннән таныдым.

Пристаньнан пароход кычкыртуын ишетү белән, эшен ташлап йөгергән инде ул монда.

— Җә-зи-лә-ә!..

Әлбәттә, ул минем тавышны ишетмәде, мәгәр кул болгавымны күрде, үзе дә башындагы кыек яулыгын салып, ашыга-ашыга селки башлады. Ләкин, пароход тиздән борылмага кереп, Җәзилә күмелде, зәңгәр косынкасы гына зәңгәр күктә эленеп калгандай булды.

Шул чак койрыкта утырып килгән егетләрнең берсе, Хәвадис абыйныкы төслерәк тальянын алып, мин моңарчы бер дә ишетмәгән моңлы бер көй уйнап җибәрде. Аңа шундук, Агыйдел буйларын яңгыратып, кызлары, егетләре кушылды. Азактан белдем: мин белмәгән бу көй «Таһир-Зөһрә» дигән яңа көй булган икән.

Ике тәүлек буена күз алдымнан Җәзилә, колактан шул көй китмәде. Шулай Уфага барып җиттем. Бәләкәй генә пароходтан дөнья халык төшеп, урамнар тулды. Мин дә шуларга кысылып нярдем. Баскычбаскыч тротуардан калага менәбез. Күзем өйләргә йотылган. Болар Шәрифулла абзыйларныкы ише генә түгел: кәрнизләрe, тәрәзә башлары Җәзиләнең зур челтәр якасы шикелле сырлап-чигелеп ясалган иде. Мин инде бу урамның, өй почмагына сугылган язуларын укымасам да, Хәвадис абый сөйләвеннән Ленин урамы икәнлеген беләм. Техникумы да шушы урамда булырга тиеш иде.

Тауга менеп җиткәндә, каршы яктан трамвай килгәнен күрдем. Эчен белмим, мәгәр тышы тулы кеше иде. Тукталышта и чыкты халык, и чыкты — әрҗә аударып бәрәңге түктеләрмени! Иң азактан муенына сумка аскан бер апа төшеп, артка бәйләнгән юан бауны чишеп алды да, ике аягын җиргә терәп басты. Шунда трамвай да чигенә башлады, ә бу апа шуны җибәрмәскә иткән сыман иде. Ул — өстәге дуганы тарта икән: бер вакыт дуга тураеп, алгы якка ауды, ләкин шундук, туптай сикереп, чыбыгына ябышты — зәңгәр утлар чәчрәде. Трамвай шулай, борылмыйча гына икенче юлга чыгып, кире китә икән. Көтеп торган халык өеме, җимереп ташлардай булып, ишегенә ябырылды.

Хәвадис абый миңа техникумга чаклы җәяү генә барырга кушкан иде. Мин шулай иттем дә — карана-карана җәяү генә киттем.

Көн кыздыра гына. Тротуар өсләре кайнар бәреп, беләүдәй ялтырап ята, ә рельс сыртында ике буй кояш нуры уйный иде. Урамның чиге-мазары юк, бик ерак очы күкшел төскә төренеп, рәшәдәй кыймылдап тора, барган саен өйләр зураеп, кешеләр бәләкәйләнә бара иде.

Шушы икән Уфа дигәннәре!

Техникумны тиз таптым: нәкъ абый әйткән урында иде. Бер нинди сырсыз-бизәксез, шоп-шома итеп сылап салынган өч катлы бер бина иде. Каушап кына эченә кердем. Ап-ак йөзле бер бик чибәр апага белер-белмәс русчам белән үземнең кем икәнлегемне әйттем. Ул минем аттай гәүдәмне баштан-аяк күздән үткәрде дә, бик ягымлы итеп аңлатып бирде. Монда килеп йөрүемнең кирәге дә булмаган: мине имтихансыз гына кабул иткәннәр икән. Язу да җибәргәннәр. Алмавымны әйткәч, аптырагандай кашларын күтәреп, бер кәгазь язып бирде.

— Шушы язу белән августның егерме бишеннән дә калмыйча килеп житегез, тулай торак мәсьәләсе каралачак,— диде.

Шул ук көнне кич үзем утырып килгән пароход белән кайтып та киттем.

Егермеләренә чаклы рәхәтләнеп колхозда эшләргә була иде әле, эш сорап бригадирга бардым.

— Алачыкта — абыең белән энең. Лобогрейканы Чегән Хәмзәсенә бирдек. Синең гәүдәгә ярардай эше дә калмаган бит әле аның, — дип шаяртып алды. — Ярый инде, алай бик ялынып сорагач, заготзерногa йөрерсең.

Белә ул бригадир миңа нинди эш кушарга!

Мин ике атлы арба белән заготзерногa иген ташый башладым. Көшел төбендә сиртмәле үлчәү: бер ягына эреле-ваклы шестернялар белән икешәр потлы ике гер асылган, икенче ягында — биш пот сыешлы

тимер бадья: шуны көшелгә чумырып аласың да, көчең житсә бер үзең, житмәсә икәүләп, сиртмә башын аска иеп, ыргагына эләсең. Весовщик үлчәп тора. Биш пот ясагач, бадьяны такта читле арбага бушатасың — шулай йөк саен илле пот... Ә заготзерногa илткәч күргән газаплар... Баскан саен сыгылып киткән такта басмадан таудай өем өстенә капчык күтәреп менеп кара әле!

Шуңа күрә бу эшкә тазарак егетләрне куялар иде.

Безнең бригададан без Тәрҗимә белән икәү. Тәрҗимә бер үзе — егетләргә биргесез. Безнең басу заготзерногa якын булганлыктан, көненә икешәр юл ясыйбыз. Иген күп чыкканда, без әйләнеп кайтуга, капчыкларны көшел өючеләр тутырып куя иде — төяп кенә китәсең.

Җәзилә дә көшел өя иде. Кайсы көнне ул Тәрҗимә белән урыннарын алмашып, заготзерногa иген илтә бара. Без ындыр табагыннан, гадәттәгечә, икебез ике ат белән кузгалып китәбез. Ләкин олы юлга төшкәч бахбайларны үз көенә куябыз да, мин Җәзилә янына күчеп утырам. Ул, итәге белән тезен каплап, аякларын сузып утыра. Мин чалкай ятып, аның терсәктән ачык беләгеннән тотам. Без шулай, талгын искән җилдәй, тын гына барабыз. Һәр тарафтан, җил белән бергә, яшь арышның әрем катыш әчкелтем-татлы исе саркып килә. Инде кайнар буына сулышлар киңәеп, туйганчы бер, яңа пешкән яңа ипекәй ашаганбыз, — тын белән суырып алырдай көткән көзге байлык иде бу!

Җәзилә сүзсез барудан ялыккач, муеныма иркәләп кенә арыш коя башлый. Тәнем кош каурые белән сыйпагандай рәхәт кытыклана. Ләкин азактан кызыгы бетеп, мин аны биленнән кочып алам да, өстемә егам. Җәзилә бар көче белән кулымнан ычкынып тагы торып утыра. Ачылып киткән итәген тезенә үк кыстырып куя. Үпкәләгән сыман, битемә учлап арыш сибә.

— Менә сиңа! Укырга киткәч, шәһәр кызларына күзең төшеп мине ташларсың әле. Шәһәр кызлары алар чибәрдер: Актаныш базарында падручкем [1] генә йөргән кызлар шикелле, гел киенеп-ясанып йөриләрдер...

Минем күз алдына ни өчендер, ап-ак матур йөзе белән, техникумдагы секретарь апа килеп баса.

— Тач дөресен әйттең! — дим мин. — Шәһәр урамы гел Актаныш базары төсле. Кызлары да киенгән дә ясанган — агы ак чибәр, карасы кара чибәр. Бер эшләре юк, падручкем тик йөриләр. Алар ачмаган капка, алар кочмаган егет юк...

— И, миңа димәгәе, кочсыннар ла — бик ушым китте ди!

— Китәр дә! Әгәр синең апаң минем абыйга иргә чыкса?.. Ул чакны без кода белән кодача булабыз түгелме соң?

— Булса ни!

— Ә йөрергә ярый микән соң ул кода белән кодачага?

— Әллә тагы... Йөрмәсәң йөрмәссең.

— Туктале, син уйла.

Җәзилә чынлап торып уйга төште. Аннары түгәрәк йөзенә тулып чыккан үпкә белән:

— Син шул мине ташлар өчен сылтау эзлисеңдер әле, — диде дә, бу юлы бик нык авырттырып, битемә тагын бер уч арыш бәрде.

— И шул холкыңны яратам да инде: аяз көнне бөтерчек өермә сыман булып китә.

Мин аны тагы, бер кулым белән генә, биленнән кысып алдым.

— Җибәр! Холкы әйбәт кызларны шәһәрдә кочарсың.

— Менә сантый! — дидем мин.

Җәзилә кинәт моңсу гына елмаеп башын күкрәгемә салды:

— Безнең бөтенләйгә аерылышу көннәредер инде бу, Сирин...

---

[1] Култыклашып йөрү. Русчаның «под ручку» дигәненнән бозылган.

— Нишләп алай дисең әле?

— Белмим...

Мин ул әйткәннәрне йөрәгемә алмадым, шуңа күрә җыр сүзләре белән, уйнап кына җавап бирдем:

— Агыйделләр акмый торыр без аерылып киткәнче...

Ләкин Җәзиләнең күңеле белеп сизенгән: бу безнең чынлап та бөтенләйгә аерылышу көннәре булган икән.

Августның егерме бишендә мине Җәзилә, Тәрҗимә, Хәвадис абый, өчәүләп, үзебез йөк ташыган атлар белән иген илтә барышлый, пристаньга озата килделәр. Пароход кузгалганда Хәвадис абыйның Агыйдел буйларын яңгыратып уйнаган тальян тавышы Уфага барып җиткәнче колагымнан китмәде. Өйрәнмәгән башым шәһәр шау-шуына катышплар йөргәндә дә, шул моң, унсигез ел буе каныма сеңгән тын басу, болыннар һавасыдай, колагыма әллә кайдан агылып килеп керә иде дә, йөрәгемне әллә нинди сагышларга сала иде...

## 9

Мин Уфада Хәвадис абый торган квартирада яши башладым. Карточка системасының беткән елы. Шулай да ипине бик мулкытмыйлар — кулга биш йөз грамм. Дәрестән соң без үзебезнең буфет авызына өелеп, ипи сата башлаганнарын көтәбез. Кысылып чират басып торганда, миңа еш-еш карап алган сатучы кыздан оялып, гәүдәмне кая куярга да белми идем...

Ипи юк елларны да бер кимсенү күрми үскән очар кош булган икән мин үз авылымда!

Ләкин минем өчен иң авыры, үзәкләргә ярып үткәне бу түгел — уку иде. Группадагы малайларның күбесе (кызларыбыз биш кенә бөртек) җиденчене быел гына бетергән. Буйга миннән бик нык бәләкәйләре дә русчаны чатнатып сөйлиләр иде. Ә минем — шушы буем белән дә ык-мыктан узмый. Дөрес, үзләрен генә аерым әйткәндә, белгән сүзләрем дә байтак төсле, ләкин мин аларны бер-берсенә ялгый алмыйм. Ә инде укытучы сөйләгәндә зиһенем бөтенләй куе томанга төрелеп, бик аңлаган берәр сүз чыкса гына, бер як чите ачылып киткәндәй була иде. Ике-өч кабат сорап та, бөтен класс алдында кызарып-бүртенеп, сөяп куйган баганадай басып торганнан соң миннән сорамый да башладылар. Өмет өзеп кул селтәүләреме... дисәм, буем өчен генә стипендияләр түләп кеше исәбендә тотмаслар иде. Үшән колагы бераз русчага ятсын дигәннәрдер инде.

Тик аңардан ни куаныч! Мин барыбер — язын күтәрткән мал кебек ярдәмсез идем. Тәүлегенә туксан тапкыр: «Әллә ташлап кына китим микән техникумнарын, мин укымаудан гына илдә укыган кеше уннан тугызга калмас иде әле!» дип уйлыйм. Әмма акылның икенче чаты йодрык төеп тора: «Дәрес белмәвең бер оят булса, ташлап китүең — ун оят. Хәвадис абыең чире сәбәпле укый алмады. Ә син?.. Тап-таза башың белән, укуыңны ташлап кайтып, әнисенә син дә борчу салыр идеңме? «Укыган угыл атадан олы» дип, ул әйтә түгелме?..»

Шулай итеп, кимсенгән күңел тәүлегенә туксан тапкыр ташлап китәргә талпынса, кимсенмәгән күңелем туксан тапкыр «юк!» дип җавап бирә иде.

Мәгәр мине укуга бәйләп тоткан җеп болар гына да түгел. (Бәлки бөтенләй болар булмагандыр!) Мине иң тотканы — секретарь апа иде. Ул үзенең матур ак йөзе, нәфис, ябык гәүдәсе, ягымлы теле белән уйларымны көн саен били бара. Ул көн саен диярлек мине туктатып, ничек укуымны сораштыра. Әйтерсең лә шунда утырган кеше, минем

ничек укуымны белми! Минә шунысы бөгә иде башны. Мин оялуымнан битем каплап җир читенә качар хәлгә җитсәм дә, качып китә алмыйм. Алай гына да түгел, аның үзенең дә китми торуын, тагы бераз — тагы бераз гына! — янымда торуын телим. Йөзенә туры карый алмасам да, рәхәтләнеп, сөйләвен тыңлыйм. Аның сүзләре дә, абыемның тальян уйнавыдай, йөрәгемә саф тамчылы көмеш авазлар булып тама, — бусын инде мин русча белмәсәм дә аңлый идем.

Башта мин аңа кем дип эндәшергә дә кыймый йөрдем. Бик тә инде чын безнеңчә итеп «апа» диясем килә: кадере дә, хөрмәте дә... кечелеге дә бар бу сүздә, ләкин мин аның русчасын белмим. «Тетя» дисә-әм, үзебезнең Питрау базарында, гел татарча сөйләшеп, тозлы кыяр, тозлы кәбестә саткан марҗа апаларга малайларның «түтя-түтинкә» дип дәшүләре исемә төшә дә — бу ап-ак йөзле, ап-ак куллы секретарь апага «тетя» дияргә телем бармый. Шул «тетя»дән башка, безнең «апа»га тиң берәр сүз булырга тиештер бит инде русчада!.. Мин аның исемен дә беләм белүен: Любовь Васильевна. Тик мин аны нәкъ үзләренчә итеп әйтә генә алмыйм: минем татарчага ятып беткән телем, «Любовь» урынына, «Любуф» ди. Шуңа тагы «Васильевна»сын да китереп кушсаң, иреннәрем «б»гә ябышып ката да, әллә нинди «Любуббасилибна» килеп чыга.

Күпме көннәр ятладым мин бу исемне!..

Бер көнне ул мине техникум китапханәсенә алып кереп, һәр фәннән үземә генә берәр дәреслек яздырып бирде. Юкса барыбызга да китап җитми — кайсын биш кешегә берне бирәләр, кайсын бөтенләй бирмиләр, китапханәдә генә укырга мөмкин иде.

— Күп укы. Аңлап җитмәсәң дә укы. Ятлаганчы укы. Белмәгәненне сора. Укытучыдан сора. Миннән сора... — дип Любовь Васильевна киңәшләр бирде.

Аптыраш: мин аның һәр сүзен аңлый идем!..

Менә шулай чәмләнеп-үҗәтләнеп укуга керешеп киттем. Мин һәр көнне муенымa муенчак, аягыма тышау «салып», үземне үзем өстәл янына бәйләп куям — хуҗа торып электрын сүндергәнче, күзләремне ача-йома дәреслектән догадай сүзләр ятлап утырам. Ләкин сүзләр бер ятлауда гына мигә йокмый, күзем ачып җибәрү белән, яңа күргән авыр төштәй газап кына өстәп, әллә кая китеп бетәләр иде. Мин аның саен чәмләнеп ятларга тотынам — сүз арты сүз, җөмлә арты җөмлә... Күп вакыт мин, күземне шул йомган җирдән оеп китеп, таңда башым китап өстендә яткан килеш уянам. Әгәр миңа шул чак, бугазыма басып: «Йә уку, йә таш чоку!» дисәләр, мин чарасыз таш чокуны сайлар идем. «Уку — энә белән кое казу» дип, әйтсә дә минем кебекләр әйткәндер. Ике ай газап дәверендә ике генә көн — ОРС хуҗалыгына барып бәрәңге алганда гына бер язылып суладым. Кәрәк тотуларга ни җитә!..

Әгәр шунда Любовь Васильевна булмаса... Ул — күземнең көндәлек юанычы иде. Бәлки аның ире дә, баласы да бардыр, тик мин аларын уйламыйм — миңа аны күреп тору гына кирәк: сылу ак йөзен бер күрсәм дә, шул караңгы, ямьсез көннәрем ачылыплар киткәндәй була иде. Бер уйласаң, бу интегүләремнең барсы да гел аның өчен иде бит! Аны күргәндә йөзем кызармас өчен иде...

Мин өйдән хат алып торам. Хәвадис абый хат саен Раббани абый белән Тәрҗимәнең Октябрь бәйрәмендә туйлары буласын яза, «Син дә кайта алсаң икән!» ди. Мин — теләсәм дә кайта алмыйм. Чөнки быел пароход бәйрәмгә кадәр үк туктап бетте, ә юл өзегендә атлы юлаучы табам дип авыз да ачасы түгел. Шуңа күрә мин тизрәк санитар самолеты йөри башлавын көтә башладым: Хәвадис абый һәр елдагыча тубдиспансерга килергә тиеш булып, ул килсә, аннан бигрәк миңа күңелле булачак иде.

Җәзиләдән дә ике-өч хат алдым. Ул да Тәрҗимәнең Раббани абыйга кияүгә чыгасын, инде бөтен өй эчләре белән кубып, бер бәйрәмдә булмаганча, туйга әзерләнүләрен яза. Бу хәл аны бөтенләй каушатып җибәргән: «Болай булгач без нишләрбез? Ярармы соң?.. Тик барыбер мин сине яратам, гел уйлап, гел сагынам. Нигә бу минем туй түгел икән?» дигән.

Шунысы сәер, аның хаты минем күңелдә ни ярату, ни сагыну хисе уятмый: чәчләреннән җәйге болын, күзге арыш исе аңкып торган Җәзиләкәй баштагыча юксындырып, сагындырмый иде инде. Минем өчен ул хәзер — бер бала гына. Дөрестән дә, Җуәйрәттәй куенныннан яңа чыгып, ишек төбендә генә күзен ачкан уналты яшьлек кыз бала — чынлап та бала гына түгелме соң?..

Моңарчы мин, унсигезгә җитеп, Актаныштан башка базар, Җәзиләдән башка кыз сөймәгән малай, Уфадай зур каланы күрдем. Уфасында-бер Любовь Васильевнаны күрдем. Мин хәзер бер ни эшли алмыйм: әни әйтмешли, мин бер галдак Мәҗнүн идем.

Ләкин бу газаплы рәхәт көннәрем озакка сузылмады. Ноябрь башы белән военкоматка чакыртып, кулга повестка тоттырдылар. Мин инде районда да, монда да комиссия үткән — ни тышымда, ни эчемдә солдатка ярамаслык бер нәрсә дә юк иде. Без — группадан ике малай. Чишмәнеке, якын булгач, каралу белән кайтып китте, ә мин, туйга да кайта алмаган кеше, күзге Агыйдел бозыдай ябышып, шәһәрдә калдым.

Инде укуга йөрмәсәм дә була иде. Ләкин Любовь Васильевнаны күрми ничек торыйм!.. Миннән, капыл исләренә төшкәндәй, дәрес саен сорый башладылар. Сөйли алган кадәресен үзем сөйләп, алмаганын үзләре сөйләп, миңа тиз-тиз генә «өчле» дә «дүртле» куеп чыктылар. Монысы ни өчен кирәк булгандыр — күңел күтәрү өченме? — белмәдем.

Елга-сулар туңып, җир катырып җибәргәннән бирле авылдан Хәвадис абыйның килеп төшүен көтәм: ичмаса каңгырып яткан чит җирдән чит җирләргә киткәндә кул биреп калыр иде!.. Юкса мине кем озатыр? Инде мин ник укырга килүемә дә үкенә башладым. Мин бит үземнең быел солдатка алынуымны белә идем. Мирза абыйның: «Китсәң дә укудан китәрсең» дип, бик нык язганына була гына килдем шул...

Без ноябрь азагыннан да калмый китәргә тиеш. Урамнардан бер җырлап та әйләнмәгәч, солдатка китү — китү буламени ул.

Хәвадис абыйны көтеп борчылуым йөземә үк чыккан булса кирәк. Шулай инде: телне тыеп булса да, хисне тыеп булмый — йөзгә бәреп чыга. Любовь Васильевна минем боек күңелемне үзенчә аңлап:

— Егет кеше солдатка киткәнгә борчылырмы? — диде.

Мин аңа ватык-җимерек русчам белән борчылуым сәбәбе һич аңардан түгел икәнлекне әйттем.

— Детдом баласын да тәрбияләп озаталар, мине генә озатучы юк. Мин читтә ялгызым — ярга ташлаган балык шикелле, — дидем.

Минем: «Ат тоягы җитмәс җирләргә китәм бит мин хәзер!» дип тә әйтәсем килә — тик анысына телем юк иде.

Любовь Васильевна, эчемдә ни бар, барысын да үтәли күргәндәй итеп, елмаеп әйтте:

— Ә мине исәпкә алмыйсыңмени?..

Калган сүзләрен мин ишетмәдем. Җиргә төшә алмый җилпенеп очкан җиңел кардай, авырлыгым бетеп, идәнсез, стенасыз бер бушлыкта йөзә башладым.

Любовь Васильевна йомшак кына итеп беләгемә кагылды:

— Не унывай, джигит...

Шунда гына, әйләнгән башым туктап, баскан җиремә кабат кайтып төштем...

Любовь Васильевна бер тәнәфестә мине читкә чакырып алды да, сәгать алты тулгач, Якут бакчасында көтеп торырга кушты.

Мин — тагын өч көннән китәсе кеше. Солдатка китәсе булгач, ноябрьныкына кушып, декабрь стипендиясен дә бирделәр. Мин инде Хәвадис абый килереннән өмет өзгән: врач кулындагы кеше, әллә ниләре килеп чыккандыр әле. Шулай итеп, каран торып бердән бер кешем Любовь Васильевна булып, техникумына да тик аны күрер өчен генә йөри идем.

«Колагым ялгыш кына ишетмәде микән?.. Әллә төштә генә күрдемме соң?» дип, курка-шикләнә Якут бакчасына киттем. Айның соңгы җомгасы иде. Басуларга инде буразналарны тигезләп кар салгандыр. Инде малайлар да, сөңгеләре белән тәңкә ясый-ясый, көзгедәй буа өстендә боз шуалардыр. Ә шәһәрдә карны яуганда гына күрәсең икән — төшә дә эри, төшә дә эри. Аяк асты гел юеш — күңел дә шуның салкын дымын тартып тора төсле... Тиздән каз өмәләре башланачак. Тиз генә күреп булмас инде ул каз өмәләрен... Мин шулай, бер кемгә кирәкмәгәндәй, япа-ялгыз башым Якут бакчасының акбурга буялган агач капкасы төбендә басып торам. Йон оекбаш белән кирза итек кигән аягым да өши башлады. Мондый гына суыкта авыл җирендә аяк өши димени! Ә монда — өши. Авылымдагы җылы-йомшак җир түгел шул мондагы таш!..

Уем авылда йөрсә дә, күзем монда — гел бер якта, гел техникум ягында.

Сәгатьне белми көткәнгәме, миңа бер вакыт Любовь Васильевна бөтенләй килмәс кебек тоела башлады. Болай да кирәгем юклык хисе капыл көчәеп, йөрәгемә котып салкыны йөгерде.

Юк, бәхетем бетмәгән икән әле! Әнә ул, бөтен урамга бер үзе ямь биреп, коштай очып килә. Башына ак мамык шәл бәйләгән, кулына ридикюль тоткан иде. Салкын дими, пычрак дими һаман йөреп торган шәһәр халкы эченнән, бу тар тротуардан йөзе бергә тыгылып килсә дә, мин аны таныячак идем!

— Аз гына соңладым инде, үпкәләмә, — диде ул.

Мин бу бәхет, бу куанычтан очарга җитешеп, телсез калдым. Ә күңелем: «Мин барыбер көтәчәк идем. Менә бу трамвайлар туктаганчы, менә бу кешеләрнең дә бер арып егылыр сәгате җиткәнче, шәһәр уртасында ялгыз каен төсле бер-үзем калганчы көтәчәк идем!..» дип сайрый гына. Тик әйтергә сүзем җитми, җиткәне дә бер-берсенә ялганмый. Шулай да мин әйтәсе килгәнне гаҗәп тиз аңлый торган бер кеше иде ул Любовь Васильевна! Мин фикеремне бер кат ерып чыккач, беләгемнән тотып, рәхәтләнеп көлеп җибәрде.

— Чудной ты!..— Аннары инде бер тоткан беләгемне җибәрмичә: — Тунгансыңдыр, әйдә китик,— диде.

Чатка җиткәч, без трамвайга утырдык. Аннары «Совбольница» дигәндә төшеп, яңгырдан караеп бүрткән өйләр, коймалар буйлап киттек. «Совбольница менә шушы инде» дигәч, күп бармадык, бер кечерәк капка янында Любовь Васильевна туктады.

— Менә мин кайтып җиттем. Бүген мин сине өйгә чакырмыйм, әберсекөнгә сәгать биштә безгә кунакка килерсең. Йортыбызны онытмассың бит? На всякий случай менә адрес,— дип бер кәгазь тоттырды. — Значит, в воскресенье в пять часов.

Бу бәхетле минутларны мин хәзер бер ничек тә сөйләп бирә алмыйм. Ничек квартирыма кайтканмындыр, кайчан ятып кайчан торганмындыр — берсен-бер хәтерләмим. Җаным бу фани җирдә түгел, җиде кат күк өстендә иде. Ниләр генә уйлап бетермәдем мин ул көнне!.. Соңыннан үзем үк оялып йөрдем.

Шимбә көнне дә мин, йөрәгемне баса алмыйча, техникумга барып дәрестә утырып кайттым. Любовь Васильевна мине күргәч, оялып кына күреште дә, тизрәк китү ягын карады. Миңа бу нәкъ авылча, үзебезчә якын булып китте.

Якшәмбенең сәгать бишен житкерә алмый йөргәннән соң, сабырым бетеп, трамвайга утырдым. Төшкәч берәүдән сәгать сораган идем — дүртенче ярты гына икән! Тагы сәгать ярымны ничек үткәрермен?.. Каршы якка чыгып, кире трамвайга утырдым. Шулай ике кабат «кольцо» әйләндем.

Ишек ачарга Любовь Васильевна үзе чыкты. Күз күреп өйрәнгән киемен алмаштырып, эре чәчәкле озын күлмәк кигән иде.

— Бик вакытында килдең, әйдә чишен, — диде.

Минем өстә сырган фуфайка, аягымда кирза итек, шуларны салдым. Чишенгән җир такта белән генә бүлеп куелганлыктан, кухнядан бик тәмле аш исе саркылып чыккан иде.

Любовь Васильевна мине зур якты бүлмәгә алып керде. И ул андагы ямьне күрсәң!.. Бүлмә тулы әйбер: комод, көзге, пыяла шкаф, этажерка, сәгать — тагын әллә нәрсәләр. Шәрифулла абзыйлар өе нише генә идемени мондагы ямь! Түрдә чуклы зәңгәр чаршау эленгән тагы бер ишек бар иде, шуннан ап-ак чәчле бик матур бер әби килеп чыкты.

— Бу — минем әнием, — диде Любовь Васильевна.

Әйтмәсә дә, әнисе икәнлеге аермачык иде.

— Менә шушы егет инде мин әйткән. Безнеңчә исеме — Сережа.

Әнисе миңа диваннан урын күрсәтеп, ягымлы тавышы белән утырырга кушты. Мин утырдым. Любовь Васильевна комод өстеннән бәрхет тышлы альбом алып бирде. Аннары алар әнисе белән икәү кухняга чыгып киттеләр. Түр ишектән башын гына тыгып күзәтеп торган ике-өч яшьлек бер малай, йөгереп килеп, минем альбом актарганны карап тора башлады. Мин аңа күз генә кыстым да, бөтенләем белән альбомга йотылдым... Менә Любовь Васильевна — бәләкәй генә кыз бала. Менә ул тиз-тиз генә үсеп укырга китте. Менә — житкән кыз чагы. Чәчен ике яктан киртләч-киртләч ясап, башына берет киеп төшкән. Кашлары сызып куйган төсле, күз кабагы белән керфекләренә моңсу күләгә өртелгән. Фотосы шундый әйбәт-ачык — күзләренең һәр нуры йөрәкләргә үтеп төшә иде... Аннары, йөрәгемә ут салып, янында бер егет күренә башлады. Гел шул бер егет! Ахырда ул, солдатка әйләнеп, пилотка кигән килеш, бер үзе бер биттә Любовь Васильевнадан аерылып калды. Мин тагы кире кайтып, икесе бергә басып төшкән карточкага карап тора башладым...

— Бу — Миша. Мансур. Без бер мәктәптә укыган идек. Сугышка киткәч бер генә фотосы килде...

Мин күземне карточкадан алып, сизмәгәндә яныма килеп баскан Любовь Васильевнага карадым. «Ник шул егет урынында мин булмадым икән?!.»

Любовь Васильевна кулымнан альбомны алды да, комод өстенә кире илтеп куйды. Шунда гына мин табынга инде аш-су килгәнен күрдем.

...Ике көннән безне Уфа вокзалында эшелонга төяп армиягә озаттылар.

Без киттек. Көлдәй соры, болыттай юеш перронда, тик мин генә күргән кояш төсле, миңа ак юл теләп, бәхеттәй ак йөзле Любовь Васильевна басып калды.

Инде аннан соң күпме көз, күпме язлар үтеп, мине кемнәр, мин кемнәрне озатмаган! Тик һаман да, поездны күрсәм, яшьлегемнең Любовь Васильевнасы миңа шулай кул болгап кала төсле. Тик хәтеремдәге йөзе моңсулана бара, моңсулана бара. Мине озатканда елмаеп калган иде бит ул...

Шулай итеп, укырга дип аткан икенче угыбыз да ташка тиде.

Хәрби хезмәткә мин Казанга эләктем.

Без авылда «Казан каласы таш кала»... дип җырлый торган идек, чынлап та таш икән. Туганнан бирле телебездән төшмәгән, укыган һәр китапның эченә дә, тышына да язылган, ерак та, якын да Казан шул икән!.. Шул таш калада мин туган җиремнең йомшак җылысын тойдым. Любовь Васильевна озатып куйган сәгатьтән башлап, буранлы көндәй бер ни күрми барган юлыма кинәт төшкән якты нурдай булып китте ул Казан!

Хәрби антны иткәннән соң ике ай үткәч, мине үзебезнең отделение командиры чакырып алып, спорт белән шөгыльләнергә кушты. Хезмәттәге дүрт-биш ай эчендә мин турниктыр, бөҗрадыр кебек нәрсәләрдә шактый елгырлана башлаган идем. Командирыбыз шуны күреп йөргән икән.

Без башка отделениеләрдән дә байтак җыелдык. Һәм безне көн саен, мәҗбүри тактик занятиеләр төсле үк, спорт серләренә өйрәтә башладылар — һәр көн өчәр сәгать тир түгәбез. Тир белән бергә кирәкмәгән авырлыгым да сызып кына юкка чыкты... Мин гәүдәмнең һәр мускулын сизеп йөри башладым.

Яз башында гимнастика дигән хикмәткә беренче тотынган кеше — көзгә инде мин һәр снарядта тугызар балл җыеп өченче разряд алдым. Мине ярышларга йөртә башладылар. Иң элек үзебезнең гарнизонда, аннары офык киңәя-киңәя, соңгы елны инде мин округ күләмендәге ярышка барып, Куйбышевтан «беренче разрядлы гимнаст» дигән дәрәҗә алып кайттым.

Техникумда өч ай интегүем ярап куйды: үзебезнең замполит беренче елны ук минем уку мәсьәләсен кузгатып җибәрде. Миңа Казанның татар мәктәбендә экстрен тәртибе белән укырга рөхсәт иттеләр. Укучылар бер мин генә түгел — без бер унлап идек. Күп вакытым спортка китеп барганлыктан, миңа уку җиңел булмады. Шулай да иптәшләр ярдәме белән ун классны җиңеп чыктым.

Безне бик еш булмаса да театрларга йөртәләр. Әгәр инде гарнизондагы татар егетләрен җыеп, үзебезнең татар театрына да алып барсалар, ул көн безнең өчен олы бәйрәмгә әйләнә иде.

Хезмәт итүемнең соңгы елында тагы бер шатлык өстәлде: Казанга Мирза абыйлар күченеп кайтты. Хатыны — Нилүфәр җиңги Кырым кызы иде. Аркасына елкылдап төшкән куе кара чәчле, озын кара кашлы, «Кара диңгезме әллә бу» дип карап торырлык зур кара күзле, безнең якта мин күрмәгән бер чибәр иде ул. Әнисенең бертуган апасы сугышка кадәр үк безнең татарга кияүгә чыгып, Казанда төпләнгән булганнар. Ире сугышта үлгән! Хәзер инде Анифә апаның ике кызын да кияүгә биреп, бер үзе бер квартирада яшәгән көне икән. Квартиралары соцгородта иде. Мирза абыйлар шуңа кайтып төште. Абый, демобилизациядән соң үзе хезмәт иткән җирдә калып, хәрбиләштерелгән сакта эшләгән. Казанда ул милиция лейтенанты булып урнашты.

Мин, увольнение алсам, тиз генә аларга китәм. Кырымча пешкән ашлар ашап, чәйләр эчеп кайта идем. Алардан да бигрәк Нилүфәр җиңгинең Кырымча сөйләшүен рәхәтләнеп тыңлыйм. Сүзләре үзе гел безнеңчә сыман, тик әйтүен генә башкачарак әйтәләр — нәкъ әниемнең мөнәҗәт теле кебек иде. Алар да, безнең Актаныш ягы шикелле, «бармайым», «кайтмайым» дип сөйләшәләр икән. Шунысы якын иде йөрәгемә.

Октябрь аенда мин, өч елга бер ай гына тулмый калган хезмәтемне тутырып, казарма белән бөтенләйгә хушлаштым.

Мин туры абыйларга кайттым.

Минем кайту хөрмәтенә алар кичен мәҗлес ясадылар. Анифә апа

белән Нилүфәр җиңги чурбадыр, чибәрәктер кебек Кырым ашлары пешергән — бүлмә тулып борыч, суган, кызган май исе таралган иде.
Мирза абый ике рюмкага тигезләп кенә аракы салды.
— Әйдә, туганым! Синең шатлыктан бу. Синең дә ил алдындагы изге бурычны исән үтәп, исән кайтуың хөрмәтенә бер гөрләшеп утырыйк әле. Әйдә! Еллар имин булсын...
Мин хезмәттә бер грамм капмаган. Аракы түгел, тәмәке төтене дә эчмәде минем организм! Менә шуннан соң инде, — авыр, ләкин авырлыгын җиңгәч рәхәт хезмәттән соң, — җилкенеп берне эчеп куйдым.
— Менә шулай, апыкаем!.. Синең белән иркенләп утырыр көннәрне дә күрдек... Чынлап торып уйласаң, бөек шатлык түгелмени: бер анадан без биш малай туган, и — бишебез дә исән!.. Тик бер ояда гына түгел — бишебез биш таба таралганбыз. «Үскән чакта үскән идек тал тамырлары кебек, үсеп житкәч таралыштык кош балалары кебек» дигәннәре шушыдыр инде... Мин сугышка киткәндә сиңа — булса унике яшь булгандыр. Ә Әдрәнне күргән төсле дә түгел. Хәзер — ул да армиядә!..
— Төрекмәннең Кушка дигән җирендә хезмәт итә. «Хәвадис абый яткан ком чүлләрен күрдем инде» дип язган...
— Өйрәнгәнче бик авыр булыр инде: СССРның иң эссе ноктасы бит!
— Әллә сиңа хаты килмәдеме? Мин сиңа адресын язган идем лә...
— Хаты бар. Карточкасын да җибәргән!.. — дип Мирза абый комод өстеннән Әдрәннең фотосын алып килеп, өстәлгә куйды.
— Менә!..
— Бу — миңа да җибәргән фотосы иде.
— Тач син булып бара инде Әдрән дә... — дидем мин. Мирза абыйның әллә нинди куәт бәреп торган киңчә йөзенә карап алдым. — Әдрән ул — яшьтән үк төпле булып үсте. Зурлар акылы бар анда.
— Минем акылны тотмады әле әнә — укырга китмәде.
— И китмәячәк тә! Менә мин әйтте диярсең, армиядән туры авылга кайтачак. Аның җилеге җирдә.
— Булды, инандым! — диде абый. — Үз башы үзендә. Гомере буе аю кебек табанын имеп ятмаса ярый.
— Ятмас. Әдрән — башка!.. — дидем мин.
Мирза абый, күзләрен тутырып, яратып, миңа карап торды.
— Җә, инде үзеңнең планнар нинди соң, туганым? Укыргамы, әллә эшләргәме исәп?
— Белмим әле...
— Сиңа «белмим» дип торасы да юк. Син түгел мин берәр кечке мәктәпкә укырга дәрт итеп йөрим әле. Җиде класс бүген яраса да, иртәгә ярамаячак. Ә синең кулыңа кош үзе очып кунарга тора!.. Ун класс белемең бар, гимнастикадан беренче разрядың бар. Тот та кер физкультура факультетына. Теләмәсәң — башкасына кер.
— Быел булмый инде. Кайтып бер арыныйм инде бу өч ел күтәргән йөктән, — дип сүзне читкә бордым: — Мирза абый, җиңги белән, Анифә апа белән, үзегезгә дә бер кайтып китәргә иде авылга. Без димәсәң, әни бар бит!..
— Их, апай! Белмисең шул син!.. — дип Мирза абый бик озак уйла免 утырды. — Ярый инде, хәзер бар да көйләнде шикелле. Яренгә, алла бирса, җәйнең иң ямьлесендә бер кайтып килербез әле. Туган-тулпы, дус-ишне күрербез. Шулаймы, севгилим[1]? — дип ул җиңгигә карады. — Син дә бер безнең туган илләрне күреп килерсең. Кара диңгезе булмаса да, Агыйделе бар. Син сагынып көйгән кыялары булмаса да, ямь-яшел болыннары бар...
— Кунакны сүз белән генә сыйлайсың дәгилме, Мирза? — диде аңа Нилүфәр җиңги.

---

[1] Севгилим — сөеклем. Кырым-татарча.

— Их, шатлыгым да, кайгым да бит син минем!.. — дип Мирза абый Нилүфәр җиңгинең озын чәчләрен сыйпап сөйде. — Безнеңчә кыяны да алар кая диләр бит. Кая, кая... Кайда соң ул сезнең каягыз?..

— Болур, хатырлатма... — диде аңа җиңги.

— Булды, булды, хәтерләтмәйем. Әйдә алайса, Сирин апай, бер сайрашып утырайык әле. Дус табылыр, туган табылмас...

## 12

Иртән уянып күзем ачуга инде яктырган, өй эченә болытлы көн сорысы төшкән иде. Барысы да торып, Анифә апа эшкә киткән, Мирза абый көзге алдында кара чолгый мыегын төзәтеп утыра иде.

— Уяндыңмы, апай? Әйдә торып юын, — диде ул.

Сәгать унберләрдә без билет хәстәренә чыгып киттек.

Юлның төрле яктан өзелгән чагы. Актанышка самолет очмый. Аны көтсәң, җир туңганны көтәргә кирәк. Пароход йөрми. Поезд белән Свердловск ягына китсәм дә, Раббани абый кебек, авылдан авылга ат яллап, урман да болын эченнән җитмеш чакрым кайтырга кирәк. Безнең якның кара ләпегеннән аты да йөрмәс әле аның. Бердәнбер юл — Уфа кала. Хәвадис абый былтыр ук инде Уфадан безгә автобус җибәрделәр дип язган иде.

Шулай итеп, бердәнбер ышанычлы юл — Уфа. Хәтта бу юлларның һәммәсе дә безнең өй янышнан үткәндә дә, мин, ихтимал, туры юлны урау итеп, Уфа аша кайтыр идем. Юк, шәһәрен сагынудан түгел: ул минем күңелдә гел көз, гел шыксыз булып калган — минем Любовь Васильевнаны күрәсем килә иде. Мине озатканда хат яз димәсә дә, мин аңа бәйрәм саен, иптәшләрдән күреп, чәчәкле открытка җибәрә торган булдым. Башта аерым кәгазьгә язып карыйм, интегеп бетәм, аннары иптәшләргә күрсәтеп төзәткәч кенә, тырыша-тырыша чистага күчерә торган идем. Бу гадәтем русчага өйрәнгәч тә калды. Хәрби эштә, билгеле инде, барысы да русча. Мин дә, сөйләшми йөреп-йөреп кинәт теле ачылган бала төсле, русчага кинәт остарып киттем. Әлбәттә, язуы татарча кебек җиңел түгел, шулай да, инде иптәшләрдән төзәттермичә, хезмәтемнең икенче елында Любовь Васильевнага куш бит тутырып хат язып җибәрдем. Балаларча мактанасы килү дип әйтимме, «Менә мин дә русчага өйрәндем бит!» дигәнрәк бер уй яздыртты ахры. Җитмәсә фотомны да салдым. Ләкин үзенекен сорарга, теләсәләр нишләтсеннәр, кыюлыгым җитмәде. Открыткаларыма җавап булмаган шикелле, хатыма да җавап көтмәгән идем. Көтмәгәндә җавабы килде. Уңышларым өчен шатлануын язган, ә русчама «прямо молодец!» дип куйган иде. Ул көнне мин коштай очып йөрдем...

Безнең хат язышуыбыз шулай башланып китте. Шуңа күрәме хәзер, Уфа аша кайтып, Любовь Васильевнаны күреп китү теләге тыелгысыз калкып чыккан иде.

Без вокзалга барып җиттек. Самолетлар очмаганга бөтен кеше тимер юлда ята — вокзалның эче-тышы халык иде. Хәрбиләр кассасы үзенә аерым булып, бер сәгать эчендә билет эшен хәл дә иттем. Тирләр агып урамга чыктык. Мирза абый уңга-сулга карап алды да, «Әйдә башка җиргә» дип, мине кәкре-бөкре урам белән Кремль ягына алып китте. Без Болак буендагы «Закусочная» дип язылган бер ишеккә сугылдык. Монда иркен дә, аулак та иде.

Мирза абый йөзәр грамм аракы әйтте.

— Кабарга ни телисең?

— Минем ашыйсы да килми.

— Килер әле. Икра бик җилле була кабып җибәрергә, — дип өстенә кап-кара уылдык ягылган ике телем ипи алды. Шуларның барсына — ике йөз грамм аракы, ике бутербродка төп-төгәл ун сум акча түләде.

Стена буена күкрәк тиңентен такта сугылган иде, без шуның буена барып бастык.

— Тагы кайчан күрешәбез әле! Туйганчы бер күреп калыйм үзеңне, — диде Мирза абый.

— Инде авылга бөтенләй кайтмаска булдыңмени?..

Мин тагы нидер әйтмәкче идем, капыл киселеп, уйга калдым: чынлап та Раббани абыйлар өстенә кайтып төшсенмени алар? Өйдә болай да, без үскәндәге сыман, алты җан: Тәрҗимә җиңги белән ике балалары артты.

— Бөтенләй кайтулар булмастыр инде, апай...

Мирза абыйның бу сүзе, җилекләргә төшеп, күңелемне изеп ташлады.

Аннары чыгып киттек.

Килгәндәге төсле кайтканда да Кремльне карап үттем. Казан елгасының бистә ягыннан бу якка таба бик биек итеп сап-сары ком өеп килгәннәр иде. Бу — дамба булачак. Куйбышев ГЭСының су тибүе шунда ук житеп, әле без барган җирләр тоташ су астында калачак дип сөйлиләр, һич ышанасы килми иде.

Казан елгасын чыккач, Кәҗә бистәсе башланып китте. Мин тәрәзә аша бу җилле, болытлы көнне өшеп-караеп утырган агач өйләргә карап барам. Бу — гел авыл. Өйләре дә камышлы сазлык, болынлыклар эченә кереп югалган шикелле, тирә-юньдә сарыктыр, кәҗәдер утлап йөри иде.

Галәмәт зур таш өйләр салынып яткан бушлыкны үтеп, тимер юл астыннан чыккач, без трамвайдан төштек.

Кичкә тагын аш җиткерделәр. Кырымча пешерелгән үткен-зәһәр шулпадан күңелләрем ачылып китте.

— Аш лезетини кетирген — соганнен бибер, — диде Нилүфәр җиңги.

— Аш ләззәтен китергән — суган белән борыч ди, — дип Мирза абый үзебезчә кайтарып әйтте.

Тагы бер йөз грамм эчеп куйгач, төшлеккә менеп җиткән кояштай булып, «куй, ояттыр» дип әйтүенә карамастан, Нилүфәр җиңгине кочаклап алды. «Хәсрәтем син, бәхетем син, язмышым син...» дип сөйләнә-сөйләнә, шапылдатып аркасыннан сөйде. Һәм, минем алда беренче тапкыр, җил искәндәй сагышлы бер көйгә алар теле белән җырлап җибәрде:

— Сокаклардан мән китәйим,
Йол саңа олсун.
Агуларыны мен ичәйим,
Бал саңа олсун...[1]

Ахырын бик озын итеп сузып бетердә дә, сул кулы белән һаман Нилүфәр җиңгине кочаклаган килеш, уңы белән рюмкаларга аракы бүлде. Нәфсем артык күреп, мин баш тарттым:

— Кардәшең ния ичмәй? Кайным, безем севгигә ичмәйсеңмени? — дип җиңги миңа карады.

Нилүфәр җиңгинең, үз моңын тоеп, кинәт балкып китүе минем дә күңелне күтәреп җибәрде. Мин дә рюмкага үрелдем:

— Бу мәхәббәт өчен агу да эчәргә була!..

Ә төнлә мин поездга утырдым.

## 13

Юл озын. Әллә ниләр уйлап бетерә торган озын юл иде. Мин бу юлда күп уйладым. Солдат икмәген бушка ашау бетте. Бүгеннән үз икмәгем табарга тиеш — миңа хәзер шуны уйларга кирәк иде. Минем ун класс белемем бар. Гимнастикадан беренче разрядым бар. Хәзер берәр

[1] Сукмаклардан мин китим, юл сиңа булсын; агуларын мин эчим, бал сиңа булсын.

мәктәптә укыта алам. Я берәр җирдә тренер булып эшли алам. Иң кирәге — формадан язмаска кирәк. Тизрәк кайтып өйдә бер күренергә дә, кире Казанга китәргә булыр. Анда пединститут бар, аның спорт факультеты бар. Быел эшләп, киләсе ел институтка тәвәккәлләргә мөмкин иде.

Уйның чиге булмаса да, юлның чиге бар. Егерме алты сәгатьтән соң поезд, ниһаять, Уфага килеп җитте. Төн дип тә, таң дип тә булмый торган бер чак иде. Агыйдел күперен кергәндә Уфа тавы ярты күкне каплаган күкшел болыт төсле каршыга килеп басты. Өстендә шәһәр барлыгы да беленми: шәһәр әле иң тәмле йокысын йоклый иде.

Вокзал мәйданына чыккач, кая барырга да белмичә, юлыма каршы төшкән биек тауга башым чөеп карадым. Әле бик иртә. Әле таң карасы да бетмәгән. Мин борылып вокзалга кердем. Көчкә урын табып, күзләремне йомдым. Күз алдыма шундук Казан килде. Анда мин аңлап бетермәгән әллә нинди кайгысы белән Мирза абый торып калды, боек гүзәл Нилүфәр җиңги калды... Авылда инде телеграмманы алганнардыр. Бәлки әни дә бу минутта йокламыйча, мине сагынып көтәдер. Мин әле кайчан өйдә булам!?. Мин әле Уфада. Әле Любовь Васильевна да йоклыйдыр. Бөтен Уфа йоклаганда нишләп ул гына йокламаска тиеш икән!.. Өенә бару килешмәс, эшенә килгәнен көтәргә кирәк. Ничек каршы алыр икән ул мине?..

Яктыру белән халык та кими төште. Вокзалдан шәһәргә автобус йөри башлады. Ләкин ул мин барасы җиргә бармый — мин җәяүләп кенә паровоз ремонтлау заводы ягына менеп киттем. Бераз менәм дә, ял иткәндәй туктап, кара ярны юып аккан Агыйделгә карыйм. Инде тоташ зим ага — күзге Агыйдел аккургаштай авыраеп калган иде. Тау битеннән вокзалга таба яңа трамвай юлы салып төшә башлаган булганнар. Ләкин төшеп җитмичә туктап, хәзер рельслары тутыгып ята иде. Менгән юлым — шуның буйлап салынган сукмак кына. «Сукмаклардан мин китәем, юл сиңа булсын...» Күңелемә Мирза абыйның шушы җыры килеп төште дә, адымымнан һич калмыйча, тел очымда тик кабатлана башлады.

Шулай үземнең таныш та, якын да Ленин урамына килеп чыктым. Монда инде трамвай йөри иде. Ләкин минем әле вакыт бар, җәяү генә баруымны белдем. Җыр сүзләре дә, һаман өзелмичә, салмак адым көенә кабатлана иде: «Сукмаклардан мин китәем, юл сиңа булсын...»

Тугыз тулып дәрес башлану белән, йөрәгем дөп-дөп типкән хәлдә, техникум ишеген ачып кердем. Башта коридордан уңга, аннан — сулга... Любовь Васильевна бүлмәдә бер үзе генә иде. Мине тану белән: «Сережа» дип атылып каршыма килде. Ике кулын да иңбашыма куеп, башын күкрәгемә тигереп алды.

— Чын ир-егет булгансың бит! — диде ул. Дымлы күзләрен тутырып күземә карап торды. — Әллә кайтып кына төшүеңме юкса?

— Туры вокзалдан! — дидем мин.

— Поезд белән кайттыңмени?.. Боже ты мой! Әлегә кадәр вокзалда утырдыңмы?

— Әйе.

— Йокламагансыңдыр да әле мөгаен?

— Ничего, зыян юк, — дидем мин.

— Юк-юк, син хәзер үк безгә кайт. Кайт та, бик әйбәтләп ял ит. Аннан...

— Бик рәхмәт, Любовь Васильевна. Миңа бүген үк кайтып китү ягын чамаларга кирәк. Тубдиспансерга сугылып, абыйның да килүкилмәвен белешеп чыгасы бар. Мин монда сезне күрер өчен генә кердем.

— Китү турында тагын авыз да ачасы булма — үпкәләрмен, — диде ул. Тиз генә сумкасыннан ачкыч актарып алды. — Әни каядыр барам

дигән иде. Менә өй бикле булса, үзең ачып керерсең. Кыенсынып торма,— дип ихтыярыма куймыйча, ачкыч тоттырды.— Безнең квартираны онытмадыңмы әле?

— Оныта буламы, Любовь Васильевна! Күземне бәйләп җибәрсәгез дә табам мин аны.

— Ә үзең вокзалда утыргансың...

Шунда бүлмәгә мин белмәгән бер укытучы кергәч, Любовь Васильевна минем белән коридорга чыкты.

— Әни кайтып җитмәсә, үзең чәй куеп эч. Аннары абыеңны белешеп кайтырсың. Тик — бүген китәргә түгел. Ишеттеңме? Мин дүрттән дә калмам. Өйдә бул,— дип мине озатып җибәрде.

Трамвайга утырып, Ленин урамыннан борылу белән, кубесе бер катлы шул ук иске өйләр, дым эчүдән бүртеп карайган коймалар, шүрәле бармагыдай шәрә ботаклы биек алмагачлар башланып китте. Мин «Совбольница»да төшеп, Любовь Васильевналар урамына борылдым.

Әнә ул — аларның өе! Буявы беткән калай түбәсе дә, такта тышлыгы да күзгә күннән һич аерылмый — соры, шыксыз. Ләкин минем өчен аннан да сөйкемле өй Уфасында юк иде. Эчендә дә бер ни үзгәрмәгән: ике тәрәзә арасында шул ук комод, түр бүлмә ишегендә шул ук зәңгәр плюш чаршау, шул ук көзге, өстәл... Кичерәймәгән дә, зураймаган да — нәкъ мине солдатка озаткан, өч ел хыялымда йөргән, ә хәзер каршы алган җылы, ягымлы өй иде. Тик хуҗасы — җан җылысы булмагач, кинәт бу әйберләрдән күңелемә саркып кына моңсулык иңә башлады. Мин итекне генә салган идем. Кабат кидем дә, кеше күп йөргән шәһәр эченә йотылырга ашыктым.

Иң элек Хәвадис абыйны белешеп чыгарга кирәк иде. Әгәр ул монда булса, миңа тагы берничә көн торырга туры киләчәк, шуңа мин башта тубдиспансерга киттем. Абыйны барысы да белә икән: исемен әйтү белән сестралар сырып алып, мин алардан сорыйсы урынга, алар миннән сораша башладылар. Ярты сәгатем шунда калды.

Больницадан күңелем төшеп чыккач, Уфаның иң ямьле урамнарында да миңа ямь калмады: урам тулы кеше арасында мин ялгыз идем. Эзләп табып, автобусны белештем. Безгә йөри торганнары инде киткән, ә иртәгәгесен иртә белән килеп, шушында көтеп торырга куштылар.

Аннары кинәт ашыйсым килеп китте. Башта мин Сталин урамы чатындагы «Урал» ресторанына сугылдым, ләкин анда бик күп офицер утыра иде, ялт кына кире чыгып тайдым. Безгә ашханәсе дә бик житкән, һәм мин базар капкасы янындагы бер ашханәгә кердем. Монда барысы да авыл халкы — базарчылар иде.

Артымнан ук минем өстәлгә ике башкорт апасы килеп утырды. Өч ай укып китеп, Уфада беренче тапкыр башкорт күрүем иде. Шул ике апаның үзләренчә сөйләшүен тыңлап, сагышланып киткәнмен — гүя мин бу ашханәдә түгел, ә Шәрифулла абзыйларда икән, гүя мин аналы-кызлы Җүәйрә апа белән Рәҗимәнең «с» авазын сакау итеп сөйләшүләрен тыңлый идем. Авылга тизрәк кайтасы килүем тагы да көчәя төште.

Ашап чыккач эшем беткән иде инде. Әле сәгать бер генә. Вакытны ничек үткәрергә дә белмичә, игъланнар укый-укый шәһәр буйлап йөри башладым. «Октябрь» кинотеатры янындагы стена биеклек афишага «Тарзан» дип язганнар иде. Тышыннан ук көтүче чыбыркысы төсле урап-урап чират басканнар. Мин бу тамашаны исем китеп карап тордым да, китеп бардым: бу галәмәт чират торып кинога керәме соң кеше!..

Шәһәр ярыткан иде — Любовь Васильевналарга кайтып киттем. Ап-ак чәчле әнисе — Клавдия Михайловна әби мине шундук танып, улы кайткандай күрешеп, электр плиткасына чәй куеп җибәрде. Чәй

өлгерүгә Любовь Васильевна үзе дә кайтып керде. Бакчадан улын да ала кайткан. Йөгереп бүлмәгә кергән җиреннән туктап, ятсынып миңа текәлде. Төскә гел әнисе, тик чәче коңгырт та, йөзе кара-тут иде. Каешыма карап торуын сизеп, каешымны чишеп бирдем.

Любовь Васильевнаның кемедер кемгәдер шалтыратып, мин чиратын күреп кайткан «Тарзан»га билет алган икән, сигездәге сеанска җыена башладык. Любовь Васильевна эчкәреге бүлмәдә өстен алмаштырып, биек иңсәле пан-бәрхет күлмәген киеп чыкты. Әнисенең:

— Театрга барасызмы әллә? — дигәненә каршы:

— Кинода да кичке сеансларда өсне салмыйча утырып булмый — мунча була, — диде.

Күлмәге өстеннән ул төлке якалы, нечкә билле, бостон тышлы пальтосын киде. Минем өс алмаштырып торасы юк, шинелемне каптырдым да, без кинога киттек. Көндезгедән кинәт туңдырып җибәргән, трамвай тукталышы ягыннан безгә каршы йөзгә бәреп җил исә, аяк асты катып тайгакка әйләнгән иде. Капкадан чыгып берничә адым атлау белән Любовь Васильевна, шуып килеп, мине култыклап алды.

Икенче көнне иртүк автобуска китәсе урынга мин Любовь Васильевна белән техникумга киттем. Техникумның элекке, әле мин дә белгән физкультура укытучысы яңарак кына икенче урынга күчеп, аның урынына хәзер кеше эзлиләр икән.

— Барып сөйләшеп карыйк. Булмаса, берсекөнгә кайтып китәрсең, — дип Любовь Васильевна кичә кичтән үк мине бүгенгә китми торырга күндереп куйган иде.

Мин карышып тормадым. Кая инде ул карышу! Киресенчә! Шул урынга мине алмасалар, дөньясыннан бизәр дәрәҗәгә житеп, йокым да йокы булмады. Әнидән күчкән гадәттер: төшкә чынлап ышанмасам да, матур төш күрсәм күңелем үсеп, начарыннан кәефем китә торган гадәтем бар иде. Бүген мин әллә нинди саташулы бер кыен йокы эчендә начар төшләр күрдем. Шуңа иртән кәефем бик шәптән түгел: юкка калдым, мине ул эшкә барыбер алмаслар кебек иде.

Ләкин — техникумда мине чак күтәреп кенә алмадылар. Хәтта, бер ишегеннән кереп, икенчесеннән чыгып китүемә карамастан, шушы техникумда укыган булуыма тикле хуп күрелде. Директор шундук приказ басып кертергә кушты. Любовь Васильевна аны дәртләнеп пианино уйнагандай гына басып, директордан кул куйдырып чыкты.

— Котлыйм! — дип, кайнарланып кулымны кысты. Миңа калса ул миннән ким шатланмый иде.

Кайтып килер өчен бер атна вакыт бирделәр.

Икенче көнне җиде тулар тулмастан автобуска киттем. Барсам — өченче көнге сыман, урам чатында өелешеп кеше тормый, килгәне-берсе касса будкасына борын төртеп нидер укый да, кире китә. Мин дә, инде эшне сизенеп, шул игълан янына бардым. Безнең якка йөрү өчен Агыйдел аша понтон күпер генә булып, Агыйделдә боз тотар алдыннан ул сүтелә торган иде. Әле нәкъ шуны игълан иткәннәр: боз ныгымыйча автобуслар йөрүдән туктала диелгән иде.

Нишләп башыма да килмәгән соң бу минем... Шулай авылга кайта алмый калынды. Ә икенче көнне инде мин — үзем укып киткән техникумда физкультура укыта башладым.

## 14

Эшкә урнашып, квартир эзләргә дип авыз ачу белән, Любовь Васильевна үпкәләбрәк:

— Безне яратмадыңмени? — диде.

— Минем кыз туганнарым юк, мин кыз белән малайның туганлык хисләре ничек була икәнлеген белмим. Шулай да сез мине туганыгыз-

дан да болайрак күреп, кадер-хөрмәт белән кабул иттегез. Мин дә сезне яраттым. Тик...

— Нәрсә — тик?

— Бездә шундый сүз бар: хәерчегә якты чырай катсаң, ямаулык сорый, ямаулык биргәч, «бирәр иске сырмагыз да юкмы?» дип әйтә икән диләр. Шуның сыман, мин сезгә ничек итеп: «Сездә торыйм әле» дип әйтә алыйм ди!

— Чудной ты! — диде ул.

— Безне яраткансыз икән — калыгыз. Шурик та сезне якын итте, — дип Клавдия Михайловна әби мәсьәләне хәл итеп куйды.

Мин аларда яши башладым. Любовь Васильевна Шурыгы белән эчкәре бүлмәдә, Клавдия Михайловна әби залның иң түрендә, ширма корып, никельле караватында ята иде. Диван миңа булды. Беренче ял көнне үк без Любовь Васильевна белән универмагка барып, ул миңа урын-җир әйберләре сатып алды. Мин, Мирза абый биреп җибәргәнне дә тотып, инде бер тиен акчасыз калган идем.

— Зарплата алгач түләрсең, — диде Любовь Васильевна.

Алар миңа үземә аерым ашарга да рөхсәт итмәделәр.

— Бары бергә булыр, без кешедән аерым ашарлык бай яшәмибез, — диде Клавдия Михайловна әби.

— Көтүче малае кебек, «сездә ашыйм, сездә йоклыйм» килеп чыга түгелме соң?

Любовь Васильевна рәхәтләнеп көлеп җибәрде:

— Әни, син аның сөйләгәнен тыңла әле, сөйләгәнен!.. Каян таба диген шундый сүзләр?

— Безнең авылда һәр кем шулай сөйләшә...

Шуның белән сүз бетте. Без бүтәнчә квартир мәсьәләсенә дә, ашау мәсьәләсенә дә кире кайтмадык.

Бер ай эчендә тәмам үз кешеләр булып киттек. Иртән-көндез төрле вакытта ашалса да, кичке табынга барыбыз бергә утырабыз. Минем Уфада бер кешем, бер танышым юк, шуңа мин кичләрен күп вакыт өйдә уздырам — без өчәүләп кәрт уйныйбыз, патефон уйнатабыз... Яңа кино булганда Любовь Васильевна белән киногa барабыз.

Техникумда минем, программ дәресләрдән тыш, спорт секциясе бар иде. Мин аны көн аралаш сәгать дүрттән алтыга чаклы үткәрергә көйләдем. Ул көнне Любовь Васильевна белән эштән үк бергә кайтабыз. Ә башка көннәрне мин аны каршы барып ала идем.

Бераз вакыт үткәч, мин артыбыздан кемнеңдер күзәтеп йөргәнен сизә башладым. Ләкин Любовь Васильевнага әйтергә кыюлыгым җитми: әллә ни уйлавы бар. Мин аңа кем — иреме, сөйгәнеме? Янынннан кумаса, мин Мәҗнүнгә тагы ни кирәк?.. Әмма Любовь Васильевнаның үзенең дә, миңа сиздермәскә тырышкан саен борчыла башлавы күңелемә бик тиз килеп кагыла торган булып китте. Инде мин дә, аның кәефенә бирелеп, аркама терәлеп йөргән авыр күзне күтәрә алмый башладым. Ниһаять бер көн, эштән бергә кайтканда, ихтыярсыз артыма әйләнеп карарга мәҗбүр булдым. Безнең арттан, буксирга тагылган баржа кебек, зур кара гәүдәле бер кеше килә иде. Сүзем дә ихтыярсыз чыкты:

— Любовь Васильевна, безне кемдер күзәтеп йөри.

— Алла хакы өчен борылып карамагыз, — диде ул.

Без шактый тиз атлап киттек. Трамвай тукталышына җитәрәк мин тагы, теләмәстән артыма әйләнеп карадым. Теге кеше дә адымын кызулаткан — узып та китми, артка да калмыйча, күләгәдәй ияреп килүендә иде. Без сикереп менеп, трамвайга утырдык.

— Кем ул? — дидем мин.

Любовь Васильевнаның чырае качкан иде.

— Гафу ит, Сереженька. Урыны бу түгел. Бер сөйләрмен әле...

Лэкин вакыйга, Любовь Васильевнаның «сөйләрмен»ен көтмәстән, үзе ашыгып килде.

Җылы, йомшак кар явып торган декабрь киче иде. Нәкъ сәгать алтынчы яртыда Любовь Васильевнаны каршы алырга киттем. Минем өстә шинель, аякта итек: мин әле солдат киемен салмаган. Үзебезнең капкадан чыгып, күршенекенә җитәргә өлгермәдем, шулар капкасы төбеннән ике гәүдә аерылып юлымны бастылар. Мин аны-моны уйламыйча, юл сабарга итеп карадым. Юк, тагы кистеләр. Шунда мин берсенең, йөзенә караганчы ук, теге кеше икәнлеген таныдым. Йөрәгем сикереп тибә башлады.

— Юл бирегез, — дидем мин.

— Сабыр ит, егеткәем, ашыкма.

Яше бар иде инде моның. Буйга минем чаклы ук булмаса да, гәүдәсе таза, лэкин йөзе таушалган, бите ирен өстенә салынып төшкән иде. Аннары мин аның җәелеп үсә башлаган корсагына карадым. Юк, бу минем белән сугышырга килмәгән. Сугышырга булса — иптәше сугышыр. Яшьрәк тә, көчлерәк тә күренә, кулы кесәсендә иде. Мин шунысыннан секунд та күз алмастан:

— Сезгә миннән ни кирәк? — дип сорадым.

— Әйтәсе сүзебез бар... Тирә-ягында күпме яшь кыз! Ә син шул хатынга килеп бәйләнгәнсең...

— Минем сезне тыңлап торырга вакытым юк.

— Ничауа, Люба апаң көтәр әле. Безне дә көтә торган иде...

Мин шунда капыл йөрәгемнән кан качканын сиздем, битем ут янып, битемә кунган карлар бу булып күтәрелә башлады.

— Китегез юлдан,— дидем мин. Без инде күкрәккә күкрәк терәшкән идек.

— Без синең гимнаст икәнлегеңне дә, башкасын да беләбез. Тик шундый егет башың белән без йөргән юлдан йөрүең генә кызганыч...

Минем куллар икесен ике якка бәреп очырыр чиккә җитеп йомарланган — хәзер мине туктатыр көч юк иде. Мин кузгалу белән, икесе ике якка тайпылып юл бирделәр. Арттан мыскыл белән тел чарлап, шүрәледәй көлеп калуларын гына ишеттем:

— Һа-һа-һаһ!.. Көчең булса да, бездән калган белән тукланасың, үзең эшләп ашамыйсың икән. Һа-һа-һаһ!..

Гайбәт мина беренче кабат йөзен шулай күрсәтте, пычрак сүзне беренче кабат ирләр авызыннан ишеттем.

Техникумга барып кергәндә йөзем калмаган иде булса кирәк: Любовь Васильевна мине күрү белән коты очып:

— Сереженька, сиңа ни булды? — дип сорады.

— Бер ни булмады, Любовь Васильевна... — дидем.

Лэкин күңел әрнүен басар әмәл юк иде.

— Сиңа алдашу килешми, Сереженька. Әйт: теге очрадымы?..

— Үзе генә түгел, иптәше дә бар иде.

Любовь Васильевна курка калды:

— Ходаем, әллә сугыштыгызмы?..

— Юк, сугышмадык.

— Ул сугышырга да күп сорамас.

— Андый исәпләре юк иде сыман...

— Сугыша күрмә берүк. Әллә кемнәрен кушып, гарип ясап куя күрмәсеннәр.

— Борчылмагыз, Любовь Васильевна.

Ул бераз тынычлангандай булды.

— Гафу ит, Сережа. Мин бит сиңа «сөйләрмен» дигән идем, һаман суза килэм — миңа бик авыр аны сөйләве...

— Авыр булса сөйләмәгез, Любовь Васильевна. Мин аларның кем икәнен аңладым инде.

— Рәхмәт, Сережа. Синең йөрәгең саф. Шулай да, бер авызны ачкач, сөйләргә кирәктер. Күңелендә әллә ниләр калмасын... Юк-юк, алай димә. Минем дә күңелем бәлки бушар. Мин озак сөйләмәм... — дип Любовь Васильевна уйчан күзләре белән миңа карап алды. Аны бүлдермәдем, ул сөйләп китте.

— Сугыш чыгасы елны Мансур исемле бер татар егетен сөйгән идем. Без аны, русча гадәт белән, Миша дип кенә йөртә идек. Ул сугышка китте дә — югалды. Бер хаты белән фотосы гына килеп калды. Минем альбомда шуның фотосы инде. Анысын да кайда төшеп өлгергәндер. Кыскасы, безнең сөешү бер җәйгә дә сузылмады. Сугыш вакытын үзең беләсең — җинелдән булмады. Әгәр әни үзе укытучы булмаса, мин бәлки унны да бетерә алмаган булыр идем. Институтка керергә мөмкинлегем юк иде, мин эшкә урнаштым. Сугыш беткәндә шушы, әлеге урынымда эшли идем инде. Кырык бишнең көзендә безнең техникумда сугыштан кайткан бер солдат математикадан укыта башлады. Ул чынлап та солдат иде: сугыштан бер званиесез кайткан. Мәгәр математикадан бик көчле диләр иде. Шул минем арттан йөри башлады. Миннән үзенеке яшькә зур. Өйләнмәгән. Бигрәк тә кыюсыз иде инде үзе!.. Яшьтәш егетләр сугышта кырылып бетте. Кайтканнары да уналты-унҗиде яшьлек кызлар янында гына бөтерелә иде. Безнең кебек, егерме биш ягына киткән карт кызларга кем карасын. Кыскасы, озак ялындырып тормадым, алучысы барда чыгып калыйм дип, шул укытучыга чыктым. Без хәтта йөрмәдек тә. Сентябрьдә таныштык — октябрь бәйрәмендә туй ясадык... Ә кырык алтынчы елның маенда аны алып киттеләр. Сугышта күпмедер вакыт әсирлектә булган икән. Шулай да каты режимда түгел, янына күчеп барырга да мөмкин иде. Ул мине хат саен чакырып карады, ләкин мин бармадым. Мин Уфада туган. Ничек инде туып үскән дөньямны, карт әниемне ташлап, әллә кая күчеп китим дә, бала белән баракта яши башлыйм ди!.. Ул мине аңлады — чакыруыннан туктады бер вакыт... Хәзер инде өйләнеп, балалар үстереп ята. Кайтмады. Калды шунда....

Любовь Васильевнаның күзләреннән бөртек-бөртек яшь килеп чыкты. Ул күзен, борынын сөртеп алды да, сүзен дәвам иттерде:

— Аннары мин менә шушы бәндәгә кияүгә чыгып карадым. Исемен дә әйтәсем килми хәтта... Хайван, чистый зверь булды!.. Күкрәгемдә пәке эзләре бар. Ярый тайпылып калдым да, ярый калын пальтодан идем... Шуннан, үтергәнче дип, үзем куып чыгардым. Менә шуннан бирле бәйләнеп йөдәтә. Үз өйләре бар, әнисе бар. Юк, өенә хатын алып кайтмый — хатыннан хатынга йөри. Тамагын шулай туйдыра. Хәер, алып кайтканы да тормас иде. Эчә дә — сугыша. Күзе күгәрмәгән чагы бик сирәк. Минем арттан сагалап йөри башлады мы — беләм: тагын бер хатыннан чыгып киткән булыр... Менә шулай ул дөнья, Сереженька... Ирсез хатын хәлләре шулай...

Ул сөйләгәндә үк яшьләрен түгеп елый иде инде. Сөйләп бетергәч кульъяулыгын алып, битеннән, борын буйларыннан яшен сөртә башлады. Мин, барысына да гаепле бер кеше сыман, кыймылдарга да кыймый өстәл янында басып торам. Өстәлнең бу ягында — мин, теге ягында — ул. Үрелеп кенә ефәк чәчләреннән сыйпыйсы иде дә соң — йөрәгем җитми. Болай да инде мин аның ярасын ачтым. Мин фәкать:

— Елау килешмәс, Любовь Васильевна. Елап кына, үлгән терелеп, үткән борылып кайтмас. Күз яшьләрегезне бер нык кына итеп сөртегез дә, башка еламагыз. Мин әнинең кайгыдан елаганын күрмәдем,— дип кенә әйтә алдым.

Шулай дигәч, төнбоектай дымсу күзен күтәреп, миңа карады, яшь аралаш елмаеп:

— Дөрес әйттең, Сережа. Син хаклы. Еламыйк, — диде.

## 15

Декабрь уртасында бер нинди хәбәр-хәтерсез генә Раббани абый килеп чыкты. Кич белән эштән кайтып керсәк — ул утыра. Тартынып кына Любовь Васильевна белән күреште.

— Мин хәзер китәм. Менә братны гына күреп чыгыйм дип керүем. Өч елдан артык күрешкән юк...— дип аклангандай сөйләнеп алды.

Любовь Васильевна аңа кыймылдарга да ирек бирмәде.

— Бер кая да китмисез. Энегез янына килгәнсез икән — энегез янында кунып та китерсез,— диде.

Бер яктан — ул, бер яктан әнисе кыстап, абыйны күндерделәр. Абый алар алдында минем белән ни татарча, ни русча сөйләшергә белмичә, уңайсыз гына утыра бирде. Шактый олыгаеп киткән — маңгаена сыр сызыла башлаган иде.

Любовь Васильевна, өстен алмаштырып кухняга чыгышлый, сиздерми генә миңа ым какты. Артыннан чыктым.

— Сереженька, абыең килгәч, болай гына килешмәс. Бар, магазинга барып кайт.

— Нәрсәләр алырга?

— Тигезләрен сайлап кына бер өч селедка ал — атлантический булсын. Бер ярты кило копченый колбаса. Краковский дигәнен алма: әрчеп булмый. Бер ярты кирпеч арыш ипие. Эчәргә дигәнен — үзең чамала.

Мин киенә башладым. Тәмәке тартырга дип абый килеп чыкты.

— Кая барасың, апай? — диде ул.

— Монда, кибеткә генә.

— Мин дә барыйм алайса.

Любовь Васильевна безнең арттан:

— Бик озак йөрмәгез,— дип калды.

Капкадан чыгу белән без иркенләп сөйләшеп киттек. Өй хәлләрен сорашып алдым.

— Бар да исән-аман, сәлам әйттеләр...— диде абый.

— Нигә хәбәр итмәдең?

— Ә нәрсәсен хәбәр итәсең аның? Менә бит, килдем — таптым. Менә син үзең нишләп кайтмадың, шуны әйт?

— Хатка язган идем бит инде...

— Хат нәрсә ул! Без сугышта йөргәндә генә ана йөрәген хат баса иде... Хәзер аңа улының үзен күрү кирәк. Телеграмың килеп үзең кайтмагач, көчкә юатып тордык инәйне. Йокысыз калды. Әллә ниләр уйлап бетерде. Юл өзеге чак иде бит... Шулай ул, апай...

Йөрәгем кысылып куйды: абый да мине, Любовь Васильевнага бәйләп, «ана» сүзе белән шелтәли сыман иде.

— Җае чыгу белән кайтам, Раббани абый,— дидем мин.

— Бер күренеп китү кирәк, апай, кирәк. Безгә дә күңелле булыр.

— Уфага ни йомыш белән соң? — дип сүзне үзенә бордым.

— Урманга барыш, Йөрүзән леспромхозына,— диде абый.— Әртил белән барабыз. Бер елга договорлаштык әле. Бер ел эшләгән кешегә бер йортлык агач бирәләр. Үзең кисеп, үзең әзерлисең... Башка чыгарга да вакыт, апай. Төп йортта өелешеп яшәп булмас. Әни. Авыру энекәш. Әдрән дә кайтса...

— Хәвадис абый нигә синең белән килмәде?

— Аның хәлләр шәптән түгел әле, апай. Җәен бик матурланган иде. Артистлегеннән дә, тазарып, йөзенә бер төрле алсу нур йөгереп кайткан иде. Шунда авылдан авылга йөргәндә, карточкага да төшереп йөргән. Шактый акча эшләгән. Үзенә бик җилле кара постау костюм алып киде... Күзгә — тагын бетте. Октябрь бәйрәменнән соң больницага кергән иде, һаман ята. Уфасына бер генә дә барасым килми, ди.

Раббани абый махоркасын чыгарып тәмәке төрде. Бик озаклап, уйанып, шуны суырып барды. Бер арада тәмәке уты, эре төелгәненә эләеп, чытырдап янып китә иде.

— Уфада калып бик әйбәт иткәнсең, — диде ул ахырда. Кайтып китәвенә борчылсак та, Уфа тикле Уфаның үзендә мондый эшкә керүенә бик шатландык. Бөтен авыл сөйләде: бездән дә бер кеше чыкты, диләр... Инде икәү генә чакта сорыйм әле: бу квартирында... ничегрәк соң?.. Эби сөйләп алды: ире дә юк икән. Бергә дә эшләгәч, әллә... ниме?..

Мин абыйның урап сүз башлавыннан ук сизеп, бу сүз чыгасын көткән идем инде. Җавабын да әзерләп куйган идем. Тик җавап урынына үпкә килеп чыкты:

— Син дә җаныма тимә әле, абый!..

— Бетте. Бетте, апай. Үзеңә кара. Үзең беләсең. Мин синең янга кәефеңне кырыр өчен килмәдем. Сагынып, бер күреп сөйләшер өчен килдем. Их, апай!..— дип, барган җирдән бер кулы белән генә кочаклап, үзенә кысты.

Любовь Васильевна турында без башкача сүз кузгатмадык.

Ә иртән мин абыйны бөтен әртиле белән Кариделгә озатып җибәрдем. Ул көнне сүз гел безнең абыйлар турында гына булды диярлек.

— И бишегез дә шулай озынмы? Тазамы? — дип гаҗәпләнеп, тагы бер кат сорап куйды Клавдия Михайловна эби.

— Берсен авыру дип әйтте бит, — диде Любовь Васильевна.

— Анысын ишеттем, колагым каты түгел,— диде әби.— Мин «буйга шулай озынмы?» дип сорыйм.

— Барыбыз да шулай, Клавдия Михайловна, — дидем мин.

— Ходай бирсә дә бирер икән — бер анага биш ул! Нинди уллар бит әле!..

Абыйны шулай бер гаиләдәй сыйлап, хөрмәт итеп җибәргәч, Любовь Васильевна миңа тагы да якыная төште. Ләкин безнең арада, һаман элеккечә, минем ялгыз яратуымнан башка, бер ни юк. Кич ятканда бер-беребезгә тыныч йокылар теләп, һәр кайсыбыз үз урынына ята, иртән торганда үз урыныннан тора иде.

Әмма яңа ел алдыннан миңа сүзләр ишеттерә башладылар. Техникумга минем кебек быел гына килгән бер укытучы егет белән дуслашып киткән идек, беренче булып шул сорады.

— Сине Любовь Васильевна белән тора икән дип сөйлиләр. Ачуланма — шул дөресме?

— Кем әйтте сиңа аны?

— Барысы да сөйли.

— Кемнәр ул — барысы да? — дип усал итеп йөзенә карадым.

— Укытучылар инде...— Ул каушый калды.— Гафу ит, минем кеше сөйләгәнне генә соравым.

— Сөйлиләр икән — сөйләгән җирләрендә калсын. Минем сиңа бер кеше турында берәр сүз әйткәнем булдымы?.. Кеше үзен үзе кешедән яхшырак белә!..

— Кызмале, Сирин. Мин бит кешегә сөйләмим. Үзеңнән сорыйм. Моның ни гаебе бар? Менә — белдем. Инде сорамам. Мин болай да ышанмаган идем.

— Бел: әгәр мин Любовь Васильевна белән тора башлыйм икән — мин сиңа иң элек үзем әйтермен.

Бу сөйләшүдән соң күңелемә төшкән татсыз бер хис бетеп җитмәгән иде әле, бер көн урам аша су алып кайтканда, мин һич күрмәгән бер хатын:

— Су да ташыталармени, энем? Люба сынлы чибәр хатыннар шулай инде алар. Без түгел...— дип сүз катты.

— Сез кем соң? — дип сорадым мин.

— Мин сезнең сул як күршегез, — ди.

— Бик кызганыч! Алай булгач, сез дә минем кебек су ташый торга эйбәт егет кертегез, — дип китеп бардым.

Кайткач, үртәлеп-ярсып Клавдия Михайловна әбигә сөйләдем.

— Ах, сынок! — диде ул. — Бу көенә барсаң, яман авызлар дан әллә нинди яманлыклар ишетерсең әле!.. Дөнья күргән яхшы кеше ләр, авызлары пешә-пешә килеп, хәзер инде санап сөйлиләр, карап эц итәләр. Ә син яшь. Синең — эчеңдәге тышыңда. Люба яшь булмаса да шулай. Син менә Любаны эшеннән каршы барып аласың. Бу — табигый хөрмәт. Кешеләрнең бер-беренә иткән хөрмәте. Ә яман телләр моны, үз күңелләренә туры китереп, яманга бора: монда нидер булырга тиеш, ди Мин — ана кеше. Мин Любаны карынымда йөртеп тапкан. Мин аның холкын беләм. Сезнең арада, кеше сөйләрлек, бер нинди ярамаган эц юк. Шуңа күңелем дә тыныч. Ә син борчыласың. Үз күңелең үзенә мәгъ лүм, хәсрәт чикмә. Гайбәтне түбән, үзеңне югары сана. Иң олы кайгы— бала үлеме. Сугышта ике улым үлде. Шул ике кайгыдан соң миңа хәзер бер кайгы да кайгы түгел. Мин гайбәткә көлеп кенә карадым... Менә сиңа — чал чәчле бер карт укытучы киңәше.

Клавдия Михайловна әбинең бу сүзләре тәнемә җылы нурдай җәе леп, йөрәгемне җылытып җибәрде. Иелергә иткән башым туры калды.

Ярый, гайбәте — гайбәт. Тәкрек җәл түгел, йөзенә төкердем дә ди Ләкин аңардан миңа җиңелме? Мәхәббәттән җәрәхәтләнгән йөрәгемә дәвасы бармы?.. Әгәр мин — бүген я иртәгә Уфасыннан ук чыгып кач масам, миңа котылу юк: бу яшемә җитеп тә татылмаган эссе тойгы ми не мәхәббәт газабына салган иде. Мин ул газаптан качарга тырышма дым да — ләззәтем дә шул иде бит! Инде ничә вакыт икең бер өйдә яшәп, бер-береңнең һәр сулышын сизеп торганда, күзгә карап килгән мәхәббәттән качар әмәл бармы?..

Минем Любовь Васильевнага, тел тибрәтеп, хисем ачканым юк. Кү ңелем тулы сөю булса да, телемә сүзе якын да килми — шаярып әйтер гә дә йөрәгем җитми иде.

Ләкин йөрәкләребез сүзсез дә аңлашкан булып чыкты — без бер-бе ребезгә очар кош тизлеге белән якынлаша башладык.

Яңа ел җитеп килә иде. Кар иртә дә, күп тә яуды. Безнең урамның буеннан буена тротуар читенә кеше биеклеге кар өелгән. Без ап-ак кар яктысында Любовь Васильевна белән техникумнан кайтып киләбез Янымда ул булгач миңа рәхәт — күңелем дә кардай якты иде.

— Әйтергә дә онытып торам, Сережа: безне яңа ел мәҗлесенә ча кырдылар, — диде ул.

Табигый, «кемнәр?» дип сорадым.

— Безнең коллективтан түгел. Анда без яшьлек дуслары гына җые лабыз. Күп дигәндә бер ун кеше булыр.Синең үз планнарың юкмы?

— Минем нинди планнар булсын, Любовь Васильевна. Сезнең күзе гезгә күз атып торган кеше бит мин! Кушыгыз гына — җәя булып бө гелэм...

Ул, гадәтенчә, кычкырып көлеп җибәрде — тавышы җемелдәп торган зәңгәрсу кар өеме буйлап бездән алга таба йөгереп китте.

— Алай булгач, «барабыз» дип әйтәм. Юкса мин аңа, синең белән сөйләшмичә торып, үзеп кенә әйтмәгән идем.

## 16

Елның соңгы көне — декабрьның утыз бере килеп җитте.

Кыска көн бетеп, күптән утлар алгач, без киенеп-ясанып кунакка киттек. Яңа ел алды кичендә генә ява торган күбәләк кар ява. Йөрәгем дә шушы кардай җилпенеп, нидер көтеп, яңа елның үзе кебек күренгән ямьгә — кичәгә очадыр төсле иде.

И гел шушылай яңа ел кичәсе булып торсын иде дә, Любовь Васильевна белән гел менә шушылай — гел янәшә барасы да барасы иде...

Без, киемнәргә кунган кардан ап-ак булып, җәяү генә, ашыкмый гына барабыз. Октябрь революциясе дигән урам буйлап азагына хәтле төштек тә, биек күпердән чыгып, Иске Уфага менеп киттек. Аннан сулга борылып — тагы бардык. Бу тирәдәге өйләр сугышка кадәрге төзек авыл өйләре сыман иде. Без дә шуларның берсенә — каралты-куралы, бакчалы бер өйгә җитеп туктадык.

Кунакларның ашыкмый гына җыелган вакытлары иде. Любовь Васильевнаны кочаклап алдылар. Яшьлек дусты өенә килгәч, шундук үз кеше булып, биленә алъяпкычлар бәйләп, булыша да башлады. Җилкенеп йөрүләренә хәтле гел яшь кызларныкы сыман иде. «Синә күңелсез түгелме?» дип минем яннан да урап китте. Аны күреп, гәүдәсенең һәр җиренә карап калганда, миңа нишләп күңелсез булсын ди!..

Сәгать ун тулгач без табынга утырдык. Любовь Васильевна колагыма әкрен генә:

— Сереженька, син мине кара инде: минем тәлинкәгә салаттыр-нидер сал, — диде.

Мин мондый табыннарда утырган түгел, — шунда гына мин башка ирләрнең, кашык-чәнечке уйнатып, янындагы хатыннары тәлинкәсенә салкын ризык салып утыруларын күрдем. Мин дә Любовь Васильевна алдындагы өлеш тәлинкәсен алып, кырдан башак җыйгандай, төрлесеннән җыеп чыктым.

Аннары һәммәсе рюмкаларын күтәрде. Минем, бүгенге хәлдән болай да исереп, аракыга йогынасым да килми иде. Шулай иттем дә. Ләкин:

— Юк инде, юк. Беренче рюмканы бездә алай куймыйлар, — дип табыны белән миңа ябырылдылар.

— Гафу итегез, кунаклар, мин эчмим, — дип кулымны күкрәгемә куйдым.

Любовь Васильевна да мине яклап:

— Өч ел күрмәгән абыйсы килеп тә — бер грамм капмады, — диде. Ләкин кунаклар тыңларга да теләмәде.

— Яңа ел табынында бераз гына тотарга ярыйдыр инде...

— Тавык та эчә...

Табында ике ялгыз хатын да бар иде, шуның берсе, Любовь Васильевнага үпкәләгәндәй:

— Егетең безне хөрмәт итми икән, — диде.

Ахырда Любовь Васильевна:

— Азрак булса да эч инде, Сережа. Барысы да сине көтә, — дип миңа карады.

Инде дә чара юк иде — мин рюмканы бик озаклап, шулай да яртылаш кына эчеп куйдым.

Моннан соң инде мине артык кыстамадылар. Ә сөйләшеп-танышып киткәч бер ир:

— Шулай, спортсмен кешегә бу нәрсә дошман инде,— дип, кыстауларга нокта куйды.

— Йөз грамм алкоголь ярышка әзерләнгән спортсменны утыз алты сәгатькә формасыннан чыгара, — дидем мин.

Ләкин шунда ялгыз килгән ике хатынның берсе, бик телгә беткәне, күзенә шайтан чыгарып:

— Кадерле кунаклар! Әйдәгез Любовь Васильевна белән Сережага күп бәхет, рәхәтләр теләп, бу рюмкаларны төбенә кадәр эчеп бетерик әле!.. — дип тост әйтте.

Ни өчендер барысы да кул чапты.

Миңа бу мәҗлестән дә ямьле табын, бу кешеләрдән дә чибәр кунак булмас шикелле тоела башлады.

Кай арада уникe җиткәндер, Кремль куранты суга башлагач, барыбыз да аягүрә басып, юка читле стаканнарны зыңлатып шампань күтәрдек.

— Яңа еллар котлы булсын!..

— Бәхете белән килсен!..

— Озын-озак яшәгез!..

Мин, уң кулыма бокал тоткан килеш, сулы белән йомшак кына итеп — беренче кабат! — Любовь Васильевнаны биленнән кочып алдым.

— Сезнең бәхет өчен!..

— Сезнең тулы бәхет өчен!..

Без бер-беребезнең күзенә тутырып карап эчтек.

Түшәмдәге зур ут сүндерелгән, почмактагы чыршы очында гына бер тонык ут яна иде. Бүлмә эче бөтен кешеләре белән сихри бер дөньяга күчкәндәй булды... Шунда патефон уйнатып җибәрделәр — яңа гына Яңа елы туган сихри бу дөньяга «Амур дулкыннары» килеп тулды. Мин солдатта иптәшләрдән ояла-ояла өйрәнгән, өйрәнгәч сөенеп туймаган, сөйгән вальсым иде бу!..

Любовь Васильевна, яшь кызлар төсле, шашып әйләнә башлады.

— Бүген кайтмыйк... Шушында калыйк... — дидем мин.

— Мин исердем... — диде ул.

— Ике рюмка «Хирса»дан кеше исерәме?..

— Хатын-кызга күпме кирәк!..

— Алайса кайтмыйбыз...

Ул минем яңагыма яңагын тигереп алды.

Тагын, тагын биегәч, без тагын өстәл янына утырдык. Эчә алганнар тагын эчте. Аннары тагы җыр башланды...

Безгә бәхетләр теләп тост әйткән ялгыз хатын шактый кызган иде — рюмкасын күтәреп минем янга килеп басты да, үтереп эчәргә кыстый башлады. Ләкин мин эчмәгәч, үзе бетереп эчеп куйды да, көтмәгәндә бәгырь тавышы белән:

— Любушка, син нинди бәхетле!..— дип кычкырып елап җибәрде.

Көчкә юатып, аны бүлмәгә кертеп яткырдылар.

... Сәгать бишкә кайтасылар кайтышып бетте. Хатын-кыз урын-җир хәстәрен күрә башлады. Любовь Васильевна мине бәләкәй генә бер бүлмәгә алып керде.

— Син шушында ятарсың, — диде ул.

Мин җан атып:

— Ә сез?.. — дип пышылдадым.

— Хәзер.... — диде ул. Һәм ут сүндереп яныма килде.

Шунда мин, үземә буйсынмаган бер теләк белән, аның татлы тәнен кочаклап алдым.

— Әйдә, гайбәтләре чынга әйләнсен!..

— Сөекле генәм!.. — диде ул. Эссе сулышы белән иреннәремә суырылды.

Аның сулышы гына түгел, бөтен күкрәге ут яна иде.

Һәм мин яңа елның беренче таңында, башымны югалтып, шул утка ташландым...

## 17

Сөю-сөелү бәхетендә очып кына йөргән көннәремнең берендә Хәвадис абыйны (инде килүенә өмет өзгәч) больницага китерүләрен хәбәр иттеләр. Күпме кереп, күпме шалтыратып йөдәткәнлектән, тубдиспансерда инде мине беләләр иде. Абый килгәннең икенче көнендә үк үзләре шалтыратты. Мин техникумнан туры диспансерга киттем.

Дүрт тулу белән, өстемә ак халат киеп, абый янына кердем. Ул ятып тора иде. Мендәрдән башы күренмәсә, кеше ята дип уйламассың да: караван өстенә одеал ташлаган төсле генә. Мине күргәч елмаеп, әкрен генә торып утырды. Мөлдерәмә зәңгәр күзләренә карау белән, тавышсыз гына йөрәгем елый башлады. Шул хәлемдә янына барып, как сөяккә калган иңбашыннан кочып алдым.

— Хәлләрең ничек соң, Хәвадис абыкай гынам?..

— Менә күрәсең инде хәлләремне!.. — диде ул. Аның шунда ирен-нәре тартыша башлады. Ләкин ул, иренен кысып, тамак төбенә килеп утырган яшен йотып җибәрде. — Түгелергә торган күз яшьләремне дә мин кеше алдында түкмим бит...— дип күз төбендә җемелдәп торган ике бөртек яшен сөртеп алды.

Мин көлеп:

— И абый, абый! Мин сиңа «кеше» түгел бит, — дидем. — Нигә килер алдыннан хат язмадың?

— Хат язарлык идемени минем хәлләрем!.. Җәннәт эчендә яттыммы, җәһәннәм эчендәме — белмәдем. Тәнемә кулың тисә — кулың пешәр иде, — дип елмайган булды. Йөзендә авызы гына торып калгач, көлүе дә күңелгә авыр иде.

— Берсе җитмәгән, тагы нинди чирләр кагылды соң?

— Шул «иске чабата чире» булды инде. Врачлар грипп диләр. Йөрәк таза булмаса, китеп тә бара идем...

— Йөри аласыңмы соң әле?

— Кая йөрү! Җанга гына хуҗа. Ярый инде — анысы үтте. «Үземнеке» генә китми. Чират китә, атап килгәне китми. Анысын, бик китәргә теләсә дә, җибәрмәбез инде!.. — дип Хәвадис абый бүлмәдәге иптәшләренә карап тагы елмайды.

«Шушы хәлендә дә елмаерлык көчне кай җирләреннән ала икән?» дип шаккатып уйлап куйдым.

Аннары без өй хәлләренә күчтек.

— Миннән башка һәммәсе дә исән-сау калды, — диде Хәвадис абый. Арабызда иң җор теллесе дә ул иде.— Тәрҗимә җиңги генә бер ара чирләп ала. Болай, авырганда да, телгә-тешкә таза үзе.

— Инәй картайгандыр инде?

— Әнине тәтәй кәгазьгә генә төреп йөртерлек аны!.. Больницаның ни икәнлеген дә белмәс инде...

Үзебезчә «инәй» дигәнемә каршы «әни» дип җавап биргәч, мин абыйның сөйләшүенә колак саласы иттем. Больницада гына ятса да, Уфа йогынтысы тигән — гел татарча сөйләшә иде.

— Ә Шәрифулла абзыйлар ничек яши, тазалармы?

— Таза-а!.. Бал абзый ул үлмәскә сәбәбен табып кына тора: инде кыш өстеннән суганнар үстерә башлады. Витаминны күп ди. — Шунда Хәвадис абый кинәт кенә миңа текәлеп карады: — Син Җәзиләнең Актанышка кияүгә чыкканын белә идеңме әле?..

— Бер язган идең бит.

Минут эчендә күз алдыма Җәзиләнең Агыйдел яры өстендә миңа зәңгәр яулык болгап калуы килеп басты. Аннары — быелгы яңа ел... Любовь Васильевна...

Хәвадис абый, тыны бетеп, тукталып торды. Күзе миндә түгел, еракта иде. Аннары ул сулышы җитмәс тавыш белән:

— Их, тазалыгын миңа биреп калдырган булса!.. Белер идем мин кадерләрен!..— диде.

Бу сүзе бәгырьләрне тырнап үтте — мин өнсез калдым. Ярый әле үзе коткарды:

— Мирза абыйлар ничек яши соң анда?

Теленнән «үлем» сүзе төшүгә сөенеп, тиз генә җавап бирдем:

— Мирза абыйлар яхшы яшь алар. Карап туймаслык яшиләр. Ул син Нилүфәр җиңгине күрсәң икән!..

Шуннан мин абыйларны сөйләп киттем.

Инде икенче кабатка сестра килеп, иңсәмә кулын тигезгәч кенә, ашыгып кузгала башладым.

Хәвадис абый:

— Икенче килгәндә миңа Тукай шигырьләрен алып кил әле,— дип калды.

Шул көннән алып һәр якшәмбедә Хәвадис абый янына килә башладым. Мондый көннәрне мин, вакыт булганда гына килеп, дежур аша әйбер-мазар гына биреп китсәм, якшәмбедә инде янына кереп, иркенләп утыра идем.

Ул мине сагынып, түземсезләнеп көтеп ала, больницада үткән гомерен дә мин килүдән — мин килүгә, атналап саный; ләкин аның өчен ул атна газаплы бер айга тиң булса, минем өчен атна юк: минем көннәрем эштә, иректә, мәхәббәт ләззәтендә җилдәй исеп кенә үтә иде.

Эш бетүгә мин Любовь Васильевна янына барып җитәм. Бүлмәсендә кеше булмаса, мин ишектән керү белән сикереп торып, каршыма килә, буема үрелеп, битемнән я иренемнән үбеп ала. Ә мин аны, ике кулым белән ике яңагыннан тотып, ике каш арасыннан үбәм. Үпкән саен әнием сүзе искә төшә: «Сөләйман пигамбәр улын яуга озатканда ике каш арасыннан үпкән, безгә бу шуннан калган» дип әйтә торган иде. Мин дә, Любовь Васильевнаны үпкәндә, үземне чал сакаллы Сөләйман пәйгамбәр дип тоя идем.

Өйгә кайткач без яңа ел кичә булмаган да төсле йөрибез. Ләкин мин Клавдия Михайловна әби күзенә карый алмыйм. Чөнки ул бу кадәр эшне сизми калырга тиеш түгел сыман,— кашын күтәреп, күзлек өстеннән бер карап куйса, битем яна башлап, күзем аска төшә иде. Тик, бәхетем, аның миңа булган мөнәсәбәте үзгәрмәде. Я ул бер ни белми, я белеп тә хуплый иде. Без аның белән буш сәгатьләрдә бик озаклап, нәсел-нәсәпләргә кадәр актарып, сөйләшеп утыра торган булып киттек. Ул үзенең гимназиядә укыган вакытларын, Крупская белән Калинин бабайны күргәннәрен сөйли. Ни генә булмасын, аның миңа шелтәсе юклык — сөюмне газаплы итми иде.

Ләкин вөҗданым газапсыз да түгел: башым-күзем белән мәхәббәткә йотыла барган саен, әни белән абыйлар ныграк искә төшә башлады. Алар ни әйтер?.. Минем бу хәл Агыйделгә аткан таш түгел — бер заман чыгачак. Раббани абый сизенеп китте. Хәвадис абый монда. Иң авыры аның беләчәге иде.

## 18

Күзләрне чагылдырып март кояшы күренә башлау белән, Хәвадис абый сагынуын сөйли башлады. Мин баргач, үз көенә генә, ниләрне сагынганын тезеп китә, кайвакыт исә мин гомер уема китермәгән нәрсәләрне китереп чыгара иде.

— Син бер вакыт, бик бәләкәй чагыңда, миннән: «Абыкай, кояшка мылтык белән атсаң, ни эшли?» дип сораган идең. Ә мин: «Тилгән сымак, җиргә егылып төшә дә, дөнья бетә» дип җавап биргән идем... Ә шул җәйне, эти тилгән атканда: «Кояшка тигерә күрмә!» дип елаганыңны хәтерлисеңме?..

— Мин этинең үзен дә хәтерләмим...

— Алачык тирәсе гел чирәмлек иде. Без синең белән шунда чебиләр саклар идек. Тилгәне дә күп иде ул вакытта. Берсендә эти, алачыктан берданкасын алып чыгып, өстә әйләнеп очкан тилгәнгә төзи башлады. Син шунда: «Кояшка тигерә күрмә!» дип елап җибәрдең. Тик эти тил-

тәнгә дә тигерә алмады — бик биек оча иде. Син аптырап: «Нишләп егылып төшми инде?» дип сорагач: «Канатын гына тишеп чыгып китте шул, улым» дип җавап бирде...

Без бәләкәй чакны безнең авылның түбән очыннан гына башланып киткән ап-ак каенлык бар иде. Бер баруымда Хәвадис абый шуны да исенә төшергән:

— Күзләр чагыла иде карасаң! Сугыш алдыннан кисеп, сугыш чыккач төпләп үк бетерделәр. Гомерлек утын әзерләп калгандай кыйландылар. Бала кабере төсле вак-вак түмгәкләр генә калды. Төшләремә керә шул каенлык!.. Ә син шунда шүрәле күрергә йөргәнебезне хәтерлисеңме?

— Чаукалыгын[1] хәтерлим, шүрәлесен — юк, — дидем мин.

Хәвадис абый, башын иеп, бик озак уйланып утырды. Уйларына мине дә ияртеп, инде булмаган да төсле тоелган балалык елларыбызга кайтарды.

— Ә мин синең маңгаеңа көлкәй[2] типкәнен хәтерлим, — дидем мин.

— Ат — куркытам гына дип, көлкәй — үтерәм! дип тибә икән ул. Мин читкә тайпылып калдым, тоягының очы гына тиде.

Мин абыйның маңгай өстендәге беленер-беленмәс җөенә карап куйдым. Ул сөйләвендә иде:

— Эти, алачыгыннан чыгып, ике куллап мине күтәреп алды... Әгәр шунда читкә тайпылмаган булсам, башым ярылып, әти кулында гына үләсем булган икән... — Ул тәрәзәдән тышка караган килеш уйланып китте. Ә тышта яз, кояш — күлләвекләр тулы нур иде. — Мин бит районда концертлар куеп йөргәндә Тукай шигырьләрен ятлап йөрдем. Тегәләкәй егете аны сәхнәдән бик матур итеп сөйли дә, җырлый да иде. «Тәндә җаным, чык та, тәңреңә юнәл, бар кайт кире!..» — Аннары кинәт, башыма суккандай итеп:— Минем дә гомер язгы кардай эреп кенә бара инде, Сирин... Бетә... Үлгәч, мине әти янына җирләгез, аның кыйбла ягы буш әле,— диде.

— Юкны сөйләмә!.. Күзгә күренеп савыгып килгәндә.

— Бетте. Мин болай гына. Менә, дәваланып чыккач, чүлмәктәге гөл кебек булырмын әле, алла бирса. Хәзер газитләрдә дә: «туберкулезны дәвалап була» дип язалар...

Апрель кергәч, бик калкып-әйбәтләнеп, Хәвадис абый күбрәк сәхнәдәш иптәшләрен сөйли башлады.

— Алар белән өч сезон йөреп, артистлыкка өйрәнеп беттем. Көн саен бер авыл, яңа кешеләр, уен-көлке. Анда мин чиремне дә уйламыйм. Иптәшләр дә әнә: «Кайчан кайтасың?» дип хат язганнар. Ай азагында чәчүгә төшәләр — безнең самай авылдан авылга йөргән чаклар башлана. Миңа беренче пароход белән үк кайтып китәргә кирәк...

— Алай ярсып, йөрәгең атып торма әле. Бөтенләе белән терелеп бет. Театрыңа өлгерерсең. Врачларың ни әйтер бит әле?

— Мин аларны беләм,— диде ул.— Менә бу юеш, алама көннәрне үткәреп җибәрсәм... Сине дә ялкыттым инде.

— Нинди ялкыту ди! Әлләниләр сөйләмә син миңа.

— Сизеп торам: синең күңелеңдә хәзер мин түгел. Үпкәләп әйтмәдем, ачулана күрмә тагын.

— Нишләп ачуланыйм ди. Беләм бит инде: кайтасың килгән дә — хәзер әллә ниләр уйлап чыгарасың...

— Йә инде үпкәләмә, авыру күңелгә ни килмәс...

Ләкин күңеле дөрес сизгән иде. Җан тынычлыгым юк иде минем хәзер.

---

[1] Төптән үсеп чыккан яшь каен куаклыгы.
[2] «Колынкай» дигәннән нәзегәеп үзгәргән.

Инде апрель башы. Ә минем күңелдә һаман Сигезенче март кичәсе.

... Мин Мирза абыйның җырын русчалатып Любовь Васильевнаның колагына пышылдыйм:

— Агуларын мин эчәем, бал сиңа булсын...

— Абыең җиңгәңне бик яратадыр — шундый җырлар җырлагач,— ди Любовь Васильевна.

— Бик ярата. Үлеп ярата. Мин дә сине үлеп яратам...

— Ник яраттың соң әле син мине, Сереженька!.. Мин синең өчен карт бит инде. Ун яшь бит — ун яшь!.. Чынмы соң бу яратуларың?..

Ул минем куенымда иде. Яңагымны битенә терәгән килеш, тыннарым кысылып әйттем:

— Сине яратуыма бер нинди киртә-кура юк. Өйләнешик без, Любовь Васильевна...

— Шул кадәр яшь аермасы булып та миңа өйләнер идеңмени, Сереженька?.. Чынлап та өйләнер идеңме?

— Риза булсаң — ике дә уйлап тормыйм!

— Рәхмәт, кадерлем... Гел шулай бер-беребезне яратышыйк кына. Яме, акыллым?..

... Моннан ары — икең бер өйдә яшәп — мәхәббәтне качып-посып, урлашып кына дәвам иттерү мөмкин түгел иде.

Җитмәсә, Клавдия Михайловна әби дә бер дә бер көн, уема да килмәгән җирдән, әйтә куйды:

— Ах, Сережа, Сережа! Башын әйләндерден бит син Любамның. Тәмам әйләндерден!.. Аның болай очып-талпынып йөргән чакларын күптән оныткан идем инде. Мактау кәгазе белән бишенче класска күчкән чагы диярсең!.. Тик, күгәрченем, әйт әле зинһар: Син Любамны яшьлек йөрәгең белән чынлап торып яратасыңмы, әллә... бер ирсез хатын итеп кенәме?

— Ни сөйлисез сез, Клавдия Михайловна! Ярату ялган буламени? Минем күземә Любовь Васильевнадан башка бер кем күренми хәзер. Колагым да — аның тавышыннан бүтәнгә — киез каплаган. Җир йотсын әгәр!..

— Ах, сынок, сынок! Синең мондый мәхәббәтең аны бәхетсез итәчәк бит!

— Мәхәббәт кешене бәхетсез итәмени, Клавдия Михайловна?..

— Тиң булмаганы — итә.

— Мин аңа өйләнәм, Клавдия Михайловна.

— Син бит әле яшь — бала гына. Синең яшьлегең — үзе бер бәхет... Кайлардан килеп тап булдың син Любакаем юлларына?..

Мартның соңгы көннәре иде инде. Чокырлардан чабып су аккан чак. Без ял көнне, вакыт табып, Якут паркына киттек. Инде өсләрдән кышкы кием салынган, Любовь Васильевнаның аягында биек үкчәле, кыска кунычлы резин итек, өстендә юка драп пальто, башында ак җиңел шәл. Парк эче әле гел ак кар — сукмаклары гына җебеп, караеп ята иде.

— Ә-эх, агачлардан инде яз исе аңкый!.. — дип Любовь Васильевна сузып сулап торды. — Сизәсеңме?

— Любовь Васильевна, бүген сезгә минем бик зур сүзем бар, — дип мин сүз башладым.

— Шуның өчен алып чыктыңмени?

— Әйе, шуның өчен.

— Сөйлә, акыллым.

— Любовь Васильевна, хәтерендәме? Син миннән Сигезенче март көнендә: «Миңа өйләнер идеңме?» дип сораган идең.

— Шул исеңдәмени әле?

— Бик нык исемдә!..

— Мин бит аны болай гына әйткән идем.
— Ничек — болай гына?
— Үпкәләмә, Сережа. Ялгыз хатын күңеленә ни килмәс...
Ул башын күкрәгемә салды. Без паркның иң якты урынына килеп чыктык — тирә-ягыбыз тулы кояш иде. Мин Любовь Васильевнаны үбеп алдым да, март кояшыдай җылы күзләренә карап, йөзенә пышылдадым:
— Әнә кояш, менә күзләрең шаһит — мин сине яратам — өйләнешик без, Любовь Васильевна...
Ул миңа, йөзе моңсулана барып, моңсулана барып, бик озак карап торды да, әйтте:
— Их, моннан ун ел элек миңа шушылай әйткән булсаң икән!.. Миша мине бер генә үпте. И шул — гомеремдә бер генә кызны бер генә үпкән егет мәхәббәтнең ни икәнен белә генә башлаганда сугышка китеп үлде... Ә син — минем соңгы мәхәббәтем! Их, гомерлек булса иде ул!..
— Өйләнешик... — дидем мин тагы.
— Өйләнешсәк — ул мәхәббәт бетәчәк.
— Нигә? Нигә?
— Их, акылсызкаем! Кара әле күз төпләремә — анда чәчтәй нәзек кенә җыерчыклар төшә башлаган. Әле мин аларны пудра белән каплый алам: һәр кем болай кояшка куеп карамый бит. Синең дә беренче кабат кына күрүеңдер әле. Тагын ун елдан соң инде мин аларны пудра сөртеп тә каплый алмаячакмын... Ә аннан соң — аңа кадәр житсә әле!— мин сиңа ярамый башлаячакмын. Мин кырыкта булганда син бит әле утызда гына буласың!.. Яшь чакны ирләр сукыр була. Өйләнеп, хатыны белән берничә ел торгач кына күзләре ачыла башлый. «Кара, тирә-якта күпме яшь кыз! Нишләп күрмәдем икән?» ди. Ә хатыны, минем төсле бер ун яшькә карт та булса?!. Юк-юк, ул кайгыны мин күтәрә алмаячакмын... Кадерлем, менә шушылай яратышыйк кына. Мин — син өйләнгәнче синеке!..
Анын яше тулышкан иде инде — мин күземне читкә алдым.
Бу көннән, бу сөйләшүдән соң минем алдагы көннәрем караңгыланып, иртәгә, киләсе елга дигән юлыма, сузылып, кичке шәүлә төшкәндәй булды.
Хәвадис абый нәкъ менә рухымның шушы хәлен сизгән иде.
Ләкин бу чарасыз хәлемне аңа сөйләп, аңлатып бирергә тартынам, кыенсынам. Ул авырып ятканда минем, башны-күзне ташлап, өйләнергә йөрүем килешеп үк бетмәс сыман иде. Кемне яратуым, я кемгә өйләнүем абый кулында булмаса да, киңәш сорау, әлбәттә, кирәк иде. Ләкин киңәш белән килсәң, иң элек — өйләнүгә һич каршы булмаган хәлдә дә — «кая, кем ул, күрсәт» диячәк иде. Ә минем Любовь Васильевнаны больницага китерәсем килми — күңелем тартмый: әллә нинди авыру йөзләр, өмете өзек күзләр күргәч, мәхәббәтнең яме китәр сыман иде. «Менә үзе чыгар, шунда күрер» дип, алга йөгермәскә булдым.
Хәвадис абыйны апрель азагында чыгардылар. Яз бик иртә килеп, карлар гөжләп кенә агып беткән чак иде. Егерме дүртендәме, инде Уфадан Казанга беренче пароход төшеп китте. Хәвадис абый анысына өлгерә алмады, икенчесенә калды. Без аны өчәүләп «май бәйрәмен бәйрәм итеп китәрсең» дип кыстап карасак та, җавабы «юк-юк» кына иде.
— Бәйрәм килер дә, китеп тә барыр, минем өчен генә Уфада туктап тормас, — дип берне генә кунды да, икенче көнне кайтып та китте.
Көн бик җылы, әсу шул кадәр күп — җәй көне җәһәннәм төбендә торган дебаркадер ярның иң югары билгесендә — вокзал рестораны тигезлегендә тора иде. Ул да нәкъ су өстендә сыман. Тәрәзәсеннән аргы яктагы, билдән суда басып торган карт тирәкләр күренә. Су буе салкын, пассажирлар күп түгел.
— Абый, син миңа фатихаңны бирмәдең бит әле, — дидем мин.

— Риза түгел дисең бит...
— Ә риза булса?
— Риза булмавы бәлки әйбәттер дә.
— Нигә?
— Өйләнү ул — икенә бер читлек ясау инде ул. Бу яшеңнән читлеккә кермәсәң иде.
— Абый, мин бит аны яратам!..
— Мәхәббәт ул елан авызына да кертә диләр, үзең кара инде, апай. Мин бер сүз әйтә алмыйм.
— Ярый алайса. Тик минем хәлне үзең генә белсәң иде.
— Борчылма, апай. Миндәге—кабердә булыр.
— Инде аерылышканда да сөйләмә әле шул каберне!..
Ул арада пассажирларны утырта башладылар. Мин Хәвадис абыйны каютасына кертеп урнаштырдым да, китәр вакыты җиткәч, хушлашып дебаркадерга чыктым. Абый да икенче кат палубасына чыгып басты. Пароход өзеп-өзеп өчне кычкырткач:
— Йә, күрешә алмасак бәхил бул, Сирин апай!..—диде.
Авызын чак кына ачып, көлгәндәге сыман итеп, керфек тә какмый минем күземә йотылды. Ә үзенең күзләреннән тулып яшь ага иде.
— Юкны сөйләмә әле, юкны сөйләмә!..—дидем мин.
Ул минем сүзне ишетмәде дә. Пароход түгел, мин китеп барган төсле тоелганда:
— Йә, бәхил бул!..—дип кулъяулыгын болгый башлады.
Пароход ераклаша бара, еракլаша бара — күземне томалаган яшь аша Хәвадис абыйны аермый башладым... Яныма дежурный килеп: «чыгарга вакыт» дип әйткәндә, озатучылардан тик мин генә басып калган идем...

## 20

Күңеле сизеп бәхилләшкән, күңеле сизеп елаган икән Хәвадис абый: бу безнең соңгы күрешүебез булды.
Озатканда ук эчем сыкрап калса да, әҗәл бу кадәр тиз килмәс дип уйлаган идем: менә бетте дигәндә дә, калкынып китә торган иде бит абый моңарчы...
Авылдан кайгылы телеграмма килгәндә, алмагачлар, өсләренә куе сөт түккән төсле, шау чәчәктә утыралар иде. Ә мин кара кайгы белән автобуска утырдым.
Ләкин хәсрәт минем зиһенемне дә томалаган икән: мин телеграмманың бирелгән көнен карамаган — бәлки карап та күрмәгәнмендер — ул кайдадыр тукталып, бер көнгә соңлап килгән иде.
Безнең якта мәетне, иртән үлсә, көндез күмәләр. Болай да инде Хәвадис абыйны, мин кайтмасмы дип көтә-көтә, астына бозлар куеп, бер тәүлек тотканнар. Ә мин — күмгән көннең кичендә кайтып төштем.
Шулай итеп, пәрәвездәй нәзек күңелле Хәвадисебез үлгәндә, безнең дүрт туганы — дүртебез дүрт якта сибелеп калдык. Раббани абый урманда, Әдрән армиядә. Тимершәех абый аларга хәбәр дә иттермәгән: өч-дүрт көнсез кайта алмагач — ни файда? Ярый инде Мирза абый, туры Актанышка очып, Хәвадис абыйның үле гәүдәсен булса да күреп калырга җитешкән.
Иртәгәсен мәрхүмнең өчесен уздырдык. Без малай чакта ук сиксән яшендә булган Разетдин бабай кәҗә сакалын калтыратып бер мәкамсез[1] корьән укый башлагач, Хәвадис абый сүзе исемә төшеп, күңелемә җылы бер сагыш кагылып китте. Бер вакыт шулай, бик күптән инде, мәрхүм абый: «Корьәнне «Шахта» көенә укып буламы?» дип Разетдинбабайның һушын алган иде. Хәзер үзе булса, ни әйтер иде икән?..

[1] Мәкам — гарәп сүзе, «көй» дигәнне аңлата.

Мин юкта килен булып төшкән Тәрҗимә җиңги безнен өйдә бөтенләй үз булып беткән. Ләкин миңа аның, итәкләрен биленә кыстырып, олы гәүдәсе белән аш хәстәрләп, ике арада аш ташып йөрүе әллә ничек мәзәк тоела иде.

Әни, күзен сөртә-сөртә, Хәвадис абыйның үлемен сөйли:

— ... Уфадан кайткач, көнләп түгел сәгатьләп сызды, балам. Терелеп түгел, йөрәкләнеп кенә кайткан инде Уфасыннан да. «Бүлнис куйкыларында үлгәнче...» диде. Вафатына ике генә көн кала, дүшәмбедә: «Тукай яшенә дә җитми үләм инде, әни, — дип җылады. — Дөньяда исемем калырлык эш тә кыла алмадым ичмаса, үлемнән дә үкенечлесе — шул» дип башларын салындырып утырды. Яңа ел кергән төнне Җәзиләкодачаның ире асылынгач та бик нык әрнегән иде. Ике сүзенең берендә: «Нигә бу тап-таза кешеләр үзләренең газиз җаннарына кул салалар икән? Яшәүнең кадерләрен нишләп белмиләр?..» дип бигрәкләр дә уфтанган иде, балакаем.

Үләр көнне иртә торып, битен кат-кат сабынлап юды. «Чиста ак күлмәгемне бир әле, әни», диде. Сондыктан күлмәген алып бирдем. Гластугын бәйләде. Әртисендә йөргәндә генә кия торган кара кәчтүнен киде. «Кая болай бик иртә, базар көн дә түгел?» дип сорадым. «Китәм инде, әни...» диде. «Еракками?» мин әйтәм. Тик монысына җавап бирмәде. Шулай караватына барып утырды. Мин урын-җирен җыеп куйган идем инде. «Кая, әни, баш астына мендәр бир әле», диде. Мендәр китереп салдым. «Хәлем бетте, ятып торыйм әле» дип ятарга итә башлаган иде, кинәт ютәле кубып, кан коса башлады. Мин тиз генә базга төшеп, боз алып мендем: шуны вак-вак кисәкләп йотса, туктый торганые. Тик балакаем — башын гына чайкады. «Китәм... бәхил бул, әни...» диде дә, әкрен генә артына авып төште. «Ай алла!» дип тиз генә башын мендәргә куеп, аякларын караватка күтәреп салдым. Баш очындагы тастымалы белән авыз-борынын сөрткәләгәнче, китеп тә барды...

Җеназа укыганда Хәвадисемнең башына бер күбәләк килеп кунган. Китми ди, канатын селкеп тик тора ди. Моны Мәүләй карт сөйләде. Барыбыз да аптырадык ди... Зиратка да кергән бу күбәләк. Җәймәләрен чишкәндә юкка чыккан. Җеназадан кайткач, җәймәләрен килен юарга әзерләп куйды. Күбәләк юк бит әле. Ә бүген иртән чәй эчеп утырганда бит очыма бер күбәләк килеп кунды. Селкенергә дә куркам. Шуннан Хәвадисем яткан карават башына күчте. Мин карап тик торам. «И улым, улым, мин әйтәм, инде синең сөйләргә сүзең юк, рухың шулай күбәләк булып кайттымы?..» дип җылыйм. Шулай тик кенә торды-торды да, карават янындагы әнә теге тәрәзәдән кыйбла тарафка очып китте. Артыннан карап калдым — бер җиргә дә кунмады...

— Улың изге җан булыр, — диде бер әби.

— Кызлардан да болайрак әдәпле иде шул... Җир куеннары өчен генә үстергәнмен икән!.. — дип әни тагы күз яшьләрен сөртеп алды.

Икенче көн базар көн иде. Без базарга барырга булдык.

— Базар бетте инде ул хәзер,— диде Тәрҗимә җиңги.

— Бик сагындырган, барыйк әле, — диде Мирза абый.

Нәкъ теге вакыттагыча, бу юлы да Тимершәех абый үзенең атын бирде. Тик бу юлы елан-туры айгыр түгел (аягы сынып суйганнар), яшь чаптар иде. Без дә,теге вакыттагыча, бишәү түгел — икәү генә идек.

Авылдан шактый читтә — юл өстендәге зират турына җиткәч, мин атны шунда бордым. Сугыш чорында бөтенләй бетеп таралган, өстендә мал йөргән зиратны соңгы елда гына әйләндереп алганнар. Капкасын бармак юанлык тимерчыбык белән борып-борып бикләп куйганнар иде.

— Апайны күмеп чыккач, инде монда нәсел-ыруга кирәргә язмасын дип, үзем боргычлаган идем, — дип Мирза абый каты юан тимер чыбыкны тегәрҗеп урынына да курмичә, кире сүтеп атты.

Зират эче ялан кебек — им өчен бер генә зур агачы да юк: булганы сугыш чорында һәркем үзенекен кисеп якты. Биш-алты чардуган эчендә сәрби куаклары гына үсеп утыра иде. Коймалап куйгач, тездән печә үскән, шуның уртасында, Сөн борынындагы Пугач тавы төсле, Хәвади абыйның өр яна кабере калкып тора иде. Янәшәсендә — тип-тигез үлә баскан эти кабере... Без Хәвадис абыйның кояшка җылынган туфрагы алып, күлмәк изүеннән күкрәкләргә койдык та, зираттан чыгып, базар га киттек.

Базар юлы хәзер элекке сыман түгел, буп-буш иде.

Тузанлы юлдан җилдереп кенә авыл капкасыннан килеп кердек. Ик җил тегермәне, әлсерәп утырган ике кош сыман, юл читендә калды. Бе больница ягыннан — элек ерып кергесез базар капкасы төбенә бары туктадык. Әйләндереп алган коймалары исән, ат бәйли торган буй-бу баганалары исән, Шәрифулла абзый бал саткан лареклар да исән, ти базары гына юк иде. Булса кырык-илле кеше бардыр. Берничә урынд тозлы кыяр, кәбестә саталар. Ләкин кеше монда ни дә булса сатар алыр өчен түгел, ә йомыш белән бер-берсен күрер өчен генә җыелга Ике таш кибет каршысына бик зур ашханә салып куйганнар — кибеттә аракы алган-бере шунда кереп китә иде.

Мин элек гармуннар уйнап, җырлап, халык ял итә торган чирәмлек кә атладым. Сугыштан соң менә шушында ярты базар халкын җыег Хәвадис абый гармун уйнаган иде. Шулар искә төшеп, үкереп елый сым килеп китте. Биш туган арасында моңлы җырдай бер туганыбы бар иде — хәзер ул юк... Их, бүген инде тәмам беткән шул көнне кир кайтарып, уйнатасы иде Хәвадис абыйны тагы бер!..

Мин яшьләнгән күзем белән тирә-ягыма карап алдым. Әле яңа гы на кош кунып сайрар агачы да юк зиратта булган идек — бу да нәк шул зират төсле булып китте. Һәм без, авыр башларыбызны иеп, җи генә исеп уйнаган буш базар эченнән ат янына чыктык.

— Йә, күңелең булдымы инде, апай? — диде Мирза абый.

— Әйдә киттек... — дидем мин.

Шул ук көнне кич белән мин пароходка төшеп утырдым. Мирза абы исә, иртәгә самолет белән генә очарга булып, әни янында тагы бер ки куна калды.

## 21

Мин Уфага бөтенләй бушап, тилерер дәрәҗәгә җиткән сагыш белә барып төштем. Бер төн, бер көн,тагы бер төн буена, кайта-кайта уйла ныл, күңелем инде язмыш белән килешкәндәй булды. Миңа чыннан да Хәвадис абый әйткәнчә, ашыкмаска кирәктер? Мин әле карт түгел. Ми нем әле укыйсым бар... Любовь Васильевна да хаклы—ун яшь аермасы кая куясың!..

Ләкин кабат Любовь Васильевнаны күрү белән уйларымның һәм мәсе, уйсу җиргә таңда төшкән томан шикелле, күз алдында юкка чык ты да бетте. Әгәр шунда кулымнан алып: «Өйлән миңа» дисә—димәсе дә, ым гына каксын!—шул минутта аягы астында туфрак булырга әзе идем.

Шулай да мин өйләнешү сүзен бүтән кузгатмадым.

Май ае бик тыгыз килде. Мин һәр көн дәрестән соң, кичке сәгать си гезгә-тугызга кадәр, егетләремне техникум, училищелар күләмендә үтк реләчәк ярышка әзерләдем. Безнең егетләр спорт ягыннан, мин килгән че, физкультура техникумыннан кала, икенче урында булган, — ә физ культура техникумы ярышларда вузлар белән тиңләшә иде, — димә миңа шул урынны саклап калу гына түгел, тагын алга җибәрергә дә ки рәк иде. Элекке укытучыга рәхмәт: миңа яхшы малайлар калдырга

лэкин аларга үземнэн дэ өстэмэсэм, мин нинди укытучы булырмын икэн? Аннары минем үземэ дэ тезгенне йомшартмаска кирэк. Эгэр егетлэремнең җиде кат тирен чыгарсам, үземнеке ун кат чыга иде.

Мин суырылдым, ябыктым. Божрага менеп «тэре» ясый башласам да, җан көчемне туплый алмыйм: исемэ Хэвадис абый килеп төшэ иде. Шундый, ялгышу я ычкынып китү мөмкин булган иң авыр хэрэкэтлэрдэ мин Любовь Васильевнаны уйлый башлыйм. Аның мэхэббэте миңа көч бирэ иде. Һэм мин — миңа иң кирэге — үземнең спорт формасын җиңел саклап калдым. Э егетлэремнең һэммэсе разряд алды.

Моңарчы мин: «укытуымны дэвам иттерсэм, укуны исэ читтэн торып укырмын» дип ныгытып куйган идем. Лэкин бу вариант инде тормышка ашмаячак—мин хэзер бу техникумда кала алмаячак идем.

Любовь Васильевна белэн безнең бергэ кайтулар бетте: техникумда ямьсез сүзлэр йөреп, безнең арага инде эллэ кемнэр килеп кысылган иде. Любовь Васильевна уйчан моңсулык белэн йөри башлады, гүяки ул, үзе эйткэнчэ, кайчан да булса тукталачак мэхэббэтебезне бүгеннэн үк күңелендэ күмэ башлаган иде.

Мэсьэлэне Клавдия Михайловна эби хэл итте.

— Сереженька,—дип башлады ул бер көн, — үзең белэсең, без сине бик яраттык. Мин сине үз улым төсле күрдем. Ни эйтер идем дэ бит, эгэр кызым сиңа тиң булып, сиңа кияүгэ чыкса!..

— Ул миңа чыкмый... — дидем мин.

— Аңлыйм хэллэреңне, бик аңлыйм. Тик син дэ безнең хэлне, кызымның хэлен аңла. Берэү булса, ходай тэгалэ үзе биргэн дип, килэчэген дэ уйламас иде — синдэй егетне бэйлэп кенэ алыр иде. Лэкин минем кызым алай түгел. Ул мэхэббэттэн уңмады. Аңа ходай матурлык биргэн, тик ир белэн тигез мэхэббэт бирмэгэн. Ирлэрнең дэ матурлары шулай була... Син миңа ачуланма, Сережа: эшлэр болайга борылып киткэч, моннан ары без өчебез бер өйдэ болай яши алмаячакбыз...

Июнь уртасында мин эшемнэн расчет алдым.

Расчет алганның икенче көнендэ Раббани абыйдан хат килеп төште. Абый рус хэрефе белэн татарча яза белми: аның барлы-юклы дүрт классы латин хэрефлэре белэн иде. Үз гомерендэ хаттан гайре нэрсэ язмаганлыктан, калэмгэ күнекмэгэн, — чатлы-ботлы хэрефлэр белэн ул үзлэренең сал белэн кайтырга чыгуларын, егермелэрендэ Уфага житеп, Затон күпере янында туктап китэчэклэрен язган. «Вакыт табып төш», дигэн.

Затон күпере Уфаның Нижгород дигэн бистэсендэ иде. Мин, кайтуны кичектереп, сал төшүен көтеп тора башладым. Сал пароход түгел, аның иртэрэк тэ килеп житүе бар дип, бер-ике көн алдан Нижгородтан эйлэнеп мендем. Егермесендэ инде, тугыздан ук Затон күпере буена төшеп, ике-өч сэгать көтеп торганнан соң, Клавдия Михайловна эби генэ утырган җэйге караңгы өйгэ кайтып керэсем килмичэ, Агыйделнең комлы яры буйлап бистэ артыннан экрен генэ елга үренэ менеп киттем. Агыйдел Уфаны божра ясап эйлэнеп үтэ. Мин шул божра буйлап барам да барам. Битлэрем, муеннарымнан дымлы су җиле туктаусыз сыйпап-ягылып бара. Күзем гел алда. Лэкин сал күренми, каршымда — сузылып киткэн су да билгесез ярлар гына. Мин үзем дэ язмышымның билгесез яры буйлап бара идем шикелле.

Тимер юл зонасын да үттем. Инде сул ягымнан кыядай текэ, болыттай биек Уфа тавы башланды. Уенты җирлэрендэ сыерчык оясы кебек өйлэр сибелешеп утыра. Биредэ инде ком түгел — таш, сукмак. Инде миңа кешелэр дэ очрый башлады.

Э төш җиткэндэ Иске Уфа белэн ике арада торган бер кечкенэ пристань янына килеп туктадым. Күзем хэзер бөтенлэй Агыйдел үрендэ түгел, Иске Уфада иде. Димэк, мин Затон күпереннэн алып Сутула күперенэ кадэр ярты шэһэр эйлэнгэнмен. Шул күперне, шуның теге ягын-

дагы агач чиркәүне, күпердән менеп киткән урамны күргәч, яңа ялкын белән эчемнән сагыш, юксыну уты бәреп чыкты...

Шунда мин «Чегәнский» борылмасыннан, җай гына агып, сал килеп чыкканын күрдем. Борынындагы ике көсмәнгә дүрт кеше тотынган — йөри-йөри ишеп, борынны агым җаена каералар иде. Менә салның урта бер җиренә ясалган такта куышы,аннан соң инде койрыгы да килеп чыкты. Койрык көсмәнендә дә ике кеше иде. Шунда йөрәгем януына бик туры килгән җыр күңелемә килеп төште:

Салларга салып башымны, агыплар китәр идем...

Бу җырны безнең базарда күрше авылның «Хыялый» апа җырлый торган иде. Баласыз да, ирсез дә иде ул. Баласы булмаган. Шуңадыр ирен дә бала урынына күреп, бик яраткан дип сөйлиләр иде. Ә соңыннан, ире сугышта үлеп, хыялый булып калган. Без бер ни аңламый тыңлар идек шуның җырын... Мин шул «Хыялый» апаның хәлен менә яңа гына аңладым: «Салларга салып башымны, агыплар китәр идем...»

Ә нигә китмәскә!..

Ул арада сал якынаеп бетте. Мин пристаньга йөгереп мендем. Инде катер күперне ике якка аерып куйган иде. Сал, нәкъ шуңа турылап, мин басып торган пристань турыннан үтә башлады. Салдагылар бөтен көчләрен көсмәнгә салдылар. Борын көсмәнен тоткан дүрт кешенең иң тазасы Раббани абый иде. Мин:

— Раббани абый!.. Раббани абый!.. — дип кычкырырга тотындым.

Бөтен күзләре күпер аерылмасында булганлыктан, сал өстендәгеләр минем тавышны ишетмәде.

Мин пристаньнан чыгып, агым уңаена йөгердем. Су читендә буйдан-буйга машина тыгылган иде. Шуларны ерып дигәндәй түбән якка үттем. Ачык җиргә туктап, салның житүен көтеп тора башладым. Абыйларга катер да ярдәм итә: салның бу якка бүселеп, күпер өстенә килгән «корсак» өлешен каршы якка этәрә иде. Ахырда сал исән-аман гына күпер аерылмасын үтте. Моннан соң инде Агыйдел Дим тамагына хәтле туп-туры ага иде. Салдагылар да, көсмәннәрен ныгытып куеп, хәл җыярга туктадылар. Раббани абый, кесәсеннән алып, тәмәкесен төрә башлады. Мин, кулымны болгый-болгый, абыйга кычкырдым. Тавышны ишетү белән дүртесе берьюлы миңа карадылар. Абый шундук танып:

— Сирин!.. Әү, апай!.. — дип кул болгады.

Сал шундый якын иде — мин абыйның елмаюына кадәр күргәндәй булдым.

Аннары ул иптәшләре белән киңәшеп алгандай итте дә:

— Хәзер яныңа чыгам! — дип кычкырып, куышларына кереп китте.

Аннан өстен алмаштырып чыкты. Аннары бер иптәше белән койрыктагы көймәгә утырдылар. Минут эчендә дигәндәй көймә ярга житеп, абый минем янда сикереп төшеп калды. Мине корычтай кочагына алып:

— Нишләп әле син монда? Әллә безне көтеп тордыңмы? — диде.

— Мин инде өченче көн көтәм.

— Менәгаеш! Мин сиңа егермеләрендә дип язган кебек идем бит.

— Язсаң ни! Расписание белән акмагансыздыр ла?

— Почти што расписание белән. Салчыбыз бик оста туры килде. Егермесендә Уфада булабыз диде, и точно — бүген егермесе. Бүген төн кунып китәбез. Каридел бик котыру елга икән — чистый эт булдык. Азыгы да бетте. Әйдә, хәзер үк базарга менеп бәрәңгедер-нидер алыйк. Менә — иптәшләр мине шуңа чыгарды, — дип Раббани абый кулындагы капчыгын күрсәтте.

— Мин дә сезнең белән китәм, — дидем мин.

— Ничек?..

Абый су җилендә караеп янган йөзен миңа текәде.

— Мин быел Казанга укырга китәргә уйлыйм... Мирза абый да анда.
— Ни мени, апай: монда рәт чыкмадымени?.. Мин бит сине, техникум чаклы техникумда укыта дип,иптәшләремә дә мактанып сөйләгән идем.
— Мин инде расчет алдым, синнән хат алмасам, инде өйдә була идем — сине генә көтеп тордым.
— Бәй, ярар, алайса. Бергә-бергә күңеллерәк булыр, — дип абый шундук килеште дә.

## 22

Без пристань ягына кире барып, такси тоттык. Шәһәргә менеп, абый базардан ит, бәрәңге, кибеттән ипи, чәй-шикәр, тагын нәрсәләрдер алды. Әйбәтләп төреп капчыгына тутыргач, минем квартирага киттек. Әйберләрем җыелган иде инде. Шуларны да таксига чыгарып салгач, абыйны утыртып җибәрдем дә, кире өйгә кердем: Клавдия Михайловна әби белән әйбәтләп хушлашырга кирәк иде.
— Бу йортның нигезе начардыр инде: барысы да бездән — китә генә. Берсе дә таш булып төшми... — диде ул. Әллә нинди авыр күңел белән әйтте.— Любаны күрми дә китәсеңмени инде?
— Хәзер анда барам.
Тик Любовь Васильевна белән адәм рәтле хушлаша алмадым. Эшенең бик тыгыз вакыты иде. Директор аңардан, үзе әйтеп торып, нидер бастыра иде. Любовь Васильевна гафу үтенеп, бер генә минутка мине озата чыкты. Сал белән китәчәгемне әйткәч:
— Иа хода! Сал белән!.. — дип тыны беткәндәй булды.
— Сиңа булган мәхәббәтемне Агыйдел буйларына сөйләп, кайгымны чәчеп кайтырмын ичмаса... — дидем мин.
— Иә хуш, кадерлем — сөеп туймаган мәхәббәтем... — дип пышылдап, Любовь Васильевна миңа кулын бирде.
«Кольцо»га барып җиткәч, ике кулымның да буш икәнлегенә гаҗәпләнеп тордым. Нишләп болай соң әле бу? Өйгә кучтәнәч алып кайтырга кирәктер лабаса!..·Ә нәрсәгә салырга? Башым эшли башлап, иң әүвәл бер ларектан сетка сатып алдым.Кондитер кибетенә кереп конфет үлчәттем. Прәннеген дә үлчәтә башлаган идем — сал белән кайтачагым исемә төште: атна буена катып бетәчәк бит... Аннары, барысына да кул селтәп, эчемлек кибетенә киттем. Үземә түгел — абыйларны уйлавым. Иптәшләре дә гел суфи түгелдер: юл озын, эшләре авыр...
Мин сәгать бишләр тирәсендә генә сал туктаган төшкә барып җиттем. Агыйделнең бу өлеше, пароход-мазар йөрмәгәнлектән, нейтраль бер зона сыманрак иде. Шуңлык белән салны да читкә чыгармыйча, урта бер җиргәрәк туктатканнар. Раббани абый бер үзе аш пешереп утыра, иптәшләре Нижгород кибетләренә чыгып киткән иде. Әкрен генә кайнап менгән ит шулпасы исе борыныма ярып-килеп кергәч кенә, мин үземнең киселеп ачыкканлыгымны сиздем. Аруны әйтәсе дә түгел: көн буе җәяү йөреп, янбашларыма хәтле менгән иде.
Киткәннәр дә кайтып, барысы бергә җыелып беткәндә, борыныма тынгы бирмәгән итле аш та пешеп өлгерде. Табынны куыш эченә — ике такта гына сугылган өстәлгә әзерләделәр. Казаны белән аш кергәнче, өстәл өстенә аракы менеп утырган иде инде. Раббани абый бер кулы белән шешәнең ас ягыннан тотып, икенче кулының учы белән гөпелдәтеп төбенә сукты. Бөке яртылаш кына чыгып туктады.
— Менә бит, Раббани чама белән генә суга. Ә син чамасын белмисең. Синеке атылып түшәмгә оча да, күпме аракы түгелә,— дип бер салчы икенчесеннән көлеп куйды.
Алар алты кеше. Шәһәргә чыкканда һәммәсе кырынган — җилгә киселеп, кояшта янган чиста йөзләреннән кырыс тазалык бәреп тора иде.

Ялланып озатучыларыннан башкасы йөз граммны эһ тә дими эчеп куйдылар да, итле ашны каерып ашарга да тотындылар.

Раббани абый миңа да бер йөз грамм чамасы салып куйган иде. Аларга кызыгып, мин дә: «Су өстендә бер ни дә булмас әле!..» дип, стаканны иренемә терәдем.

Берсе ашавыннан туктап миңа карады:

— Энең агу эчә диярсең!..

— Бүлдермә, — диде аңа Раббани абый.

— Агу да инде! — дип икенчесе каршы төште. — Агу булмый нәрсә булсын!.. Чын агу!..

— Син шул агуның йөз граммыннан да исерәсең икән, — дип көлде беренчесе. — Авыллар ерак булса да, Октябрь бәйрәменә кунакка чакырам әле үзеңне. Расходы да юк. Йөз грамм аракы белән бер кап «Беломорканал» бирсәм — житкән. Аннары, бәйрәм ашы кара-каршы дип, яңа елга син мине кунакка чакырасың. И — отыласың. Һа-һа-һа!..

«Яңа ел» дию белән йөрәгем яна башлады. Юкка әйтәләр икән, аракы йөрәк януын баса дип!.. Киресенчә, сизелеп башка менеп житү белән — ныграк янарга тотынды. Ник эчтем дә, ник «яңа ел» диделәр?.. Янымда Любовь Васильевна йөргәндә минем һәр минутым тулы бәхет булган икән. Хәзер ул бәхет әллә кайда — кош очып житмәс жирләрдә калган төсле тоела башлады. Юкса Уфасы да әнә генә бит — йөгереп кенә менәсе!.. Тик ул таба инде юл юк — юлларны бүген кисеп төштем...

— Син нишләп, апай, бу дөньяда гамең юк кеше шикелле утырасың әле болай? Үзең ачыктым диден, үзең капмыйсың да,— дип Раббани абый мине сискәндереп бу дөньяга кайтарды.

Үзләре һаман, эчмәгән дә кебек, рәхәтләнеп сөйләшеп утыралар иде.

— Хәзер ашыйм, хәзер... — дидем мин.

Ә күз алдымда һаман, үрелеп кенә тотардай якын булып, Любовь Васильевна тора. Күземнән китсен, югалсын иде ичмаса...

— Әйдә, булмаса миңа да сал тагы бер йөзне! — дидем мин. Шул кадәр ачык йөргән зиһенемне томалар өчен миңа йөз грамм да житкән иде инде. Монысын эчкәч, зиһенем бөтенләй җәйге төн карасына әйләнеп юкка чыккан: салчыларны көлдереп, тизрәк йоклау ягын караганмын...

Мин кычкырып сөйләшкән тавышларга уянып киттем. Башта кайда икәнлегемне төшенми тордым: яткан жирем кыймылдый, хәрәкәтләнә, шуыша иде. Колагыма су чапылдавы килеп кергәч кенә исемә төште — салда бит мин!.. Торып, тышка атылып чыктым.

Раббани абыйлар инде, бар көчләрен куеп, ике көсмәнне дә агым үзәгенә җайлап ишәләр иде.

Мин сал читенә чүгәләп, башымны-битемне юып алдым. Тик Агыйделнең салкын суларына сикереп төшсәм дә, эчем тулы сагыш уты сүнеп-сүрелер төсле түгел иде. Шунда Уфа тавыннан кояш килеп чыгып, су өстен яктыртып жибәрде — суда чагылган йөзем, кырыкка сынып, вак дулкыннар белән чапылдап, сал читенә килеп кагыла иде. Мин торып, сал борынына киттем.

— Тордыңмы, апай? — диде Раббани абый.

— Кая, миңа нинди эш бар? — дидем мин.

— Бар, чәй куеп жибәр. Күперне ябар вакытлары житте, безне генә көтеп торалар, тизрәк чыгып калырга кирәк.

Мин кире куыш янына киттем. Утынны күп әзерләгәннәр — учак янына кисеп-өеп үк куйганнар иде. Каен кайрысын чыра итеп, ут тергезеп жибәрдем. Казан астындагы учак йөрәгем шикелле дөрләп кабынып китте.

Сал әкрен генә аккан саен, Уфа әкрен генә артка чигә башлады. Сәгать уннарда инде без крекинг заводы турысында идек. Ниһаять, Уфа

һаман өзелмичә килгән тау өстендә — кояшка якын бер җирдә балкып күздән югалды.

Эчемдә Уфа тавы чаклы сагыш кына торып калды.

Кыя тау кинәт бетеп, Агыйдел сулга борылды. Ерактан ук кычкыртып, каршыбызга пароход килеп чыкты. Без малайлар пароходларны тавышларыннан ук таный идек. Шуларның иң матуры — «Советский полярник» — дулкыны белән салга бәреп, чапкан аттай ашкынып узып китте. Артыннан кызыгып карап калдым: ул бер сәгать ярымнан Уфада булачак. Их, тагылыплар гына китәсе иде кире!..



## 23

Салчыларга читтән карап торганда гына алар ямь эчендә рәхәтләнеп баралар төсле икән. Ә чынында исә сал агызу кул битләрен генә түгел, арка-күкрәкләрне дә чиләндерә икән. Мин — яшьтән үк эшләп үскән. Беләк көче кирәк булган бер эш тә миңа ят түгел, җинем һәр вакыт сызганулы иде. Бу эшкә дә шундук җигелеп киттем — абыйлар белән бер тиң көсмәнгә тотындым.

Туры гына аккан җирләрдә без, алты метрлы бүрәнә көсмән сабын бәйләп куеп, үзе җае белән генә барабыз. Яр өстенә басып безне тамаша иткән малайлар кызыгып карап калалар. Беләм, чөнки үзебез дә шулай идек. Ләкин Агыйделнең туры җирләре бик аз. Ул, бөгә-бөгә сузган дилбегә төсле, элмәк ясый да элмәк ясый. Кистереп чыкканда бер чакрым араны ун чакрым әйләнеп килә иде. Шулай итмәсә Агыйдел булامени ул!..

Дуга сыман түгәрәк кенә әйләнми ул. Әнә, ерактан караганда, кыелып кына төшкән биек ярга төртелгән дә, шунда бетеп, яр астына коеп югала кебек. Барып җиткәч кенә күрәсең — ул кинәт, терсәктәй бөгелеп, я уңга, я сулга борылып китә. Андый чакны без, икешәр-икешәр булып, дүртебез ике борын көсмәненә, икебез койрыкка барып тотынабыз. Мин дә кушылып, җидәү булганлыктан, беребез алмашка йөри. Менә шунда чиләнә инде салчының күкрәге! Чөнки көсмән ул — ишкәк түгел, аны җиңел генә селтәп салып булмый...

Пароходлар белән юл сабышканда да шулай. Дөрес, без фарватерның үзәгеннән бармаска тырышабыз. Ләкин сал синең тырышуыңа бик буйсынып бетми: агымына, җиленә карап, фарватерның я уңына, я сулына сугыла. Шул сәбәпле пароходлар да юлны я уңнан, я сулдан сабып китәләр иде.

Абыйларга сал агызучының яхшысы туры килгән. Аны Каридел белән Агыйделнең һәр борылмасын белә дип сөйләделәр. Шулайдыр: мин моңа үзем дә ышандым. Шуңа без төннәрен дә курыкмыйча ага идек.

Торуы читен булса да, минем үземә төнге вахта күбрәк ошый. Көндездәгедән дә уяу булып, көсмән саен берәү торасың. Борын белән койрыкта — икесе ике башта — агым уйнавына тирбәлә-тирбәлә, ике фонарь яна. Миңа бәйләп куелган фарватер маяклары алардан көнләшеп каладыр кебек тоела иде.

Минем өстә солдаттан киеп кайткан гимнастерка белән галифе чалбар. Ә төннәрен мин иңемә шинельне салам: җәйге төндә су салкыны бик сизелә. Ярый әле, безнең бәхеткә, көннәр аяз тора. Мин йолдызларның кара су өстенә сибелгән шәүләләренә карап, уйланып китәм. Ләкин минем уйлар, ике баштагы ике фонарь шикелле, ике ноктада гына бик озаклап туктап тора ала. Берсе — Хәвадис абый, икенчесе Любовь Васильевна иде. Хәвадис абый инде — кабер читләрен тырнап еласаң да — кире кайтачак түгел. Любовь Васильевна белән безнең мәхәббәт тә шулай — кире кайтмаячак. Ул мәхәббәттән мин менә шушы сал агы-

5*

мы белән әкрен генә, beләкләрне сызлаткан авырлык белән аерыла барам... ерагая барам...

Мин башка уйлар да уйларга тырышып карыйм. Тик бер нәрсә дә чыкмый: башкага күчтемме — бар булган уем, әлеге йолдызлар кебек, суга сибелә дә бетә... Аннары тагы җыелып кайталар. Һәм, үзем дә сизмәстән, я Хәвадис абый, я Любовь Васильевна булып, сагыш белән күңелемне биләп алалар иде. Мин чыдый алмый көсмәнгә тотынам. Күкрәкне бер авырттырып көсмән сабына баскач кына, бар нәрсә онытыла: ярга бәрелмәү, пароходка төртелмәү уе гына торып кала иде.

Кулларымның атна эчендә кабарып тишелүе, арка-күкрәкләрнең рәхәт сызлавы үлем кайгысын басмаса да, мәхәббәт сагышын ярыйсы ук басты, дәвалады. Ул җәйге кара төннәрдә күгендә дә, сайлап куйгандай, гел эре йолдызлар гына яна иде. Шуларның чәчрәп Агыйдел төбенә төшүләрен, шунда чумып уйнауларын мин инде элекке гамьсез уй белән түгел, инде дөнья күргән бер кеше булып күзәтәм. Үземне дә, су коенган шул йолдызлар шикелле, сафлангандай хис итә башлыйм.

Юк, мин барыбер, Любовь Васильевнаны сөеп, ялгышмаганмын. Ул сөю барыбер гайбәт сүзе кебек пычрак түгел, әнә теге иң зур йолдыздай зур да, чиста да булган. Без аерылыштык, ләкин мәхәббәтем бер нур булып сүнми калды. Әнә, башка йолдызлар белән бер рәттән ул да яна...

Сал агызучы Гыйлаҗ агай ни кадәр оста булса да, безнең бу озын юлыбыз бер бәласез генә бетмәде. Лачын-Тауны үткәч бик ямьсез давыл кубып, сал астыннан илле тонна чылбыр сөйрәлеп баруга карамастан, төнлә белән безне сайга утыртты. Җил исеп давыллый башлаганда без уяу идек инде.Тирәндә калган койрыкка тиз генә якорь салып, барыбыз бергә борынга күчтек. Тик, күкрәк итләре суелганчы ишсәк тә, сал безгә буйсынмады. Без давылга җиңелдек. Ахырда, ничә кат бүрәнә аша аяк астыбызда нык җирне тойгач, хәлдән таеп көсмән төбенә аудык.

Әгәр давыл артыннан, гадәттәгечә, коеп яңгыр яуган булса, су күтәрелеп, без дә җиңел котылган булыр идек. Ләкин төн буе Агыйдел өстендә гарасат кына уйнады. Ярый әле, вакытында якорь салып өлгергәнбез, юкса койрык уйнап фарватерга аркылы килүе бар иде. Инде төн үткәреп, көндез буксир көтүдән башка чара калмады.

Иртән күрдек: каршы якның сөзәк тау битендә зур бер авыл тора иде. Мәҗбүри тукталыштан файдаланып, ике агай азык-төлек хәстәре белән авылга чыгып керергә җыена башлады. Юлга бирелгән акчаларының соңгысын Бөре шәһәрендә тотып, инде төбенә төшкәннәр иде. Кырып-себереп, кайсысы ун, кайсысы егерме сум биргәч, ике агайның берсе:

— Боларга ни генә алырбыз икән соң, егетләр? Ашарга алсаң — эчәргә җитмәс, эчәргә алсаң — ашарга җитмәс,— дип авызын ерды.— Алсак шул, бәрәңге алырбыз инде...

— Тукта, мин тагы бирәм — дип куышка кереп, тагын илле сум акча чыгарып бирдем.

Ике сәгать үттеме-юкмы, капчыкларына ипидер, бәрәңгедер салып, күтәренеп кайтып та җиттеләр. Суеп ук алып кайткан ике тавык та бар иде. Шундук казан асып җибәрдек.

Нәкъ каршыларына сал килеп туктагач, авыл ягыннан өч абзый, көймәләрен ярдан чишеп, безнең янга чыктылар.

— Сатлык юкмы, агай-эне?.. — дип туры эшкә күчте болар.

— Юк, сатлык юк, — диде Раббани абый. — Үзебез дә сатып алабыз.

— Бәлки теге... ни... табылыр. Сезгә нәрсә инде ул бер-ике кушма бүрәнә!.. Катерны да үзебез китерер идек...

— Булмый дигәч булмый. Әллә сез татар телен аңламыйсызмы? — дигәч кенә бик аптырап чыгып киттеләр.

— Әллә бер-ике кушманы җибәрәбезме соң? — диде шунда безнең бер агай. — Аның болай да бүрәнәләп таралып агуы мөмкин иде бит, шулаймы?..— дип Гыйлаҗ агайга карады.

Гыйлаҗ агай туры җавап бирмәде.

— Минем эш — салны тиешле урынына илтеп җиткерү. И — трос-ларын, чылбырларын үлчәп, кире кайтарып тапшыру, — диде.

— Анысы дөрес, бер-ике кушмадан сал кимемәс кимүен, шулай да дәүләт мөлкәтенә кул тигермик инде, егетләр, — диде Раббани абый. — Менә ярен үзебезгә алып кайтканда — анда инде теләгән кеше үзенең өйлек бүрәнәсен дә сата ала.

— Безнең бит буксирга түләрлек тә акча калмады,— дип әлеге агай тагы сүз катты.

Юк, аның да сал сатасы килеп тормый — сораучысы булган өчен генә кутыры кызган иде.

— Акчасын үзем бирермен, буксиры гына булсын, — дидем мин.

Көндезге сәгать уникеләрдә генә буш катер килеп чыгып, салны көч-кә фарватерга тартып төшерде.

... Тагын ике тәүлектән соң, иртә таң белән, салны үзебезнең Тоба яры астына китереп төрттердек. Кичтән үк, каршыбызга ат чаптырып, без кайтуны белеп киттеләр, шуңа инде тракторлар китереп, безне көтеп торалар иде.

Салны кымшанмаслык итеп ярга бәйләп кую белән, сүтә дә баш-ладылар. Мин дә эшкә ялландым.

Трактор җитмәү сәбәпле эш озакка китте. Ун көн дигәндә көчкә эш-не бетереп, расчет алдык.

Раббани абыйлар өч-дүрт көнләп ял иттеләр дә, кабат җыелышып, киләсе язга кадәр кабат урман кисәргә менеп киттеләр.

Алар киткәч, эш бетеп, күңелсез булып калды. Җәй башы белән авылда да шактый үзгәреш булып алган: биш колхозны бергә кушып бер колхоз ясаганнар иде. Басуында безне башак җыйдыртмаган күрше колхоз председателе — председатель, ә башкалары, шул җөмләдән Ти-мершаех абый бригадир булып калган. Яшьтәшләремнең дә күбесе Туй-мазыдыр, Әлмәттер ягына нефтькә чыгып киткән; өстәвенә, эшләргә ярарлык бар кешене суырып алган печән өсте җиткән иде.

Мин бик сагынсам да, тагын эшкә уралып китүдән куркып, болынга бармадым. Китәр алдыннан гына бер әйләнеп кайтырмын әле дип, им-тиханга әзерләнергә керештем.

Мин көн саен иртән үзебезнең Саклау буеннан биш чакрым йөгереп кайтам да, китапка утырам. Җиңги болында. Ике малае миңа комачау-ламый: бер чыгып китсәләр, карыннары ачмыйча өйгә кайтып та керми-ләр иде. Җәйге озын көн авышып, инде нуры сүнгән кояш Актаныш ягы-на турылап төшә башлагач кына, мин укудан туктап Агыйдел буена китәм. Су кереп, өйгә йокларга гына кайта идем.

Бер ай эчендә мин, спортчылар теле белән әйткәндә, «формага кер-дем». Ә июль ахырында, үземне имтиханга шактый әзер санап, педа-гогия институтына керер өчен Казанга карый юл тоттым.

## 24

Институтка керү минем өчен авыр булмады. Беренче разрядым бар-лыгы да, техникумда укытуым да, хәтта Казанның үзендә хезмәт итеп, үзендә унынчы классны экстрен бетерүем дә — һәммәсе искә алынган иде.

Имтихан биргән вакытта ук, Мирза абыйлар өстендә яшисем килми-чә, тулай торакка урнаштым, укырга кергәч тә, шунда яшәвемне дәвам иттердем.

Беренче елны ук мине комсомол комитетына сайлап куйдылар. Ни әйтсәң дә, күбесеннән яшем зур булып, инде тормыш күргән кешеләр исәбендә идем.

Беренче разряд — безнең факультетка кергәннәрнең байтагы өчен институт бетергәндә генә ирешә алган хыял иде. Ә без, разрядлылар, беренче көннән үк махсус төркемнәргә бүленеп, икенчеләр беренчелек, беренчеләр мастерлык программасы белән күнегүләр үтә башладык.

Уку башыннан ук мин үземне каты режимга йөгәнләп куйдым: һәр көн җидедә торып, унбиш минут зарядка ясыйм, бил тиңентен салкын су белән юынып, сигездә укырга китәм; шул китүдән кичке унга кадәр тулай торакка кайтмыйм, ә унбердә — яту белән йоклап китәмме-юкмы — йокларга ята идем.

Ял көннәрендә бүлмәдәш егетләрем эртилгә оешып, тимер юлга йөк бушатырга китәләр. «Анда эш муеннан — иренмичә эшлә генә» диләр. Кайсы көнне алар иллешәр-алтмышар сум эшләп кайта. Бу акча аларга көненә өч тапкыр мул итеп ашаганда да биш-алты көнгә җитеп бара иде. Алар киносын да, театрын да калдырмый йөриләр. Алар гына түгел, башкалар да шулай: бәйрәмнәрдә шау-шулы, күңелле компанияләргә оеша, — бер минем генә андый күңел ачуларга вакытым юк: сәгатем түгел, минутларым да шыплап төелгән кебек иде. Үземне үзем куу өстенә, атнаның алты көнендә мине тренерым куа, шулай итеп фәкыйрь студентның байларча тормышы миңа бөтенләй кагылмады. Минем өчен бәйрәм, солдаттагы увольнение сыман, Мирза абыйларга барыр өчен китә. Тулай торактагылар миңа «эре, тәкәббер, әллә кем булып йөри» торган кеше итеп карый башладылар.

Бер вакыт политэкономиядән лекция буласы аудиториягә кереп утыргач, башка бүлектәге бер егет яныма килеп:

— Бу — безнең урын, күчегез, — дип әйтте.

Миңа сәер булып китте: моңарчы бер кем дә монда үз урынын киртләп йөрми торган иде. Мин:

— Әнә, урын бик күп, теләсә кайсына утырыгыз, — дип җавап бирдем.

Лекция башланып биш минут та үтмәгәндер, миңа арттан бер язу төрттеләр. Өлгерә алмый лекция язуым сәбәпле мин аны укымыйча гына дәфтәргә кыстырып куйдым. Тәнәфестә укысам, исем китеп торды. Мин йөзен дә танымый калган егет: «Яхшы костюм кию генә әле әллә кем булдым дигән сүз түгел. Безнең әти-әниләр сезнеке сыман бай түгел шул!..» дип язган иде.

Мин аны бөтәрләп чүплек савытына ташладым. Тәнәфестән соң диамат булып, анысы да бөтен курс бергә шул ук аудиториядә иде. Арттан миңа тагы бер язу төрттеләр. «Әһә-ә, авырткан җирегезгә тидемени?!» диелгән иде.

Кызык, мин кем икәнлегеннн дә белмәгән бер кеше — «моның әти-әнисе бар микән?» дип уйлап тормаган! Димәк аның үзенең әтисе дә, әнисе дә бар, тик анықылар бай гына түгел, ә минекеләр бай булып чыга. Аннары ул егет — «бу костюмның бәлки эшләп алгандыр» дип тә уйламый, димәк үзе эшләмәгән.

Мин аптыравымны кая куярга да белмичә, өстемдәге костюмыма карадым — үз гомеремдә кигән беренче костюм иде бу. Без аны Любовь Васильевна белән икәү, бик ошатып, Совет Армиясе көненә алган идек. Чынлап та әйбәт иде ул; корыч төсендәге трико булып, бәясе дә биш йөз илле дүрт сум иде шул аның!..

Теге егетем миңа язу җибәреп кенә калмаган күрәсең, телен дә эшкә җиккән ахры. Бернича вакытлар үткәч, бер бүлмәдә торган иптәшләрдән берсе:

— Әтиең райком секретаремени синең? — дип сорады.

— Кем әйтте сиңа?

— Шулай сөйлиләр.

— Юк. Минем эти шахтада эшли — уналты ел инде! — дидем мин. Шул ук егет Любовь Васильевнаның: «Керләреңне кем юа?.. Ачлытуклы йөрмисеңме?..» дип, мине кайгыртып язган хатын укыган иде. Шуннан соң: «Аның хатыны бар икән, безгә генә әйтми йөри икән!..» дигән сүз чыгардылар.

Ярый инде, монысы ярап куйды, юкса үзебездәге Люция атлы бер кыз, мине кичәләрдә чакырып я чакыртып, сүзен дә, күзен дә саба башлаган иде. Болай чибәр дә, ни дә иде үзе. Тик минем — һаман булса! — Любовь Васильевнаны оныта алганым юк. Нәкъ җырдагы шикелле: күзем йомсам, күз алдымда тик тора. Күңелем Люциягә түгел, башкаларына да төшми, юкса сынлы гимнастика белән шөгыльләнүче кызлар арасында ниндиләре юк иде дә, ярышлар вакытында мин тагы ниндиләрен генә күрми идем! Озын җиңле озын күлмәк киеп йөргән кызлар түгел иде инде алар...

Көнем фәкать уку, фәкать спорт белән уза барган саен, йөрәгемдәге сагыш та сүрелә төште.Акыл үзенә кадәр йөрәк эшләп куйган эшне соңыннан барыбер үз юлына сала күрәсең. Тормышның балын гына түгел, борычын да миннән күбрәк татыган Любовь Васильевна төптәнрәк уйлап әйткән: хактыр, өйләнешкән ихтималда безнең тигез мәхәббәт булмаячак, бүгенге сөю ләззәтенең бер ун елдан тик үкенү белән бетүе бар иде. Аннары соң өр-яңа дөньяны кайсыбыз яңадан кора ала?..

Тора-бара Любовь Васильевнаның миңа язган хатлары күбрәк кечесен өлкәне кайгырткан дуслык, туганлык хатларына әйләнде. Ул миңа күбрәк: «Анда синең ашау-эчү яклары әллә ни шәптән түгелдер инде, ит-мазар алып җибәрсәм, пешереп ашар җаең бармы?..» шикелләрәк яза иде.

Шулай кыш үтте. Яз да җитте. Минем бөтен нәрсәдән баш тартып, фәкать спортка йотылып бирелүем бушка китмәде: куйган максатыма ирештем — май ахырында Идел буе зонасында үткәрелгән ярышта спорт мастеры нормасын үтәдем.

## 25

Имтихан бетеп каникулга чыккач, мине генә көтеп торган Мирза абыйлар белән бергә, пароход белән, авылга кайтып киттек.

Һәм без, инде дүрт туган, кырык алтынчы елдан соң беренче кабат янә бергә җыелдык. Былтыр көзен хәрби хезмәттән кайткан төпчек энебез Әдрән МТСта эшли, Раббани абый быел беренче сал белән төшеп, инде үзенә йорт эшләтеп ята иде. Бурасын ул Йөрүзәннең үзеннән үк буратып кайткан икән. Без нәкъ өмәсенә өлгердек.

Без кайтасы да булгач, өмә көненә Шәрифулла абзый ике мичкә бал ачытып куйган.Күрешергә баргач, тиктомалдан:

— Минем дә әтиегез мәрхүм яннарына китәр көннәр җитте инде ахры, — дип иреннәрен кыймылдатып алды. — Бер генәләр дә бу якты көннән кара гүрләргә кереп ятасы килми шул...

Күз төбендәге җыерчыгы тулы яшьне күргәч, әллә нишләп киттем. Безгә сый хәстәрен күреп яшь корт балына чыгып кергән бер арада Җүәйрә апа, тешләре төшеп, инде бөтенләй сакауланган теле белән:

— Быел кыш бөтенләй аяктан язып, бульнискә барып ятты. Дәвалый алмаенча, майга хәтле тоттылар да шунда, күп торса өч ай торыр дип чыгардылар. Тәрҗимәбез ат белән генә барып алды. Менә шуннан бирле җылый да җылый инде. Капка төпләренә чыгып утырып җылый... Аңа ния брачка бару кирәк? Алтмышка җитеп килгән кешегә брачтан ни дәва? Инде чирләмәсәң дә: менә үләм, менә үләм дип торасың. Яшь чакны гына мәңге үлмәс сыман икән ул... Әй, сабый бала сынлы, җылап

кына утырып, гомеркәйләрне озайтып булсайде! Көллебез дә жыла кына утырырыек... «Эчкән балың кай җирләреңнән чыгып бетсен, шуң күзеңнән дә чыга!» дип әйтеп тә карыйм аптырагач... — дип, минут эчен дә күпме сүз сөйләп ташлады.

Иртәгә өмә буласы көнне балны Шәрифулла абзый мичкәсе белә безгә китереп куйды. Ул — бу өмәнең башлыгы иде. Матча күтәргәнд биленә бәйләп меңгерер өчен кибеттән аракы да алган. Мона әни:

— Карт башың белән, борыңгылар йоласыннан чыгып, нишләп ала матчага шул хәсис аракыны әлеп күтәрергә котыртып йөрисең? Ми бит шуңа дип икмәк салырга йөрим, яңа нигезгә башта яңа икмә керсен... — дип бик нык каршы төште. Шәрифулла абзый:

— Кодагый, син бер дә борчылма юк өчен. Бу өйнең матчасы жи тәрлек — ипиен дә элербез, аллаһы боерса. Әйдә картларча да, яшьләр чә дә булсын, кәҗәсеннән бигрәк мәзәге, — дип караса да, әни үз сү зеннән кайтмады.

Иртәгесен көтү куу белән халык өмәгә җыелды. Бураның зурлыгы әйтерлек кенә түгел: унике ярымга тугыз ярым. Биеклеге дә — гел бе тигез юан бүрәнәдән уналты ниргә иде. Төп ниргә инде көйләп-тигез ләп салынган.Мүклеккә сүсе-ние хәзерләп куелган иде. Ике оста жи тәкчелегендә өмәчеләр эшкә башлады. Өлкәнрәкләр мүкли, ә без, таза ир-егетләр, бүрәнә күтәреп салабыз. Кеше буен үтәрәк, эчке яктан тас как ясап мендек, бүрәнәне аркан белән шуннан тартып ала идек.

Сәгать берләрдә инде иң тантаналы моментка — матчага килеп җит тек. Ана матчага яңа гына мичтән чыккан зур түгәрәк ипи бәйләп, өс тә торган ике кеше ике баштан аркан белән тигез генә тарта башлады лар. Ипи чайкала-чайкала менеп китте. Башка матчалар да менеп яткач, түшәм такталарын бирә башладык — монысын инде осталар күзеннән үткәреп кенә, буыны-буыны белән ырмауларына кертеп тезде ләр.

Күпме кеше булуга карамастан, өмә шактый озакка китте: бу чак лы өйне авыл агайларының күтәргәне юк иде шул әле. Шулай да кояш көн түбәсеннән төшә башлаганда, безнең эш беткән — бәбкәләренә ка дәр менгезеп куйган идек инде.

Аннары бәйрәм башланды. Иң әүвәл баскыч белән менеп, ипине кисеп төшерделәр. Шәрифулла абый аны, бөтен килеш, инде өченче баласын көткән Тәрҗимә апага тоттырды.

— Менә, кызым, яңа нигездә яңа бәхетегез шушы түгәрәк ипекәй ке бек булсын. Балаларыгызны тигез карап үстерегез, — диде. Аның ирен нәре тагы йомшарып китте.

Аннары өмәчеләр өс-башларын каккалап, юынып-сыйпанып, өйгә керделәр. Анда безне табын тулы ит, мичкә тулы бал көтә иде.

Раббани абый өмәчеләргә рәхмәт әйтеп, кыстый-кыстый сыйлый башлады. Эчкән саен берсен-берсе куәтләп, өйнең һәр бүрәнә, һәр так тасын мактап алалар иде.

— Никулай заманында мондый өйдә земский начанник кенә тора торгание, — диде Шәрифулла абзый да. — Инде салып кереп, күзгә өй туйлары ясарга насыйп итсен. Аллаһе боерып, исән булсам, өй туе на миннән биш сарык, биш баш умарта, и башкалары да гел биштән булыр.

— Нишләп алай биштән генә? Бәлки җиңгәбез бәбәйне көянтәләп алып кайтыр? — дип Әдрән дә сүз кушты.

— Амин, кода! Авызыңа бал да май! Сүзең рас килсә, сиңа да бе рәрдән өстим. Ягез алайса, исән булайык, кодалар, оланнар...

Кыза барган Раббани абый төшлеккә менгән кояштай балкып кит кән иде.

— Әллә, бабай, киявегез Раббани, кызыгыз Тәрҗимә рәхәтләнеп яшисе йорт нигезенә багышлап, «Шахта» көенә бер корьән дә укып

җибәрәсеңме? — дип көлеп алды. — Хәвадис мәрхүм шулай ди торган иде...

— «Шахты» безнең көй түгел, — дип Шәрифулла абый кулын селтәде. — Әтиең белән без «Уел» көен әйтә торганиек. Мысыр мәкаме белән үк булмаса да, күкрәк тулы тын — сузып кына сала торганиек үзен! Шулай бит, Мәһисәрвәр кодагый?

Әни кече яктан җавап бирде:

— Шул бер көе бар иде инде мәрхүмнең. Гаеттән соң сездән үк эчеп кайтырие дә, шуны тик җырлап утырырие.

— Тучны! — дип Шәрифулла абзый көлеп куйды. — Мәрхүм, ураза тотмаса да, рамазан аенда тамчы да капмас иде. Ул чүкечне ничек сукмак кирәк ураза тотып! И, картлар гаеттән дә чыгарие — бу да безгә килеп керерие. Чәчен-сакалын кырган, мыегын төзәткән. Йомшак кына тамагын кырып мич башына карап куя бу...

— Төн буена бер-берегезне озатышып йөридериегез инде шуннан...

— Тучны! Валлаһи! — диде Шәрифулла абзый. — Бу бәхетле көннәрне генә күрә алмады. Раббаниның бу йортын күрсәмә!.. Үләрдәйгә үлем юк, торырдайга торым юк, дип шундыйга әйтәләрдер инде... Ягез әле, кияү, кодалар, күршеләр! Солтан мәрхүмне дә искә алаегыз инде бу бәхетле көнне.

Барысы бергә стакан күтәрделәр. Раббани абый махоркадан кысылган тавышы белән: «Темная ночь... Только пули свистят...» дип җырлап җибәрде. Кече яктан Тәрҗимә җиңги башын тыкты.

— Минем диванага житте болай булгач, — башлады!.. — диде ул.

Раббани абый сул кулы белән колагын каплап җырлавын белде. Шунда Әдрән:

— Абый, сугыштан кайтканнан бирле җырлыйсың инде шул бер көйне, нишләп туймыйсыңдыр? — диде.

— Туя торган көй түгел бу, апай. Безнең сугыш көе!.. — дип Раббани абый туктады. — Әйдәгез, инде сез җырлагыз.

— Нилүфәр җиңги җырласын! — дидем мин.

Әдрән дә:

— Җырласын әле җиңги бер көнге көен. Көйләре төрекмәннәргә тартым икән, — диде.

Барыбыз да кече якка таба йөзләребезне борып карадык. Анда әни белән ике җиңги аш-су тирәсендә кайнашалар иде. Раббани абый да калын тавышы белән дәште:

— Нилүфәр, килен! Исемең дә — төнбоек, җырың да төнбоек икән синең! Чык әле бу якка. Җырла әле бик матур иттереп Кырымча татар көен!.. Алып чык әле Тәрҗимә үзен.

Тәрҗимә, «әйдә, әйдә» дип житәкләп, Нилүфәр җиңгине алып чыкты. Җиңги күзен тутырып Мирза абыйга карады.

— Сәнең йырламагыңны телиләр — тюркү айтмагыңны сорайлар. Йырла, гюзүмниң нуры! — диде Мирза абый.

— Нәне йырлайым?

— Истәгәниңне айт — теләгәненне йырла.

Нилүфәр җиңги Мирза абый янына килеп утырды да, күзен аска төшереп, моңлы озын көйгә җырлый башлады:

Ал алайым, алайым, алланайым,
Ал гүл болып юртында салланайым...

Айдай айдай, нә айдай, мажар айдай,
Судай тынык юрегим майдай кайнай...

Икенче көнне Актаныштан Җәзилә кайтып төште. Без кайтканны да ишетеп, көндез күрешә килде.

Биш ел элек мин сөйгән, ул чакта әле өске ирennәреннән сабыйлык та китеп бетмәгән Җәзилә түгел иде инде бу. Бит алмалары гына ту-

гел, бөтен җире тулып түгәрәкләнгән, янып торган япь-яшь хатын ид инде. Без, ничә ел элек аерылышканнан соң беренче кабат күрешеп, а гына сөйләшеп алдык. Хәлләрен ишетеп торсам да:

— Ничек яшисең соң, Җәзилә? — дип сорадым.

— Солдаткалар кебек!

— Ничек?..

— Шулай инде... Әткәй белән әнкәй дә монда ялгыз,— диде у. бераздан.— Бер-беребезгә иптәш булып яшәрбез ичмаса...

— Алар да картайган, — дидем мин.

— Үзең ни хәлләрдә соң? Өйләнмәдеңме әле? Шәһәр җиренд нәрсәгә ул — болай да күп диген.

— Тиз генә өйләнә дә алмам...

— Әллә өйләнеп карадыңмы?

— Алай ук түгел...

Җәзиләнең бит алмалары кызарып китте.

— Нигә мин ир булып тумаганмын!.. — диде ул.

— Нигә?

— Яраткан кешемә ичмаса «мин сине яратам...» дип әйтә алыр идем...

Инде аның бөтен йөзенә ут капкан иде.

— Хатын-кыз килеш тә әйтә алмыйсыңмени?

— Минә әйтә алмыйм бит...

Әтисенең өчен уздырып, кире Актанышка киткәндә ул күрешергә дип безгә керде. Мин капка төбенә озата чыктым.

— Нигә «кал әле» дип әйтмисең? — диде ул.

— «Кал» дисәм, калыр идеңме?

— Калыр идем...

— Их, Җәзилә!.. Җәзиләкәй!..

— Хуш-сау бул! — диде ул. — Ялгыз гына януыма сабырлык телә...

Ул тиз генә күзен читкә алып, тиз-тиз атлап китеп барды. Йөрәгем кысып сызлап куйды.

## 26

Институтка килгәч, минем язмышым бөтенләй уйламаган җирдән икенче якка борылып китте.

Беренче көнне үк кафедрага чакырып алып, укытучылык эше тәкъдим иттеләр. Мин: «Уйламый гына җавап бирә алмыйм, уйлыйм әле» дидем.

Бер-ике көн үзем уйлагач, бер көнен Мирза абый белән уйлашкач, мин килеп ризалык бирдем. Бер приказ мине тренер-ассистент ясаса, икенче приказ читтән торып укырга күчереп куйды.

Укыта башлау белән квартирага күчтем. Квартирам институттан ерак түгел — Кабан күле буенда гына, тәрәзәсеннән Мәрҗәни мәчете күренеп тора иде. Ишегалды гел татар — биш вакыт намазын калдырмыйча, читек тегеп көн иткән диндар бабайдан алып көнозын күгәрчен очырган егетләргә кадәр яши иде монда. Хуҗаларым яхшы кешеләр туры килде: Үзбәк абый шофер, Ярия апа — китапханәче. Уникe яшьлек бер генә малайлары бар. Миңа раскладушка куеп йокларга, шул малай яныннан — өч тәрәзәле зур залдан урын бирделәр.

Гадәтемчә, мин вакытында ятам, вакытында торам — биш минут соң, я биш минут иртә яту-тору юк иде. Бөтен факультетларга да бе-

ренче ике елда физкультура кергәнлектән, минем эшем — иртәдән кичкә кадәр. Буш сәгатьләр килеп чыкса, берәр лекциягә кереп утырам, я булмаса үзлегемнән укый идем.

Квартира хуҗаларын мин беренче көннән үк ошатып яшәп киттем. Өйдә чакны мин утын кертү, су алып кайту кебек эшләрне үзем сорап эшлим. Минем өчен генә утлары янмасын дип, иртәнге гимнастиканы ут алмыйча, йокыдан уянмасыннар дип, сикерми-йөгермичә генә ясый идем. Алар да миңе бик тиз якын итеп, бер кардәш-якыннарыдай күрә башладылар. Һәм, озак та үтми, мине үзләренең күрше кызлары белән таныштырырга ниятләре барлыгын әйттеләр. Любовь Васильевнадан соң кызлар белән танышу бик кызык тоелып, мин шундук, танышырга җилкенеп торган бер кешедәй:

— Нинди кыз соң ул? — дип сорадым.

— Нишләп? Бер дә күргәнең юкмени? — дип Ярия апа күзен түгәрәкләде.

— Иртән китеп кич кайткан кеше кайдан күрсен инде? — дип Үзбәк абый хатынына карады. Чәчрәп торган зур күзле, бик кечелекле, йомшак фигыльле бер кеше иде ул.

— Хәер, Диләранын үзенең дә күренергә бик вакыты юк: аның да беренче генә ел эшләве, — дип Ярия апа мәсьәләне ачыклый төште.

— Кайда эшли соң ул? — дидем мин.

— Кооперативный техникумда укыта. Мәскәүдән январьда гына укып бетереп кайтты. Чибәр, тәүфыйклы кыз.

— Анысы шулай, — кечкенәдән күз алдыбызда үсте, — диде Үзбәк абый.

— Мәскәүдә, үзе укыган институтта ук, аспирантурага бик димләп караганнар да, бу калмаган. Әниемне кем карар дип кайтты... Нишләп бер дә күргәнең булмады икән соң синең? Әнә генә бит аларның өе! Син йоклаган зал тәрәзәсеннән күренеп кенә тора, — дип Ярия апа мине тәрәзә янына алып килде. — Әнә, дүрт тәрәзә аларныкы...

— Юк, ул өйдән чыккан бер кызны да күргәнем юк, — дидем мин.

— Ярый, алайса күрерсең, — диде Ярия апа.

Шул көннән алып мин, эшкә киткәндә дә, кайтканда да, күрше йорт ишегенә борылып карап үтә торган булдым. Тик анда бер хатын белән бер әбидән башка керүче дә, чыгучы да юк кебек иде. Ишек төбендә генә ике карт өянке үсеп утырган бу бәләкәй өй — үзендә бер кызны яшереп тоткан серле бер дөнья булып китте. Мәгәр кызы минем күз алдында фәкать Любовь Васильевна төсле булып сурәтләнә иде. Ләкин ул кыз миңа һаман очрамады. Гүяки бу өйдә балалы хатын белән бер әбидән башка бер кем яшәми иде.

Октябрь бәйрәменә дәртләнеп-ашкынып әзерләнгән чак житте. Карлы-яңгырлы бер якшәмбе иде. Мин квартирада укып утырам. Шунда мин ачык зал ишегеннән кухня ягына бер кыз килеп кергәнен күрдем — иңенә плащ кына салган иде. Кухняда кеше булмагач, зал ишегеннән башын гына сузып, Ярия апаны сорады. Күңелем шундук: «Шул!» диде.

Мин җавап биреп өлгергәнче, Ярия апа үзе, шуны гына көтеп торган шикелле, эчкәре бүлмәдән килеп чыкты.

— Әйдүк, Диләра! Әйдүк, җаным! — дип каршына килде. — Син безнең егетебез белән таныш та түгелсеңдер әле? Таныш булыгыз: Сирин исемле. Пединститутта укыта...

Мин урынымнан торып, күрешергә җайлы булсын өчен дип өстәл башына килдем. Ләкин ул кул бирмәде. Куе соры күзләрен бер генә сирпеп карады да:

— Бик зур егетле булгансыз икән, күргәнем бар, — дип, миннән күзен алды.

Аннары алар Ярия апа белән ниндидер бостон отрез турында сүз башлап, эчкәре бүлмәгә кереп киттеләр.

Битенә-башына бер нинди буяу якмаган, алсу түгәрәк йөзле, икегә аерып таралган коңгырт-кара чәчле, ясап куйгандай матур гәүдәле бер кыз иде бу. Күз төшүдән түгел, кызыксынудан, инде укый алмыйча, мин ул кызның кире чыгуын көтеп тора башладым. Ул озак утырмады, — күренеп тора, эш кешесе иде, — газиткә төрелгән төргәк тотып килеп тә чыкты. Ярия апа белән Үзбәк абый икәүләшеп озата чыккан иде.

Мин көтеп торганлыгымны күрсәтмәс өчен, утырган булган идем. Ул:

— Егетегез ялны да белмимени шулай? — дип миңа тагы күзен сирпеп алды. Уң кашы өскә шуышып менде — гаҗәпләнү гадәте иде булса кирәк.

— Егетебез бик тырыш, алны-ялны белми, — дип Ярия апа мине мактап алды.

— Данные начар түгел икән!

— Минем әйбәт якларым ул гына түгел әле,— дип мин дә уен сүзне күтәреп алдым: — Мин әле — аракы эчмим, тәмәке тартмыйм, и — кызлар белән йөрмим...

— Менә монысы мактау түгел инде.

— Нишлисең бит: миңа дигән кыз тумый калган, күрәсең.

— Монастырегыз[1] тулы кызлар ич!

— Кызлар күп, тик күңел төшкәне юк.

— Күңелегез бик югары менгән икән!

— Әгәр башта ук сезне күргән булсам... Тик сез дә — күренә торган түгел.

Уен сүз шуннан ары китмәде: Диләраның йөзенә җитдилеге кайтып, шаянлык шунда бетте. Бу инде җил-җилкенчәк түгел, акыл утырткан, яше җиткән бер кыз иде.

— И Ярия апакай гынам! Эшем бик күп, чыгыйм әле, болай да озакладым, — дип ашыгып плащын бөркәнде.

— Тагы керегез, — дидем мин.

— Чынлап та, бер дә кермисең, ешрак кер әле, Диләра җаным,— диде Ярия апа да.

Диләра, миңа да «сау булыгыз» дип, хушлашып чыгып китте. Без ишек төбенә җыелып баскан килеш озатып калдык.

— Йә, кызыбыз ничек, ошадымы?..

— Артык җитди инде — көлмәде дә, — дидем мин.

— Син тагы бигрәк! Беренче күрүдән үк иһа-һай да һиһа-һай килмәс ич инде кыз бала! Үзе укытучы да!.. Төскә-биткә килгән. Холкы әйбәт. Эше әйбәт...

— Рәхмәт, Ярия апа. Рәхмәт таныштыруыгызга,— дидем мин.

Октябрь бәйрәме җитте. Нәкъ җидесендә Үзбәк абыйның да кырык яше тулачак иде. Бу көнгә алар бик күп кеше чакырып, атна буе әзерләнделәр. Мин дә катнашырга тиеш булганлыктан, Мирза абыйларга баруны, алдан мәгълүм итеп, сигезенә калдырдым.

Мин демонстрациядән кайтуга өйгә бәйрәм яме кереп тулган: кухнядагы зур мич, җылысы белән җаннарны эретеп, казан ашы, таба ашлары исе аңкытып утыра иде. Залның буеннан-буена өстәл сузып, өсте тулы ризык өстенә кәгазь каплап куелган иде.

---

[1] Пединститутның тулай торагы элекке монастырь бинасына урнашканлыктан, аны «Монастырь» дип кенә йөртәләр иде.

— Бәйрәм көнне тума икән ул!.. Өстәл сорап кермәгән кешем калмады — көчкә таптым, — диде Үзбәк абый.

Сәгать биш тулгач кунаклар килә башлады. Һәр кайсысы котлап Үзбәк абыйга бүләк тоттыра, Үзбәк абый елмаеп кына рәхмәт әйтеп, алган бүләген кая куярга да белми тора иде. Күп кунак арасында төрлесе бар: шоферы да, колонна башлыгы да; ләкин күбесе интеллигент, хәтта исемле бер җырчы ханым белән баянчысы да килгән иде.

Күршедә генә торгач, иң ахырдан диярлек Диләра керде. Ярия апа аны минем янга утыртты.

Безнең бер-беребезгә ашкынып тартылмыйча, ипле генә танышып китүебез шулай башланды.

## 27

Әз генә кар төшкән, ләкин бик суык бер көн иде. Без беренче кабат Диләра белән ишегалдында очраштык. Дәресрәге, капкадан аллы-артлы кайтып кердек.

— Исәнмесез, Диләра туташ!..— дигәч, гаҗәпләнеп артына әйләнеп карады.

— Хәерле кич, Сирин.

— Менә — бер танышкач очраша да башладык.

— Юкса моңарчы күрми генә үтә идегез, — диде ул.

— Анысы минем минустыр инде.

— Һәр хәлдә плюс түгел.

Мин аны ике өянке үсеп утырган ишек төпләренә кадәр озатып куйдым да:

— Сезгә хәерле кичләр!.. — дип китәргә җыендым.

— Вакытыгыз булса, әйдәгез безгә рәхим итегез, — диде ул. Мин икеләнебрәк калгач: — Чынлап чакырам, әйдәгез, — дип өстәде.

Без аларга кердек. Әнисе чәй кайнатып, өстәл түренә ап-ак самавар китереп куйгач, йөрәгемә җылы ямь бөркелде. Диләраның әнисе Фатыйма апа чәй пешереп, мине бер кунак төсле кыстый-кыстый чәй эчерә башлады. Тәмле самавар чәен татып җибәргәч, туып-үскән ягымлы нигеземә — үз әнием янына кайтып кергәндәй булдым. Фатыйма апа да — самавар янында утырулары, чөеп яулык бәйләүләре, мине кыстауларына кадәр — үземнең әни сыман булып китте. Уйларымны белгәндәй:

— Эти-әниең бармы соң, улым? — дип сорады.

— Эти юк, әни бар, — дидем мин.

— Хәзер барысының да шулай: этиләр юк. Сугыштан кайтмагандыр инде?

— Юк. Безнең — сугышка кадәр үлде...

— Туганнарың бармы соң?

— Бар. Өч абыем бар.

— Сөбханалла!.. Сугышта булмадылармени?

— Икесе булды. Исән кайттылар.

— Бәхетле аналар да бар шул!..— дип Фатыйма апа уфтанып куйды.— Минекеләр дүртәү иде — берсе дә кайтмады. Өчесе германда, берсе япунда һәлак булдылар...

— Булды, әни, — диде аңа Диләра. — Бер синекеләр генә үлмәгән ич сугышта!..

— Искә алырга да ярамый инде сиңа...

— Аннары тагын «йөрәгем!» дип ятасың...

— Дүрт улым да юкка чыккач, «йөрәгем!» дип әйтми нәрсә дип әйтим соң?!

Ул, шулай дип, инде сүзсез генә табын җыя башлады. Иң азактан самаварны алып чыгып китте һәм шуннан соң кермәде.

Без бераз төрле юк-барны сөйләшеп утырдык.

Шул көннән алып без Диләра белән очраша башладык. Я киного барабыз, я — театрга, я салкын кичтә кар шыгырдатып Кабан буенда йөрибез. Кайсы көннәрне мин, эштән иртәрәк кайтып, кич Диләраларга керәм. Фатыйма апа мин кергәч самавар куеп җибәрә — әчәсем килсә-килмәсә дә, кыстый-кыстый чәй эчерә. Аннары бәйләмен алып кухня ягына чыгып китә. Без бердәнбер бүлмәдә икебез генә калабыз. Диләра, гадәтенчә, миңа сирәк-мирәк кенә сүз кушып дәресен карый, мин дә укырга бирәр китап я журнал табып алам. Шулай утырабыз. Сөйләшсәк тә, күбрәк мин сөйлим. Диләра аз сүзле. Кайвакыт ул миңа: минем белән ачылып кына китеп сөйләшә алмый кебек тоела иде.

Шулай без бер-беребезгә иҗләшеп, дуслашып киттек.

Мин беренче күргәндә яратырмын дип уйламаган да Диләраны көннәр узу белән әкрен-әкрен күңелемә якын итә башладым. Киләчәк көннәрем дә ничектер аның белән бергә булыр төсле күз алдыма килә иде. Әмма иң гаҗәбе шул: ул минем кочакка керергә, мин җиңел генә уйлаганча, бер дә атлыгып тормый иде. Бу хәл горурлыгыма тиеп, аны үземә каратасы килүне көчәйтеп җибәрде. Хисләр үзенекен эшләп күрсәтте — яндык! — инде акыл белән дә эшләп карарга кирәктер дидем.

Бер заман шушы уй минем ялгыз янган хисләремнең барын биләп алды. Ничә ел каты тоткан режимымның кичке ягы тезгеннән ычкынды. Көн саен төгәл унбердә яту бетте. Унбердә яткан чакларымда да мин, элеккечә, тиз генә йоклап китә алмыйм. Чөнки бу вакытта әле Диләра йокламый — ул һәр көн сәгать бергә-икегә кадәр иртәгә укытасы дәресләренә хәзерләнеп утыра. Ә мин, йоклый алмый уйлап ята торгач, караңгы тәрәзә янына басып, аның өстәлендә янган яшькелт утка карап торам. Шулай онытылып: «Кайчан ятар икән? Тәрәз пәрдәсе кыймылдап, ул да миңа карамас микән?» дип көтәм. Ләкин күпме вакыт шулай көтсәм дә, Диләраның бер тапкыр да минем якка пәрдәсен күтәреп караганы булмады...

Һәм шундый, йоклый алмый пыялага маңгаем терәп, Диләраның яшькелт утына текәлеп торган төннәрнең берендә мин үз-үземә урын таба алмыйча йөрүемнең сәбәбен аңладым: мин бер ярдан тибеп йөзеп киткән, икенче ярга килеп тотынмаганмын икән әле. Ун яшемдә беренче тапкыр, йөрәгем җитеп, Агыйделне йөзеп чыгуым исемә төште. Инде шактый агып, шактый эчкә кергәч, каршы якның һаман якынаймавыннан куркып, артыма әйләнеп карадым. Инде ул яр да ерак калган иде. Димәк, борылу юк. Тип-тигез комлыкка барып чыккач, гел колач салып йөзүдән башым әйләнеп китеп, мин бик озак мамыктай йомшак, рәхәт, җылы ком өстендә яттым. Баш очымда акчарлаклар очып йөри. Ул ел сугыш чыккан ел булып, сугышка китәргә пароход көтеп яткан абыйлар, озата килгән апалар, я көймә, я паром белән аръякка чыгып йөргәнлектән, кайнар ком өстендә күкәй салган акчарлакларның да, ояларына төшә алмыйча, елап-чыелдап йөргән чаклары иде. Мәгәр мин Агыйделне йөзеп чыктым!

Шул елны безнең малайлык та мәңгегә теге ярда калды.

Хәзер дә — кирегә кайту булмаячак. Любовь Васильевна — Агыйделнең мин йөзеп киткән яры. Мин хәзер икенче ярга таба йөзәм. Ул яр якынмы, еракмы — белмим. Тик шуны беләм: инде артка юл юк...

Февраль ахыры иде. Кичтән Диләра миңа үзе:

— Иртәгә төп-төгәл сәгать алтыда безгә кер, бер җиргә барабыз, — диде. «Кая?» дип сорагач: — Баргач үзең күрерсең...— дип беренче кабат чәчемнән сыйпап алды.

Икенче көнне нәкъ шул сәгатьтә минем тренировкам бар иде — аны күчердем. Ашыгып квартирыма кайттым. Өстемне тиз-тиз алмаштырып, Диләраларга кердем. Ул, гадәтенчә, мин кергәч кенә киенеп, без ул әйткән «бер җиргә» киттек.

Кабан өстеннән Куйбышев мәйданына чыктык. Аннан «Собачка» белән өскә күтәрелеп, «Гоголь»гә борылдык. Бераз баргач, ике катлы таш йортның ишек төбенә туктадык. Икенче каттан җиңел адымнар белән кемдер йөгереп төшеп, безгә ишек ачты. Бу — җитеп килгән, озын буйлы, чибәр генә бер кыз иде. Ул шатланып күрешге дә, Диләра белән русча сөйләшеп китте. Өйгә кергәч, безне бик таза буйлы бер апа кычкырып көлеп, кочакларын җәеп каршы алды. Диләраны кочаклап үпкәч, үз итеп миңа кулын бирде.

— Кечкенә Диләраның бик зур апасы менә мин булам инде, — диде ул. — Гөлсем апа диярсез.

Ул минем белән шундый ачык сөйләшә башлады ки, әйтерсең лә без аның белән күптән күрешми торган якын кардәшләр идек. Диләра да, үз өендә һич булмаганча, иркенәеп, ачылып китте. Мин сизендем: мине ул тәгаен шушы Гөлсем апасына күрсәтергә алып килгән булырга тиеш иде.

Кире кайтканда, Казанның инде караеп яткан тротуарлары, кеше күп урамнарын үтеп, иркен Кабан өстенә чыккач, бүгенге кичәдә икебезнең дә күңел күтәрелеп, бераз уйнап, кар атышып алдык. Диләра яшь җилкенчәк түгел — нәкъ минем белән бер елгы булып, быел ул да егерме бишен тутырырга тиеш иде. Яшеннән дә бигрәк, фигыле басынкы, сабыр булганлыктан, минем белән моңарчы болай уйнап-көлгәне юк. Бәлки шуңадыр, кайсы вакыт минем: «Ул мине яратмый. Яки кемнедер оныта алмый» дип уйлап та куйганым бар иде.

Бүгенге шаяруы бик тә хуш килеп, күңелем Кабан күле өстедәй киңәеп китте. Мин, барган җирдән җилтерәтеп, Диләраны күтәреп алдым да, бала төсле итеп күкрәгемә кыстым.

— Җавап бир: мине Гөлсем апаңа күрсәтергә алып бардыңмы?

— Барсам ни әйтерсең?..

— Рәхмәт кенә әйтәм. Гөлсем апа миңа бик ошады.

— Син дә ошагансың... «Бик» дип әйтмим әйтүен, я борыныңны чөя башларсың... Я, җибәр...

— Мин сине гел шушылай күтәреп кенә йөртермен. Төшәм дип ялынсаң да, төшермәс идем...

— Ялынып әйтәм: төшер. Миңа уңайсыз. Кешеләр дә үтеп йөри...

— Диләра, чык миңа кияүгә!.. — дип пышылдап, күзләренә карадым.

Ул бик озак күземә карап, сүзсез дә, хәрәкәтсез дә торганнан соң:

— Уйлашыйк әле, Сирин. Болай гына хәл итәлә торган эш түгел ич... Син дә уйла, — диде.

— Мин уйлаган инде. Уйламасам, андый сүзне кузгатмас та идем.

Шуннан соң ул атна буе миннән качып, өенә дә соң гына кайтып йөрде. Нигә керсәм дә, башым иеп чыгып киткәнлегемне күргәч, Фатыйма апа түзмәде, берсендә юатып алды:

— Ул тикле борчылма син, улым. Кыз бала күңелендә ниләр генә булмас. Мин аңа әйтермен, — дигән булды.

Мин беләм: ул безнең яратышуны хуплый, хәтта тизрәк кавышуыбызны тели иде.

## 28

Март башы иде инде. Любовь Васильевнадан бер хат килде. Ул үзенең кияүгә чыгуын әйтеп язган. Киявен инде балалары житеп, үзләре дөнья көткән, тыныч-сабыр фигыльле бер тол ир дигән, башка хат язмавымны үтенгән иде.

Бу хәбәр бәгыремне бал кортыдай чагып алды. Мин шуннан соң ничә көннәр бер кемне күрәсем килмичә, башымны кая куярга белми йөрдем. Япан җирдәй бушлык, ялгызлыктан, моңа тикле һич атлыгып

тормаган киноларга кереп, котылырга итеп карадым. Ләкин котыла алмадым. Киносында бераз онытылып киткән булсам да, чыгу белән мин тагы Казан уртасында бер үзем кала идем.

Диләраларга да кермәдем: үзе миннән качып йөргән кешенең ник кәефен бозарга!..

Күңелем шулай, бер җирдә дә ямь тапмыйча, бәргәләнеп йөргән көннәрнең берендә, кич белән соң гына үзебезнең ишегалдына кайтып кергәч, каршыма килүче Диләраны очраттым.

— Әллә нигә башым түнеп китте дә, менә һавага чыктым әле, — диде ул. — Әйдә, вакытың булса, Кабан буеннан бер урап килик...

Сизәм: бу мине көтеп торган.

Без мәчет тыкрыгыннан Кабан буена төштек. Айлы кич иде. Кабан өсте чип-чиста кар, якты ай яктысында күз кыскандай җемелдәп, зәңгәрләнеп ята иде. Күзем Болакка таба кистереп чыккан сукмак өстенә төшкәч, күңелем кинәт шушындый сукмакларым калган Уфа якларына китеп барды. Күзем дә, уем да алмашынды... Арырак, әз генә биек булып, утлары сибелеп янган бу шәһәр Казан түгел, Уфадыр төсле тоела башлады. Бу — янымда басып торган кыз да Диләра түгел, Любовь Васильевна икән дип хыял итеп, онытылып киткәнмен.

— Бу арада сезгә нидер булды, Сирин. Сез бик нык үзгәрдегез... — дип Диләра мине Кабан ярына кайтарды.

Әйе, каршымдагы бу шәһәр Уфа, янымдагы бу кыз Любовь Васильевна түгел иде.

Мин, кинәт телем бәйләнгәндәй, ни әйтергә, әйтсәм нидән башларга белмичә, тын гына атлый бирдем.

— Әгәр минем белән сөйләшәсегез дә килмәсә, мин хәзер үк кайтып китәм, — диде Диләра. — И шуның белән... ике арада бер нәрсә дә булмады дип уйлагыз... — Ул беләген кулымнан суырып ала башлады.

«Я бүген сөйлим, я бер кайчан да сөйләмәячәкмен», дидем мин.

— Тукта, Диләра!.. Син ялгыш уйлыйсың... — Мин аны ныграк култыклап алдым. — Бу көннәрне мин чынлап та үземне-үзем кая куярга да белми йөрдем. Әле дә шундый хәлдәмен. Тик аңла, сиңа булган карашымның чак кына да үзгәргәне юк... Әгәр мин сиңа бер көн: «Миңа кияүгә чык» дип әйткәнмен икән, мин әле һаман да синнән җавап көтәм. Ләкин мин бер нәрсәне сөйләмичә җавап бирергә ашыкма. Мин аны — синнән җавап алганчы сөйләргә тиеш... Тыңла...

Диләра хәзер сулыш та алмый кебек иде..

— Диләра!.. — дидем мин. Капыл минем дә тыным беткәндәй булды. — Мин бит егет килеш бер хатынны сөйгән идем...

Һәм мин Любовь Васильевна белән танышканнан алып соңгы хаты килгән көнгә кадәр ни булганнарын бик озынга сузмый гына сөйләп бирдем.

Бер вакыт Диләра бөтен гәүдәсе белән калтырый башлады. «Өшисең бит!..» — дип салкын аркасын күкрәгемә терәп, кочагыма алдым. Ләкин ул әллә каян килгән көч белән кочагымнан тартылып чыкты да, өенә йөгерде.

Мин җәрәхәттәй ачылган хатирәләрем эчендә тең ялгызым Кабан читендә басып калдым.

... Ә бер айдан ул миңа кияүгә чыгарга ризалыгын бирде.

Язылышуны без апрельнең бер унбишенә, туйны Беренче майга дип билгеләдек.

Иртәгә загска барасы кич иде. Фатыйма әби кухняга чыгып китү белән, мин очынып Диләра янына килдем.

— Менә, ялгыз йөрәкләрнең соңгы ялгыз көне дә үтте!.. Иртәгә инде алар — кавышачак!.. — дип кочаклап алдым.

Җитди холкын белгәнгә күрә, шашкын хисләр көтмәсәм дә, елмаеп

булса да берәр татлы сүз әйтер дип уйлыйм. Ләкин Диләра бик уйчан бер йөз белән:
— Әллә язылышуны чигереп торабызмы соң, Сирин? — диде.
Мин аягым таеп киткәндәй булдым.
— Әллә минем турыда берәр начар сүз ишеттеңме?..
— Юк, синең турыда әйбәттән башка бер сүз ишеткәнем юк минем. Аннары — кемнән ишетим?..
— Шулай булгач?..
— Белмим... Бик куркам мин...
— Нәрсәдән?
— Син мине Любовь Васильевнаны яраткан кебек ярата алмассың дип куркам...
— Диләра!.. — дидем мин ачынып. — Мин бит аны синң исемен искә төшереп торыр өчен сөйләмәдем!..
— Гафу ит... — диде ул.
— Аннары, ярату дигәннән, мин аны хәзер, киләчәк өчен, ничек кенә исбат итим икән соң инде? «Яратырмын! Яратырмын!..» дип мең кабат әйтсәм — ышанырсыңмы?..
— Рәхмәт, мин сиңа ышанам, Сирин. — Диләраның күңеле ярына төшеп, йөзенә елмаю әсәре чыкты.— Бар инде кайт, Сирин,— диде ул бераздан. — Миңа тынычланырга кирәк. Иртәгә минем иртәдән дәресем дә бар.
— Иртәгә мин сине кайда көтим соң: загс янындамы, өйдәме? Әлбәттә, өйдән бергәләп чыгып китсәк күңеллерәк булыр иде.
— Мин бер дәрестән сорап китәрмен, мине өйдә көт.
— Булды, сөйләштек, — дидем мин.
— Хуш, тыныч йокылар сиңа!..
Яңа көн кояшы белән туды. Инде шәһәрдә кар юк — көндезләрен генә җылынган тротуарлар өстеннән җылы бу күтәрелә иде.
Мин иртүк торып, Диләраны капка төбеннән техникумына озатып җибәрдем дә, кире кереп, аларда чәй эчтем. Минем бүгенге беренче эшем — караватсатып алып кайту иде. Ун тулу белән универмагка киттем. Ике йөз егерме сумга ике кешелек панцирьлы караватсалып, ун сумга машина яллап, Диләраларга кайтарып куйдым. Аннары мине Фатыйма апа кибетләргә җибәрде. Ул безнең кушылу хөрмәтенә таң-нан торып пешеренә башлаган икән.
Сәгать бердә Диләра да кайтты.
— Бер генә дәрес укыттым,— диде ул.— Калган дәресләрдән сорап киттем.
— Шул гомер кайда йөрдең соң? — диде әнисе.
— Урамда йөрдем...
— Әстәгъфирулла! Бу көнне!..
— Ялгыз чагым белән хушлашып йөрдем... — диде Диләра.
Сәгать ике тулгач без загска киттек. Өйдән чыгу белән Диләра мине сул ягымнан килеп култыклап алды.
Загс бюросы — ул чакта ялгыз тәрәзәсеннән генә якты төшкән, көндез дә утсыз утырып булмый торган бер бүлмәдә иде. Бездән алдагы кеше, кемедер үлгән булып,шуны күмәргә кәгазьләр яздырып алды. Чөнки туганы да, үлгәне дә, өйләнгәне-аерылганы да бер чират белән шушы бүлмәдән үтә икән. Менә безне дә урын бушагач кара-каршы утыртып, секретарьмы-кемме ханым безгә дә таныклык язып бирде. Торып кулыбызны кысты.
Аннары без бу «баз»дан тышка — күзләрне чагылдырып җибәргән якты язга чыктык. Чыгып бер-ике адым китү белән, безнең каршыга чын чәчәкләр тотып, йөзеннән нур чәчкән Гөлсем апа килеп басты.
— Котлыйм, бәгырьләрем!.. Тазалык-саулык белән тигез гомерләр кичерегез!.. — дип башта Диләраны, аннары мине кочаклап үпте.

Без туйга әзерләнәбез. Күбрәк әби чаба, Гөлсем апа чаба. Әби, йоласына туры китереп, бал коеп җибәрде. Мин, язылышкан көнне үк, әниләрне туйга чакырып хат салдым. Быел яз иртә килү сәбәпле пароход та иртә төшәчәк иде.

Ләкин эшем шул кадәр тыгыз — тик торып бер тын алырга да ирек юк: программада каралган дәресләрдән тыш, без көн саен дүрт сәгать институт командасын Горький шәһәрендә үтәчәк ярышка әзерлибез. Аннары — мин үзем дә студент: ярышка китәсе булгач, мин дә имтиханны алдан бирергә тиеш идем.

Без һәр көн кич Диләраның туганнарын, дусларын туйга дәшеп йөрибез. Беренче көнне картлар, икенче көнне яшьләр дип сөйләштек. Мирза абыйларга да чакыра бардык. Ул инде миңа бер тапкыр: «Бу кызың белән йөри башлагач, үзгәрдең әле син, апай. Элеккечә килеп йөрмисең, увольнениегә чыккан чакларында да ешрак килә идең» дип үпкәсен дә әйтеп алган иде.

Без барганда Мирза абый өйдә юк иде. Нилүфәр җиңги ягымлы тавыш белән:

— Тиздән кайтыр инде, үзем дә чук вакыттан бирли бикләйим [1], — диде.

— Эштәме соң ул бүген?

— Дәгил, ишинә акшам бараҗак, әле заводка киткән иде.

Безнең тавышка уянып, тирбәтмәле караватта яткан яшь бала — икенче кызлары елап җибәрде. Нилүфәр җиңги аны кулына алып имезергә утырды. Диләра миңа пышылдап кына:

— Бик озакламыйк, яме? — диде.

— Абыйны күрмичә китеп булмый бит инде.

— Абыең кайткач дип әйтәм.

Сумка тулы ризык күтәреп Анифә апа кайтып җитте. Безне күрү белән:

— И-и, кунаклар бар икән!..— дип елмаеп килеп күреште.— Нишләп болай кайнең белән киленне чишендермичә тотасың, кыз кардәшем? — дип җиңгигә шелтәсен әйтте.

— Без тиз генә кереп чыгарбыз дип уйлаган идек, — дидем мин. — Үзегез беләсез, бик ашыгып йөргән вакыт.

— Кая ашыгасыз? Гомеребез тизрәк үтсен дип ашыгасызмы? Үткән гомер рүзгәргә бинзар — җилгә тиң — дип әйтә торган иде безнең бабабыз — әтиебез... Салдыгызмы өстегездән?.. Менә шулай. Инде хәзер иркенләп утырыгыз. — Ул сөйләнә-сөйләнә чәй куеп җибәрде. Аннары җиңгигә дәште: — Мирза кая китте, кыз кардәшем? Эшенә китмәгәндер лә?

— Ул заводка китте. Озак тормам дигән иде.

— Һаман шул Андрей өчен йөри торгандыр инде, шуның өчен борчыладыр, — диде Анифә апа.

Шунда, ишекләргә сыймыйча, Мирза абый үзе дә кайтып керде. Тиз генә чишенеп аткач:

— Килдегезме?.. — дип яныбызга килеп икебезнең дә аркабыздан сөеп алды.— Тигез ярату белән тату яшәгез, туганнарым. Бөтен бәхет — икең дә тиң яратуда.

— Рәхмәт яхшы сүзегезгә, — дип Диләра башын түбән иде.

— Без сезне, Мирза абый, бер көн сөйләшкәнчә, туйга чакырырга килдек. Беренче май көнне өчегез дә безгә рәхим итегез.

— Рәхмәт, апайлар. Сезнең кебек сандугачлар туена да бармагач — кем туена барырбыз соң без!.. Туктагыз әле, мондый шатлыкны болай

[1] Үзем дә күптән бирле көтәм.

гына үткәрмәек, — дип пыяла шкафтан коньяк алып килде. Лимон куйды.

Мин — миңа дигән рюмканы учым белән капладым.

— Бер грамм да каба алмыйм, Мирза абый, гафу ит. Бик тә җаваплы тренировкалар вакыты.

— Илле генә грамм!.. — диде Мирза абый. — Егерме биш кенә грамм... Бүген минем дә шатлыклы көн бит!..

— Нинди? — Барыбыз берьюлы абыйга карадык.

— Әле заводтан кайтышлый участокка кергән идем. Керсәм, барысы да мине котлый — званиемне күтәргәннәр.

— Шөйләме [1]?.. — Нилүфәр җиңгинең диңгездәй зур күзләре нур чәчә башлады.

— Өлкән лейтенант, димәк?

— Шулай була инде, — диде Мирза абый. — Йолдызны сугыш беткәннең егерме еллык бәйрәмендә кадаячаклар.

— Алайса сал инде бер илле грамм миңа да! — дип рюмкамны суздым.— Ә нигә үзеңә бик аз?

— Бүген дежурство, — диде абый. — Әйдәгез! Тормышыгыз түгәрәк булсын!

— Йолдызыңның игелеген күр, абый!

Анифә апа чәй китерде.

— Андрейның хәлләр ничек соң? — дип сорады ул.

— Тәгәрәп бара! — диде Мирза абый. Аннары, бер миңа, бер Диләрага карап, сөйләп китте: — Монда безнең күрше йортта бер яшь егет бар. Сигезне генә укыды да, бер җирдә эшләмичә, укымыйча, бозык юлга йөз тота башлады. Бер чыгып китсә, өчәр-дүртәр көн кайтмый йөри. Үз участогында андыйларны беләсең бит инде. Бер чакыртам мин моны, ике чакыртам. «Менә эшкә урнашам инде» дип сүз бирә дә, тагын үз юлына китә. Шуннан, башта әнисе белән сөйләштем дә, өендә чагын туры китереп, өйләренә кердем. Бердәнбер малай. Әтисе сугышта үлгән. Әнисе бер кибеттә җыештыручы булып эшли. Кара-каршы утырып, өчәүләп сөйләштек менә шушылай. Унҗидесе яңа тулган малай — эшкә урнашырга үзем ярдәм итәргә сүз бирдем. Андыйларны беренче генә урнаштыруым түгел. Октябрь бәйрәме үтү белән, илтеп бирдем мин моны калай заводына.

Ике ай да үтмәде, цех начальнигы шалтырата миңа: «Теге малаең юкка чыкты, сызды ахры...» ди. Аптырап, шул көнне үк өйләренә киттем. Дөрестән дә, егетем ике атнадан артык өендә ята икән. Ярый әле компаниясен тараткан идек. Шуннан сәбәбен сөйләп бирде бу. Бер көн иртәнге сменасына йоклап калган булган. Ләкин үзе, шул көнне үк барып, гаебен әйтергә курыккан — яшьлек!.. Аннары репутациясе дә бик үк шәптән түгел. Икенче көнне дә бармаган. Хәзер инде атна үткәч бөтенләй кулын селтәгән: «Күзләренә ничек күреним — оят!» ди. Кабат цех начальнигы янына керергә туры килде. Уйлашып киңәшләшкәннән соң без Андрейны, каты бәрелмичә генә, шулай да прогулының күпмегә төшкәнлеген аңлатып, цехында калдырырга сөйләштек. Эшләп китте малаебыз шулай. Менә бүген, кызыксынып, заводына бардым. Цех начальнигы канәгать.

— Ничаво егет булып чыкты ул синең! Тик әлегә мактарга гына куркабыз: йә бозылып китәр,— ди.

— Мактарлык эше бар икән — курыкмагыз, мактагыз. Аңа хәзер самый мактау кирәк чак! — дидем.

Үзен дә күрдем. Бите-күзе кеше танырлык түгел: кара корым — тешләре генә ялтырап елмаеп тора. Кәефе жиде кат күк өстендә. Аны кү-

[1] Шулаймы.

реп сөйләшкәч, үземә дә бик күңелле булып китте. Шуңа тагы званиемне күтәрү шатлыгы өстәлде, — дип Мирза абый сүзен бетерде.

Минем дә — әллә коньяктан, әллә абыйның шатлыгыннан, әллә бөтенесе бергә җыелып, — өйгә кайтканда кәефем күтәренке, тәнем җиңел иде.

## 30

Беренче майның ямь тулы якты иртәсе иде. Диләра әле тормаган. Эби инде кухняда, мич ягып йөри. Тиздән Гөлсем апа килеп җитәчәк. Инде атна буе кайнашалар, бүген ни пешерәләрдер тагы.

Мин Әми тавы өстеннән чәчрәп чыккан кояшка күзем чагыла-чагыла иртәнге гимнастика ясарга керештем. Ләкин гадәттәгечә онытылып, күңел салып ясый алмыйм. Күңелем гел әллә кайда. Бүген безнең туй көне!.. Бүген сәгать икедә әниләр дә килеп төшәргә тиеш. Әни белән тагы кем килер икән дип уйлыйм. Раббани абыймы, Әдрәнме? Телеграммага исемләп язмаганнар, «Безне каршыла, әниең» дип кенә куйганнар... Юк, Әдрән килә алмас. Районда-бер тракторчыны чәчү өстендә Казан тикле Казанга кем туйга җибәрсен!.. Сорамаячак та. Килсә Раббани абый килер. Иң зурыбыз — ул. Минем яктан ул утырыр инде башкода булып...

Мин, уйланып китеп, алар утырып киләчәк пароходларга кадәр уйлап бетердем. «Алымов» дигәннәр. Ләкин мин андый пароходны белмим. Мин белгәннәр: «Тукай», «Жан-Жорес», «Никитин», «Ходайбирдин», «Гафури», «Советский полярник»... Мин аларны шәрә корсагым киереп Агыйдел ярында басып торган малай чагымнан бирле беләм... Тик алар хәзер юк. Менә ике ел инде Уфа белән Казан арасында Венгриядән алган, көзгеле, йомшак урынлы яңа пароходлар йөри. Әниләр дә шуның «Алымов» дигәне белән килеп төшәчәк инде...

Шул вакыт коридорга кемдер кергәне ишетелде. Гөлсем ападыр, ул шулай ашыгып, каты басып килеп керә.

— Кодагый җаным, Сирин тордымы әле?.. — дип соравын ишетү белән тәнем буйлап салкын йөгереп үтте.

— Ходаем! Ни булды?.. — диде әби.

— Ай, әйтерлек кенәме?.. Ай, әйтерлек кенәме?.. — дип кабатлыйкабатлый, бүлмәгә төсе тәмам качкан Анифә апа килеп керде.

Аның артыннан әбинең дә инде яман хәбәр сизенеп чиксез борчу чыккан йөзе күренде.

— Сирин!.. Башкаебызга тегермән ташы кадәр кайгы төште бит: Мирза абыеңа бандитлар чәнечкән!.. — дип Анифә апа ишек яңагына сөялде.

Мин сулышым өзелеп караватның салкын никеленә тотындым.

— Нинди бандитлар?..

— Исерек бандитлар инде... Яшьләр!.. Бер хатынны талап яткан чакларында Мирза өсләренә барып чыккан... Һәр кайсында ялтырап торган пычак ди... Берсенекен шундук чөеп очырган, икенчесен каерып аткан, өченчесенең, күрәшкәндә, үз пычагы үзенә кадалган... Ләкин бишәү булганнар бит, бишәү!.. Калган икесенә кулы җитмәгән... Эчен айкап ташлаганнар...

Диләра да, коты алынып, сикереп торып утырган иде инде. Ни әйтергә белмәгәннән:

— Сирин, өстеңә кияр идең, — диде.

Шунда гына мин әби белән Анифә апа алдында трусиктан гына килеш басып торуымны сизеп, аңсыз хәрәкәт белән пижамымны алып кидем.

— Харап иттеләр Дөлдөл сыман ир-егетне!.. — дип Анифә апа елый башлады. — Бер сөйләп ун көлә торган кеше иде бит. Ничек күтәрербез бу хәсрәтне!.. Анагыз нишләр?.. Нилүфәркәем нишләр? Аһ!..

— Туктагыз әле, Анифә апа, ул хәтле тойгыга бирелмәгез әле, Мирза абыйның хәле ничек? Хәлен әйтегез...

— Ничек булсын инде эчен айкап ташлагач...

— Әле кайда абый?

— «Шамский»да... Нилүфәр дә шунда. Мине машина белән сине алырга җибәрделәр. Әйдә тиз генә...

Мин юынып та тормыйча тиз-тиз генә киендем дә, без Анифә апа белән милиция машинасына чыгып утырдык.

Хәл эчендә ятканлыктан, мине бер тоткарлыксыз абый янына керттеләр. Елап ярсыган, шашынган Нилүфәр җиңгине ике сестра култыклап палатага алып кереп баралар иде. Без кергәч, милиция майоры безгә баш кагып тын гына чыгып китте. Мирза абыйның кечке кояштай нуры сүнеп барган саргылт-ак йөзен күрү белән — йөрәгем өзелде дә төште. Мин барын да аңладым. Безне генә көтеп ята иде ул...

— Абый! Нишләттеләр сине болай? Нишләттеләр?.. — дип тезләнеп, баш очына сыгылып төштем.

Абый һушында иде әле.

— Менә... нимес пулясы тимәгән иде...

Күзләремне тыелгысыз яшь каплап алды.

— Елама, апай... — диде абый. — Туеңны гына күрә алмадым... Инәйне ничек тә юатырга тырышыгыз инде... Елап йөрәген бетермәсен... — Абый кинәт «ай!» дип тартыша башлады, маңгаена тир бәреп чыкты,сикереп торырдай талпынып: — Кая, кил каршыма, Нилүфәр!.. — диде.

— Мирзам!.. Акайчыгым[1]!.. — дип җиңги, атылган кош кебек, абый өстенә егылганда сестралар гына тотып калды. Аны болай да баядан бирле сестралар гына тотып тора иде.

— Башымны күтәр... — диде Мирза абый.

Мин аның инде авырайган башын мендәрдән калкыттым.

Абый, дөньяда мин барын да, бүтәннәр барын да онытып, Нилүфәр җиңгинең күзләренә текәлде. Шул килеш, карап торган килеш җан бирде. Җан биргәч тә күзе йомылмады — тутырып ачкан күзләре белән туп-туры җиңгигә карап ята иде.

Былтыр җәй авылда Нилүфәр җиңгинең: «Үлсәм күзем китәҗәк жумулмай ачык...» дип җырлаганы исемә төшеп, тетрәнеп киттем.

Сестралар килеп абыйның күзен көчкә йомып куйдылар.

Диләрә да безнең арттан больницага килгән, без палатадан чыкканда коридорда көтеп тора иде. Күзләренә гаҗизлек белән коелып төшү галәмәте чыккан. Мине читкәрәк чакырып алып:

— Инде нишлибез?.. — дип миңа карады.

Мин аның соравын аңламадым.

— Нәрсә — нишлибез?

— Туйны әйтәм...

— Белмим инде. Мондый көнне...

— Чакырган кешеләргә «килмәгез» дип кире әйтеп чыгаргамы? Ул бүген мөмкин дә түгел. Инде юллар ябык — халык демонстрациягә чыга...

— Белмим, белмим... Абыйны нишләтергә?.. Кем алып кайтырга тиеш? Кайчан?..

Без Нилүфәр җиңгиләр янына бардык. Аны бер ягыннан Анифә апа, икенче ягыннан бер сестра көйләп тотып тора иде. Мин мондый хәлне белгән кеше түгел, сестрадан ничек сораштырырга дип торганда яны-

---

[1] Акайчыгым — ирем.

быэта каяндыр баягы милиция майоры килеп чыкты. Татар кешесе икән. Күбрәк миңа карап:

— Әллә кайдан күренеп тора, сез Мирза Солтановичның туганыдыр инде. Йөрәгем бик әрнегән хәлдә, барыгызның да ачы кайгыгызны бүлешәм... Биредә торуның инде кирәге калмады. Кайтыгыз, безнең машина сезнең карамакта... — диде ул. Нилүфәр җиңгинең иңбашыннан сыйпап алды. — Батыр булыгыз, Нилүфәр сеңелем... Балаларыгыз бар...

— Ә Мирза?.. Мирза мында калаҗакмени?..

— Калмый, калмый. Мәрхүмнең гәүдәсен сәгать икеләрдә — демонстрация бетү белән алып кайтырбыз. Бүген сездә торыр, ә иртәгә иртә белән без аны үзебезнең клубка күчерәбез, мәрхүм белән хушлашу сәгате шунда үткәреләчәк.

Ул бер яктан, мин икенче яктан Нилүфәр җиңгине култыклап, без больницадан чыктык. Мирза абый — калды...

Бөтен урамнарга бәйрәмчә киенгән халык тулган, шәһәр бии, җырлый иде.

Машина безне әллә нинди урамнар белән соцгородка алып китте.

Абыйлар торган подъезд төбенә кеше җыелган иде. Без машинадан төшкәч, икегә аерылып юл бирделәр. Барысы да абыйны үз итеп хәлен белергә килгән күрше-күлән — демонстрациягә чыкмаган апалар-әбиләр иде. Бер апа миннән әкрен генә:

— Энем, хәле ничек?.. — дип сорады.

Мин ничек җавап бирүемне хәтерләмим. Без кереп киткәндә абыйның үлү хәбәре инде барысына да ирешеп, җыелган халык «аһ» итеп тынсыз калды.

Нилүфәр җиңги кайтып керү белән сыгылып кына төште. Дүрт яшьлек кызы Сөмбел: «Әннәм!.. Анайым!» дип йөгереп килеп, аның тезеннән кочаклап алды. Җиңги аны, хәсрәт чиксә дә, сүнмәс бер матур хәрәкәт белән күкрәгенә кысты.

Минем дә йөрәгем кысылды.

— Кузучыгым!..[1] Менә без дә ятим калдык... — дип Нилүфәр җиңги кайгы дулкыны бәргән көйгә чайкалып зарын түгә башлады: — Мынавы һаятта мән бабандан[2] башка насыл яшайым?.. Май соңында, көннәр ысылаткач, мәне Маристанга алып барырман дигән иде. Мәнем дә бабам мари урманында туңып үлгән. Яз башында сөякләрен генә тапканлар. Кафәсендән танып, бу безнең карт бабамыз дип күмгәнләр. Кайда күмелгән ере бар, күмгән кишиләре бар дип яздылар. Мирза мәңә: «Бабаң күмелгән мазарны күрсәтермән, кабир топрагыны алып карындашларга йоллармыз» дип айткан иде... Хазыр бу дүньяда яңгызым. Мирзам, җигәрем, нә өчен мәне яңгыз башым калдырдың?.. Яңгызлыгымны кем белән пайлашыйм?..[4] Үгетеңни бир, насиатыңны айт, кайнем: нейләйем, ярдым ит...

Тиздән милиция хезмәткәрләре килеп, озакламый мәет алып кайтачакларын, шуңа тизрәк бүлмәне бушату кирәклеген әйттеләр.

Без китәргә җыендык.

— Кая, Сөмбелне без алып китик булмаса, дәү әнисен бергә каршыларбыз, — диде Диләра.

Анифә апа тиз генә Сөмбелне Нилүфәр җиңги кулыннан алып киендерә башлады.

— Менә хәзер минем тәти кызым Сирин абыйсы белән, Диләра апасы белән картыен[5] каршыларга бара. Картые пароход белән килә.

— Әннәм барамы? — диде Сөмбел.

---

[1] Кузу — бәти. Яратканда иркәләп әйтелә.
[2] Баба — әти.
[3] Кафә — баш сөяге.
[4] Пайлашу — бүлешү. «Пай» сүзеннән ясалган.
[5] Картый — әтинең әнисе. Кырым-татарча.

— Бара, бара, әннәң дә бара.

Нилүфәр җиңги, «хазыр барырман» дип, Сөмбелне тагы кочаклап алды. Мин аларга карап: «Кызың да бала, үзең дә бала. Ирсез башың ике бала белән нишләрсең?» дип уйлап куйдым.

Сөмбел миңа ияләшкән иде, мин аны күтәреп алдым да, без кайтырга чыктык. Әле демонстрация бетмәү сәбәпле шәһәр үзәгенә кадәр трамвай, троллейбуслар йөри башламаган — безгә ярты юлны җәяү атларга туры килде. Баягыча урам тулы кеше, урам тулы шатлык чәчелгән иде.

Югалтып тормасыннар өчен кайтып кына күрендек тә, Мирза абый турында бер кемгә дә әйтмәскә кушып, портка төшеп киттек. Әби белән Гөлсем апа ни кылырга да белми калдылар. Миңа Сөмбел чат ябышкан, капкадан чыгу белән иңсәмә атландырып, без тагы чаптык. Ярый әле Бишбалта ягына трамвай йөри башлаган иде.

### 31

Пароход ике сәгатькә соңлап килде. Шушы ике сәгать вакыт эчендә мин абый үлеменең — үз күз алдымда үлсә дә — күңелем ышанып җитмәгән чынлыгына ышандым.

Чынлап үлдеме соң әле ул минем Мирза абый?..
Чынлап үлде түгелме соң минем Мирза абый?..
Чынлап үлде шул, чынлап... күзләрен йомасы килми үлде...
Мирза абыкай-ыйм!..

Мин дә, Нилүфәр җиңги сыман, утырган килеш кенә Сөмбелне кочагыма алдым. «Ә картыеңа ни әйтербез, наныем? «Әтиең кайда, кызым?» дип сорар бит ул.«Үлде» диярбезме?.. Ә картыең нишләр?.. Ул бит сөенеп-шатланып минем туйга килә. Күңеле сизенә микән?.. Ходаем, нигә мондый хәбәрне әнигә мин әйтергә тиеш?.. Үз анам йөрәгенә ачы үлем угын башта мин кадыйм булып чыга түгелме соң?..»

Үзем шулай уйлыйм, үзем туктаусыз яшемне сөртеп утырам. Диләра:

— Елама инде шул кадәр... — ди.

Абыйларың үлгәч елыйсың икән шул!

Кайгы тулы ике сәгать үткәч кенә, Маркиз атавының бу ягыннан кечкенә бер пароход күренде. Агыйделдә генә зур шул алар. Агыйделдә генә чапкан ат тизлеге белән узып китәләр иде. Иделдә бик алдыра алмыйлар икән...

Пароход тавышы үзәгемне телеп алды.

Менә инде килеп тә җитте. Шатырдатып бәйләп тә куйдылар. Кырылышып халык төшә башлады. Яр буе тулды. Әллә безнекеләр юкмы тагын?.. Бар икән. Әнә кешеләрдән бер баш калку булып Раббани абый килеп чыкты. Янында Тәрҗимә җиңгинең таза гәүдәсе. Ә әни кайда?.. Тыгын җирдән үтеп иркен басма башлангач, әни дә күренде. Тик нигәдер бик ачык түгел. Абый белән җиңгинең дә гәүдәләре эреп ага башлады... Күземне сөртеп, яшемне селтәп аткач кына, дөнья элекке хәленә кайтты. Абый да мине күргән:

— Апай Сирин! — дип кул болгап миңа карап килә башлады.

Әни елмайгандай итте.

Менә инде алар капкадан чыктылар. Без үзебезчә ике куллап, ә Диләра, шәһәрчә итеп, әнине кочаклап күрешә. Әни:

— Сөбханалла! Киленем бик сылу икән! Тфү-тфү күз тимәсен. Тигезлек белән, тазалык-байлык белән гомер итәргә язсын,— дип теләк теләде. Аннары минем чалбарга ябышып, минем артка качкан Сөм-

белне күреп алды.— Бәй Сөмбелем түгелме соң анда? Кил әле, лачыным, кил әле, гөлем, кил әле, күз нурым! — дип шапылдатып сөя башлады. — Зуп-зур булган бит. Зуп-зур булган!.. Әтиең эштәдер инде? Эштәме, ә?.. Яратмады әле, җавап бирми... Эштәдер шул әтиең, эштә булмаса төшәр ие...

Мин инде тыела алмадым — Раббани абыйның күкрәгенә капландым.

— Их, абый! Раббани абый!..

— Чү, балам! Сиңа ни булды кинәт? Кеше болай шатлыктан кеше алдында җыламас, — дип әни иплэп кенә иңбашыма кагылды.

— Ходайдан сабырлыклар сора, инәй!.. Мирза абыйны үтерделәр бит!..

— Булмас! — дип Раббани абый мине күкрәгеннән этеп җибәрде. Ул кызмача иде.

— Тәңрем, тәүбә! Ул ни дигән сүз? Өнемме бу, төшемме?.. — диде әни дә.

— Их, төш кенә булса иде!

Хәбәрнең чын икәнлеге Раббани абыйга да барып җитте.

Тик ул минем шикелле җебеп елый алмый иде.

Беренче булып әни телгә килде:

— Ягез, балалар, кеше каршында җылашып тормагыз. Килешмәгәнне! Җылаудан гына үлгәннәр терелә калса, җир йөзендә мәңге-бакый җылашу гына булыр иде, — диде. Ләкин үзенең сыны каткан — ни үле, ни тере түгел, иреннәре генә дерелдәп елый иде.— Әйдәгез, күзгалдык. Инде күмеп үк куймаган булсагыз, Мирзамның йөзен күрим, күмгән булсагыз — каберен күрсәтегез, — диде әни.

Без такси тотып соцгородка киттек.

Мирза абыйны инде алып кайтканнар. Өстәл өстенә куелган зур озын табутка сыя алмыйча, гел тере кебек ята иде. Әни шунда гына абыйның битен сыйпый-сыйпый елый башлады. Ләкин аның тавышы юк, тыны юк — күзеннән генә моңарчы бөялеп торган яше ага иде. Моны күрү һәммәбезне тетрәндереп җибәрде. Елаудан туктагач та әле бик озак итеп абыйның битен сыйпап торды. Шуннан соң гына табут яныннан китеп, урындыкка барып утырды.

— Хәнифә кодагый, — дип дәште ул Анифә апага, — күрше тирәгездә татар корткалары бармы? Төнгелеккә утырырга кеше табылырмы?

— Бар, кодагый, бар. Әйтелгән.

Сәгать алты җитеп килә — инде дә соңларга ярамый иде. Диләра да тынгысызлана башлады. Ләкин сүз әйтергә базмый, миңа гына төртә. Мин әни янына килдем.

— Әни, туйны нишләтәбез соң инде? Җидегә кунаклар чакырылган. «Килмәгез» дип һәр кайсына әйтеп чыгып булмады. Бу бит авыл җире түгел...

— Ай, балаларым! Башкаемнан чыккан бит... Туйга килгән кешене кире куалар димени? Ходай тәгалә безгә биргән кайгылы үлемнең ахыры хәер-догалы булсын — ясагыз туегызны, балам. Гомер гомергә ялганмый, юньле туй да бер генә килә.

— Ә үзең бармыйсыңмени?

— Юк, улым, бара алмам. Син дә үпкәләмә, килен. Әле сезнең туйны без авылда да итәрбез, боерган булса... Раббани улым, Тәрҗимә килен, сез дә барыгыз. Мәет янында төн үткәрү сезнең эш түгел. Ә мин Мирзам янында соңгы кабат утырып калыйм инде. Хәвадисемә дә кырык бер ясин чыккан ием... Барыгыз, балалар, бар. Тик җылап-мазар итеп кунакларыгызга сиздерә күрмәгез тагы. Бу хәлне белсәләр, үзләре дә килмәсләр иде дә бит. Килгәч инде — белмәсеннәр. Барыгыз,

Лэкин безнең туй туй булмады.

Бер ни белмәгән кунаклар бик матур гына кәефләнеп, рус гадәте белән «ачы!» дия-дия, безне дә бастырып үбештергәч, ашапэчеп, инде уен-җыр кызганда гына, Раббани абый хәмердән кызып алды да:

— Бәхетле булыгыз, үскәнкәйләрем! Тик шушы кадәр дә күңелле иттереп утыруларны Мирзакай гына күрә алмады бит!.. — дип сытылып елый башлады. Тәрҗимә бер җиңеннән, мин икенче җиңеннән тартып карыйбыз, лэкин абый «ычкынган» иде инде: — Әткәй үлгәч, колхоздагы бөтен авыр эшне без икәү эшләдек, сугышны да башыннан аягына хәтле икәү тиң ярып чыктык... Ә шул энем хәзер, монда без күңелле иттереп җырлашып утырганда, менә шушындый өстәл өстендә табутларда ята... Их!.. — дип кулын селтәп, өстәлгә капланды.

«Ни булган?» да «Ни булган?» китте. Әйтеп бирүдән башка чара калмады.

Табында әдәпле, дәрәҗәле кешеләр утыра иде. Минем яктан — кафедра мөдире, өлкән укытучылар, тренерлар; Диләра ягыннан да нәкъ шундый ук — һәммәсе укымышлы кешеләр иде. Мирза абый үлемен ишеткәч, барысы да, өсләренә су сипкән төсле, бер минут тынсыз калдылар.

Билгеле инде, безнең ачы кайгыны уртаклаштылар. Туй онытылды. Әдәп йөзеннән генә бераз сөйләшеп утырдылар да, безгә озын гомер, бәхетләр теләп, берәм-берәм таралып та беттеләр.

Әнә шулай үтте безнең туйлар.

Мирза абыйның өчесен үткәргәч, әниләр кайтып китте. Озатырга мин генә төштем. Раббани абыйны каютага кертү белән урынга салдык, лэкин ятмый — «Мирзакаебыз калды бит!..» дип сикерә дә тора, сикерә дә тора, көчкә йоклап китте.

— Абый бик нык үзгәргән, — дидем мин. — Элек бер дә исерми иде лабаса?

— Үзгәрерсең дә, — диде Тәрҗимә җиңги. — Элек кунак-төшемдә генә, йә өмә-мазарда гына эчә торган иде. Ә хәзер «аз гына» дип көн дә эчә. Эчсен иде ул айга бер дә, кайда бер. Бер дә ялган түгел, әнә әнкәйдән сора.

Әни йөзен әз генә бора төшеп тәрәзәгә караган. Казан өстенә текәлгән төсле. Лэкин күрәме ул Казанны, юкмы, кайгырамы ул, юкмы,— йөзеннән бер ни сизелми, бер сыры селкенми, тик тез башына куйган сул кулы гына дерелдәп тора иде.

Әни бер сүз дә әйтмәде.

Тәрҗимә җиңги генә дәвам иттерде:

— Колхозда да тормышлар бик әйбәтләнеп бара шул хәзер. Раббани абыең шикелле кулы эш белгәннәргә акча табар җир күбәйде. Шуңа эчәләр дә... Син дә сөйләшә алмадың шул абыең белән. Бәлки син әйтсәң, әзрәк тыелыр да иде. Сөйләшерлек булдымени соң?..

Ахры әни дә телгә килде:

— Мирзакаемның газиз сөякләре ата-баба туфрагыннан читтә җирсеп ятар инде дип бик пошынган идем. Зиратлары бигрәкләр дә ямьле икән! Җәннәт бакчалары диярсең. Тукай кабере дә шунда диделәр... Безнекендә кош кунар агач та юк шул... — дип куйды. — Эшләрегез беткәч, отпускыгызда кайтыгыз әле, балам, бергәләп. Балалары белән Нилүфәр киленне дә алып кайтыгыз. Күңелләре күтәрелеп китмәсме ичмаса бер... Сөмбелкәем зур күзләре белән карап калды лабаса...

Пароход икенче кабат кычкырткач, мин чыгып киттем.

Лэкин без ул җәйне кайта алмадык. Ялга чыгу белән Ташкентка киттек. Диләраның әллә күпме туганнан-туганнары, сеңелләре-энеләре, апалары-агайлары дигәндәй шунда яши булып чыкты. Нигезләре нык — һәр кайсының үз йорты, үз бакчасы, үз мунчасы, вино базларына тикле бар иде. Сугышка кадәр үк китеп урнашкан кешеләр, — кайсы бухгалтер, кайсысы ревизор. Безнең юлга дип алган, икебезгә икемең сум акчабыз алар өчен акча да түгел иде.

Алар мине яраттылар шикелле. Әлбәттә, беренче карауда япь-яшь башым белән институт кадәр институтта укытуым дәрәҗәмне күтәрсә дә, икенче карауда ассистент буларак аена мең илле сум гына алуым, җитмәсә, аларча әйтсәк, спортсмен гына булуым дәрәҗәмне киметеп тә куйды. Алар өчен Диләраның махсус Мәскәү белеме белән кооператив техникумда укытуы ун өлеш артык иде. «Связьләрең күп булачак!» дип мактап бетерә алмадылар. Кая инде Диләрага «связь»!..

Мәгәр безне бөтен байлыкларын күрсәтеп кунак иттеләр. Чын туй шунда булды. Шулай һәр кайсында кунак була-була ай ярымны үткәреп, Ташкентыннан, байлыкларыннан тәмам туеп диярлек кайтып төштек үзебезнең үз Казаныбызга.

Аннары инде тагын, иртәдән кичкә кадәр чын-чынлап тир түгеп эшемә чумдым. Тир түкмәсә дә, Диләраның да эше минекеннән ким түгел иде.

Авылга без икенче елны да кайта алмадык. Монысына бәбәй сәбәпче булды.

Балага үтүенең бишенче аенда Диләра тын гына яткан җирдән минем уң кулымны иләп кенә тотып, биленә тартып китерде.

— Менә шуннан әз генә басып тор әле,— дип үзе үк кулымны учы белән эченә басып тотты.

Мин тынымны тыйган килеш:

— Сизәм!.. — дип пышылдадым.

Карында яткан балам нәкъ уч төбемә генә тибеп-тибеп ала иде.

Шул көннән башлап мин балам барлыгын күңелем белән генә түгел, кулым белән дә тоя башладым. Минем тар нәфесле көннәрем Иделдәй тулып-җәелеп агып китте. Диләрага да инде мин, яңа гына яралган булса да, үз баламның әнисе итеп карый башладым. Сөюем дә — икесен бергә сөю иде. Гаҗәеп тә бер тойгы икән ул — ата булачагың тойгысы! Канның тамырда күкрәк киереп агышы гына түгел, ә «мин бар!», «мин яшим!» дигәнне аяк терәп тою, тыннарны кысып алган сөенеч икән ул!

Әгәр берәр көн мин тотканда ул тибешми торса, миңа күңелсез булып китә:

— Нигә типми соң әле? — дип эчем поша башлый иде.

— Йоклый әле, ял итә, — ди андый чакны Диләра.

Бер көнне, көмәне шактый зурайгач:

— Бигрәк каты тибә — үзәкләремне ярып җибәрә инде кайвакыт! Малай булыр ахры — врач та шулай дип әйтте,— диде.

Шуннан соң икебез дә гел малай дип көтә башладык. Диләра инде: «Улың тибешә!..» генә ди иде.

Февраль аенда көткән улыбыз дөньяга килде. Ул таң алдыннан диярлек туды. Мин, сестра чыгып әйтү белән, таң атканын да көтмичә, Зур Кызыл урамыннан җәяүләп, Казан чаклы шатлык белән өебезгә кайтып киттем. Дүрт кило ярымлык малаең тусын әле!..

Мине бергә эшләгән иптәшләрем, ярышларга бергә йөргән дусларым, ничәсе ничә яктан котлап, коньягын-ниен кочаклап өйгә килеп керә-

башладылар. Хәтта хәрби хезмәтне бергә иткән, хәзер кадровыйда калган элекке спортсмен дусларыма хәтле, җаен табып, котларга килделәр. Казан шәһәрләренә сыймас шатлыгың булгач, дусларны кем кабул итмәс!

Мин көненә ике тапкыр больницага барам. Диләрадән мин улымны имезергә кайчан китерүләре, имезеп алып киткәч, кайсы бүлмәдә ятуларына хәтле сорап язу язам. Җавабын алгач, китәсе килмичә, «улым кайсы тәрәз турларында ята икән?» дип, һәр тәрәзәгә кереп чыгардай булып, больница әйләнә йөрим. Ләкин — салкын февраль, тәрәзәләргә юка бәс катып, эчтә ниләр барлыгы тышка мәгълүм түгел иде.

Бер атнадан кара «ЗИМ»гә генә утыртып, улым белән әнисен алып кайттым. Чыгарганда бер сестра зур итеп юрганга төреп кулыма тоттырган иде, кайткач юрганын чишеп, ачып җибәрсәм — бәләкәй генә, борын өсләренә сары бөрчек сибелгән бер бала имеш!..

— Сөбханалла, күзләр тимәсен! — диде әби.

Ә мин Диләрага:

— Дүрт кило ярым дигән идең бит! Шушылай гынамени?..— дип аптырап караганмын.

— Зур инде бу, кияү, зур инде! Кеше балалары песи баласы чаклы бер кызыл ит кенә була. Ә бу — әнә күзен дә ачарга итә! Тфү-тфү, күз тимәсен берүк...

Шунда улым күзләрен ачып җибәреп дөньяга карады.

— Былбылым!.. — дидем мин.

Телемә һич алдан уйлап килгән сүз түгел иде бу.

Яшәүнең мәгънәсе инде бөтенләй башка ягы белән ачылып китте. Минем өчен хәзер шушы зур җиһанда шушы бәләкәй генә бер җан иясеннән башка бер кем юк иде. Чөнки ул — әнисенә булган сөюемне дә тулысы белән үзенә җыеп алды. Бу шатлыгым миңа көннәр буена җитәрлек көч бирә: иртән «улым бар!» дип уянып китсәм, кичен дә шул сөенеч белән йокларга ята идем. Юк, мин әүвәлгечә үлеп йокламый идем инде. Улым чак кына тавыш биргән, шыгырдаган саен сикереп торып, әнисенә һич ирек куймастан, улымның чүпрәкләрен алмаштырып, төреп-биләп имезергә бирәм. Кайчак имеп тә тынычлана алмаган чакларында, тын-кара төндә ялгызым, талгын бер көйгә туктаусыз көйли-көйли, салкын идән буйлап җылы күкрәгемдә тирбәтеп йөртәм. Шулай — йоклап киткәнче.

Әнисенең күкрәге шешеп, улым акырып елаганда, шушы интеккән ике җан өчен башларымны кая куярга да белми идем. Ә улыбызны имидән аерганны мин күземә яшь тулмыйча сөйли дә алмыйм. Диләра бала күзенә күренмәс өчен иртәдән кичкә кадәр өйгә кайтмый йөри, соң гына кайтып кухня ягына кереп ята. Ә мин эшем бетү белән, хәтта кайберләрен калдырып, тизрәк өйгә чабам. Тышкы ишек ачылган саен улым, һәр тавышка һич төшенмәс бер сизгерлек белән борылып, ишеккә тилмереп карап торыр иде. Йөзләре суырылып, күзенә чын хәсрәт ачысы чыкты. «Кеше башына беренче кайгы имидән аерганда төшә» диләр иде — рас икән. Өч төн буена, җил искән бер тавыш белән, бер үк көйне көйләп, куенымнан бер илле дә аермыйча, улымның кайгысын күреп бәгърем кисkәләнде...

Менә шул улыбыз аркасында без авылга икенче җәйне дә кайта алмадык. Диләра кисеп әйтте:

— Кул баласы белән ай буе авылда ята алмыйм, син аңларга тиеш,— диде.

— Алайса берәр атна гына торырбыз.

— Баланы көйсезләпме?

— Нигә — көйсезләп?

— Сирин, — диде Диләра, — әйдә быел ялны шәһәрдә генә үткәрик. Мин аз-азлап кандидатлык минимумын да әзерләрмен. Ташкенттан да берәрсе килеп чыгуы бар. Миннән дә болайрак үзең бит: «Киләсе елга безгә рәхим итегез» дип кат-кат чакырдың. Ә авылга киләсе ел кайтырбыз. Ул чагында инде Хәсәнгә дә яшь ярым була, — дип гадәтенчә мине күндереп тә куйды. Аннары, тагын гадәтенчә, теләсәң нишлә дигән бер тавыш белән: — Үзең кара алайса, бик кайтасың килсә, кайт, — диде.

— Әйттең сүз! Нишләп мин улымнан башка кайтыйм.

Чынлап та, әни хат саен: «Хәсәнемне күрәсем килә, кайчан шул баламны күрсәтәсез инде? дип яздырганда, мин нишләп, бер буйдак төсле, ике кулымны селтәп өйгә кайтыйм ди!

Шулай калдык. Ташкенттан да килмәделәр, Диләраның минимумга әзерләнүе дә бик минимум гына булды.

## 33

Без авылга — өйләнешкәннең өченче җәендә генә кайттык.

Гомер үпкә сүз әйтмәгән әни үпкәләп алды:

— Самолетка гына утырып, Актанышка час арасында кайтасы юл — ике ел тилмертәсең кайтмыйча. Сезне уйлап саргайганны кеше генә сизми бит! Болай да инде Хәвадисем белән Мирзам сәгатенә ничә искә төшеп, барган сукмакларымнан чыгып китәм.

— Яныңда ике улың бар, мин дә исән, бик бетерешмә инде, инәй, — дидем мин.

Бер ара әни үземә генә сүз катты:

— Шул Әдрәнгә әйт әле нык кына итеп — өйләнсен инде. Гөл кебек кызлар китеп бетә ләбаса! Аның да бәбәйләрен күреп үләсем килә,— диде.

Ләкин Әдрәннең өйләнергә исәбе юк иде.

— Әтәйдән калган иске өйгә ничек яңа кәләш алып кайтасың? — дип шаяртып җавап бирде.

— Бүрәнәңне кайтарт та — сал яңа өй. Трактор үз кулыңда. Сиңа нәрсә!

— Шул-шул: трактор үз кулымда. Үз кулымда булмаса, мин инде бүрәнәсен түгел, урманын кайтарткан булыр идем. Шул тракторга эт кебек бәйләнгән. Күз юк, кыш юк... Менә әле — болында. Печәнен дә трактор белән генә чабабыз бит хәзер!..

Без кайткач, Әдрән бер көнен, ял сорап, безнең белән үткәрде. Безне ул — улым, Диләра — өчебезне «матае»на утыртып, болынга алып чыгып китте. Агыйдел буеның әле чабылмаган, гел җиләк, гел чәчәк, гел кояш җирендә хуш ис иснәп, сулар кереп, ял итеп яттык.

Кире кайтканда гына чак бәлагә тармый калдык. Юл аша колхоз көтүе чыгып килә иде. Әдрән кычкырта-кычкырта барганда бер коба сыер аягын икегә аерып, йомышына кереште. Ярый, Әдрән туктатып өлгерде, юкса бәласе зур булачак иде. Сыер бер ни булмагандай китеп барды, ә «матай»ның моторы сүнде. Әдрән беребезгә дә охшамастан кызу канлы иде, сикереп төшеп:

— Юл өстендә нитмәсәң, башка җир беткәнмени сиңа! Сыер!.. — дип башта сыерны кыйнап килде, аннары, моторын бик озак кабыза алмый

интеккәч, үзен сүгеп ташлады: — Юньле кеше кешенең искесен аламыни? Юньле булса, аны сатмыйлар да. Бер туры китереп, җә хуҗасын ярам, җә «матаен» Тоба ярыннан атам!..

Ул тынычланып беткәч кенә:

— Сиңа чыннан да өйләнергә кирәк, апай: бик нервынныйлана башлагансың, — дидем мин.

Аннары без өйгә кереп кенә чыктык та, базарлы авылга киттек. Инде базары булмаса да, ни өчендер шул авыл гел сагындырып йөдәтә — кайтсам күрми китә алмый идем.

— Кибеткә дә керербез, — диде Диләра.

Ләкин кибетләре ябык булып чыкты.

— Монда коньяк өзелми торган иде — булмады, — диде Әдрән. — Үзебезнең магазин кала, тик анда шул «акбаш» кына инде.

— Миңа дисәң, миңа берсе дә кирәкми, — дидем мин.

— Алай итмик инде, абый. Болынга да алдырмадың, өйдә бераз кабып куярбыз. «Абыйсы кайтты, ярты да алып эчермәде» дияр ату Җәмилә.

— Алырсың инде алайса, — дидем мин көлеп.

Без кайтып үзебезнең авыл кибетенә кердек. Яртыны гына сорагач, сатучы кыз Җәмилә майлы елмаеп Әдрәнгә карады:

— Кит әле моннан, тау чаклы гәүдәгезгә бер ярты сорап торасың, оялмыйча! Әллә нигә бер кайткан абыеңа ящигы белән ал. Синең бер яртың белән мин ничек план тутырыйм ди?..

— Җә, телеңә бик салынма,— диде аңа Әдрән.— Планыгызны Раббани абый тутырган да житкән.

— Одеколон белән генә бик тутырып булмый шул...

— Әйтер идем инде, жиңгәй бар,— диде аңа Әдрән. Ә чыккач:— Нервынныйланырсың да! Шул кәнтәенә кадәр көлсен әле. Юри сезнең алда әйтә ул,— дип Раббани абыйдан зарланып китте.— Одеколон да капкалый инде, гел аракыга каян җиткерәсең?.. Жиңгәй әйтеп жиңгәй сүзен тыңламый, инәй әйтеп инәй сүзен тыңламый. Бер мин тыеп торудан нәрсә? Мин дә бит камчылы ишан түгел. Киткәнче бер сөйләшер идең, Сирин абый...

## 34

Бер көнне кич, Диләрага «соң гына чыгармын» дип әйтеп, Раббани абыйларга кердем.

Тагын үрчегәннәр — бишектә инде дүртенче балалары елап ята иде. Аны сигез яшьлек кызлары тирбәтеп утыра. Ләкин сабыйга ими кирәк, ә Тәрҗимә казан тирәсендә кайнаша иде.

— Имез әле балаңны. Йөрәгем әрни бала елавына,— дидем мин.

Тәрҗимә баласын имезергә утырды.

— Абый кайчан кайта соң?

— Кайтырга бик вакыт та бит — юк. Сәрхушлеккә китсә — белмим инде...

— Көн саен шулаймени?

— Шулай булмый! Эчми кайткан көне бик сирәк.

— Тавыш чыгармыймы соң кайткач?

— Гөнаһына керә алмыйм, андый гадәте юк. Затыгызда юкны! Ачуым килеп үзем генә кыздырып җибәрмәсәм, талаш-тиргәшне белми. Бер кемгә начар сүз әйтмәс, бер кемгә бәйләнмәс. Үзенә дә бәйләнмиләр.

Кем йөрәге житеп бәйләнсен инде аңа? Сугу түгел, тотса да — кара яндыра бит!..— дип Тәрҗимә, имеп туйган бәбәен бишеккә салып, татын кызына тирбәтергә кушты, үзе сөйләнә-сөйләнә токмач кисәргә тотынды.— И Сирин! Эш аның өйдә тавыш чыгармавындамени? Өйгә акча кайтмый бит, акча!.. Тимершәех абый ни әйтүенә әйтте: «Китмә колхоздан, китмә, тиздән колхозлар аякка басачак», диде. Китте. Акчага эшлим мин дип кирпеч заводына барып керде. Вәссәләм — акча да юк, икмәк тә. Клуб чаклы өй салып кердек тә, шуннан ары китмәдек. «Тамак ач түгел, өс шәрә түгел, ни кирәк?» ди. Ничек инде кирәкмәсен? Әле ярый балалар вак. Үсә башласыннар әле менә! Колхозда бит ул бер үзе җиде кешелек эшли иде. Ә монда күпме эшләсәң дә — алты йөз тәңкә. Сәгатеннән соң кешеләргә бура бурап, капка-койма ясап, мунча салып йөри. Акчасын эшкә керешү белән ала башлыйлар: утыз тәңкә дә илле тәңкә — эчәргә инде — эшләп бетерүләренә бер тиене калмый... Көләм дә инде. Быел яз Сабираттәйләргә ак мунча салырга сөйләшкән. Ун көн эчендә гөл кебек иттереп салып та куйды. Бер үзе бит! Мунча алларына кадәр бүрәнәдән бураттылар. Май бәйрәме житте. Һәр кем хәленчә кунак җыйган буласың бит инде. Сабираттәйләргә дә Ижаудан туганнары кайтып төште. Аракы каян житкерәсең, бал койганнар инде. Кунаклары бәйрәм итте дә китте. Бәйрәмнән соң безнекенең дә башы авырта, иртән барган бу Сабираттәйләргә. «Сабираттәй, башым чатный, калмадымы балың?» дип сораган. «И Раббаникәем, калмады шул, эчеп бетерделәр» дигән. Минеке: «Чүпрәсе дә калмадымени?» дип сорый икән. «Чүпрәсен әле генә сыерга ашаттым шул» дип әйткән Сабираттәй. «Алайса мунчаңны да сыерың салып бетерсен» дип, минем дивана — инде бетте дигән эшен ташлап кайта. Ике ишек куеп мичен чыгарасы калган. Бүтән кеше эшләп бетерде. Акчасын да алмаган, миңа кертеп бирде Сабираттәй. «Нигә алдың?» дип бер көн буе табалады абыең. Көлке дә, гыйбрәт тә инде.

— Бал дигәннән, умарталарыгыз исәнме әле?— дидем мин.

— Әнкәй, әтиеңнең вәгъдәсе булган дип, биш башын безгә биргән иде. Кем карасын инде аны. Раббани аның белән пычранмый. Үз тамакларын үзләре туйдырырлык бал җыялар шунда. Әткәй үзе дә киметкән иде инде ул умарталарны. Биш башын Җәзилә алып китте. Рәҗимә апа көтүгә ялланып килгән бер карт егетне йортка керткән иде. Аның да умартага кулы ятмый. Бер унлабы исән бугай әле. Әнкәй үзе карап яткан була.

— Шулай, һәр нәрсәгә белгән кул кирәк,— дидем мин.

Күрешмәгән ике ел эчендә Тәрҗимә бик картайган иде. Минем яшьтәш. Диләрә белән дә яшьтәш. Ә Диләрә янында өлкән бер апа иде инде бу. Дүрт бала, борчулы тормыш... Әллә ниләре бардыр әле, барсын да сөйләмидер генә. Шулайдыр инде ул.

Тәрҗимә тагы сөйләп китте:

— Быел Әдрән җайлап кына: «Әллә, Раббани абый, дәваланып карыйсыңмы? Әле бит соң түгел» дип әйткән иде. Каралай көеп чыкты абыең. Сабырлыгы җиңеп кенә өстенә җикерүдән туктап калды. «Әллә мин бер алкоголикмы? Теләсәм мин иртәгәдән үк туктый алам» дип бик гарьләнде. Шуннан сүз кузгаткан юк әле. Менә син кайтсын дип тордык. Эчеп алгач бар эше шул: «Мирзакаем... Хәвадискәем...» дип җылый. Сине дә еш искә ала. «Сириннең безне ташлавы шул микәнни инде, кайтып күренми дә» дип. Син кайтканга бик сөенде инде. Салуын да киметте...

Раббани абый сәгать ун тулгач кына кайтып керде. Бераз кызмача гына иде. Кесәсенә яртысын да тыгып кайткан.

— Кереп бик әйбәт иткәнсең, апай,— дип аркамнан килеп сөйде дә, өстәлгә аракысын чыгарып утыртты.

— Акчага мулкыгансың икән!— диде Тәрҗимә мыскыллап.
— Баш исән булса, акча табыла ул.
— Үтечкә алдыңмы?
— Нигә, үтечкә алу гаеп эшмени?
— Үтечкә эчкән — ике исергән,— диде Тәрҗимә.

Шунда Раббани абый, кесәсеннән учы белән йомарлап алып, өстәлгә гел уңлыклар чыгарып салды.

— Сана, не отходя от кассы. Биш йөздән артык булырга тиеш. Эштән соң РТСта культиватор ремонтлаган идек.— Аннары ул миңа карап:— Җиңгәң телгә-тешкә бик шәпләнде әле, Сирин, нишләргә?— дип көлде.

— Шәпләнерсең дә. Сиңа килгәч күпме тешем төште!..

— Дәүләттә тимер бетмәгән, куйдырырбыз. Тырма теше кебеген үзем дә ясый алам,— диде Раббани абый.— Хәер, теш булмаса, эчәргә җиңел була ул.

— Әйтәм җирле син бик авыр эчәсең, шул тешләрең таза булгангадыр инде.

— Җә, Сирин кергәч кенә телләшергә ясканып торма әле. Кая, кабарга бирәр нәстә бир дә...

— Аракы булса, чабата да ашыйбыз дисең бит,— дип Тәрҗимә аш бүлә башлады.

Раббани абый шешәсен ачты.

— Синең эчмәгәнне беләм, апай. Шулай да ничә елга бер күрешү хакына үткән хәтле генә кабып куярсың инде. Кайтмыйсың да...

— Үпкәләмәгез инде, туры килмәде. Мин дә семья кешесе бит хәзер,— дидем мин.

— Җә, булды. Үзең үпкәләмә. Нигә Нилүфәр киленнәрне алып кайтмадың?

— Алар июнь башында гына Фирганәгә китте. Кырымнар шунда җыела икән. Абыйлары да шунда төпләнгән. Калуы да бар әле җиңгинең.

— Мирзаның еллыгын үткәрдегезме?

— Үткәрмичә!.. Бөтенләй әйтергә онытканмын икән: участоклары урнашкан урамга Мирза абый исемен куштылар бит.

Раббани абый озак кына башын иеп утырды да, айнып киткәндәй:
— Их, Мирза, Мирза!..— дип кукрәгенә сукты.— Мәнә шушыны өзгәлиләр бит алар... Мирза да, Хәвадис тә...
— Исермә,— диде аңа Тәрҗимә.
— Димәк, Казан урамында безнең фамилия дә бар.
Раббани абый, кайтканда, тыштан гына исерек күренмәгән икән, аз гына эчү белән исереп тә китте.

— Кайтып торма инде, апай. Ак якка гына кереп йокларбыз. Сөйләшәсе сүзләр дә бетмәгән,— диде ул.

Тәрҗимә безгә ак яктан урын җәеп бирде. Раббани абый яртылаш та эчелмәгән аракысы белән стакан да алып чыкты. Ләкин Тәрҗимә теге яктан ишекне ябып кую белән урынына ауды. Шул килеш — тынды да. Мин дә аңардан күп калышмадым бугай...

Җилкәмә бер авыр нәрсә төшкәнгә куркып уянып киттем. Абый торып утырган да, минем өскә кулын куйган икән.

— Нишләп тордың әле?— дип сорадым.
— Сине әллә кая алып китәләр икән дә, аерылабыз икән дип куркып уяндым,— диде Раббани абый.
— Сәгать ничә соң әле?

— Өчтер. Гел шулай төнге өчтә уянып китәм. Әле беренче этәч кенә... Ник кычкырмый соң әле ул этәч?..

— Йоклыйк әле, Раббани абый, ят,— дидем мин.

— Син йокла. Мин инде йоклый алмыйм.

— Йоклый алмасаң, күзеңне йоммыйча, ачкан көе генә сан санап ятып кара әле. Мин үзем ярышка бик нык әзерләнеп, йокы качкан вакытларда гел шулай итәм.

— Файдасы буламы?

— Була.

— Ә мин хәзер эчмичә йоклый алмыйм,— диде Раббани абый.— Кая, кичтән безнең калган булырга тиеш бит?

— Әнә тәрәзә төбендә.

Раббани абый ут кабызмыйча гына тәрәзә янына китте. Тәрәзәдән, упкындай, болытлы кара төн күренеп тора иде. Беленер-беленмәс кенә яктылык төшкән. Аны да абыйның караңгы өйдә зураеп киткән кара гәүдәсе каплады. Өнсез тынлыкта тирән стаканга, шешәдән тын да алдыртмыйча, аракы агызган тавыш ишетелде. Йокым ачылган иде инде.

— Менә һәр вакыт шулай, апай. Уянам да, миллион уйларга батып ятам. Башым шундый нык эшли — әллә ничә айларга алга китеп, күкнең читенә җитеп уйлый. Ә кайвакыт бөтенләй томаланып, кара болыт шикелле, өсле-өсле кара уйлар өелеп килә. Мин тең үзем кара камерада ятам икән төсле тоела, йә кабер кебек була башлый... Әллә нинди хәшәрәт бөҗәкләр өстемә килеп, битемә-күземә, богазыма тулалар кебек. Моны бер кемгә дә әйткән юк иде әле... Теге, сугыштан кайткач йөри алмый яткан аягымның чире дә сизелә башлады. Торып-торып аягым юкка чыккандай була...

— Сиңа аракыдан дәваланырга кирәк, абый.

Ләкин ул бу сүземә җавап бирмәде, кара тәрәзәне каплап, бик озак сүзсез басып торды...

## 35

Раббани абый белән мин тагы бер тапкыр, бу юлы инде иркенләп сөйләштем. Һәр хәлдә, без Казанга кайтып киткәндә, пристаньга озата төшкәч, үзе әйтте:

— Борчылып китмә, апай. Мин синең киңәшне уйладым. Тик җәй көне барып ятып булмас больницага, көзгә инде,— дип калды.

Ләкин көз җитте, кыш керде. Хат саен сорап язсам да, «һаман шулай» дигәннән башка хәбәр ала алмадым.

Февраль ае иде инде. Авылдан хат килеп төште. Энем Әдрән язган иде.

«Раббани абыйны мәҗбүри дәваларга җибәрделәр. Бер көн эштән кайтсам, дүрт баласы белән бездә җиңгәй утыра. Абзый куып чыгарган. Йөгереп өйләренә бардым. Ишекне эчтән бикләгән. Шакылдатам. «Ач!» дип кычкырам. Ачмый. Үзе эчтә ишек төбендә тора. «Ач!» дип шакылдаткан саен: «Якын килмәгез!.. Минем бер гаебем юк!.. Мин сугышның башыннан азагына кадәр сугыштым!.. Мирзаны да шулай алып киттеләр!..» дип акырып елый. Кыскасы, аракыдан тилерүе башланган, диделәр. Арып йоклап киткәч кенә, участковой белән тәрәзәдән кереп, бәйләп, үзебезнең больницага илтеп тапшырдык. Ләкин икенче көнне үк, больницаның ике кат тәрәзәсен бәреп төшереп, качарга уйлаган. Киселеп-каналып беткән. Шундук тотканнар, билгеле. Кыш өстендә буй-буй халат белән, оекчан килеш кая качасың инде.

Аннан Уфага озаттылар. Хәзер шунда. «Лечхоз» дигән җирдә. Эшләтеп дәвалый торган җир инде...»

Менә сиңа Раббани абый! Гомер буе җыеп килгән сабырлыгын чыгарып түккән икән! Сизенгән идем шул мин моны... Үз аягы белән, әйбәт кенә, больницага үзе барып кергән булса!.. Хәер, нәтиҗәсе барыбер бер инде.

Мин икенче көнне үк Раббани абыйга хат салып җибәрдем. Ләкин җавабы ике ай үткәч — апрель урталарында гына килде. Хат язарлыгы булмаган күрәсең. Ул үзенең байтак вакыт чирләп ятуын, хәзер инде аякка басып эшли башлавын язган. Чыгарулары тиз генә күренми әле дигән.

Без, һәр елдагыча, апрель-май айларында вакыт житкерә алмыйча җәйге ярышларга әзерләнәбез. Ә шәһәрдәге җаваплы ярышлар күбрәк апрель ахырында була. Шуңа күрә, бик теләгем булса да, бу ике айда мин бер көнгә дә китә алмый идем.

Ләкин миңа абый янына бармый калу һич тә ярамый. Үзем белмәгән бер сәбәп белән Уфага барасы килү теләге көннән-көн арта барды. Күңелнең тыярга көч җитмәгән тартылуы иде бу. Дөрес, имтихан башлангач, без дә бераз бушанабыз. Анда инде мин болай да ике-өч көнгә генә сорап китә алам. Ләкин минем уй — Уфадан кайтышлый әниләргә сугылып, берәр атна торып килү иде. Чөнки быел тагы кайтып булмаячак: быел инде чыннан да Ташкенттан Диләраның туганнары киләчәк иде.

Минем ялга чыгу графигы июньнең егерме бишеннән диелгән. Мин шуны бу табарак — июнь уртасынарак күчереп булмасмы дип, үзебезнең кафедра мөдире янына кердем. Графикны вату бик кыен булса да, сәбәбен аңлаткач, отпускыны ун көн алга күчерергә ризалашты инде, ярый.

Мин җыена башладым. Китәр көн якынлашкан саен минем күңелем Диләра белән тора башлаганнан бирле бөтенләй булмаганча күтәрелеп, Диләраны шиккә салган. Һәм моның ахыры яхшы бетмәде. Без, өч елга беренче тапкыр, бик зур сүзгә килештек.

Инде самолетка билетлар алып, очып кайтып керсәм, Диләрам хәсрәт кискән бер йөз белән, кашын күзенә төшереп, тәрәзәгә текәлеп утыра.

— Ни булды? Әллә авырыйсыңмы?— дип янына бардым.

— Булмады, кит янымнан!..— ди.

— Әллә эшеңдә берәр борчу бармы?

— Юк. Сораштырма зинһар...

— Ә нигә балтаң суга төшкән кеше кебек утырасың?

Монысына бөтенләй җавап бирмәде. Мин дә киселеп туктадым. Тик әби генә кайчанга билет алуымны, ничек алуымны сораштырып, хәлемә керергә тырышып йөрде. Чәйгә дә без йомган авызыбызны ачмый дигәндәй утырдык. Әби:

— Ни булды сиңа, кызым Диләра? Ник болай кәкре кыяр кебек утырасың?— дип сораган иде, Диләра эчә башлаган чәйләрен чайпалдырып читкә этәрде дә, чыгып ук китте.

Башыма кистереп кенә сызлау капты. Ике абый үлеменнән соң башым әз генә борчылуны да күтәрә алмый — ике чигә кан тибеп сызлый башлый иде.

— И балалар, балалар!— диде әби.— Гөл төсле яшьлектә сөешеп туймый яшәр урынга!.. Әйтим инде алайса үпкәләвенең серен: синең Уфага китүеңне яратмады. «Абыйсы өчен генә бармый ул анда», ди. Кайләбрәк китәргә тырыш инде, кияү. Каты күз белән каты сүзгә күнекмәгән, йомшак сүзеңне кызганма. Мин дә әйтермен.

Диләра Гөлсем апаларга киткән булган ахры, кич кенә кайтып керде.

— Йә, үпкәң беттеме инде? — дип иңбашына иләп кенә кулым салдым.

— Ал, пожалуйста! Юмалама! — дип кулымны бәреп җибәрде.

Мондый хәлне бер дә күрмәгән улыбыз тын булып, хәтта куркып, безгә карап тора башлады. Ләкин әнисенең, баягы катылыгы сынса да, бирелергә исәбе юк.

— Уфага син абыеңнан бигрәк Любовь Васильевнаң өчен барасың..— дип әйтеп салмасынмы! Ә үзе «эләктеңме!» дигән шат бер мыскыл белән күземә текәлде.

— Каян актарып чыгардың әле син аны? — дидем мин.— Гомердә теленә алмаганны? Мин бит сиңа аны өйләнешкәнче үк әйттем. Әйтмәгән булсам бер хәл иде. И без синең белән ул исемне мәңге телгә алмаска сөйләштек. Күптән беткән, өзелгән... Яшьлектә кем кемне сөймәс!

— Кәрләреңне дә югач, квартирасында да тоткач... сөйгәнсеңдер инде!..

— Әле син хатларын да эзләп укыдыңмени? Бусын инде мин синнән бөтенләй көтмәгән идем... Мин бит синекеләрне укымыйм.

— Бик укыр идең дә — минем кадерләп төреп куйган хатларым юк шул.

— Ә мин кеше хатын укуны үземә түбәнчелек саныйм. Моны, беләсең килсә, кеше серенә төнлектән керү диләр.

— Ә-ә, авырткан җиреңә тидемени?

— Максатың шул түгел идемени? Әллә тагын сүзеңне «кадерле иремнең авырткан җиренә тимим әле» дип башлаган идеңме? Рәхмәт, максатыңа ирештең...

Әйтешү шуның белән бетте. Ләкин ярасы ачылган бәгырь әрни башлады.

Икенче көнне мин иртә белән Уфага очтым. Диләраның дәшмәвенә карамастан, ул иртәдә минем күңелем, бала чакта базар барасы таң шикелле, сөенеч белән тулган иде.

## 36

Уфада минем эшем юк иде. Гостиницага урнашу белән, мин абыйны эзләп киттем.

«Лечхоз» дигәннәре бөтенләй шәһәрдән читтә — бүген генә үзем очып төшкән аэродром ягында булып чыкты. Элек шәһәрнең бәрәңге утырта торган җирләре иде бу. Хәзер чокылып-актарылып беткән: Черниковскийга таба яңа шәһәр төзеп яталар иде. Мин шул тирәдә трамвайдан төшеп Кариделгә борылдым. Уфа тирәсенең иң ямьле җире, булса да, шушы тирәсе булыр. Бик аста Каридел. Ләкин ул — турыдан күренми, фанера заводы ягыннан гына сызылып күренә иде. Уң якта — Шайтан тавы кыясы. Ә каршыда, иң аста, өстеннән атлап кына китәсене китергән яшел урман офыкларга җитеп югала иде.

Мин «лечхоз»ларын бер больницадыр инде бу дип килсәм, ул әллә кайдан әллә кая җир биләп торган, бәләкәйрәк авыл чаклы бер хуҗалык булып чыкты. Зур капка янында каравыл өе. Шунда утырган сакчыдан абыйны сорап кергәч, мин кая барырга да белми аптырап калдым.

— Туры бар! — дип кычкырып калды миңа сакчы.

Мин ике яктан да агач корпуслар тезелгән сөзәк урам буйлап аска таба киттем. Көндезге аштан соң йоклап торган вакыт иде. Корпус буйларында уңып беткән пижамнар кигән ирләр утыра. Ләкин алар миңа, бер тиле кеше күргән сыман, бик тә сәер итеп карап калалар иде.

— Сирин, апай!..

Тавышка әйләнеп карасам, читтәге бер корпус янында бер үзе генә утырган абыйны күреп алдым. Ул тиз генә сикереп торып, миңа каршы килде дә, кысып кочаклап алды.

— Капкадан кергәнеңне күргәч үк сиңа охшатып куйган идем куюын, тик башта син булырсың дип уйламадым да.

Без шундагы эскәмиягә утырдык.

— Әллә монда акылга зәгыйфьләр дә ятамы? — дип сорадым мин.

— Күп эчсәң, зәгыйфьләнерсең дә! Мине китергәндә күрсәң — куркып качар идең әле... Җә, ярар, монда безнең брат күп булыр. Үзеңне сөйләп җибәр. Нинди эшләр белән килеп чыгасы иттең? Кайчан килдең? Үзең генәме?..

— Үзем генә,— дидем мин.— Бүген генә килеп төштем әле.

— Ни йомыш белән?

— Бәй, синең хәлне белергә килдем. Язган идем бит.

— Бик рәхмәт инде, апай, бик рәхмәт...

— Бер уңайдан авылга да кереп чыгармын дидем.

— Уфада күпме булырга итәсең соң әле?

— Менә сине күрдем — Уфада эшем бетте.

— Соң алайса бергә кайтырбыз!— диде абый шатланып.

— Сине җибәрәләрме соң?

— Курс лечения тәмам!— диде абый мактангандай.— Өченче көн Терегулов, безнең баш врач инде, мине үзенә чакырып алды да әйтте: «Синең сыман эшчене үз хуҗалыгымда гына тотар идем, но ләкин дәвалану срогың бетте, ди. Мәгәр соңгы сүзем шул — безнең дәваның синең гомер буена җитәрлек көче юк, ул көч үзеңдә, ди. Эчүдән тыелсаң — үзең тыеласың, тыелмасаң — кәкрәеп катасың. Исеңнән чыгарма» дип выписывать итте. Менә расчет алырга көтеп тора идем әле.

— Нинди расчет?— дидем мин.

— Нинди булсын! Монда эшләгән өчен. Көненә ике-өч нормаларын эшләп килдем бит! Бар эшләгәнемне ашап та, эчеп тә бетермәгәнмендер әле. Чүдеки дүрт айның өч аен эшләдем бит...

Без сөйләшә-сөйләшә Каридел буеннан урап мендек. Аннары абый расчет алырга дип бухгалтериягә кереп китте. Аннан ул зур сөенече бар бер малай сыман килеп чыкты. Эшләгәне өчен — ашаудан-эчүдән калганы — мең ярымга якын акча биреп чыгарганнар икән.

Ул бүген үк шәһәргә минем белән китәргә талпына башлады. Ләкин:

— Бүген чыксаң кайда кунарсың, гостиницалар тулы,— дигәч, уйга калды.

Ул мине бүген Любовь Васильевналарга кайтып кунар, үзе дә шунда сыяр дип уйлаган икән. Любовь Васильевнаның иргә чыкканлыгын, инде аларга барырга ярамаганлыгын әйткәч:

— Әх, шәп маржа иде!— дип, телләрен шартлатып куйды.

Без иртәгә, сәгать уннан да калмый, мин туктаган «Астория» гостиницасында очрашырга булдык. Бүләк-күчтәнәч кебек нәрсәләрне мин бүген үк алып, иртәгә пароходка төшәргә сөйләштек. Раббани абый дүрт баласына дүрт төрле әйбер алырга кушып, миңа дүрт йөз сум акча бирде.

— Үзең беләсең инде: ике малай, ике кыз. Барысына да кием-салым булсын. Икеләнеп торма — кара корсак авыл балаларына теләсә ни ярый, тот та ал, нык кына булсын,— дип калды.

Диләра белән ямьсезләнеп китү сәбәпче булдымы, әллә яшьлек хатирәләре биләп алды — Уфа җиренә аяк басу белән күңелем җилкенеп Любовь Васильевнаны күрәсем килә башлады.

«Лечхоз»дан шәһәргә кайту белән, сәгать алты тулар алдыннан, ул эшләгән техникум тирәсендә йөреп торырга уйлаган идем. Ләкин, ни кадәр ашыксам да, алтыга кайтып өлгерә алмадым. Шулай да «Совбольница»да төшеп, йөрәгемне хатирәләр сагышына салган килеш, өйләре турысыннан урап килдем. Тик тын урам, тын өйләр Любовь Васильевнаны йоткан шикелле иде. «Кач моннан! Кач тизрәк!» дип, йөгерә-атлый, кире трамвай тукталышына киттем...

Ә иртән сәгать сигездә мин Якут паркы белән техникум арасын тапгап йөри идем инде. Любовь Васильевнаның әле бу вакытта килмәвен дә беләм. Ләкин, таңнан торып, нинди йөрәк сәгать җиткәнне көтеп утыра алыр икән!..

Миңа ни өчендер, үзем шулай иткәнгәме, Любовь Васильевнаны ире озата килер сыман тоела иде. Көнчелек түгел, ләкин ниндидер бер кызыксыну белән минем шул ирне күрәсем килә башлады. Нинди икән ул — отставкадагы полковник?..

Сәгать тугыз туларда инде мин урамның каршы ягыннан авиация институты тукталышына юнәлдем. Любовь Васильевна шунда төшеп, нәкъ шул турыдан урамны кисеп чыгарга тиеш иде.

Мин почмактагы сары йорт капкасына сөялеп, килгән-бер трамвайны көтеп ала башладым. Күрми калмагаем дип, йөрәк түземсез тибә дә тибә. Тик нигә тибә ул?.. Барысы беткән, өзелгән бит инде: мин — башканыкы, ул — башканыкы. Ләкин йөрәк барыбер тибә...

Ниһаять — әнә ул! Яшьрәк булганым өчен генә миннән киткән коя-шым!.. Ул ишектән чыкканда трамвайның минем якка төшкән күләгәсе дә юкка чыккандый булды. Любовь Васильевнаның да күз текәп көткәнемне күңеле сизми калмаган: әнә ул да, ишектән төшкәндә үк, миңа карап төшә иде.

Туп-туры минем янга чыкты.

— Сережа! Сереженька! Син түгелме соң, ходаем?!.

— Мин, Любовь Васильевна! Мин!..— дидем мин.

Беренче тойгы — кулларының, тиресе купшакланып, картаюы булды. Күз төпләренә дә, сизелеп, берничә сыр төшкән. Чынлап та, ул бик тиз картаеп киткән иде. Тик күзләре — шул. Мине үтәли күргән төсле, бетмәс ягым-ярату белән түгелеп карап тора иде.

Хатирәләр!.. Аның мине бик нык үрелеп үбеп алулары; минем аны, җирдән аерып, кочып сөюләрем — инде булган кебек тә түгел, матур төштәй сурәте генә хистә калган... Ә чынлыкта исә ул матур төшне хәзер кабатлый алмыйбыз. Менә шушылай — тән җылысын кулга, җан җылысын күзгә генә түккән килеш — карашып тик торабыз. Ике арада инде киртә бар иде. Иде...

«Кайчан килдең?», «Нигә килдең?» дип сорамады.

— Бәхетле яшисеңме соң, Сереженька?..— дип сорады.

— Рәхмәт, әйбәт яшибез. Улым-былбылым бар...— дидем мин.— Үзегез ничек яшисез соң, Любовь Васильевна? Үзегез?..

— Хатын-кыз ничек яшәсен инде! Ирем бик сабыр холыклы. Бик хөрмәт итә...— Ул тагы туп-туры иттереп күземнең эченә карап торды. Бу юлы инде пышылдап кына:— Сереженька, кадерлем! Мин беләм, син бит бәхетле булырга тиеш!..— диде.

Ләкин аның шушы, пышылдап кына түгел, ялынып диярлек әйткән сүзләре йөрәк итемә килеп кадалды.

Шунда мин аның, китәргә вакыты җитеп тә, китә алмый торуын сизеп алдым.

— Мин бүген китәм, Любовь Васильевна. Рөхсәт итсәгез, соңгы тапкыр, әйдәгез мин сезне озатып куям.

— Юк-юк, Сережа, ярамый. Берәрсе күреп, иремә җиткерүе бар. Болай да инде күршеләрнең чыш-пышы күп булды. Ярый әле, акылым җитеп, соңыннан үпкәсе-нисе булмасын өчен, үзенә чыгарга риза булуымның бер шарты итеп, синең турыда башта ук үзем сөйләгән идем...

— Мин дә нәкъ шулай иттем бит!— дидем мин.

— Китче! Чынмы?..— дип йөзләре кабынып китте.

Мин Любовь Васильевнаның хәлен аңладым. Һәм без, ашыга-ашыга, инде мәңгегә хушлаштык.

— Инде йөрәгем бөтенләй басылган шикелле булган иде бит, Сереженька, ах!..— дип яңадан күзләремә карады да, дөньясына кул селтәгәндәй, бетеп-басылып китеп барды.

Әкрен генә институт ягына чыкты. Әкрен генә техникумга таба юнәлде. Миңа бер тапкыр да әйләнеп карамады.

Аның белән бергә яшьлегемнең бердәнбер мәхәббәте китеп, урынына тик кызганулы бер хис кенә торып калды...

## 37

Раббани абый мине гостиница төбендә көтеп тора иде инде. Без, кичә мин алган бүләкләр өстенә, кочагы белән клиндер, сохари ише нәрсәләр алдык та, такси тотып пристаньга төшеп киттек.

Пароходы да безне генә көтеп торган төсле иде. Без төшү белән утырта да башладылар. Билетка да мин белгән вакыттагы кебек су буе чиратлар беткән. Исең китәрлек иркенлек — бер нинди чиратсыз икебезгә бер каюта алдык.

Икенче көнне кичке тугызда без өйдә идек инде.

— Инәй, менә апайны да алып кайттым әле!— диде Раббани абый.

Әни минем аркамнан сөеп:

— Үзең генә кайттыңмени, балакаем? Килен белән оланым кайтмадымени?..— диде.

— Алар Казанда калды, инәй. Диләраның отпускысы түгел әле. Мин Уфага Раббани абыйны күрер өчен генә бардым. Бер генә көн соңлап барган булсам да, күрешә алмый идек. Менә бер уңайдан сезне дә күреп чыгыйм дидем. Чөнки без быел кайта алмыйбыз.

— И ходаем! Оланымны быел күрә алмыйм икән инде болай булгач!..— дип әни үрсәләнеп алды. Аннары ул тазарып-матурланып киткән абыйга карап торды.— Синең соң, балакаем, дәваланып кайтуың шушымы инде?

— Шушы инде, инәй, шушы! Моннан ары иске авыруым тотмаячак. Менә ипи!— дип әле генә үзебез күчтәнәчкә алып кайткан бер зур клиндерне баш өстенә тигереп алды.

— Ай алла! Антың башыңа төшмәсен берүк!..— дип әни коелып төште.

— Мине бик гайрәтле американский дару белән дәваладылар. Уналты тугызын эчсәң, атны үтерә торганы белән. Ат булса үләр идемени, ләкин миңа чуртым да булмады. И — эшләгән өчен мең ярым акча да бирделәр!..

Әнигә шатланыр өчен күп кирәкми иде, битен сыйпап:

— Бигрәкләр дә әйбәт бүлнис икән — шул тикле акча да биреп җибәргәч! Нигә безнең бүлнистә дә бирмиләр соң аны?

— Анда бит эшләтәләр, инәй.
— Кит, авыруларны эшләтәләрмени?
— Юк, әлек әчкәннәрне эшләтәләр.
— Шул кирәк аларга!— диде әни.— Балаларыңның өс-башын алып кайттыңмы соң шул кадәр акча эшләп?
— Менә бары шушында,— дип Раббани абый сумкасын актарып ташлады.— Менә сиңа да бер яулык бар.— Аннары ул, кесәсеннән тар тып кына чыгарып, әнигә егерме бишлек бирде.— Буш вакытында, би әйбәтләп кенә дога кылырсың, яме.
Шул вакыт өйгә, ике баласын ияртеп, без кайтканны ишеткән Тәр җимә килеп керде. Балалары «әти!» дип икесе ике ботына килеп урал ды. Раббани абый аларны, икесен ике ягына күтәреп алып, сөя баш лады.
Бераздан алар бүләкләрен, күчтәнәчләрен күтәреп, сөенешеп-шау лашып чыгып киттеләр.
Караңгы төшкәч кенә, «матаен» тырылдатып, Әдрән кайтып керде Мин, көтеп утыра торгач, йокыга китеп бара идем инде. Ул бензин ис ләре таратып минем белән килеп күреште.
— Бик вакытлы кайткансың, Сирин абый. Шимбә көн авыл сабан туе!..— диде.

## 38

Чын сабан туен мин гомеремдә өч тапкыр күргән кеше: кырык ал ты, кырык җиде, кырык сигезенче елларда күрдем. Шулардан беренче се — Җиңүдән соң беренче сабан туй!— яшьлек хыялымда гомер к релмәгән бер ямь, моң булып уелып калган. Исемә төшерсәм — әле һаман да бөтен бизәге-чәчәге белән, колгадагы сөлгеләре белән кү алдыма килә дә баса. Йөз җирдә йөз гармун уйнаулары, бәхеткә, мә хәббәткә сусап җырлаулары — бүген ишетәм диярсең — колагымнан китми тора иде. Күңелдә ул сабан туе әле булса таралмаган, таралыр га тиеш тә түгел сыман; теләсәм, менә бүген үк шунда бара алыр идем төсле торып калган...
Казанда мин бер генә тапкыр сабан туена бардым. Каенлыкта иде Ләкин мин күңелемә сеңгән яшьлек сабан туен күрмәдем. Урам булып тезелгән буфетларга, каен төбе саен утырган компаниягә очрап, көрәш кән-йөгерешкән җиренә барып җитә алмадым. Дөресрәге, анда боры төртерлек тә түгел, халык күп иде. Мин кул селтәп, кайтып киттем.
Хәзер минем яшьлегем сабан туен күрәсем килә иде.
Әни иртәдән пешеренә башлаган. Тәрҗимә мунча яккан. Иртә белә сабан туй мунчасы кереп чыктым. Сабан туеннан соң Раббани абый ларга ашка керәсе булганлыктан, җыелышып, Иске Агыйдел яланын киттек. Сабан туйның урыны үзгәрмәгән иде.
Менә сабан туй башланып китте. Берничә җирдә берничә ярыш Күз кайсына карарга да белми. Әдрән килү белән көрәшкә әзерлән башлады. Ул инде ике ел рәттән батыр калган, быел да мәйданга би дәртләнеп чыкты. Ләкин... бөтенесен рәттән кырып килгән Актаныш батыры аны җиргә әйләндереп тә салды. Искәрми дә калдык. Бу яшь яңа батырның гайрәтенә халык «аһ»! итте. Әдрән бик кызу да, гарьче дә иде, сикереп тә торды — аңа дусларча кул биргән Актаныш егете салып та екты.
Инде батырга чыгарга кеше дә калмаган иде. Шунда түгәрәкн ерып Раббани абый килеп керде. Пинҗәген салып атты, күлмәген са лып атты, сул кулына сөлгене урап тотты.

— Кил, акыллым!..— диде ул әлеге батырга.

Батырның да гаре кузгалган иде — җан ачысы белән алыша башладылар. Минем яндагылар:

— Нишләп кирәсе итте соң әле бу Раббани? Гомер көрәшкән кеше түгел бит. Көрәштә ул, көчтән дә бигрәк, сол кирәк,— дип абый өчен борчылып алдылар.

Ләкин, спортны белгән кеше, мин күрәм: бу егет абыйның унике яшьтән тимер сугып каткан билен ала алмаячак иде. Ул да булмады, абый аны «у-ух!» итеп җирдән суырып та алды.

— Ат үзен Актаныш ягына!..— дип безнекеләр дәррәү, кычкырып җибәрделәр.

Ләкин абый тегене, үз гәүдәсеннән аерып, атып бәрә алмый: бергә егылачаклар иде. Ахырда абый, бер мәзәк итеп, батырны күтәргән килеш, түгәрәк әйләнәсеннән алып китте. Шулай бер әйләнеп чыкты да, «тик кенә тор, кыймылдама» дигәндәй, мәйдан уртасына бастырып куйды. Батырның кулын кысып, безнең янга килде.

Шунда мин абыйның һаман бетмәгән гайрәтенә хәйран калдым.

## 39

Ләкин әни алдында ипиләр тотып ант иткән кеше, Раббани абый, сабан туе көнне үк «ычкынды». Кунаклар таралышуга инде ул егылган иде.

Икенче көнне ул кичкә таба, без күз-колак булып торган җирдән, кинәт юкка чыкты. Бер мотоцикл тавышы ишетелеп калган иде, шуна утырып киткән ахры. Кибетче Җәмиләгә әйтелгән — Әдрән йодрыгын борын төбендә уйнатып әйтте,— ул хәзер абыйга бер тамчы нәрсә бирмәячәк иде. Димәк, бердәнбер җир — пристань кала. Күрәсең, акчасын да Тәрҗимәгә биреп бетермәгәндер.

Мин кая баруымны әнигә әйттем дә, пристаньга киттем. Әни арттан:

— Пристеп буйларында кеше көлдереп, абыең былагайланып йөрмәсен тагы, аң булын,— дип калды.

Үч иткәндәй юлда ни аты, ни «матае» туры килмәде, шулай җәяүләп кенә өч чакрымны барып җиттем.

Пароход, көндәгечә, сигез тулгач килергә тиеш иде. Ул килер алдыннан яр өстендәге ларекны ачып җибәргәннәр. Раббани абый шунда, ларек авызына янын куеп, мин белмәгән кешеләр белән басып тора иде. Алларында аракы.

— Раббани абый, эчмисең!— дидем мин.

— Мин эчмим дә,— диде ул.— Менә дусларны гына сыйлыйм.

Ләкин авызына инде аракы кергән: күзеннән күренеп тора иде.

— Алайса монда буталып йөрмә, әйдә кайтыйк,— дидем мин.

— Менә пароход килсен дә, кайтырбыз. Мин иртәгәдән эчмим, ләкин бүген пиво кабасым килә.

Хатын-кыз түгел, кеше алдында тартышып, кычкырышып булмый иде. Мин:

— Ләкин сыраңны да өйдә генә эчерәм,— дидем.

Пароход бер сәгатькә соңлап килде. Буфетыннан сыра алып калырга өлгерер өчен, басма салганны да көтмичә борт аша сикереп, пароходка ташландылар. Беренче булып диярлек сикергән абый, ыргакка эләгеп, артта калды. Пароход соңлап килгәч, һәммәсе ашыга, чөнки еш кына, төшә алмыйча утырып китеп, икенче пристаньнан егерме-утыз чакрым җәяүләп кайтучылар да була икән. Абый үзе дә бая ярда: «Минем инде өч кабат әйләнеп кайтканым бар» дип көлеп сөйләгән иде.

Соңлап килгәч, ун минут та үтмәгәндер, пароход китәргә дә яскана башлады. Ике матрос басманы дөбер-шатыр тартып алды. Сырачылар, йөгерешеп чыккан уңайдан, без торган дебаркадерга сикерәләр. Ләкин әле барысы да чыгып бетмәгән, шул исәптән Раббани абый да юк иде. Ул арада борын якны ычкындырып җибәрделәр. Каршы туктаган пароход борыны көчле агым белән бик шәп аерыла башлады. Раббани абый белән тагын ике кеше чабып килеп җиткәндә, пароходның борыны гына түгел, биле дә кеше буе аерылган иде инде.

— Койрыкка барың!.. Койрыкка барың!..— дип кычкырышып, без дә койрык ягына йөгерештек.

Ләкин безнең абыйлар, чыгар юл табып, койрыкка барып җиткәнче, койрык бавын да чиштеләр. Алда заготзернодан икмәк төяп бик зур «Волготанкер» торганлыктан, пароход борылып китәр өчен артка чигәргә тиеш иде — гөжләтеп куласасын әйләндереп җибәрде. Нәкъ шул вакыт, беренче булып, пароход читенә безнең абый килеп чыкты. Чалбар кесәләре, пинжәк кесәләре тулы шешә иде. Кулына да икешәр шешә тоткан. Ләкин ул мине күрмәде дә. Мин:

— Раббани абый, сикермә! Утырып кына кит!— дип кычкыруым булды — абый ике кулын да алга сузып, дебаркадерга сикерде. Ләкин култыксасына ябыша алмады, ике арага шатырдап төшеп китте. Халык «а-ах!» итте. Капитан өстән: «Стоп! Полный ход вперед!» дип кычкырды. Ләкин соң иде инде...

Пароход «полный ход» белән алга киткәч, абыйның үле гәүдәсен куласа дулкыны үзебезнең кечкенә елга тамагы сайлыгына илтеп каккан иде.

Ә икенче көнне әнинең чәче ап-ак булып агарып чыкты.

Мин Раббани абыйны күмеп кайткач утырып өстәлгә капландым. Минем туйда Раббани абый нәкъ шулай елаган иде.

...Менә биш туган идек. Раббани абый белән Мирза абый сугыштан тәннәренә пуля түгел, шырпы да тими кайтканнар иде. Базарларда, бер без генә, бөтен базар өстеннән калкып, бер-беребезне күреп йөри идек... Булмаган да сыман беттеләр. Биш туганнан икәү калдык. Каян табыйм мин хәзер андый туганнарны!..

Бер вакыт мин инде елаудан туктагач, беләзегемнән каты иттереп Әдрән тотып алды.

— Җитте, абый!

— Чү, балам, ипле сөйләш,— дип сул ягыма әни дә килеп баскан.

Мин күтәрелеп әнигә карадым.

— Балаларыңның үлемен күреп үләр өчен генә тудыңмы әллә син, инәй, бу дөньяга?!.

— Сабыр бул, балам. Без күрәсене без күрмичә кем күрсен.

— Инәй!— дидем мин.— Син бу кайгыларга ничек түзеп торасың, ә?!.

— Мин дә түзмәсәм, Раббани улымның бәбәйләрен кем карар?..

1976

**Гариф Ахунов,**

*Татарстан Язучылар союзы идарәсе председателе, СССР Верховный Советы депутаты.*

# ДӘВЕРЛӘР ДОКУМЕНТЫ

Илебез дулкынландыргыч көннәр кичерә. Котып диңгезеннән башлап казакъ далаларына, Балтик ярларыннан Сахалин утрауларына тикле иксез-чиксез киңлектә, предприятиеләрдә, завод цехларында, төзелеш эстакадаларында, колхоз-совхоз басуларында СССР Конституциясенең яңа проектын тикшерү, аның хакында фикер алышу бара. Конституция проектының илебез бәйрәменә — Бөек Октябрьның 60 еллыгына туры килүе нур өстенә нур өсти.

Партия Үзәк Комитеты, СССР Верховный Советы һәм КПСС Үзәк Комитетының Генеральный секретаре иптәш Леонид Ильич Брежнев җитәкчелегендәге Конституция комиссиясе олы эш башкардылар: даны гасырларга яңгырап барырлык тарихи документ дөньяга туды.

Конституция проекты бөтен дөньяның игътибарын үзенә туплады. Континентлар кузгалды, политик партияләр телгә килде. Ә илебез халкы, хезмәттә яңа вахталарга басып, тагын да ныграк тырышлык һәм дәрт белән эшләп, ватанга һәм партиягә тугрылыклы икәнен тагын бер кабат исбат итте һәм итә.

Депутат буларак миңа СССР Верховный Советының алтынчы сессиясендә катнашу бәхете эләкте. КПСС Үзәк Комитетының Генеральный секретаре Л. И. Брежневны СССР Верховный Советы Президиумы председателе итеп сайлаган чактагы бердәмлекне, кумәк алкышларны күреп, мин бер нәрсә турында уйландым: коммунистлар партиясенең абруе нинди зур бездә, аның җитәкчелек көче социализм җәмгыятенең барлык тармакларында, Советлар ватанының бөтен тормышында өзлексез үсә, зурая, арта бара. Шуның өстәвенә бу бердәмлек — дөньяның иминлеге өчен армый-талмый көрәшүче, безнең партиянең сыналган җитәкчесе Леонид Ильич Брежневның күренекле, көчле шәхес икәнен дә әйтеп тора.

Безнең илебез үзенең инде дүртенче Конституциясен төзи. 1918 һәм 1924 елгы конституцияләрне минем буын кешеләре күрмәде. Ул еллардагы беренче конституцияләрнең илгә, ирек алган халыкларга нинди сөенеч-шатлыклар китергәнен өлкәннәр сөйләвеннән ишетеп кенә беләбез. Ә менә 1936 елгы Конституциянең хезмәт кешеләрендә нинди дәрт, нинди энтузиазм тудырганын без үз күзебез белән күреп белдек. Кумәк тормышка берләшкән авылларда, кыр-тугайларда илнең иркенлеге, азатлыгы турында, хезмәт кешесенә чын ирек һәм зур хокуклар биргән бердәнбер ил турындагы җырлар ил өстендә яңгырап торды. Нәкъ шул елларда Гадел Кутуйның «Тапшырылмаган хатлар»ы дөньяга килде. Озак та үтмәстән, ул, рус теле аша, Европа халыклары телләренә күчте. Талантлы прозаик, ялкынлы публицист, ихлас күңелле шагыйрь Кутуй СССР халыкларының зур гаиләсендә бәхетле булырга хокук алган татар халкының яңа язмышын күңел кузгаткыч эмоциональ көчле образларда сурәтләп бирә алды, шуңа күрә дә «Тапшырылмаган хатлар» бик тиз арада үзенең миллионлаган укучысына тапшырылды, инде менә кырык елдан артык вакыт илебез халыкларының төрле телләрендә яңгырый.

Яңа Конституция проекты — алга киткән социализм иленең расланасы Төп Законы — илебез әдипләрен, шул исәптән татар совет язучыларын да, яңадан-яңа әсәрләр

язарга рухландырачак. Безнең Төп Законыбызда Совет дәүләтенең какшамас ны принциплары, Ватаныбыз утлар-сулар кичеп, канлы фашизмны җиңеп ирешкән уңыш лар теркәлгән. Зур итеп, саллы итеп теркәлгән!

Яңа Конституция проектының совет халкының рухи тормышына, культурасын әдәбият һәм сәнгать хәзинәләренә кагылган статьялары горурлану хисләре уятты Дәүләтнең иҗат союзларына, гомумән нәфис сәнгать үсешенә булышырга, ярдә итәргә тиешлеге Конституциягә аерым закон итеп кертелүе горурлану хисе уяты кына калмый, безгә зур җаваплылык та өсти.

«Социалистик Ватанны саклау СССРның һәрбер гражданының изге бурычы» ди лә проектта. Яңа Конституция проекты сугышны пропагандалауны тыя, шундый пр паганда алып барган һәркем закон белән җәзага тартылачак дип кисәтә. Бө Ленин тарафыннан Советлар дәүләте төзелгән көннәрдә үк күтәрелгән тынычлы политикасы, сәяси системаларының төрле булуына карамастан, барлык халыклар һә илләр белән янәшә тыныч яшәү политикасы Конституциядә Советлар Союзын тышкы политикасындагы төп принцип итеп игълан ителә. Тышкы политика буенч мондый билгеләмә кешелек тарихында беренче мәртәбә Төп Законга языла.

Безнең илебез язучылары, безнең илебез әдәбиятлары өзлексез һәм тайпылыш сыз рәвештә тынычлык идеясен яклыйлар, аның өчен көрәшәләр. Сугыш китерг афәтләр язучылар җилкәсенә дә төште, язучылар гаиләләренә дә зур фаҗига булы керде. Польша җирендә Гадел Кутуй кабере, Кенигсбергта — Фатих Кәрим кабере Альп тауларында Совет Армиясе политругы Нур Баян кабере... Кышкы айлы кичләр дә бу каберләрне тулы ай яктырта һәм алар Европа дәүләтләре чигендә яңа фа шизмны уздырмаучы алыштыргысыз часовойлар кебек басып торалар. Фашизм җә залап үтергән батырлар — Муса Җәлил, Абдулла Алиш, Рәхим Саттар, Хәертдин Мө җәй һәм аларның башка сугышчан иптәшләренең каберләре кайда икәнен әле кеше лек дөньясы белми. Беренче китапларын гына чыгарып өлгергән талантлы егерм яшь язучыбыз сугыш кырларында ятып калды. Әдәбиятыбызда Г. Әпсәләмов һә С. Хәким, Г. Бәширов һәм Н. Арслан, И. Гази һәм Ш. Маннур, Н. Дәүли һәм Ә. Да выдов, Т. Журавлев һәм Ш. Мөдәррис, Р. Ишморат һәм Г. Насрый, Х. Камал һә З. Мансур, А. Расих һәм З. Нури, Х. Госман һәм Г. Хуҗи, А. Шамов һәм Ә. Фәйз Р. Төхфәтуллин һәм Ә. Маликов, Г. Паушкин һәм М. Садри, Н. Исәнбәт һәм М. Мак суд, М. Әмир һәм К. Нәҗми, Ә. Исхак һәм Я. Винецкий, М. Ногман һәм М. Хәсәе сугыш елъязмасын тудыру буенча тиешенчә тырышып эшләделәр. Тәнкыйтьче-галим нәребез Гази Кашшаф һәм Рафаэль Мостафинның Муса Җәлил һәм җәлилчеләр тор мышын җентекләп өйрәнеп язган китаплары, Шамил Рәкыйпов белән Самат Шакир ның Бөек Ватан сугышы батырларын эзләп табу буенча башкарган эшләре ихтирамг лаек. Сугыш чорындагы фронт һәм тыл батырлыгын яктыртуга урта буын әдипләр һәм шагыйрьләре Аяз Гыйләҗев һәм Ш. Галиев, Г. Афзал һәм Роберт Әхмәтҗано Р. Кутуй һәм И. Юзеев, Г. Мөхәммәтшин һәм М. Шабаев лаеклы өлеш керттеләр

СССР Язучылар союзының быел булып узган Пленумында союзның беренч секретаре Георгий Марков безнең язучыларның хәзерге шартларда тынычлык өче ни рәвешле көрәш алып баруларын хәбәр итте. Конституция проектын тикшерү бар ган көннәрдә СССР Язучылар союзыннан күренекле делегация Европа, АКШ, Кан да һәм бүтән илләр әдипләренең Софиядә булып узган Халыкара конференциясенд катнашты. Конференциянең темасы: «Язучы һәм тынычлык: Хельсинки рухы hә культура осталарының бурычы» дип билгеләнгән иде. Очрашу Болгария һәм ССС Язучылары союзларының инициативасы белән оештырылды. София форумында 15 дән артык күренекле сүз остасы катнашып, 34 ил, халыкара һәм милли оешма ис меннән сүз алып барды. Дискуссия вакытында төрле илләрнең язучылары әдипләрне тынычлык өчен, планета халыкларының бәхете өчен көрәштәге урыннары турын җитди сүз сөйләделәр.

Безнең Төп Законыбыз проекты азат хезмәткә гимн булып яңгырый. Туган җир безне үзенең аңлы, намуслы хезмәте белән гөлгә әйләндергән алтын куллы кеш ләргә мәдхия ул. Социализм — тигез хокуклы хезмәтчәннәр җәмгыяте. Социализ гасырлар буе дәвам иткән хурлыклы күренешне — кешене кеше изү, җәберләү алып ташлады, кешеләргә хезмәт итәргә тулы хокук бирде. Безнең илнең кешеләр һәр яклап үсәргә, тәрәккый итәргә мөмкинлек алдылар.

Азат хезмәтнең җәмгыять байлыгы, халыкның һәм гаиләләрнең бәхетле-мул яшәү чыганагы булуын ачып бирү белән бергә, Конституция проекты безнең илдә хезмәтнең СССР гражданнарының беренче бурычы, вазифасы булуын әйтә.

Хакыйкать чагыштыруларда ныграк ачыла диләр.

Быел миңа чит илләргә чыгарга туры килде. Һиндстанда һәм Бельгиядә булдым. Һиндстан — бөек культурасы, бик борынгы культурасы булган ил. Бу бөек культураны инкарь итмәстән, аның зурлыгын таныган хәлдә, мин бер нәрсәне әйтергә тиешмен: Һиндстанда әле эшсезлек шул хәтле дә зур ки, тәүге мәртәбә бу илгә аяк басу белән халыкның фәкыйрьлеге бик нык күзгә ташлана. Торыр урыны булмаган, юньләп кияр киеме булмаган кешеләр урамнарда куна, туристлар, чит ил делегацияләре артыннан төркемнәре белән ияреп, ашарга сорап килә. Хезмәт бередә вазифа булмаган гына түгел, бередә әле күп кенә кешеләрнең хезмәткә хокукы да юк диган сүз. Менә шуңа күрә дә безнең илгә товар җитештерә торган йөз мең эшчеле предприятиеләрдә без Советлар Союзына карата иң зур ихтирам сүзләре ишеттек.

Бельгиядә «капиталистик муллык». Беренче карашка бар да ал да гөл кебек: бетонлаган юллар, кирпечен кирпечкә тезеп салган йортлар... кибетләрдә товар күп. Берничә көн шунда булып, ил белән, хезмәт кешеләре белән якыннанрак танышкач, күңелдәге хис икегә бүленә: беренче хис — культура байлыкларын саклый белүләренә, музейларына соклану булса, икенче хис — әйбәт кенә хезмәт хакы алган (хезмәттә чакта) кешеләрнең дә бик тә тыйнак киенүе, ашау якларына да акчаны бик сак тотулары, гомумән дә тормышка сагаеп караулары булды. Сөйләшә торгач, төп хакыйкать ачыкланды: бередә, барлык капиталистик илләрдәге кебек, хезмәт кешесе иртәгесе көне өчен тыныч түгел, иртәгесе көненә аның ышанычы юк икән. Эшсез калдымы — ул инде бәхетсез. Ник дисәң, квартир хаклары гаять кыйбат, хәтта ярты хезмәт хакы тора диярлек, укыган өчен, дәвалаган өчен акча түләргә — кая барма, анда акча түләргә кирәк. Бездә чит ил кешеләренең үз машиналары булуын кайбер яшьләр «авыз суларын» корытып сөйлиләр. Без Бельгия сенатындагы дәрәҗәле кешеләр белән сөйләштек. Алар әйтә: 10 миллион кешегә 3 миллион ярым машина — ул безнең бәхетсезлегебез, — диләр. Без, сездәге кебек, арзанлы җәмәгать транспорты булдырырга тырышабыз, шуңа таба барабыз, — диләр. Бу — бик табигый, чөнки безнең Татарстанның яртысы хәтле генә булган илдә шул хәтле машина саф һаваны агулый, йота, сулар сулыш калмый. Бельгиялеләр үзләре елгаларда балык бөтенләй калмаудан, елгаларның үле булуыннан зарланалар, ике атналык ялыбызны без кояшта яту, саф һавалы җирдә кузгалмый-селкенми үткәрү өчен чит илләргә чыгабыз, диләр. Менә шуннан соң «капиталистик муллыкның» нәрсә икәнен аңлый башлыйсың инде! Үз илеңдәге хезмәткә хокукның нәрсә икәнен тирәнрәк төшенәсең!

Хәзергә әле сүз хезмәт хокукы һәм хезмәт вазифасы хакында барды. Хезмәтнең безгә — язучыларга — кагылган икенче ягы да бар. Бу — әдәбиятта хезмәт кешесенең образын тудыру мәсьәләсе. Безнең Татарстаныбыз — ирекле хезмәтнең нинди могҗизаларга алып килүен раслаган иң яхшы мисал. Совет власте елларында безнең республикабыз гөрләп үскән индустриаль республикага, куәтле авыл хуҗалыгы республикасына, фән һәм сәнгать республикасына әйләнде. Табигый ки, боларның барысы әдәбиятка үз таләпләрен куйды. Быел июнь аенда Мәскәүдән килгән күренекле рус язучылары безнең эшчеләр сыйныфына багышланган, инде русча басылып чыккан 12 роман һәм повестебызны тикшергәннәр икән, бу республиканың үзе совет елларында бик нык үзгәрүдән, нефтьчеләр, химиклар, машина төзүчеләр калалары үсеп чыгудан туган нәрсә.

Безнең эшче кешеләр турында язган әсәрләребез яхшы бәя алсалар да, безгә әле тынычланырга иртә. Безнең әсәрләребездә хезмәт, әхлакый һәм сәнгать категориясе буларак, нинди урын алып тора — менә шуңа басым ясарга кирәк.

Үземнең кечкенә генә тәҗрибәмнән мисал китерәм. Әле башлап язучы чагымда ук, дустым Фазыл Мостафин белән, «Тынгысыз йөрәк» исемле пьеса язган идек. Пьесаны Татар дәүләт академия театрында куйдылар һәм ул, нефтьчеләр турындагы драма, дөбер-шатыр килеп, сәхнәдән җимерелеп төште. Бу минем өчен дә, дустым өчен дә бик рәнҗешле хәл булды, башта без гаепне режиссерларга, актерларга сылтадык, тик соңыннан гына гаеп үзебездә икәнне аңладык: без нефтьче кешенең драмасын күрсәтмәкче идек, аның урынына нефть чыгаручы техниканы күрсәткәнбез.

Техника кешене каплап киткән. Пьесада тимер бик күбәйгән. Табигыйдер ки, тимер салкын нәрсә, шатлана һәм кайгыра белми, яратуны исә белми дә белми инде — димәк, тамашачының күңелен җылыта алмый.

Мин производство әсәрләрендә һәм гомумән барча әсәрләрдә дә төп урында кеше булырга тиешлегенә шул чагында бик нык ышандым, әмма техник процесслар фон гына булырга тиешле дигән уйдан ерак торам. Ә бу хәзер бик тә таралган фикер. Производство процессы, ягъни хезмәт поэзиясе, әсәрнең үзәгендә булырга тиеш, тик шуны истә тотарга кирәк: әсәрдә ике үзәк барлыкка килмәсен. Әгәр автор кешене һәм аның эшен бердәм итеп күрсәтә алса гына, эштә хезмәт кешесенең характеры ачылса, бүтәннәргә мөнәсәбәтләре, язмышы билгеләнсә генә, роман, повесть яки пьеса ота, укучының һәм тамашачының күңелен яулап ала. «Синең замандашың» фильмында, яки Игнатий Дворецкийның «Чит кеше» пьесасында эш нәкъ шулай тора. Дөрес, аларда станоклар гөрләми, мартен мичләре янмый, техника шулай да бар. Бу очракта техника — производствоны оештыру мәсьәләсе. Әмма шул саф технология булып күренгән нәрсә психологик-әхлакый проблема да булып китә. Леонид Ильич Брежневның Май пленумында ясаган докладында һәм Конституция проектында акыл хезмәте белән физик хезмәт арасындагы чикләр бетә баруы, бу хезмәтләрнең көннән-көн тигезләшүе турында сүз әйтелә. Ә болар — безнең өчен, ягъни язучылар өчен, бик тә уйландыра торган, безнең хезмәтебезгә зур җаваплылык өсти торган билгеләмәләр.

Конституция проектының кереш өлешендә шәхесләр үсүе өчен безнең илдә зур мөмкинлекләр ачылуы, хезмәт кешеләренең югары аңлылыгы, патриотлар һәм интернационалистлар булып җитешүе әйтелә. Без моның шаһитлары. Илебезнең теләсә кайсы тарафында гөрләп күтәрелгән бөек төзелешләр — Кама автомобиль гиганты, Чебоксар трактор заводы, Байкал-Амур магистрале һәм аларда чыныгып, тәрбияләнеп үскән яшь буын, шуларга өстәлгән өлкәннәр — Стахановлар, Мирсәет Ардуановлар, Чкаловлар тәҗрибәсе безне, язучы-әдипләрне, илебез ирешкәннәрне гомумиләштерергә, социализм җәмгыятендә туып-үскән яңа кеше характерын зур итеп колачлы итеп ачып бирергә өнди, дәвер документы булган СССР Конституциясе проекты һәм аны тикшерүдә катнашкан меңнәр, йөз меңнәр фикере яңа әсәрләр язарга рухландыра.

# ЯКЛЫЙБЫЗ, ХУПЛЫЙБЫЗ!

«Язучыларның Г. Тукай исемендәге клубында ачык партҗыелыш була. Көн тәртибендә — СССР Конституциясе проектын өйрәнү, аның турында фикер алышу». Мат бугат йортының фойесына эленгән шушы белдерүне укып, җыелышка коммунистлар гына түгел, партиясез язучылар да килде. Чөнки сүз дәүләткүләм әһәмиятле, бөтен халык тормышына кагылышлы документ — Төп Закон турында барачак.

СССР Конституциясе проекты хакында докладны әдипләр зур кызыксыну белән тыңлады. Аны Татарстан Язучылар союзы идарәсе председателе Гариф Ахунов сөйләде. Докладчының сүзләре икеләтә тәэсирле, чөнки ул — СССР Верховный Советы депутаты да. Совет иле парламентының Конституция проектын бөтенхалык тикшерүенә чыгарырга карар иткән сессиясендә үзе катнашкан, шуны яклап, Татарстанның меңләгән сайлаучылары исеменнән тавыш биргән вәкил.

Төп Законыбызның яңа проекты турындагы докладны тыңлаган минутларда хыял көче, күңел күзе белән тарихи үткәннәргә карыйсың. Илебез узган юллар, халкыбы яулаган үрләр күренә.

Юлыбызның башы — 1917 елда.

Юл башында — «Аврора» залпы, Ленин кул куйган беренче Декретлар.

Шуннан соңгы 60 ел эчендә Совет дәүләте ирешкән җиңүләр — гасырлар ка занышына тиң. Бүгенге көннең кояшлы биеклекләреннән инде тарих булып калга күп нәрсәне барлый алабыз.

Ил кырларында гражданнар сугышы... Ашлык, тимер, күмер өчен көрәш... Кол хозлашу... Беренче бишьеллыклар... Совет дәүләтенең беренче Төп Законы... Бөе

Ватан сугышы һәм кырык бишенче ел язында Кызыл мәйданда Җиңү парады... Орбитада беренче спутник!.. Космоста — Юрий Гагарин!... Гигант КамАЗлар һәм БАМнар...

Конституциябезнең яңа проектында болар санап чыгылмаган, әлбәттә. Ләкин анда халкыбыз узган тарихи юл, Совет дәүләтенең һәм экономик, һәм политик, һәм социаль казанышлары фәлсәфи һәм юридик категорияләрдә беркетелгән. Яңа Конституция зур тарихи үзгәрешләрнең, җәмгыятебездәге революцион яңарышларның җимеше буларак туа.

Проектта социалистик дәүләтебез хәл итәргә тиешле тарихи бурычлар билгеләнә. Шунысы әһәмиятле, анда илнең материаль һәм социаль үсеш перспективаларын күздә тоту белән бергә, яңа кеше тәрбияләү проблемасы да нигез итеп куела. Конституциянең һәр сәхифәсе совет гражданнары, аларның хокуклары турында кайгыртучанлык белән сугарылган. Бу — Совет Конституциясенең демократик асылын билгели торган бик үзенчәлекле күренеш.

Фикер алышуларда беренче булып сүз алган күренекле язучы, Г. Тукай бүләге лауреаты **Фатих Хөсни**, бик дулкынланып һәм илһамланып, шул хакта сөйләде.

— Яңа Конституциябез проекты җирдә коммунизм төзүче бөек кеше — Совет кешесе турында кайгырту җәһәтеннән гаҗәеп дәрәҗәдә гуманлы, кешелекле, гаҗәеп дәрәҗәдә игелекле, — диде ул. — Барыннан да элек, Проект бик әтрафлы. Партия аның битләрендә җәмгыять һәм шәхес тормышының барлык якларын колачлый. Бу тарихи документта илебезнең эчке хәле дә, тышкы политикасы да чагыла. Мин аны укыганда кат-кат уйландым: дәүләтебезнең эчке бердәмлеге какшамаслык, куәте искиткеч зур бит! Дөньякүләм абруе искиткеч олы! Төп Законыбыз проекты күңелдә шушындый горурлык тойгысы уята. Булачак Конституциябезнең һәр статьясы, һәр юлы хезмәт халкының тормышы хакында тирән кайгырту хисе белән язылган. Ул, әлбәттә, дәүләт мәнфәгатьләрен күз уңында тота, социалистик җәмгыятебезне тагын да үстерүнең юлларын билгели. Куандыра бу безне, шатландыра. Гражданин язмышын, шәхесне тәрбияләү мәсьәләсен киң демократик нигезгә куя безнең яңа Конституция. Җитлеккән социализм шартларында кешенең гармонияле үсеше өчен кирәкле мөмкинлекләрне гарантияли. Гаҗәеп зур нәрсә бу! Шушы җәһәттән безнең яңа Конституция проекты бик тә кешелекле, бик тә гуманлы.

Фатих Хөсни яшьләрчә дәртләнеп сөйли. Язучы күңеле әсәрләнмәслек тә түгел шул. Төп Законыбыз проекты хәзерге социалистик җәмгыятьтә яшәүче кешеләрнең политик, иҗтимагый һәм социаль үсешен чагылдырып кына калмый, киләчәк буынны тәрбияләү юлларын да ачыкта. Проектта, мәсәлән, күп милләтле совет дәүләте гражданнарына — СССР халыкларының һәркайсына туган телдә уку, белем алу мөмкинлеге тәэмин ителә. Бу бит Ленин рухы, Ленин идеяләренең дәвамы.

Трибунада «Азат хатын» журналының баш редакторы **Венера Ихсанова**. Ул үзенең чыгышын «Ватан турында җыр»ны искә алудан башлады:

— Нәкъ җырда әйтелгәнчә, «дөньяда илләр күп, җирләр күп». Законнар да күп төрле. Капитал илләренең берсендә ул законнар хатын-кызны сайлау хокукыннан мәхрүм итә, икенчесендә эш хакын азрак түләүне күздә тота... Шуларны уйлаганда, трибун шагыйрь Маяковскийның горур сүзләрен кабатлыйсы килә: «Укыгыз, көнләшегез, Советлар Союзы гражданы мин!..»

Әйе, совет хатын-кызларының горурланырлыгы бар. Ленин имзасы куелган беренче совет Декретлары ук «чәче озын, акылы кыска» дип кимсетелгәннәргә ирләр белән тигез хокуклар бирде. Ул хокуклар миллионлаган хатын-кызларга хезмәт юлын ачты, балаларны сау-сәламәт итеп үстерү мөмкинлеге тудырды. «Әгәр дә социалистик переворотка хезмәт иясе хатын-кызларның гаять зур өлеше җитәрлек тартылмаса, социалистик переворотның булуы мөмкин түгел», дигән иде В. И. Ленин. Совет дәүләте хатын-кызны нәкъ менә шушы переворот өчен көрәшкә, хезмәт мәйданына чыгарды. Хатын-кызларның гражданлык тойгысы үсте, алар илебездә социализм төзү эшенә зур өлеш керттеләр. Моны безнең бүгенге тормышыбызда да күрергә мөмкин. Республикабызда 26 хатын-кыз — Социалистик Хезмәт Геройлары. Орденнар, медальләр белән бүләкләнгән уңганнарыбыз меңнәрчә.

Хезмәт хокукы — хатын-кызга куаныч та, бәхет тә ул! Белгечләр арасында хатын-кызларның күплеге ягыннан СССР дөньяда беренче урында тора. Илебездәге

югары һәм махсус урта белемле белгечләрнең 59 проценты хатын-кызлар. Укытучылар арасында алар 70 процент. Ленин фикеренең хаклыгын тормыш шулай раслый. Республикабызда хатын-кызлардан министр да, райком секретаре да, колхоз житәкчесе дә, язучылар, шагыйрьләр дә, авыл советы председательләре дә бар. Ә депутатлар күпме! Хатын-кызларга шундый хокуклар һәм вәкаләтләр биргән дәүләтләр дөньяда күп түгел.

Конституция проектында гаиләнең җәмгыятьтәге роленә дә зур игътибар бирелә. Гаилә татулыгы — ир белән хатынның җан тынычлыгы гына түгел, җәмәгатьчелек өчен дә кыйммәтле нәрсә. Һәр гаилә — үзенә бер дөнья. Бу «микродөньяда» каләм осталарыбыз өйрәнерлек һәм гыйбрәк-сабак итеп язарлык нәрсәләр күп. Гаилә ныклыгы, гаилә бәхетенең зурлыгын, социаль әһәмиятен ачып биргән әдәби әсәрләр көтә укучы. Конституция проектына әдипләребезнең җавабы шуның белән дә белдерелсен...

Тукай бүләге лауреаты, прозаик һәм драматург **Мирсәй Әмир,** Конституция проектын яклап, болай диде:

— Төп Закон — дәүләтебезнең нигез ташы. Проект тирәнтен уйланып, җәмгыятебез узган юлны марксистик-ленинчыл нигездә анализлап язылган. Без аны чын күңелдән яклыйбыз. Һәр язучы яңа Төп Законны тормышка ашыру өчен көрәшче булыр дип ышанам. Бу — безнең намус эшебез, безнең тарихи миссиябез...

Табигатьне саклау, аның байлыкларын ишәйтү — хәзерге заманның иң җитди проблемаларыннан берсе. Бу мәсьәлә СССР Конституциясе проектында да яктыртыла. Язучы һәм тәнкыйтьче **Рафаэль Мостафин** Төп Законга шул хактагы статьяның кертелүен бик урынлы дип санавын белдерде, шушы проблемага карата фикерләрен уртаклашты, тәкъдимнәрен әйтте.

— Конституция проектында совет гражданнарының иҗади көчләрен, сәләтләрен ачарга, шәхеснең гармонияле үсешен тәэмин итәргә дигән изге бурыч куела, — диде шагыйрь һәм прозаик **Нәби Дәүли.** — Бу бурычны үтәүдә әдәбият һәм сәнгать бик зур урын тотачак. Чын сәнгать әсәре — халык хәзинәсе ул. Шушындый әсәрләр иҗат итүче талантларыбызның кадерен белик. Төп Закон проекты һәр гражданинның кадерен белергә куша. Халык белән киңәшеп эшләргә куша.

— Ә мин бүгенге тормышыбызның кадерен белик димәкче булам.— Өлкән язучы **Госман Бакиров** сүзен шулай башлады. — Хәзерге көннәрне ерак үткәннәр белән чагыштырып утырдым да исләрем китте: чагыштырмаслык алга киттек бит, иптәшләр! Конституция проекты тормышыбызның матурлыгын сакларга, аны ишәйтергә дә өнди. Мин дәүләтебезнең Төп Законы проектын чын күңелдән яклыйм.

Язучылар партоешмасының ачык җыелышы бертавыштан карар кабул итте: илебез Конституциясе проектын бердәм яклыйбыз һәм хуплыйбыз!

**Михаил Шолохов,**

*рус язучысы, Социалистик Хезмәт Герое, СССР Верховный Советы депутаты.*

# ДҮРТЕНЧЕ БАСКЫЧ

Проектын бөтен халык тикшерә торган яңа Совет Конституциясе минем буын кешеләре өчен — сан ягыннан караганда — дүртенче конституция. Ил үсешенең дүрт тарихи баскычы — минем биографиямнең дә баскычлары.

Безнең беренче Конституциябез 1918 елны кабул ителде. Минем тормышымдагы кискен борылыш шул елга туры килә. Аңарчы мин гимназиядә укый идем, әмма илдә башланган гражданнар сугышы укуымны бүлдерде. 1918 елны, миңа әле унөч кенә яшь булса да, эшли башларга туры килде.

Продработник булдым. Донны 1922 елга чаклы җәфалап яшәгән бандаларны куып йөрдем, бандалар безне эзәрлекләде. Тормыш үз дигәненчә барды. Төрле кыен хәлләрдә калырга туры килде. Бәлки без ул чагында нык елап уйлап та җиткермәгәнбездер, әмма шулай килеп чыга, без дә ул чакта чамадан тыш яшь илебезнең төп хокукы — яшәү хокукы өчен көрәшкәнбез.

Минем биографиям хезмәткә гарантияләнгән хокук алуымны раслый. Мәскәүнең Кече Бронная урамында, хезмәт биржасында егерменче елларда эшсезләр белән чират торганым хәтеремдә. Эш ягыннан бәхетсез булмадым мин: йөк төяүче, йөк бушатучы, гади эшче, ташчы итеп куйдылар, хәтта бер йорт идарәсендә эш башкаручы булып та эшләдем... Еллар узды. Егерменче еллар ахырында газеталардан эшсезләр бетүе, хезмәт биржалары ябылуы турында укып сөендем.

Миңа ничектер шулай бер мәлне Америка публицисты Роберт Уилтонның «Россия үлем түшәгендә» дигән китабы эләкте. Исемдә, ул китап 1919 елны чыккан иде. Автор бик хәтәр селтәнә анда: экономик яктан карагада, аның уенча, совет режимының яши алуы мөмкин түгел, политик яктан карагада, бу — абсурд. СССР Конституциясенең яңа проектын укыганда мин шул сүзләрне исемә төшердем. Америка күрәзәчесен тарих әйләндереп ыргытты. Яңа Конституция проекты без ирешкән шундый да зур уңышларны теркидер ки, аларны хәтта язучы хыялы да башына сыйдырып бетерә алмый. Эш ирешелгәннәрдә генә дә түгел, эш перспективада. Ә ул перспектива — Конституциядә бик гади, бик тормышчан итеп сыйныфсыз җәмгыять, коммунизм җәмгыяте төзү дип язылган.

Безнең дүрт Конституциябез дә бер орлыктан — гаделлеккә һәм тынычлыкка омтылудан үсеп чыгалар. Шулар хакына социализм төзү өчен кирәкле, чамадан тыш авыр, сөялле, ә сугыш елларында кан коюлы алтмыш ел узылды. Октябрь революциясенең практик тәҗрибәсе, гуманизмы, пафосы һәм күркәмлеге әнә шунда.

Конституция проектының яңалыгы — ул барыннан да бигрәк социалистик демократиянең, авыр көрәшләрдә без фашизмнан саклап алып калган демократиянең киңәюе һәм тирәнәюе.

Сугыш минем буын кешеләренең язмышына ачы фаҗигасе белән килеп керде. Фронт вакыйгалары, тоталь сугыш күренешләре минем күңелемдә җуелмас эз калдырып киттеләр. Мин җитмеш яшьлек әниемне югалттым, ул безнең станицаны — бернинди стратегик әһәмияте булмаган тыныч станицаны — бомбага тотканда һәлак булды. Минем йортым, китапханәм миналардан янды. Мин әллә ни хәтле дусларымны югалттым. Бу минем шәхси бәхетсезлегем, шәхси кайгым гына түгел — шәхси бәхетсезлекләрдән, шәхси кайгылардан халык кайгысы, гомуми бәхетсезлек җыела, ул фаҗигане кешеләргә сугыш китерә.

Шуңа күрә мин тагын бер мәртәбә, нык ышанып әйтәм, Конституция проекты миңа да турыдан-туры кагыла. Өлешчә алганда, ленинчыл тынычлык политикасын Конституция белән раслау, халыкара мөнәсәбәтләрдән **сугышны алып ташлауны** закон белән беркетү, халыкларның иминлеген саклау, төрле социаль стройдагы дәүләтләрнең үзара хезмәттәшлеген киңәйтү, үстерү. Болар миңа кеше буларак та, язучы буларак та турыдан-туры кагыла. Әйе, төрле илләрдә яшәгән язучыларның дөньяга карашлары төрлечә булуы мөмкин, безне бер нәрсә: кешелеккә файдалы булырга, иминлекне сакларга омтылу берләштерергә тиеш.

Игътибар итегез: Конституция проектында социаль үсеш һәм культура дәүләт кайгырткан өлкәләрнең беренчеләре урынына куелган. Шунлыктан язучы хезмәтенең әһәмияте һәм җаваплылыгы бермә-бер арта.

Совет иленең бүгенге көне — бәхетле көн. Әмма без «бәхетле тормыш» дип әйткән чакта «җиңел тормыш» дигәнне күз алдында тотмыйбыз. Эшлисе эшләр күп әле. Җиңәсе кыенлыклар җитәрлек. Нәкъ менә шундый актив, иҗади тормыш өчен көрәшеп, җәфа чигеп һәлак булалар минем китапларымның геройлары. Язмышлары катлаулы аларның. Минем уемча, тормыш дөреслеген бер читкә куеп, чынбарлыкны бизәп күрсәткән язучы — яхшы язучы була алмый.

**(АПН).**

## Рәшит Гәрәй

### Күккә менеп... канат кагынып

Кешеләргә карыйм: йөзләрендә
Нурдай балкый якты елмаю.
Кешеләргә карыйм: күзләрендә
Чагыла кайчак сагыш-моңаю.

Кошлар җырын тыңлыйм: кайчак шашып,
Кайчак тынып-тынып сайрыйлар.
Кошлар җырын тыңлыйм: аларда да
Була, имеш, сагыш-кайгылар.

Очар кошлар авыр кайгылардан
Калыр өчен, имеш, арынып, —
Бик биеккә менеп, зәңгәр күктән
Әйләнәләр канат кагынып.

Әйләнәләр юлга җыенганда,
Диңгез-таулар аша үтәргә.
Кеше исә үзенең бар кайгысын
Йөрәгенә салып күтәрә.

### Көзләрне аралап

Көз керде авылда өйләргә,
Туйларның саны, әй, исәпсез.
Телләрдә тагын шул бер үк сүз:
— Кавышмый йөрисез нишләп сез?

Аккошлар очалар парлашып,
Сез һаман аерым ояда.
Бу сүзләр кагыла миңа да,
Кагыла бу сүзләр сиңа да.

Аккошның күзләре ни төсле,
Карамы, әллә соң зәңгәрме?
Сиңа да шулаймы икән ул:
Читен соң сагыну хәлләре.

Аккошым, дип әйтмим мин сиңа,
Көз җиткәч аккошлар китәләр.
Син китсәң, мин ялгыз нишләрмен,
Моңсу бит аккошсыз иртәләр.

Көз керде авылда өйләргә,
Мичләргә иртәрәк ягыла...
Томанлы көзләрне ералап,
Яз булып килермен яныңа.

## Сагыну хисе...

*Шәрәф Мөдәррис истәлегенә*

Яратсам да сине, «Яратам!» дип
Әйтәлмәдем исән чагыңда.
Исәннәрне искә алучы аз,
Киткәннәрне һәркем сагына.

Ә мин сине барлык дусларыңнан
Артыграк сагынам шикелле.
Юатырга теләп үз-үземне,
Иңнәреңә сарылам шикелле.

Исән чагыңда ук сагына идем,
Туганымдай якын булганга.
Куныл чыгар урын тапмасам да,
Чаба идем сезнең урамга.

Кулың биреп, белмим, тордыңмикән
Ачкан чакта йортың ишеген.
Кул җылысы түгел, кыен чакта
Җан җылысы кирәк кешенең.

Авырсынмый-нитми дәшә идең
Үзеңә дә кысан бүлмәңә.
Олы җанлы дуслар йөзенә соң
Төшәмени кара күләгә?!

Ут-суларны кичкән солдат булып
Бүлешә идең соңгы телемең.
Бүлмәң тар булса да, дуслар өчен
Иркен иде синең күңелең.

Чын дусларсыз яшәү җиңелмени
Бу тынгысыз кырыс заманда?!
... Исәндер ул әле, исәндер, дип
Сине эзләп йөрим һаман да.

Сүнми икән, бары дөрли икән
Сагыну хисе, сагыну ялкыны.
Айлап түгел, көнләп сагына-сагына
Узып барам еллар аркылы.

Әдип Маликов

# МӘЙДАН ТОТУ

ОЧЕРК



Киңәшмәдән таралыштылар. Таныш баскычлардан акрын гына атлап, Галимҗан төшеп килә. Йөзе борчулы. Асфальтка төренгән үзәк мәйданга чыгуга, үзен көтеп торган машинасына утырмыйча, авыр адымнар белән Гагарин урамы ягына, космонавтлар аллеясына таба юнәлде ул. Аның беркем белән күрешәсе дә, исәнләшәсе дә килми иде.

Бүген Әлмәткә СССР нефть промышленносте министры килеп төште, ял көне булуга карамастан, «Татнефть» берләшмәсе залында киңәшмә үткәрде. Гүя ул Галимҗан Әхмәдиев өчен генә килгән, күбрәк аңа карап сөйләде шикелле:

— Девон нефтен табу көннән-көн катлаулана бара, иптәшләр, узган дан җылысында кызынып яшәп булмый хәзер,— диде министр, залдагы тынлыкка колак салып,— җир маеның һәр тоннасын сугышып алырга туры киләчәк. Нефть чыгару күләмен киметмәс өчен бөтен чараларны күрергә, һәр яңалыкка ике куллап тотынырга!..

Тәнкыйть сүзләрен дә кызганмады министр. Исемен атап әйтмәсә дә, Әхмәдиев ягына карап-карап куйды. Бөтенесен белеп, төбенә төшеп сөйләде. Гаҗәпләнерлек тә түгел, чөнки ул үзе дә Татарстан җирлегеннән күтәрелгән, заманында «Татнефть» берләшмәсен җитәкләгән кеше.

Галимҗан башын аска иеп, министр әйткәннәрнең һәммәсен үз адресына алып утырды. Чөнки ул җитәкчелек иткән «Әлмәтнефть» идарәсе коллективы соңгы айда нефть табу графигын үти алмады.

Министр һич көтмәгәндә:

— Әхмәдиев шикелле фидакарьләр, заманында «Җәлилнефть» идарәсен аякка бастырган, патриот-шагыйрь исемен йөрткән эшчеләр поселогының нигез ташын салышкан талантлы җитәкчеләр бар чагында... — дип, дәртләндереп, аның исемен уңай яктан телгә алып куйды. Галимҗан моны, әлбәттә, үзенчә кабул итте: «Каты төрттерә бу, ерактан уратып...»

Производство планы үтәлмәүнең коллектив өчен нинди зур хурлык булуын яхшы белә Әхмәдиев. Ә җитәкчегә тагын да авыррак. Үт куыгын сытардай әчесен ул чөмерә, иң авыр җәзасын ул күтәрә. Әхмәдиев үзенең ни чаклы зур, җаваплы пост биләп торуына хәзер генә чынлап бәя бирә башлады шикелле. Министр әйтмешли, нефть бит ул индустрия азыгы гына түгел, ул халыкара политика да.

Галимҗан өенә урау юллар белән кайтырга булды. Аллея бик озын, атлыйсы да атлыйсы. Баш очында август кояшы. Юкәләргә, тирәкләргә серле моңсулык иңгән. Куе яфраклар арасыннан космонавтларның галәм җилләренә ачык, саф, мөлаем йөзләре чагылып кала. Данығыз мәңгелек, хезмәтегез авыр. Бездә дә җиңел түгел, космонавт иптәшләр. Эшче маркасын үз биеклегендә тотар өчен һәр көнне яуга барырга кирәк. Ничек килеп чыкты соң әле бу, социалистик ярышта елдан-елга җиңүче булып барган, ундүрт тапкыр СССР Министрлар Советының күчмә Кызыл байрагын яулап алган Ленин орденлы «Әлмәтнефть» идарәсе шундый хурлыклы хәлдә торып калды? Гомергә булмаган хәл. Саный башласаң, аның сәбәпләре күп, әлбәттә, Девон катламнары һаман сулана бара, басым кими. «Сөте» сыекланды девонның. Төзүчеләр нефть эшкәртү корылмаларын вакытында төзеп өлгертә алмыйлар. Ә тозлы сулардан чистартылмаган нефтьнең кемгә кирәге бар?



*Ленин һәм Октябрь Революциясе орденнары кавалеры, СССРның почетлы нефтьчесе, Татарстанның атказанган фән һәм техника эшлеклесе Галимҗан Мәннаф улы Әхмәдиев*

Әлмәт нефтьчеләре бораулаучылардан ел саен яңа йөз скважина кабул итеп алалар. Хәерчегә җил каршы дигәндәй, быел алары белән дә тоткарлык килеп чыкты. «Кысыр» скважиналар саны да арта төшкән.

Бара торгач, чайкалып киткәндәй булды Әхмәдиев. Соңгы вакытта ялы да тими, тынгылык та юк. Төннәрен күзеннән йокы кача. Ул адымнарын акрынайтты. Тирә-ягына игътибар биребрәк карый башлады. Әлмәт матур шәһәр. Шулай да Җәлил поселогын якынрак күрә Галимҗан, торган саен ныграк сагына аны. Яңа эш, гомереңдә беренче башкарган зур эш истәлекле һәм мавыктыргыч була, яшь бакча утырткандагы шикелле, өмет, хыялларың бергә үрелеп бара. Булачак шәһәрне үзләре планлаштырдылар, нигезен бергә салдылар. Галимҗан анда, беренчеләрдән булып, үзе күчеп утырды, гомерлеккә шунда төпләнеп калырга план корып яшәде. Ул — Җәлил поселогының беренче почетлы гражданины.

Урыны гаҗәеп матур. Урман арасы. Аланнарында чыпчык башы зурлыгындай җир җиләкләре кызарып пешә. Баш әйләндергеч, исерткеч саф һава. Күлләр юк икән, анысы бәла түгел...

Поселок янында, халык өмәсе белән, түгәрәк күл ясадылар. Әлбәттә, шактый өзгәләнергә һәм җилкәне кашырга туры килде: акча урынына — энтузиазм. Әхмәдиев үзе башлады, башы йомыры, җилкәсе калын, ерып чыгар әле, дипючеләр дә булды. Кулында бай техника, җиксен шул куәтне.

Әмма олысы-кечесе бергәләп ясады күлне. Бетон ярлар Кама суы белән тулгач, быргы кычкыртып, ял көннәрендә халыкны өмәгә дәшеп йөргән пионерлар, кызыл лентаны кисәргә нефть идарәсе начальнигы Әхмәдиевнең үзен чакырдылар.

— Галимҗан абый, яңа күлне котлап, бер чумып та алыгыз инде?! — диделәр алар, чәүкәләр сыман чыр-чу килеп. Сүз тыңлау-

чан Галимҗан абыйлары ялындырып тормады. Тиз-тиз генә чишенде дә, кулларын алга сузып, биек вышкадан түбәнгә очты. Күл өсте чайкалып куйды. Әхмәдиев пырхылдап, су астыннан чыгуга, яр буендагы балалар «ура» кычкырырга тотындылар. «Идарә башлыгы да коенырдай булгач, чын күл инде бу! Галимҗан абый әйтсә, балыгы да булыр әле...»

Әхмәдиев, колач салып, җиңелчә генә йөзеп китте...

Нефтьчеләр поселогы кырыенда культура сарае торгызырга кирәк булгач, төзүчеләр зәңгәр күккә канатларын җәйгән мәһабәт имәннәрне кисеп аударырга җыендылар. Күтәрү краннары маневр ясый алмаячак, эш тоткарлана, диделәр. Әхмәдиев имәннәрне кисәргә рөхсәт бирмәде. Төзүчеләр тарткалашып, бәхәсләшеп карарга булдылар:

— Галимҗан Маннапович, объектны тапшыру срогы сузыла бит?!

— Күпмегә? — дип сорады нефть идарәсе начальнигы алардан, кырыс кына елмаеп.

— Ну, кимендә ике-өч айга.

— Ә мондый имәннәрне үстерү өчен кимендә йөз ел кирәк!

Үзсүзлелеге ягыннан күршегә керәсе түгел иде Галимҗанга. Тамырларын гасырлар төбенә җибәргән батыр имәннәр ышыгында Җәлилчеләрнең куанычы булган яңа культура сарае үсеп чыкты. Җитлеккән сылу каеннарны, шәм шикелле төз наратларны да поселок пропискасына алдылар. Аларның да бит җаны бар.

Җәлил эшчеләр поселогын министр үзе телгә алмаса, бәлки әле бу турыда уйланып та бармас иде Галимҗан. Бәйләнчек истәлекләр хәзер инде бер алга, бер артка төшеп, аны эзәрлекләвендә дәвам ителәр. Җәлил биографиясенең дәвамын эзләп, герой шагыйрь исемен йөрткән калага бервакыт Берлиннан Леон Небенцаль килеп төшә. Аның кем икәнлеген Галимҗан яхшы белә иде. «Проблемы мира и социализма» журналының баш редакторы, Җәлил поэзиясен, аның батырлыгын тынычлык өчен көрәш коралы итеп күтәрүче.

— Муса — немец коммунистларының иң якын союзнигы. Аның «Алман илендә» дигән шигырендәге аерым юллар безнең дәүләт гимнына кертелде, — ди Небенцаль, нефть идарәсе башлыгына мөрәҗәгать итеп. — Сез Җәлилгә куелачак һәйкәлне ничегрәк күз алдына китерәсез?

Галимҗан ГДРдан килгән кунакны һәйкәл проекты белән таныштыра... Шагыйрь ялан баш. Йөзендә сабыр уйчанлык. Шинелен салып, иңенә аскан. Аягында солдат итекләре. Гүя ул озын походка җыенган. Карашлары кояш чыгышына төбәлгән...

Небенцальнең йөзендә канәгатьләнү билгесе. Алар, поселокның яңа кварталлары белән танышканнан соң, ак чәчәкле, хуш исле болыннарга чыктылар. Немец кунагы урман авызындагы нефть скважиналарының ритмлы сулышын тыңлап, операторлар белән дусларча әңгәмә корып йөрде. Бу җирләр «Дуслык юлы» тамырлары белән ГДРга кадәр барып тоташкан. Мондагы тормыш агышын, хезмәт пульсын, күңел җылысын аның туган илендә тоеп, сизеп яшиләр. Ул аны яхшы белә. Саубуллашкан чакта Небенцаль болай диган иде:

— Сезнең халык үзенең киләчәгенә нык ышанып яши. Кешеләр шуның белән көчле.

Озак та үтмәде, шагыйрь һәйкәле үз урынына — «Җәлилнефть» идарәсе бинасы каршына менеп басты. Һәйкәл әйләнәсендә ал, кызыл роза чәчәкләре. Якында гына автовокзал. Өзлексез вахта машиналары агыла. Бөек Җәлил аларны көн саен иртә таңнан гүя эшкә озатып кала.

Кыскасы, Җәлил поселогы Галимҗанның канында, миендә кайнап туды. «Җәлилнефть» идарәсеннән Әлмәткә күчмәскә дип, озак тартышты ул. Куптарып алгандай алдылар. Монда Ришат Булгаковның да роле зур булды, әлбәттә. Дус, җитмәсә, сабакташ. Унынчы класстан башлап бит, тормыш юллары бервакытта да кисешмәде, гел бергә диярлек узды...

Нишләп соң әле Галимҗан гел үткәннәре турында уйлана? Таяну өчен нигез ташы эзлиме? Әлмәттә дә нигезе нык ич. Ул бергә күчеп килгәннән бирле, «Әлмәтнефть» идарәсе Советлар Союзындагы барлык шундый идарәләр арасында иң алдынгы урыннарның берсен алып килде. Үзе партиянең шәһәр комитеты бюросы члены, депутат... Нигезе нык булганга күрә аңа таяналар да, йокнең саллырагын күтәртәләр.

...Әхмәдиевләр гаиләсе шәһәрдәге иң тыныч урамнарның берсендә, таш особнякта яши. Челтәр рәшәткәле мондый йортлар Әлмәттә байтак. «Без утрауда яшәп өйрәнмәгән, күршеләрсез тора алмыйбыз», — дип карасалар да, аларны бу йортка көчләп диярлек керттеләр. «Әл[illegible]нефть» идарәсенең бөтен начальниклары шунда яшә[illegible] бозмыйк инде, диделәр.

[illegible] кергәндә, капка төбендә «Москвич»ы тора, уның [illegible] Рамил, [illegible]сен көтеп, шофер белән янәшә, кабинада утыра иде. Фатыйма ханым, бер кулына термос, икенчесенә калын портфель тотып, Галимҗанның каршысына чыгып басты.

— Әтисе, Рамилне Карабаш күленә алып бармакчы идең бит,— диде ул, иренең кәефен чамаларга тырышып,— ял көнең бушка узмасын, үзеңә дә ял кирәк. Менә кайнар аш, азык-төлек...

Галимҗан эштәге борчуларын өенә алып кайтмаска тырыша, яшеннәре, күкрәүләре узгач, берәр атнадан соң гына аларны көлеп кенә искә төшереп ала. Бу юлы да сер бирмәскә тырышты ул, улының башыннан сыйпап, аркасыннан сөеп куйды. Рамил сөенеченнән нишләргә белмичә, кабина утыргычында талпынып алды, теленә салышты:

— Чәйне без учак ягып, синең солдат котелогында кайнатырбыз, әйеме, әти? Пуля тишекләрен мин кургаш белән ямадым...

Улына караса, Галимҗанның йөрәге әллә нишләп куя. Күзләре елмаерга тырышса да, йөзе моңсу Рамилнең. Мәктәпкә йөртмиләр, өйдә генә укыталар. Галимҗан елына бер килгән отпуска көннәрен гел Рамиле янында үткәрә. Урманга, су буйларына алып чыга аны. Фатыйма ханымга бигрәк тә авыр. Врач ул. Ә яраткан эшенә йөри алмый, тизрәк Рамилне сәламәтләндерәсе килә аның.

— Карабаш күленә Миңлебай аша барырбыз, улым,— диде Галимҗан, шоферга күз кыскандай итеп,— без киттек, әнисе.

Рамилгә барыбер, янында тик әтисе булсын, Әлмәт урамнарын узганда унар катлы йортлар тезелеп калсын, каршыга бөдрә каеннар йөгерсен һәм кабина пыяласы аша җил сызгырганы ишетелсен.

Их, әйбәт тә түшәлгән соң Миңлебай юллары. Кемнәр генә узмаган моннан. Бик күпләрнең хезмәт биографияләре шуннан башланган. Әлмәт шәһәренең тууына да Миңлебай мәйданары сәбәпче булды. Чупай тавы ташларыннан төзелгән ак шәһәр шушы юлдан узды, «Әлмәтнефть» идарәсе — Әлмәт шәһәренең яшьтәше.

Миңлебай елгасы янындагы икенче номерлы скважинадан девон фонтаны бәреп чыгуга, Ромашкино авылыннан атаклы нефть табу остасы Корбан ага Вәлиев килеп җитә, будка куйдыра. Ә ул кайда будка куйдырса, шул тирәдә шәһәр туа. Лениногорск белән дә, Әлмәт белән дә шулай булды.

«Әлмәтнефть» — үзе шикелле күп кенә идарәләрнең анасы. Аңардан «Сөләйнефть», «Әлки нефть» кебек эре нефть предприятиеләре аерылып үсеп чыкты. Моңа карап ул ярлыланмады, илгә «кара алтын» бирүне киметмәде.

Алты идарә начальнигы алмашынган. Тәртип саны буенча, җиденчесе булып, Әхмәдиев килде. Миңлебай, Каенлы, Әлмәт мәйданнарын биләп торган бу катлаулы хуҗалыкны сабакташ дусты Ришат Булгаковтан кабул итеп алды ул.

— Мин дүрт ел чиләндем, сиңа да бик авыр булыр,— диде Ришат, нефть идарәсе дилбегәсен Галимҗан кулына тапшырган чагында,— «ура» кычкырып, бүрек чөеп йөргән заманнар узды. Катлам басымы һаман төшә бара, фонтан ата торган скважиналар калмады диярлек. Өлкә комитетында миннән «Урыныгызны кемгә тәкъдим итәр идегез?» — дип сорагач,— «Тартса, Әхмәдиев кенә тарта ала бу авыр йөкне»,— дидем.— Ачуланма, Галимҗан.

Өлкә комитетында аның үзенә дә төшенерлек итеп әйттеләр. Булгаковны Татарстан нефть берләшмәсенең баш инженеры итеп күтәрәселәрен белгәч, бу авыр йөкне теләсә дә, теләмәсә дә үз җилкәсенә алды.

«Әлмәтнефть» идарәсенә күчеп килүнең беренче көннәреннән үк Әхмәдиев шундый кыенлык алдында калды: көн туса — кабинет ишеге ябылмый, телефон шалтыраудан туктамый. РИТСлар, цехлар аңардан техника таләп итә. Берсенә — трактор, икенчесенә — бульдозер, ә өченчесенә ниндидер агрегат кирәк. Җәлилдә чагында мондый хәл сирәк була иде. Галимҗан серенә тиз төшенеп алды. Бөтен техника, элекке система буенча, төрле участокларга сибелгән килеш калган.

«Җәлилнефть» идарәсендәге сыналган тәҗрибәгә таянып, нигә прокат-ремонт цехы оештырмаска, барлык техниканы бер йодрыкка тупламаска? Бу фикерне, беренче булып, Булгаков яклап чыкты. «Кулым җитми калды, кыюрак тотын, Галимҗан»,— диде. Үзгәртеп корулар, әлбәттә, шактый вакытны алды. Әмма тора-бара үзен бик нык аклады. Әхмәдиев янына уфылдап чабып килүләр кимеде. Прокат-ремонт цехы нефть идарәсенең мускулына, йөрәгенә әйләнде. Техника кирәк булса, барлык заявкалар шунда ява.

Әхмәдиев җаваплылыкны күбрәк производство командирларының үзләренә тапшыру ягын карады. Түбәннән килгән инициативаны тоткарлау — эш өчен иң хәвефле нәрсә. Мастерларга да, гади эшчеләргә дә йомышчың итеп карамаска, киресенчә, аларга иҗади фикер йөртергә юл ачарга кирәк. Бу җәһәттән инде Әхмәдиевне өйрәтәсе юк иде.

Галимҗанның бер «йомшак» ягы бар. Аны Җәлилдә дә белә иделәр, монда да сизеп алдылар. Ул үз янына килгән гади эшчене, кырыкка ярылырга җитешеп йөргән чагы булса да, кабул итмичә калмый. Оператор яки слесарьмы, кем генә булмасын, ул бит сине атасы урынына күреп, бик зур йомышы төшкәндә генә килә яныңа, эшче сыйныфы вәкиле буларак килә. Ни вөҗданың белән кире борып җибәрәсең аны.

Бер эпизод хәтерендә бик нык уелып калды Әхмәдиевнең. Гадәттәгечә, аның кабинетына бүлек начальниклары җыелырга тиеш иде.

— Галимҗан Маннапович, җир асты ремонты цехыннан бер оператор... кабул итүегезне үтенә,— диде секретарь кыз, идарә җитәкчесенең «йомшак кылына» кагылып һәм шуңа күрә бик кыюланып,— бүлек начальниклары бераз сабыр итсеннәрме?

— Әйе, аз гына көтсеннәр,— диде Әхмәдиев, ишек ягына карап,— кая, чакырыгыз иптәшне!

Салкын декабрь көне иде. Кабинет уртасына киемнәре ләмгә,

нефтькә буялган бер егет кереп басты. Бияләе шыкылдап идәнгә төште. Галимҗанның йөрәге кысылып куйды. Шундый яшь малай чагында, нәкъ шундый декабрь әчесендә, ул фронт юлына чыгып киткән иде. Аның кабинетында гүя теге елларда бозлы елга сулары кичкән сапер егет — үзе басып тора...

«Иптәш запастагы инженер-капитан»,— дип дәшәр төсле менә хәзер аңа.

— Өстеңне салып куй,— диде ул кайгыртучан тон белән,— сөйлә, ни йомыш?!

Егет бозланган курткасын салып почмакка сөяде, уңайсызланыпкына Әхмәдиевнең каршысына килеп утырды.

— Мине цех комсомоллары җибәрде,— диде ул, үзен кулга алып,— безнең эштә үзгәреш кертергә кирәк, Галимҗан Маннапович, болай яшәп булмый... Килгән бере качу ягын карый...

Ремонт цехы эшчесе үзенең зарларын сөйләп бирде. Тәкъдимнәрен әйтте. Егет чыгып китүгә, бүлек начальниклары, идарәнең партком секретаре һәм профсоюз җитәкчесе кереп утырыштылар. Әхмәдиев сүзне скважиналар ремонтлау цехыннан башлап җибәрде. Бераүгә дә сер түгел иде, анда эш шартлары бик авыр. Ачык кыр. Җил-буранда ышыкланыр урын да юк. Өс-баш һәр вакыт пычрак, юеш була. Квартирасызлар байтак. Хезмәт хакы да башкалардан артык түләнми.

— Андый урыннан мин дә качар идем, — диде Әхмәдиев, идарәнең партия комитеты секретаре Наилә Закировнага сораулы караш ташлап.

Закированың үтә җитди, мөлдерәмә күзләрендә елмаю чаткысы кабынып куйды:

— Качмас идегез, Галимҗан Маннапович, башка юлын табар идегез, — дип сүзгә кушылды ул, кечкенә йодрыкларын төйнәп, — мөгаен, берәр җитәкченең якасыннан алыр идегез.

— Кемнең якасыннан?! — Шулай диде дә, үзе дә сизмәстән, кызарынып көлеп җибәрде Әхмәдиев. Башкалар да аңа кушылып көләргә тотындылар.

Капиталь ремонт цехы белән Әхмәдиев турыдан-туры үзе шөгыльләнде. Беренче чиратта, әлбәттә, җир асты «хирург»ларының эш шартларын яхшыртырга кирәк иде. Ачык кырда ял бүлмәсе булдырырга (күчмә вагон да ярый), түләүсез кайнар аш оештырырга көчебез җитмәсмени? Хәтта сугыш кырларында да солдатларны кайнар аштан өзмәделәр, батальон кухнялары арттан ияреп йөрде. Девон коесыннан күтәрелгән торбаларны бәби шикелле коендырып алсаң, дип фикер йөртте Галимҗан, курткасы пычракка баткан теге егетне исенә төшереп... Чиста инструментларны ремонтлавы да ансатрак булачак. Ә юдыру агрегатларын табу зур проблема түгел.

Ремонтчылар — безнең төп терәгебез. Скважиналар сафта булганда, алар нефть биреп торганда гына без нефтьче исемен күтәреп йөри алабыз. Ни өчен капиталь ремонт цехы эшчеләренә квартираны беренче чиратта бирмәскә?!

Бригадаларга ремонт саны исәбеннән бүләк акчасы түләнеп килүен белгәч, Әхмәдиевнең ачуы йөзенә чыкты. Халтурага юл куйганбыз, димәк. Сәгать мастерскоендагы, заводлардагы шикелле, ремонтның сыйфаты өчен ниндидер гарантия булырга тиеш бит. Ул чагында скважиналарның гомере шактый озынаячак, ә ремонт саны, киресенчә, кимиячәк. Шулардан килгән экономия бәрабәренә ел ахырында түләнә торган «13 нче» хезмәт хакын арттыра төшәргә мөмкин. Производство белән идарә итү, бер карасаң, шахмат уены сыман. Бөтен фигуралар уенда булырга тиеш. Берсен дә бушка йөртмәскә...

Машина, Миңлебай үрен төшеп, РИТС урнашкан бина ягына таба борылды. Таулар куенына сыенган Миңлебай авылы сулда калды. Ә уң якта — челтәрле биек торбалар. Цирк гөмбәзен хәтерләткән бетон шарлар гүя һавада асылынып калганнар, — аскы фундаментларын башка корылмалар каплап тора. Миңлебай мәйданында табылган нефть шушы корылмалар аша үтә, тозлы судан чистартыла, җиңел фракцияләр аерылып чыга.

РИТС бинасы янында «Татнефть» берләшмәсенең баш инженеры Булгаков басып тора иде. Кай арада килеп тә җиткән. Янында — Таипов, РИТС дип аталган (элекке промысел инде) шушы хуҗалыкның җитәкчесе. Солдатка каралган яшь-җилкенчәк сыман, чәчен һәрчак төптән алдырып йөри.

Машина ишегалдында шып туктауга, урыныннан торып баскан Рамил, «Карабашка килеп җиттек тәмени?» дигән сыман, әтисе ягына борылды. Булгаков аптырап калган Рамилгә ачык кабина тәрәзәсеннән кулын сузды:

— Саумы дим! Термослар, кармаклар төяп алай кая барасыз?

— Карабаш күленә, Ришат абый, — диде тегесе, бик батыраеп, — сезне дә алып китәбез.

Булгаков зәңгәр урман өстендәге кояшка күз төшереп алды. Көн инде кичкә авышып бара иде. Август кояшының йөзенә, өлгергән бодай башакларыныкы сыман, балавыз төсе кергән.

— Бара торсыннар, — диде Ришат, Әхмәдиевнең җиңеннән тартып, — без куып җитәрбез.

«Татнефть» берләшмәсенең баш инженеры һәм идарә начальнигы диспетчерлар залына үзуга, анда утырган оператор кызлар бераз каушап калгандай иттеләр. Җитен чәчлесе электроника аппараты көзгесенә карап, төзәтенеп алды, матур гына итеп, иренен турсайтты.

— Сулану коэффициенты? — дип сорады аңардан Әхмәдиев коры гына.

— Җитмеш процентка җитте, Галимҗан Маннапович.

Табылган нефтьнең 70 проценты су!

Булгаков белән Әхмәдиев бер-берсенә борчулы караш ташлап алдылар. Ә РИТС начальнигы Таипов ике кулын артка куйган да, сүзгә кушылмыйча, бер читтә тыныч кына басып тора. Үз сменалары өчен кызлар үзләре җавап бирсеннәр, янәсе.

Җитәкчеләр эчкәре залга узды. Бер кыз «шык-шык» итеп машинкада басып утыра. Куәтле насослар җыю пунктына күпме сыекча озаткан, нефть эшкәртү корылмаларында шушы минутта нинди процесслар бара, ниләр башкарыла — һәммәсе төртке-төртке булып, телетайп тасмасына төшә. Машинистка кыз шуны саннар теленә күчерә һәм электрон-исәпләү машинасы аша үткәрә. Кирәкле мәгълүматларны минуты белән Әлмәткә хәбәр итәләр. Эшләр монда хәзер шулай көйләнгән. Миңлебай мәйданындагы барлык скважиналарның (ә алар алты йөздән артык!) хәл-әхвәлләре, «кан» басымына, «йөрәк» тибешенә кадәр идарә пультыннан берөзлексез күзәтеп торалар.

РИТС начальнигы килүчеләрне үз кабинетына чакырды. Җыештыручы Майсрур апа аларга чәй хәзерләп кертте. Иртәдән бирле авызына берни капмаган булуы шунда гына исенә төште Галимҗанның.

— Киңәш кылыйк әле, иптәшләр, — диде Булгаков, кайнар чәйне көмеш кашык белән болгата-болгата, — иртәгә Мәскәүгә очам. Министр бүген китте. Баштан сыйпамаслар мөгаен.

Әхмәдиев уйга калды: «Менә кая барып җитте эшләр».

— Миңлебай мәйданында миллион тонна нефть биргән скважиналар бар, алар инде үзләрен йөз өлеш аклады, — дип сүзгә кушыл-

ды Таипов,— ни генә кыландырмадык Девон картны. Кытыклап[1] та, күкерт белән «өшкереп» тә карадык. Хәзер басым убылып кими, ә министрлык...

Булгаков аның сүзләрен шунда ук элеп алды:

— Министрлык дәүләт планын кимету ягына бармас. Моңа исәп тотарга ярамый безгә. Татарстан илгә миллиард ярымлап тонна нефть бирде. Әле девонда запас җитәрлек. Әзер байлыкны җир астында калдыру — җинаять дип исәпләнә. Уйлашырга кирәк.

— Аска су керә бит, Ришат Тимергалиевич. Шуңа гына әйтүем.

Бер карасаң, икесе дә хаклы сыман. Бигрәк тә Миңлебай мәйданы хәзер тәмам суланды. «Әлмәтнефть» идарәсе мәйданнарында катламга су кудыручы ун насос станциясе эшләп тора. Йөздән артык скважина аша ел саен илле миллион кубометр су кудырыла. Нефтьчеләр «кара алтын»ны кая куярга күптән өйрәнделәр, ә нефтькә ияреп менгән агулы суларны нишләтергә?

Җавабы әзер: чистартып яңадан җир астына озатырга. Ә моның өчен чистарту корылмалары санын бик нык арттырырга туры киләчәк. Димәк, тәзүчеләрнең үкчәләренә басарга. Тозлы суларга торбалар, насослар да озак чыдамый. Тутыгуга каршы көрәш — бүгенге көннең кадагы. Нефтьчеләр ярдәмгә фәнни-тикшерену институтларын, галимнәрен чакырдылар. Нефть чыгару күләмен әле шушы дәрәҗәдә саклап тору мөмкинлекләре бар. Җир мае биш төрле катламда ята. Хәзергә без шуның иң астагы сәндерәсеннән генә файдаланабыз. Девон байлыгының уннан бер өлеше кадәрлесе әле карбон катламында саклана. Анысына кул да тимәгән.

Әхмәдиев «Лениногорскнефть» идарәсендә эшләгән чагында ике катламны бер скважинадан файдалану мәсьәләсен кузгаткан иде. Өлкән инженер Николай Горохов белән бергәләп, схемаларын төзеделәр, тәкъдимнәрен нигезләп исбат иттеләр. Министрлык моны хуплады. Менә ничә ел инде, кирәкле җиһазларның һаман кайтып җиткәне юк. Бу алымның киләчәге искиткеч зур. Ничәмә скважинага, күпме дәүләт акчасына һәм вакытка экономия булачак!

Әхмәдиев сүз арасында шуларны искә төшереп алды, тәкъдимен дә әйтте:

— Югары дәрәҗәдә сөйләшеп хәл ителә торган нәрсә бу, Ришат Тимергалиевич. Мәскәүгә баргач, җитдирәк итеп куй әле бу мәсьәләне.

Алар аерылышканда көн инде кичкә авышкан иде. Ришат Булгаков үз машинасын Әхмәдиевкә бирде.

— Карабашта ухагыз суынадыр. Без Таипов белән тау чишмәсенә сугылабыз, — диде ул бераз мутланып, — әнисе әле чишмә суы көтеп, самаварын да яңартмый торадыр.

Таиповның әнисе чәйгә кран суы тотмаганлыгын белә иде Булгаков.

*
* *

Әхмәдиев үзенең бөтен сәләтен, тормышын нефтькә багышлады. Туганнары да Галимҗан эзеннән китте. Әхмәдиевләр фамилиясеннән унбер нефтьче. Һәммәсе югары белемле. Күбесе Губкин исемендәге Мәскәү нефть институтын тәмамлаган. Энесе — Рифкать Әхмә-

---

[1] «Кытыклау» — катламга су кудырган вакытта, басымны бер арттыру, бер киметү нәтиҗәсендә барлыкка килгән дулкыннар. Шулар җир маен өскә күтәрүгә ярдәм итәләр.

[2] Күкерт әчелеге катламга барып җитүгә, анда көчле реакция башлана.

диев хәзер техник фәннәр кандидаты, Мәскәү ВУЗында тау токымнарын бораулау фәне буенча лекцияләр укый. Әлмәт белән дә араны өзми. Менә бит Галимҗанның өлкән кызы — Җәлил салына башлаган елны беренче класска кергән Галиясе дә әтисе укыган институт баскычларын атлап узды. Хәзер «Әлмәтнефть» идарәсендә геолог булып эшли. «Әхмәдиевләр династиясе»... дигән канатлы сүз юкка гына таралмаган шул. Тамырлары нык, тирәнгә киткән. Туган җир туфрагыннан куптарып кара син аны.

— Галимҗан абый сихерләде безне, — диләр, кайсысы белән сөйләшсәң дә, — эшем авыр дип бервакытта да зарланмады. Гел матур якларын гына сөйләде. Хәзер инде авыр булса да түзәбез.

Нефтьчеләрнең хезмәтен җиңеләйтү турында күп кайгыртты Галимҗан абыйлары. Әйтик, әзер нефтьнең күләмен савытларга салып үлчәмичә, чаннар эченә төшеп йөрмичә генә исәпләп чыгарырга мөмкинме? Кеше ышанмаслык нәрсәне дөрес булса да сөйләмә, дигәннәр картлар. Сөйләде дә, ышандырды да Әхмәдиев.

Үзәк нефть үткәргеч торбаларга нигә счетчиклар беркетеп куймаска? Бу мәсьәлә буенча Галимҗан, фәнни-тикшеренү институтларына мөрәҗәгать итә, заводлар белән элемтәгә керә. Үзе әйтмешли, бер ишектән кусалар, икенчесенә бара.

Бала еламыйча тумый, көйсезләнмичә дә булмый. Көтеп алынган автоматлар кайта, ләкин алар җир мае өчен җайланмаган булып чыгалар. Гел көйсезләнеп торалар, өстәвенә, күз дә йоммый алдашалар. Саннарны дөрес күрсәтмиләр. Кемнәрдер инде бу яңалыктан кул селтәргә дә әзер.

— Үгисетмик әле, үз балаларыбызга караган кебек карыйк, «алдашудан» туктарлар, — ди Галимҗан һаман саен үҗәтләнә барып, — дөнья реактив тизлек белән барганда, бизмәнгә тотынып ятарбызмы?

Әхмәдиев башлангычын «Татнефть» берләшмәсе җитәкчеләре — шул ук Вәлихановлар (бүгенге көндә СССР нефть промышленносте министры урынбасары), Булгаковлар (хәзер «Татнефть» берләшмәсенең генераль директоры), Үзбәк Саттаровлар яклап чыга. Автомат-счетчиклар үз хокукларын бик тиз яулап алалар. Алар, «спутник» дигән аппаратлар аша, идарә пунктларына, операторларга төп-төгәл саннарны әйтеп кенә торалар. Бу алым, Советлар Союзында беренче буларак, «Әлмәтнефть» идарәсендә кулланыла башлады.

Нефть мәйданнарын комплекслы автоматлаштыруда, производствоны яңача оештыруда Галимҗан Әхмәдиевнең хезмәтләре әйтеп бетергесез зур. Бөтенсоюз Халык хуҗалыгы казанышлары күргәзмәсе аны алтын һәм ике көмеш медаль белән юкка гына бүләкләмәгән. Татарстанның атказанган фән һәм техника эшлеклесе, СССРның почетлы нефтьчесе дигән мактаулы исемнәр дә җиңел генә яуланмагандыр.

Әхмәдиев үз кабыгында йомылып ята торганнардан түгел. Кешеләр белән аралашырга, сөйләшергә, бәхәсләшергә ярата ул. Аның дуслары һәм шәкертләре һәркайда бар. Төмәндә дә, Мангышлакта да, хәтта Афганстан чүлләрендәге нефть промыселларында да. Бу тынгысыз кеше дөньяның уналты илендә булып кайткан. Польша, Германия, Кытай — ут аша узган солдат юллары. Швеция, Италия, Испания, Алжир, Марокко, Гвинея, Сенегал... Болары туристик сәяхәт маршрутлары. Финляндия, ФРГ — нефть һәм газ табу буенча бөтендөнья конгресслары... Галимҗан бу ике конгресста Советлар Союзыннан делегат булып катнаша.

Йөргән таш шомара, диләр. Шомару бер хәл. Дөнья күрү сине масштаблы уй йөртергә, гыйбрәт алырга, үз илеңнең гражданины, чын хуҗасы булырга өйрәтә.

*
* *

Ә план үтәлеше белән эш ничек булып бетте соң? Орденлы «Әлмәтнефть» идарәсе сентябрь аенда өзеклектән чыкты һәм алдагы ике ай эчендә теге хурлыкяы көннәрнең бурычларын да артыгы белән кайтарды. Хәзер елмаеп йөрсә дә, Әхмәдиевнең йөзе ул чагында кырыс һәм уйчан иде. Вак йомыш белән янына барырга кыя алмадылар. Нефтьчеләрнең Техника йортына — тантаналы бәйрәм кичәсенә җыелган халык арасында аны кызганып куючылар да булды. Чигә чәчләре элеккедән ныграк агара төшкән, чалбар балакларына сырлан ябышкан. Кайтып эш киемен алыштырырга, кырынырга да вакыты булмаган. Президиумда иң арттагы рәттә утырды.

— Ул хәвефле өзеклек безне дә дер селкетте. Фронттагы сыман, бөтен подразделениеләрне үрә бастырдык, — дип искә ала Галимҗан Әхмәдиев шул вакыттагы киеренке көннәрне, — тәзүчеләр безнең кулга тапшыруны һаман сузып килгән нефть эшкәртү корылмалары, насос станцияләре, күмәкләшеп тотынгач, бер ай эчендә сафка бастырылды. Производство тармакларын автоматлаштыру һәм телемеханикалаштыру утыз процентка артты. Паникага бирелмичә, көн дими, төн дими эшләдек.

«Әлмәтнефть» идарәсе промыселлары унынчы бишьеллыкның беренче елы планын срогыннан бер ай алда үтәделәр.

Галимҗан Әхмәдиев «Җәлилнефть» идарәсенә ун ел гомерен багышлады. Әлмәткә күчүенә дә инде җиденче ел икән. Аның карамагында колачлы, бәрәкәтле зур нефть мәйданнары. Ә быел аны «Татнефть» берләшмәсенең баш инженеры иттеләр. Мәйдан тотулары бик авыр. Ул — көчлеләр эше. Гади көч белән генә дә алдырып булмый. Беренче чиратта — гаделлек. Тыелган алымнар куллансаң, иртәме, соңмы, хур итеп мәйданнан сөрәләр. Нәкъ сабан туендагы шикелле. Халык хәрамны, ялганны бер вакытта да кичерми. Син — ил күз алдында.

Ленин, Октябрь революциясе һәм Хезмәт Кызыл Байрагы орденнары кавалеры Галимҗан Әхмәдиевнең намусы саф. Сугышчы-солдат буларак, полк байрагы астында биргән беренче антына ул гомер буена тугрылыклы булып калган. Аның янына саф күңел белән генә килергә мөмкин.

## Самат Шакир

# КАЗАН КРЕМЛЕ ЯНЫНДА

Язгы кояшлы көннәрнең берсе.

Казан Кремле каршындагы патриот-шагыйрь Муса Җәлил һәйкәле янында олы яшьтәге бер кеше басып тора. Ул язгы җилдә җилфердәгән плащ итәген җыебрак тотты да әкрен генә атлады. Кремльнең ак таш стенасына карап ул уйланып торды.

Монда РКП(б)ның губерна комитеты җитәкчесе, большевиклар партиясенең ышанычлы улы Яков Семенович Шейнкманны, РСФСРның Милләтләр эше Халык Комиссариаты янындагы Татар-башкорт комиссариаты комиссары һәм Үзәк мөселман хәрби коллегиясе председателе, атаклы татар революционеры Мулланур Вахитовны, Бондюг заводы большевиклары җитәкчесе һәм Алабуга өяз советы депутатлары председателе Сергей Николаевич Гассарны, Казан юстиция комиссары Мартын Иванович Межлаукны, Самара партия оешмасының вәкиле Хая Хатаевичны 1918 елда ак чехлар һәм интервентлар атып үтерәләр.

Әйе, Гассар аның иң якын кешесе, беренче укытучысы иде.

Кремль алдына килеп үзенең якын кешесе Гассарны искә төшерүче олы яшьтәге бу кеше Октябрь революциясе көннәрендә кулына корал тотып дошманнарга каршы көрәшкән кызылгвардеец, соңыннан Азин дивизиясе сугышчысы Хәкимулла Шаһиморатов иде.

Ул Гассар белән очрашуларын күз алдына китерде.

Патша Россиясенең караңгы почмагына урнашкан Бондюг химия заводы. Эшчеләрнең тормыш шартлары ифрат начар. 1905 елгы революциядән соң патша жандармериясеннән качып килгән революционерлар эшчеләр арасында патшага каршы агитация алып баралар. Беренче бөтендөнья сугышы башлана... Бондюг заводы эшчеләре белән тыгыз элемтәдә торган С. Н. Гассар яшүсмерләр өчен гомуми белем бирү түгәрәге төзи. Бу түгәрәккә татар яшьләре белән бергә Хәкимулла да йөри. Гассардан дәресләр ала, революцион китаплар, брошюралар укый. Хәкимулла Шаһиморатов әкренләп кемнәр безнең дошманнарыбыз, кемнәр дусларыбыз икәнне төшенә башлый. Бу турыда әти-әнисенә һәм татар эшчеләренә дә сөйли.

Гассар түгәрәкнең бер утырышында социалистик революция турында аңлата. Ул салмак тавыш белән:

— Капиталистик җәмгыять бетәргә тиеш. Ләкин ул үзеннән-үзе бетми, аны революция юлы белән, эшче һәм крестьяннарның кораллы восстаниесе белән генә җимерергә мөмкин,— ди.

Хәкимулла большевиклар партиясе һәм Ленин турында шул утырышта күп нәрсә белде. Гассар большевикларның эшче-крестьяннарга ирек һәм җир бирү өчен көрәш алып баруларын аерата басым ясап әйтә. Ул рус телендә сөйләсә дә, татар яшьләре аны аңлыйлар, бик игътибар белән тыңлап утыралар.

Утырышларның берсендә Сергей Николаевич революцион рухта язылган листовка һәм прокламация укый. Аны татар яшьләре үз телләренә тәрҗемә итәләр. Гассар, Казанда туганга һәм татарлар белән аралашканга, кайбер сүзләрне үзе дә татарча әйтә.

Түгәрәк утырышлары Гассарның квартирасында үткәрелә, Хәкимулла анда еш була. Сергей Николаевич Хәкимулладан татар эшчеләренең тормышлары турында сораша, авыр тормыштан котылу өчен берләшергә һәм патшага каршы көрәшергә чакыра. Сергей Николаевич менә бүген дә Хәкимулла янында басып тора һәм аңа ягымлы карап:

— Дин сабагы укып вакытыңны үткәрмә, русча укы, гимназиягә кер, фән өйрән, халык бәхете өчен көрәшүчеләр сафында бул! — ди кебек. Алты дистәдән артык вакыт узган, ә ул әйткән сүзләр һаман да колак төбендә яңгырыйлар.



*Хәкимулла Шаһиморатов*

Хәкимулла авыр тормышта үсә. Аның күз алдына корымга баткан, көн-төн түтен ургытучы һәм тирә-якка сасы ис таратучы завод корпуслары килеп басты. Менә шушы завод эшчесе Шаһиморат семьясында 1896 елда бер бала дөньяга килә. Аңа Хәкимулла дип исем кушалар. Хәкимулланың әнисе Хәтирә апа авыр эшләрдән соң улын алдына утыртып сөя дә моңлы итеп җырлый башлый... Ул улының бәхетле булуын тели. Әмма, патша Россиясенең миллионлаган ач, ялангач балалары кебек, Хәкимулла да бер сыныек икмәккә тилмерә. Әтисе Шаһиморат көнтөн эшләсә дә, өстеннән иске бишмәт, башыннан каешланып беткән бүрек төшми.

— Их, замана, замана! — дип зарлана ул өйгә кайткач. — Күпме авыр эшләр башкарып та тамак туйдырырлык, өскә-башка кием юнәтерлек акча бирмиләр, җитмәсә тагы, штрафларга дип ярты хезмәт хакын тотып калганнар, — ди хатыны Хәтирәгә.

Җиде яшенә җиткәч, Хәкимулланы Бондюгтагы рус-татар мәктәбенә укырга бирәләр. Ләкин мулла, моны белеп алгач, Шаһиморат абзыйны тирги, дин-алла исеме белән каргап: «Малаеңны кяфер сабагы укытырга кем кушты?» — дип җикерене. Шаһиморат абзый уйга кала. Аннары гына хәзрәтнең күңелен күрергә тырышып болай ди:

— Урысча белү дә кирәк бит, хәзрәт. Иртәнге якта урыс мәктәбендә укыр, аннары, төштән соң, мәдрәсәдә гыйлем алыр.

Шулай итеп Хәкимулла русча да укый, дин сабагы да ала, кайвакытларда әтисенә булышырга заводка да бара. Малай тырыш, укырга сәләтле була. Рус-татар мәктәбен ул мактау кәгазе алып тәмамлый. Аннан соң укуын дәвам итәргә туры килми, унике яшеннән заводка өйрәнчек булып керә, әтисе белән бергә эшкә йөри башлый.

1914 елны бөтендөнья сугышы башлану белән заводтагы эшчеләрне фронтка куалар. Аларның күпчелеге талау сугышына каршы була. 1915 елларда эшчеләр арасында патшага каршы язылган прокламацияләр һәм листовкалар тараталар. Аларның күбесе татар эшчеләренә дә килеп ирешә. Яшүсмер егет Хәкимулла аларны эшчеләргә укый, үзе аңламаган нәрсәләрне Гассардан сорый.

Фронтка китүчеләр урынына заводка яңа инженерлар, химиклар да килә. Алар арасында яхшы фикерле, эшчеләрнең тормышын, көнкүрешен җиңеләйтүне кайгыртучылар да була. Аларның күпчелеге большевиклар партиясе членны булганнар һәм эшчеләргә дөрес юл күрсәткәннәр.

Башта эсерлар партиясендә торган инженер Борис Ильич Збарский белән яшь эшче Хәкимулла Шаһиморатов еш очрашалар, цех эшчеләре белән бергә фоторәсемгә дә төшәләр. Алгарак китеп булса да әйтеп үтик: Октябрьның давыллы көннәрендә Б. И. Збарский меньшевиклар һәм эсерлар мәнфәгатен яклап речьләр сөйләсә дә, соңыннан большевиклар партиясенә керә, медицина фәннәре докторы, профессор була, В. И. Ленин үлгәч, аның гәүдәсен Мавзолейда саклау өчен бальзамлауда катнаша. Бөек Ватан сугышы көннәрендә немец самолетлары Мәскәүне бомбага тота

башлагач, Сталинның тәкъдиме буенча, Владимир Ильичның гәүдәсен, Мавзолейдан алып, сугыш куркынычы булмаган урынга күчерешә. Немец-фашист илбасарларын Советлар Союзы территориясеннән куганнан соң гына бөек юлбашчының гәүдәсе Мәскәүгә алып кайтыла һәм Мавзолейга куела. Борис Ильич Збарский бу вакытта СССР Медицина фәннәре академиясенең действительный члены була. Ул берничә тапкыр орден һәм медаль белән бүләкләнә, 1945 елда аңа Социалистик Хезмәт Герое дигән мактаулы исем бирелә. Ул Дәүләт премиясе лауреаты була.

Октябрь революциясе җиңеп, бөтен власть эшче-крестьяннар кулына күчкәч, яшь Совет республикасын саклау өчен кызыл гвардия отрядына алдынгы фикерле Бондюг эшчеләре белән бергә беренче булып Хәкимулла да языла. Завод директоры Лев Яковлевич Карпов һәм С. Н. Гассар төзегән кызыл гвардия отряды зур эшләр башкара. Соңыннан бу отряд 28 нче Азин дивизиясенә кушыла. Шуның составында Хәкимулла Шәһиморатов авыр сугышларда, зур походларда катнаша. Алар акгвардиячеләрдән һәм чехлардан бик күп авылларны һәм шәһәрләрне азат итәләр. Азин дивизиясендә вакытта ул 40 нчы полк командиры В. И. Чуйков белән очраша.

Кызыл Армия сугышчылары — һөҗүмдә. Дошманның көчле каршылык күрсәтүенә карамастан, Азин дивизиясе алга юл яра. Әмма дошман, яңа резервлар алып, контрһөҗүм башлый. Азинчылар акларның атлыларын һәм пехотасын ут белән каршылау өчен окопларга урнашалар. Алгы окопларның берсендә — кызыларменец Хәкимулла Шәһиморатов та. Ул борчылып һәм бик җентекләп дошман ягын күзәтә.

Кичә генә анда тыныч кебек иде. Ә бүген авыл халкын аклар рәхимсез җәзалый, кешеләрне кое баганаларына аса. Йортларга ут төртә. Әнә бер ханым авылдан чыгып бирегә таба йөгерә башлаган гына иде, аклар пулясы аны аяктан екты. Ул олы юл читенә чалкан килеп төште. Бу хәлне күреп торган Хәкимулла һәм башка кызылармеецлар, дошманнан үч алырга ант итеп, тешләрен кыстылар.

Дошман ягыннан, ниһаять, атлылар күтәрелде. Аларның якынрак килүен көттеләр. Атарга команда бирелә. Бирәдән яудырылган көчле ут аларны чигенергә мәҗбүр итә. Көтмәгәндә сул яктан килеп чыккан броневик күренә. Ул ата-ата килә һәм шактый күп кешене кыра да инде. Броневикка каршы ике сугышчы шуышты. Аларның берсен шунда ук пуля чагып өлгерде, икенчесе исә, броневикка якын килеп җиткәндә генә, кулларын җәеп туктап калды. Дошман пулясы аны да һәлак итте.

Броневик шулай иркенләп, озак йөри алмады, әлбәттә — туптан атып аны сафтан чыгардылар. Көчле «ура!» тавышы яңгырады. Кызыл сугышчылар давыл булып дошман өстенә ябырылдылар. Аклар, бик күп техникасын һәм җанлы көчләрен югалтып, чигенә башлады. Аларны азинчылар куа киттеләр. Мылтыгын алга сузган Хәкимулла да беренчеләр рәтендә йөгерә иде. Ул үзенә каршы килгән берничә дошман солдатын атып үтерде.

Көтмәгәндә акларның бүтән бер төркем атлылары чаттагы урамнан килеп чыктылар. Ат өстендә кылыч белән бик оста сугышырга өйрәнгән офицерлар иде болар. Алар шактый кешене кырды һәм, ялан кылычлары белән селтәнеп, үзләренә юл ачып качарга теләделәр. Кап-кара атка атланган казак есаулы нәрсәдер кычкырды, башка атлылар, аның сүзен ишеткәч тагын да гайрәтләнә төшеп, азинчылар өстенә ташланды.

— Их, пулемет булса иде, бирер идек без бу бандитларга кирәген! — диде Хәкимулла. Ул үзенең мылтыгын төзәп казак есаулына атып җибәрде. Калын тавыш белән акыручы есаул ат өстеннән мәтәлеп төште...

Нәкъ шул вакытта станоклы пулемет ата башлады. Җайдак офицерлар инде кире борылып чигенәләр. Аларны азинчылар куа бара. Ак офицерлар яралы хәлдә дә ияр каешына тотынып, атның корсак астына төшкән хәлдә дә атуларын дәвам итәләр. Кызыларменец Хәкимулланың күз алдында җиде кеше һәлак булды, унлабы яраланды. Дошман атлылары алдына кинәт кызыл атлылар килеп чыкты. Ике арада кылыч сугышлары башланды. Кызыл атлыларга ярдәмгә пехота да килгәч, ак чехлар һәм ак офицерларның отряды тәмам тар-мар ителде. Егермеләп офицер пленга бирелде.

Дошманнан бик күп җирләрне шулай азат итеп, 28 нче тимер дивизия Алабугага килеп керде. Шәһәрдә зур митинг үткәрелде. Дивизия командиры Азин алдагы яңа бурычлар турында сөйләде, зур батырлыклар күрсәтеп сугышучы кызылармеецларга һәм командирларга рәхмәт белдерде.

Алабугада күп кенә крестьяннар үзләре теләп Кызыл Армия сафына язылдылар. Араларында татарлар да күп иде. Берничә егет Хәкимулланы сораулар биреп аптырата. Берсе — шактый өлкән яшьтәге, озын мыеклы агай болай ди:

— Син Ленинны күрдеңме? Бу дивизия сугышчылары Ленинны яклап сугышамы?

Хәкимулла аңа ана телендә бик тәфсилләп аңлата:

— Без, Ленин фәрманы белән, Совет Россиясен дошманнан азат итү өчен көрәш алып барабыз. Яшь Совет республикасын саклап калу — безнең изге бурыч. Сез нәкъ шуны аңлап, кулыгызга корал тотып дошманга каршы сугышу өчен безнең дивизиягә язылдыгыз. Сезне чын күңелдән тәбриклим!

Иртәгесен азинчылар тагын походка кузгалды. Кызылармеец Шаһиморатов белән янәшә генә атлылар, алардан соң тупчылар, арттарак дивизиягә яңа гына кабул ителгән сугышчылар уза — роталар, батальоннар, полклар.

...1919 елның июлендә Кама елгасы буйлап «Красная звезда» дигән агитпароход «Тихая Гора» пристанена килеп туктый. Пароходта Надежда Константиновна Крупская һәм РКП(б) Үзәк Комитеты членнары була. Халык аларны кызыл флаглар белән каршы ала. Пароход туктауга көчле музыка тавышы яңгырый һәм яр буена җыйналган меңнәрчә халык «Интернационал»ны җырлый башлый:

**Кузгал, уян, ләгънәт ителгән**
**Коллар һәм ачлар дөньясы!..**

Пароходтан иң беренче булып Н. К. Крупская чыга. Аны комиссия членнары каршы алалар. Шунда ук митинг була. Сүз Крупскаяга бирелә. Ул Совет республикасын буып ташларга теләгән акгвардиячеләргә һәм интервентларга каршы аяусыз көрәшергә, дошманны тәмам кырып бетерергә чакыра. Аның сүзләре көчле кул чабулар белән бүленә. Ул һәрбер эшче һәм крестьянның йөрәгенә үтеп керерлек җылы сүзләр әйтә, Совет власте дошманнарына каршы кулга корал тотып көрәшергә, тылда армый-талмый эшләргә, Кызыл Армия сугышчыларын сугыш кирәк-яраклары, азык-төлек, кием белән тәэмин итәргә кирәклеген әйтә.

Митингтан соң ул Бондюг заводында була, цехларда эшчеләр белән очраша, әңгәмәләр үткәрә. Бу вакытта заводка ярдәм итү өчен фронттан җибәрелгән Хәкимулла Шаһиморатов клубта эшли. Аның тырышлыгы белән ачылган һәм эшчеләрнең культуралы ял итү урыны булган бу клуб белән Н. К. Крупская да кызыксына. Ул клубка килеп очрашу үткәрә. Татар эшчеләре һәм хезмәткәрләре белән очрашу бик күпләрнең хәтерендә саклана. Н. К. Крупскаяның митингта сөйләгәннәрен Бондюг заводы эшчеләре шунда ук татарчага тәрҗемә итәләр. Татар хатын-кызлары ораторның сүзләрен йотлыгып тыңлыйлар. Соңыннан бергәләп фоторәсемгә төшәләр. Н. К. Крупская клубка граммофон һәм В. И. Ленинның речь язылган алты пластинка бүләк итә.

Н. К. Крупскаяны Бондюг заводы эшчеләре һәм тирә-як авыллардан килгән крестьяннар зурлап озаталар. Соңыннан күпләр илне дошманнардан саклау өчен фронтка китә. Шулар арасыннан Хәкимулла Шаһиморатов, политработниклар хәзерли торган кыска сроклы курсларны тәмамлагач, 1919 елның сентябрендә Самара шәһәренә җибәрелә. Шунда төзелә торган 2 нче Аерым Идел буе татар бригадасында хезмәт итә. Бу елларда татар-башкорт сугышчылары арасында грамоталы кешеләр әле аз була. Бригада политбүлеге Шаһиморатовка татар-башкортлар арасында пропаганда һәм агитация эшләрен ана телендә алып баруны йөкли. Сугышларда чыныккан, дары исе иснәгән Хәкимулла бу эшне бик яратып башкара. Аның тырышлыгы аркасында кызылармеецлар арасында ныклы тәртип урнаша, күп кенә сугышчылар Коммунистлар партиясенә керергә теләкләрен белдерәләр.

Шул ук елның ахырында Шаһиморатов тимгелле тиф белән авырып госпитальгә керә. һәм анда шактый озак дәвалана. Тазарып чыкканда аны завод дирекциясе, тәҗрибәле эшче буларак, заводны аякка бастыру өчен үзләренә сорап ала. Бондюг химия заводында эшчеләр Шаһиморатовны профсоюз оешмасына сайлыйлар, берничә тапкыр өяз һәм өлкә профсоюз конференцияләренә делегат итеп җибәрәләр. 1920 елда ул, РКСМ оешмасыннан делегат булып, өлкә конференциясендә катнаша.

1923 елда аны Бондюг поселок Советы башкарма комитеты председателе итеп сайлыйлар. 1924 елда исә ул, Казанга совет-профсоюз эшенә күчерелеп, республика

баш судында, Татарстан АССР Верховный Советы Президиумында һәм Финанс министрлыгында эшли.

Озак еллар зур тырышлык куеп эшләве һәм җәмәгать эшләрендә актив катнашуы өчен Хәкимулла Шаһиморатов Татарстан АССР Верховный Советы Президиумының Почет грамотасы һәм медаль белән бүләкләнә. Бөек Октябрь революциясенең илле еллыгы уңае белән гражданнар сугышында актив катнашуы өчен ул Кызыл Йолдыз ордены белән бүләкләүгә лаек була.

Гражданнар сугышы һәм хезмәт фронты ветераны Хәкимулла аганың яше инде сиксәннән узып китте. Ләкин әле ул җәмәгать эшләрендә яшьләрчә энергия белән тырышып катнаша. Тынгысыз ил агасы һаман алгы сафта! Аның батырлыгы һәм эшчәнлеге — яшьләргә якты үрнәк.

Ветеранның улы Равил дә әтисе кебек тырыш һәм эшчән. Ул Бөек Ватан сугышында катнаша, медальләр белән бүләкләнә. Елга техникумын тәмам иткәннән соң Агыйделдә штурман була. 1954 елда МТСта партком секретаре итеп күтәрелә. 1955 елда ул Татарстан өлкә комитетында инструктор булып эшли башлый. Озак еллар Алексеевский район советының башкарма комитет председателе булып эшләде. Хәзер шул ук районда КПСС райкомының беренче секретаре, Татарстан АССР Верховный Советы депутаты. Тырыш хезмәтләре өчен ике тапкыр «Почет билгесе» ордены, 1976 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены һәм медальләр белән бүләкләнде.

Кызы Разия да Бөек Ватан сугышы ветераны, озак еллардан бирле аптекада эшли. Яхшы эшләве өчен медальләр һәм Почет грамоталары белән бүләкләнде.

Язмабызның башында без Хәкимулла аганың Казан Кремле янына еш килүен әйткән идек. Әйе, Казан Кремле аңа бик кадерле һәм газиз. Ул Кремль эчендә ак чехлар тарафыннан үзенең остазы, революционер Гассарның җәзалап үтерелүен фронтта чакта ук ишетеп, зур кайгы кичерде. Кызыл фронтлардан йөреп кайткач Казанга килде һәм Кремльгә юл тотты. Анда ул чехлар тарафыннан корбан ителгән революционерларны хөрмәтләп озак басып торды. Менә шуннан бирле ул һәр елны монда килә. Гассар белән очрашуларын искә төшерә, үзенең гражданнар сугышында кулына корал тотып акгвардиячеләргә һәм интервентларга каршы көрәшеп йөрүләрен күз алдына китерә.

Казан шәһәре. Чал Кремль. Аның янында ветераннар. Арада Хәкимулла Шаһиморатов та бар.

Иделдән пароходлар кычкыртып уза. Казан вокзалыннан тиз йөрешле поездлар алга ыргыла, шәһәр урамнарыннан шатлыклы елмаеп студентлар, эшчеләр уза. Әнә бер төркем мәктәп укучылары республика музеена килгән. Кремль каршында — туристлар һәм пионерлар, комсомоллар. Экскурсовод аларга чал Казан тарихын, гражданнар сугышы елларын, Азин дивизиясе сугышчылары турында сөйли. Яшьләр өлкән яшьтәге ветераннар белән очрашалар, аларга чәчәкләр бүләк итәләр.

Тирә-якта күгәрченнәр оча. Күк йөзе зәп-зәңгәр, анда якты һәм җылы кояш елмая. Ачык күк йөзенә карап барча ветераннар белән бергә Хәкимулла Шаһиморатов та шатлана. Бүгенге бәхетле тормыш өчен алар күпме көрәштеләр, күпме кан һәм тир түктеләр. Һәр җирдә, һәр урында аларның көрәше, аларның тырыш хезмәте чагыла.

-----------

**Рәүф Игъламов**

# ЗАМАН КӨЗГЕСЕНӘ КУЕП

Күп кырлы иҗат эшчәнлеген егерменче йөзнең унынчы елларында башлап, Бөек Октябрьдан соңгы чорда гүзәл сәнгать казанышларына ирешкән Кәрим Тинчурин драматургия һәм театр сәнгате эшлеклеләре арасында аерым бер урын тота. Татар совет театры ныклап аякка басып, юл ярып китүе белән, иң беренче чиратта, аңа бурычлы. Татар театрының нигез салучысы Габдулла Кариевның вафатыннан соң К. Тинчурин — сәйярчылар арасында танылган авторитет — остазы һәм фикердәшенең иң якын ярдәмчесе сыйфатында яшь республикабызда театр эшен җитәкли. Мәшһүр драматургыбыз Галиәсгар Камалдан эстафетаны кабул итеп алып, К. Тинчурин ел саен дип әйтерлек яңадан-яңа драма-комедияләр иҗат итә. Аларның иң яхшылары — культура хәзинәбезнең аерылгысыз энҗе-җәүһәрләре. Актер, режиссер, театр педагогы һәм тәнкыйтьчесе буларак та Тинчурин — чын-чынлап ренессанс сәрәнчесе, яңарыш чоры каһарманы буларак күз алдына баса.

Татар драматургларының беренчеләре арасында Кәрим Тинчурин бүген дә иң күп репертуарлы автор. Аның әсәрләре бүген дә тамашачыны дулкынландыра, көтелмәгән яңа мәгънәләре белән үзенә тарта. «Сүнгән йолдызлар» пьесасы, мәсәлән, сәхнә теле, төпкә салынган фикере белән заманча яңгырый, фикер һәм хисләрне хәрәкәткә китерә. Яисә Академия театры сәхнәсендә 1969 елны яңартылган «Американ» комедиясе тамашачыларның күңелләрен яулар, белгечләр тарафыннан да җитди бәяләнер дип кем уйлаган? Ул әсәрләрне сәхнәгә куйган, РСФСРның атказанган сәнгать эшлеклесе Марсель Сәлимҗановның режиссерлык табышларын тәкъдир иткән хәлдә, тирән эчтәлекле пьеса булганда гына әйбәт спектакль туа ала дигән мәгълүм хакыйкатьне кабатларга туры килә. 1924 елда беренче тапкыр сәхнәгә куелып та, театр тәнкыйтеннән әллә ни зур мактау ишетмәгән әсәрнең кырык биш елдан соң сәхнә шаулатып, театр тормышында тирән эз калдырырлык вакыйгага әверелүенә гаҗәпләнмичә мөмкин түгел. СССР халыкларының театр белгече А. Анастасьев болай дип билгеләп үтә: «Г. Камал исемендәге татар театры гастрольләре закытында мәскәүлеләр Кәрим Тинчуринның һич тә искермәгән гүзәл сатирик комедиясе «Американ»ны карадылар. Миңа калса, ул бөтен күп милләтле совет театры өчен дә кызыклы әсәр». Тәнкыйтьче фикеренчә, «Американ» спектаклендә «тамашачылар кыю, үткен, һәм шул ук вакытта, нечкә сатира дөньясы белән очрашалар»[1]. «Правда» газетасында басылган рецензиядә дә «пьеса бүгенге тамашачыга идеясенең ачыклыгы, заманча сурәтләү чараларына бай булуы белән якын» диелә[2].

---

[1] А. Анастасьев. 45 телдә. Мәскәү. «Искусство» нәшрияты, 1972 ел, 89, 111 битләр. Рус телендә.
[2] О. Кайдалова. Традицияләргә таянып. «Правда» газетасы, 1970 ел, 1 август саны.



Тинчурин әсәрләре заман белән бергә ачыла, яңара, тирәнәя баралар. Драматургның бөтен иҗаты бер үк дәрәҗәдә кыйммәтле диген сүз түгел бу, әлбәттә. «Американ», «Җилкәнсезләр», «Сакла, шартламасын» сатирик комедияләре, «Сүнгән йолдызлар», «Зәңгәр шәл», «Ил» драмалары кебек идея-сәнгать ягыннан камил әсәрләре белән беррәттән (ә алар бер дистәдән дә ким түгел), К. Тинчурин мирасында тәмамланып җитмәгән, сызым-караламалар рәвешендә генә калган әсәрләр дә байтак. «Соңгы сәлам», «Зар», «Нәни абый» кебек йомшак әйберләр дә юк түгел. Шунысы гаҗәп, К. Тинчуринның драматург буларак киң танылып китүе аның иң яхшы әсәрләре хисабына булмаган. Иң катлаулы һәм бәяле жанрлардан берсе — сатира жанрына әдип үзе исән чагында шикләнебрәк карау да яшәп килә. Тамашачылар алдында К. Тинчурин барыннан да бигрәк музыкаль пьесалары белән танылa. СССР халыклары сәнгатенең 1930 елда узган беренче олимпиадасында, мәсәлән, татар театры күрсәткән өч спектакльнең икесе К. Тинчуринның «Зәңгәр шәл» һәм «Ил» мелодрамалары була. Шулай ук Казан сәхнәләрендә дә драматургның сатирик әсәрләреннән бигрәк мелодрамалары өстенлек итә. К. Тинчуринның музыкаль-драматик иҗаты аның индивидуаль иҗат стиленең үзенчәлекле бер тармагы ул. Асылда бу теоретик планда тикшеренүне таләп итә торган катлаулы мәсьәлә. Биредә бары тик шунысына басым ясап үтик: аерым-аерым алганда мелодрамаларның кайберләре каршылыклы фикерләр тудырсалар да, тәгәлләнгән бер цикл итеп караганда, алар гаять киң колачлы, тирән эчтәлекле күренеш булып алга килеп баса. «Зәңгәр шәл», «Сүнмәс йолдызлар», «Казан сөлгесе», «Ил», «Кандыр буе» музыкаль пьесаларында без революциягә кадәр һәм совет чынбарлыгы шартларында халык узаңының ничек үсә баруы темасын күрәбез. Әмма шулай да, фикеребезчә, Кәрим Тинчурин талантының тирәнлеге аның мелодрамаларында түгел, ә сатирик комедияләрендә күбрәк ачыла төшә. Ләкин Тинчурин иҗатының чәчәк аткан чорында театрның музыкаль драмалар белән күп мавыгуы әдәби процесста драматург иҗаты тоткан урынны һәм аның әһәмиятен тәнкыйтьнең беркадәр киметеп күрсәтүенә китергән. Аның эшчәнлегенә тулаем алганда югары бәя бирелеп килсә дә, кайбер кырын тенденцияләр булуы да үзен сиздерә. Бу бигрәк тә драматургның Бөек Октябрьга кадәрге чор иҗатына мөнәсәбәттә чагыла. Иҗатының башлангыч чоры кайчак тикшеренүчеләр игътибарыннан читтә үк кала. Мәсәлән, И. Нуруллинның «Путь к зрелости. Проблемы реализма» исемле кыйммәтле хезмәтендә К. Тинчурин драматургиясе читләтеп үтелә. Әдипне «Сәйяр» труппасы ихтыяҗын канәгатьләндерү өчен генә яза торган, шул труппа драматургы итеп кенә карау да Тинчуринның революциягә кадәрге иҗатын дөрес бәяләүгә комачаулый. Профессор М. Гайнуллинның «XX йөз башы татар әдәбияты һәм публицистикасы» исемле хезмәтендә, мәсәлән, «бу труппаның алдынгы һәм талантлы драматургларыннан берсе Кәрим Тинчурин иде», диген юлларны укыйбыз (Татарстан китап нәшрияты, 1966 ел, 341 бит). Болай әйткәндә, К. Тинчуринны Г. Мангушев, Г. Кариев кебек актер-драматурглар белән бер рәткә куярга кирәк булып чыга. («Алдынгы», «талантлы» эпитетлары гына мәсьәләне үзгәртми.) Югары әдәбият күзлегеннән К. Тинчуринның революциягә кадәрге иҗаты ниндидер түбәнрәк дәрәҗәдәге драматургия итеп карала дип әйтергә туры килә.

Драматургның әсәрләренә багышланган монография әле дә булса чыкканы юк, махсус фәнни мәкаләләр дә бик аз. Шулар арасында әдипнең 1935 елны чыккан пьесалар җыентыгына Гомәр Галинең «Драматургның үсеш юлы» дип аталган кереш мәкаләсе, талантлы тәнкыйтьче тарафыннан язылган булса да, инде шактый дәрәҗәдә

искергән. К. Тинчурин турында төрле планда язып чыккан кешеләр шактый булуга да карамастан, бу катлаулы талантның табигатенә үтеп керергә әллә ни омтылыш сизелми. Моның үз логикасы бар. Әдәбият белеме күзлегеннән карап тикшерү генә әлеге очракта җитәрлек нәтиҗә бирми. Эш шунда ки, Тинчурин иҗаты әдәбият һәм театр башлангычларын бик тә үзенчәлекле һәм органик төстә бергә тоташтырган иҗат. Әйтик, күп пьесаларына ул режиссер ремаркалары кертә, аннан да бигрәк, турыдан-туры текст эчендә теге яки бу күренешнең пластик чишелеше бирелә. Болар исә, гадәттә, спектакльне сәхнәгә куйганда хәл ителә торган мәсьәләләр. Алай гына да түгел, кайбер пьесаларын (барыннан да элек музыкаль-драматик әсәрләрне) драматург сценарий рәвешендә язган һәм алар театрда репетицияләр барышында төгәлләнгән хәлгә китерелгәннәр. Бу очракта без егерменче елларда театрда барган спектакльләрнең язмалары белән эш итәбез. Репетицияләрдә һәм сәхнәдә уен вакытында шомартылып, сыналып һәм билгеле бер камиллеккә ирештерелеп җитмичә, К. Тинчурин әсәрне бастырып чыгарырга ашыкмый. Болардан башка тагын шунысы да бар: Тинчурин, театрның сәнгать җитәкчесе, режиссеры, актеры буларак, труппаның, аерым актерларның иҗат колачын һәм мөмкинлекләрен бик яхшы белеп, күп рольләрне мәгълүм шәхесләргә төбәп язган. К. Тинчуринның иҗат стиленә хас бу үзенчәлекләр аның әсәрләренең сәнгатьлелек дәрәҗәсенә хилафлык китерми, әлбәттә. Чөнки ул һәр очракта диярлек зур оста, чын художник булып кала.

Әмма театраль аспект әдип иҗатының бердәнбер хикмәтле ягы түгел. Безнең карашыбызча, Тинчурин әсәрләренең иң төп һәм кыйммәтле ягы — мәгънәви эчтәлекләренең вакыт перспективасында ачыла баруында. Тикшеренүләрдә киң таралган тарихи-генетик ысул, академик М. Храпченко әйтүенчә, «әдәби әсәрләрнең киләчәк гомерен алдан күрергә мөмкинлек бирми; ни генә димә, ул әсәрләр тора-бара башка заман орбитасына күчәләр, яңа идея-эстетик ихтыяҗлар сферасына керәләр. Һәм тикшеренүче галим вак тарихи һәм тарихи-көнкүреш комментарийләре белән үзен күбрәк чикләгән, локаль әдәби чагыштыру-янәшә куюлар белән күбрәк мавыккан саен, әдәби әсәрләрнең яшәеш асылына төшенү мөмкинлекләре кими бара»[1].

Сәнгатьнең тәэсир итү көче, проблема буларак, монда хикәяләү жанрларына карата куела. Ә драматургиядә бу мәсьәлә хәлиткеч әһәмияткә ия. Чөнки драма әдәбиятка да, театрга да бер үк дәрәҗәдә карый, аның үзенә күрә бер «эстетик феномен» булуы шуның белән аңлатыла. Драма әсәре, әлбәттә, театр өчен языла, һәм театр, К. Станиславский сүзләре белән әйткәндә, «шушында, бүген, шушы мәлдә» иҗат итә.

Әсәрнең эчке куәте аның кайсы өлешләрендә, ни дәрәҗәдә сакланган булуын белү театр өчен гаять мөһим нәрсә. Кайчандыр язылган пьесадан — һәм эчтәлеге, һәм формасы ягыннан — бүгенге заманның идея-эстетик ихтыяҗлары юнәлешендә нинди дә булса җепләр сузыламы, — театрны әнә шул мәсьәлә кызыксындыра. Драманың тарихи-эстетик хәрәкәтчәнлеген өйрәнү шушы максатны күздә тота һәм ул шуның белән әһәмиятле дә.

К. Тинчурин пьесалары үзләренең идея эчтәлекләре, тема һәм образлары ягыннан аларны тудырган дәвер, заман чикләрендә йомылып калмыйлар. Алар «эчке хәрәкәткә» сәләтле, яңа чорда мәгънәви эчтәлекләре тагын да калкурак, тирәнрәк ачыла. Драматург иҗатының революциягә кадәрге чорын (ә ул әдәбиятыбыз тарихында бик аз өйрәнелгән) нәкъ әнә шул күзлектән тикшерү күп кенә кызыклы фикерләргә китерә.

Кәрим Тинчурин драматургиягә Г. Камал, Ф. Әмирхан, Г. Коләхметовтан соң килә. Аның элгәрләре, нигездә, татар либераль буржуазиясе белән демократик интеллигенция вәкилләре арасындагы бүленеш башланган чорда мәйданга чыгалар. Бу көрәшнең асылын аңлауда төрле дәрәҗәдә торсалар да, үзләренең каләм куәтен алар буржуазиягә каршы юнәлтәләр. Тинчурин шушы процессның киңәя барып, һәр тарафка таралган чагына юлыга. Сыйнфый көрәш кануннарын, тормышны тамырыннан үзгәр-

---

[1] Язучының иҗат индивидуальлеге һәм әдәбият үсеше. Мәскәү, «Советский писатель» нәшрияты, 1975 ел, 209 бит. Рус телендә.

теп коруда хәлиткеч рольне уйнаячак көчнең кайда икәнлеген ачык кына күз алдына китерә дә алмаган килеш, Тинчурин 1905—1907 ел революциясеннән соң политик хакимлеккә омтылган милли буржуазияне социаль-этик яктан фаш итүгә керешә. Патша хөкүмәтенең колониаль изү политикасы әле дәвам иткән шартларда буржуазиянең бу дәгъвасы тышкы яктан прогрессив булып күренә. Гомуммилли хәрәкәт, милли азатлык өчен көрәш әләмнәренә төренгән буржуазия үз тирәсенә демократик көчләрне тупларга омтыла. Социаль яктан куркынычлы тозак әнә шунда яшеренгән дә инде. К. Тинчурин буржуазиянең бу кармагын бик тиз күреп ала, хезмәт интеллигенциясе позициясеннән торып, буржуа сыйныфы вәкилләрен һәм аларның иярченнәрен аяусыз камчылый башлый. Ул аларның икейөзлелеген, паразитлыгын, черек фәлсәфәсен эчтән ачып сала. Шушы максатка барыннан да элек сатирик комедия җавап бирә һәм тиздән ул драматургның төп коралына, сугышчан жанрына әйләнә. Мәгълүм ки, уңай геройны гәүдәләндерү сатира жанрында мәҗбүри шарт түгел. Димәк, конфликтны да ул ачыктан-ачык калкытуны таләп итми.

Аеруча әһәмиятлесе шунда ки, буржуаз сыйныфны тәнкыйтьләү белән бергә, Тинчурин буржуаз әхлакның башка катлауларга ясаган кире тәэсирен, зарарлы йогынтысын да күрсәтә. Буржуазия вәкилләренә хас бозык хиссият, уй-фикер сөреше, черек әхлакның төрле иҗтимагый катлауларга да үтеп керүен, аның аянычлы тәэсирен күрү драматург күңелендә әрну һәм нәфрәт тудыра. Тинчурин каләменең көче дә әнә шунда — дөньяга индивидуалистик мөнәсәбәтнең агрессив, йогышлы күренеш булуын үткен итеп ачып салуында. Тәнкыйть тарафыннан игътибарсыз калдырылып килгән бу тема магистраль юл булып Тинчуринның бөтен иҗаты буенча үтә. Аны без «Беренче чәчәкләр», «Назлы кияү», «Йосыф белән Зөләйха» әсәрләрендә үк очратабыз. Ә совет чорында исә ул юнәлеш яңа мотивлар белән байый, катлаулана, үсә барып, шедевр дәрәҗәсендәге «Җилкәнсезләр» трагикомедиясенә китерә. Егерменче елларның ахыры, утызынчы елларның башында язылган «Хикмәтле доклад», «Алар өчәү иде» кебек әсәрләрендә дә язучы кешеләр аңындагы буржуаз әхлак чагылышларына каршы көрәшә. Иске тәртипләр себерел түгелгән, ә эгоизм, үз мәнфәгатьләреңнең генә колы булып яшәү, карьерага омтылу, башка төрле бозык фигыльләр күпләрнең күңелендә яшеренеп ята, алар яшәүчән, өскә күтәрелеп чыгарга һаман юл эзли. Менә шундый чорда драматургның сатирик иҗаты яңа җәмгыять, яңа кеше өчен куәтле көрәш коралы булып хезмәт итә.

---

Кәрим Тинчуринның җитлеккән әсәрләренә хас проблематика һәм драматургия үзенчәлекләре «Беренче чәчәкләр»ендә үк шактый ачык сиземләнә. Тормышта нинди максатны өстен куярга, кайда хаклык, кайда ялган — драма персонажлары үз алларына әнә шундый сораулар куя. Бу сорауларга автор Хәмит шәкертнең тормыш юлы мисалында җавап бирергә тырыша. Гади крестьян улы Хәмит аң-белемгә, фәнгә юл ярырга омтыла. Аның аңлавынча, бу юл аны сөйгән халкына файдалы кеше итәчәк, ярлылыктан интеккән, иске гореф-гадәтләр коллыгында, караңгылыкта җәфа чиккән хезмәт иясе кешесенә бәхетле тормыш алып килергә мөмкинлек бирәчәк. Хәмит киләчәктә үзен врач итеп күрергә тели. Егетнең бу теләге әсәрнең образлы системасында халык җәрәхәтләрен дәваларга омтылыш булып та аңлашыла. Әсәрдә һәр конкрет детальнең диярлек әнә шундый күчерелмә мәгънәсе, тирән кинаясе бар.

Хәмит, унбиш ел буе иске мәдрәсәнең тынчу һавасын сулап, үпкә авыруы алган. Татар яшьләре өчен мәдрәсә — үзенә бер төрмә, халык тормышы да төрмә шикелле үк караңгы. Герой менә шундый тормыштан котылу, халкын караңгылыктан йолып алу теләге белән яши. Көнкүреш планы һәм гомумиләштерелгән поэтик план бергә кушыла. Без моны беренче күренештә үк сизәбез. Мәдрәсәдә укуны тәгәлләгән пишкадәмнәр тормышта урын таба алмыйлар. «Укучы» да түгел алар, «укытучы» булырга да өлгермәгәннәр. Менә шундый арадаш ситуация авторның максатына бик тә ятыша, персонажларның фикер-омтылышларын ачып салырга мәҗбүр итә.

Хәмиткә авторның мөнәсәбәте нинди? Тәнкыйтьче Гомәр Гали автор позициясен герой позициясе белән тиңләштерә, аның фикеренчә, Тинчурин Хәмитне үз заманының иң уңай тибы дип саный. Бу хата фикер, драматик ситуацияне исәпкә алып җиткермичә, драманың сүзле сурәтләү чараларын абсолютлаштырудан килеп чыга.

Дөрес, автор бу әсәренә 1934 елны яңадан әйләнеп кайта һәм шактый гына үзәртүләр кертә. Яңа редакциядә әсәр геройларының берсе Хәйдәр яшертен эш алып аручы революционер итеп бирелә. Бу хәл әсәрнең таяну ноктасын үзгәртә, драмаа яңа этәргеч көч барлыкка килә. Элек бик үк аныкланып җитмәгән образларга мәсәлән, Ильяс образы) ачыклык кертелә. Тамашачы алдында Хәмитнең дәрәҗәсе кими төшә. Шуңа да карамастан, әсәрне җентекләп укыганда, беренче редакциядә к авторның Хәмиткә яхшы мөнәсәбәттә торуын күрү кыен түгел. Хәмит — реакция орының киң таралган интеллигент тибы. Аның омтылышлары реаль мөмкинлекләргә уры килми. Бу хакта аңа беренче пәрдәдә үк Кыям турыдан-туры әйтә. Хәмит чын ормышны да өстән-өстән генә белә. Шуның аркасында ул урам кызы Сатирә алында уңайсыз хәлдә кала. Авторның үз героена карашы гади булмавын беренче әрдә ахырында аеруча ачык күрәбез. Хәмит үз хыялын тормышка ашырырга ант тә. Аның күңеле очынган вакыты, тавышы һәм кыяфәте мәгърур. Шул чак урамнан Беренче садә» җыры ишетелә, Хәмит йөгереп килеп тәрәзәне ача... һәм нәкъ шул минутта автор патетик күренешне комедия алымы белән бүлеп куя. Шәкерт Хәкимкан, берни дә булмаган кебек: «Аш кайнап чыкты, камыр салырга әйдәгез!» диюе белән бүлмәдәгеләрне «каты җиргә» төшереп утырта. Геройның пафосына, шул рәешчә, ирония килеп кушыла. Әсәрдә шушыңа охшаш хәлләр аз түгел. Геройларның өйләмә психологик характеристиканың бер ягы гына икәнлеге аңлашыла.

Хәмит кебекләрнең җирлеге йомшак, ышанычсыз, халык терәге булырга омтылары да чарасыз хыялдан узмый. Чөнки алар реформистлык программасы белән чикләнеп калган — башта үзем кеше булам, аннары башкаларга булышам дигән утолик фәлсәфәдән арырак китмиләр. Киеренке сыйнфый көрәш барган дәвердә мәгърифәтчелек иллюзиясе геройны ялгыш юл белән алып китәргә мөмкин иде.

Драманың поэтик гомумиләштерелгән эчтәлегеннән чыгып фикер йөрткәндә, ике социаль көч геройны үзенә ияртергә омтыла. Бу көчләрнең тегесе яисә бусы өстенлек алырга мөмкин. Большевик-революционер Хәйдәр өчен Хәмит — ярлы крестьян улы, революциядә аңа урын табылачак. Буржуазия вәкиле Тимерхан өчен исә ул — вак буржуаз мохиттан чыккан интеллигент. Үз чарасына кереп китеп («кеше булам», «бәхетемне табам»), ул төп максатын онытырга, халык хезмәтчесе булу теләген югалтырга да мөмкин. Ә мондый кеше хаким сыйныф өчен бик кулай һәм файдалы ул. Хуҗалары теләндә сайрый торган, чыгышы белән хезмәт ияләренә якынлыгы аркасында, массаларга йогынты ясый алырлык тугры хезмәтчене тагын кайдан табасың? Революция байгураларның үзләрен андый йогынтыдан мәхрүм итәчәк бит. Төп геройга хас эчке каршылыкның объектив мәгънәсе, драма конфликты әнә шундый. Әсәрнең алгы планында торган көнкүреш сюжеты шул конфликтны гәүдәләндерүгә хезмәт итә.

Хәйдәр кебекләрдән аерылып калганда, Хәмитнең «Җилкәнсезләр»дәге Батырханга әверелеп куюы куркынычы да бар. Героена теләктәшлек иткән хәлдә, К. Тинчурин бик нечкә чаралар ярдәмендә шуңа ишарә ясый. Хәйдәргә килгәндә исә, 1913 ел татар мохитында алар бик күп булмый, драматургка да алар аз таныш. Соңгы пәрдәдә без Хәмитне өметсез авыру хәлендә очратабыз. Үзе сайлаган юлның ялгыш икәнлеген аңлый башлаган ул. Егет беренче чәчәкләр, яшьлек өметләре хакында уйлана, уйлары әледән-әле Хәйдәргә әйләнеп кайта.

Безнең чорда «Беренче чәчәкләр» драмасының шушы яклары алгы планга чыга. Ә элек калку күренгән кайбер образлар эстетик нейтраль булып калалар. Мәсәлән, Суфи образы актуальлеген югалта дип әйтергә мөмкиндер.

Тинчурин үз геройларының эчке дөньясын бирүдә әле зарури сәбәп-нәтиҗә бәйләнешендә тәфсилләп тикшерми. Психологик тасвир алымына ул совет чорында, иҗатының җитлеккән елларында мөрәҗәгать итәчәк. Әмма геройларның психологиясен күңел тартышлары эчендә күрсәтеп бирүгә омтылмаган килеш тә (психологик чаралар аша образ тудыру революциягә кадәрге театрыбыз өчен гомумән хас түгел), персонажның сәхнәдәге яшәешен бик нечкә тоючы драматург характерларны психологик яктан конкретлаштыруга ярдәм итә торган ситуацияләр эзләп таба белә. Әсәрнең икенче редакциясендә ул, Хәйдәр образын кертеп һәм реакция чорын марксистик күзлектән бәяләп, ситуация һәм характерлар нисбәтен тагын да камил-



*«Ак чәчәк» көнендә туберкулез белән авыручыларга ярдәм итү кампаниясендә катнашкан бер төркем татар артистлары. 1913 ел. Басканнар (сулдан): Кәрим Тинчурин, Гөлсем Болгарская, Нури Сакаев, Габдулла Кариев, Сара Байкина. Утырганнар: Мәһирә Мөштәриева, Җәләл Байкин, Гайшә Терегулова.*

ләштерә. Геройлар хакында без аларның сүзләре буенча түгел, ә теге яки бу конкрет хәлләрдә кылган гамәлләре буенча фикер йөртәбез. Менә шушы конкрет хәлләр, ситуацияләр персонаж сүзләре һәм эшләренең чын мәгънәсен ачып бирәләр дә инде.

Беренче вариантта Ильяс образы аңлашылып бетмичә кала иде. Икенчесендә автор тамашачы алдында аның битлеген тагын да ача төшә. Әсәр геройлары өчен исә бу мәкер иясенең чын йөзе һаман да сер булып кала. Автор моңа нинди чаралар ярдәмендә ирешә соң? Спектакль барышында Ильяс төрле ситуацияләргә куела һәм төрле хәлләрдә аның үз-үзен тотышы сәер рәвештә үзгәрә. Әйтик, Хәйдәр белән очрашканда ул кыланышын алыштыра. Кәефханәгә шымчы килеп керүе дә иң беренче аңа тәэсир итә. К. Тинчурин яшертен доносчы Ильяс образы белән драмага политик эзәрлекләү темасын керткән.

Күрүебезчә, автор пьесада бик еш киная алымын куллана. Ремаркаларда күрсәтелгән ым-хәрәкәтләр, театраль метафоралар ярдәмендә тамашачыда төрле ассоциацияләр тудыра, әсәрне өстәмә мәгънәләр белән баета. Мәсәлән, Хәмит сәхнәдә беренче тапкыр күренүгә мәдрәсәнең беренче сыйныфында укучы бер төркем малайлар йөгерешеп керәләр. Алар, күз ачып йомганчы бүлмәнең астын-өскә китереп, юкка да чыгалар һәм сәхнәдә башкача күренмиләр. Шушы кечкенә генә күренеш әсәрдә драматизмны көчәйтә. Унбишәр ел мәдрәсәдә яткан егетләрнең бүгенге хәлен күреп, ул малайларны киләчәктә нинди язмыш көткәнен без бик яхшы аңлыйбыз.

Музыкаль-драматик әсәрләрен санамаганда, К. Тинчурин күпчелек очракта пьесаларын ачык конфликтка кормый, сыйнфый көрәшнең капма-каршы ягында торучы геройлар бер-берсе белән ачыктан-ачык бәрелешмиләр. Ул, әлбәттә, «Җилкәнсезләр» пьесасында капиталист Нуретдингә большевик Сөнгатьне, «Хикмәтле доклад»та буш куык Мортазага принципиаль коммунист образын, «Назлы кияү» комедиясендә Рәшит байга хезмәтчеләрне, «Йосыф белән Зөләйха»да Сәфәргалигә Солдатны каршы куя алган булыр иде. «Беренче чәчәкләр» әсәренең икенче редакциясендә пьесаның төп сюжет сызыгы итеп революционер Хәйдәр белән милләтче Тимерхан арасындагы конфликтны алырга мөмкин иде. Әмма бу конфликт пьесада беренче планга чыкмый, ә тик чагылып-чагылып кына үтә. Сатирик комедияләрендә булсын,

драмада («Беренче чәчәкләр») булсын, Тинчурин чорның төп конфликтын турыдан-туры сәхнәгә алып менми, ә тик читләтеп кенә чагылдыра.

Кәрим Тинчурин бу әсәрләрендә революция җил-давыллары белән урыныннан кузгатылып, хәрәкәткә китерелгән урта катлауларның тормышын, социаль яктан «нейтраль» катлау кешеләренең яшәешен күрсәтеп бирүне максат итә; актив социаль көчләрнең уртасында торган ул элементларны үткән дәвергә, иске тормышка бәйләп тота торган җепләрне калкытып чыгара һәм яңа чынбарлыкта аларның яшәеш перспективасын, тормышның яңа принципларын үзләштерүдәге мөмкинлекләрен ача. Драматургның иҗатында тарих, әнә шул рәвешчә, хәрәкәтчән процесс буларак гәүдәләнә. Драматург, үз максатына ярашлы рәвештә, әсәрләрендә яңа драматургик чаралар куллана, композициядә яңача корылышлар таба. Ике катлы сюжет — шул чараларның берсе. Ул төрлечә төзелә.

«Назлы кияү» (1915 елда язылган) әсәрендә вакыйга барышы өзек-өзек кисәкләр рәвешендә бирелә. Мәсәлән, беркатлырак төп герой Рәшитнең «укыган, общество күргән, матур туташ»ны эзләп тә таба алмагач, асрау кыз Гайнигә өйләнергә мәҗбүр булуы, аның белән аңлашуы пьесада күрсәтелми. Һәм ул күренеш әсәргә кертелгән булса, автор әйтергә теләгән төп фикерне кабул итәргә комачаулаган гына булыр иде. Рәшитнең кыз эзләү, өйләнү вакыйгасы — бары тышкы кабык, ярдәмче чара гына. Татар театры өчен традицион булган калыпка автор сатирик эчтәлек салган, татар буржуазиясен ачы тәнкыйть иткән әсәр тудырган. Милли каһарманнар битлеген кигән Ильяс, Зыялар, демагогик нотыклар сөйли-сөйли, Төркстаннан Казанга өйләнергә дип килгән бай егетнең кесәсен талкыйлар. Сатира укларын автор нәкъ менә буш куык татар буржуа әһелләренә каршы юнәлтә дә инде. Бай егетнең килен эзләшергә дип Казанга ияреп килгән туганнарын да драматург бик тулы күз алдына бастыра. Алар ниндидер ялган, тар дөньяда яшиләр, баскан җирлекләреннән аерылып, бушлыкта асылынып калганнар. Аларның киләчәге юк. Гаилә членнары арасында бетмәс-төкәнмәс, эч пошыргыч тартыш бара. Һәркем әллә кайчан ятланган, инде үзләрен дә туйдырып бетергән бер үк сүзләрне тәкърарлый. Аларның һәрберсе әледән-әле кызып китә, гадәтләнгән буенча гына нәрсәгәдер үпкәли, нидер исбатлаган булып кылана. Спектакльдә әнә шулай чын теләк-максатсыз, уйсыз-хиссез ага торган тормыш — механик яшәеш образы туа. Әмма бу ялыктыргыч мохитны тетрәндереп, вакыйгалар кинәт куерып китә. Яшь һәм бай кияүгә чын-чынлап ау башлана. Җиткән кызлар дауламый аны. Гомумән, егетнең үзе түгел, ә акчасы кызыктыра. Сизгерлеге чамалырак булуыннан файдаланып, шәһәр түзлары, һәркем булдыра алган кадәр, яшь кияүдән акча суырырга керешәләр. Көтелмәгәндә башланып киткән бу кампаниядә журнал нашире Ильяс, шәһәрдәге ширкәтләрдән берсенең рәисе Зыя, китап сәүдәгәре Әбүбәкер һәм тагын берничә вак шулер катнаша. «Беренче чәчәкләр»дәге кебек үк, көнкүреш һәм фикер сюжеты бер-берсеннән аерыла. Беренчесе буенча: герой — миллионнар иясе. Чынлыкта Рәшитнең миллионерлыгы җитди шик тудыра. Бердән, килен булырга тиешле кызлар, сүз куешкан шикелле, егеттән йөз чөерәләр. Казанда бер ел торып, ул һаман бер ни дә майтара алмаган. Икенчедән, Рәшит анасы, апасы һәм җизнәсе белән урта кул җиһазлы фатирда яшиләр, акча белән дә артык мул кыланмыйлар. Көнкүреш сюжеты, Тинчуринның башка күп кенә әсәрләренә хас булганча, алдавыч кына булып чыга. Шунысы кызык, бай егетеннән акча каеручы Зыя, Әбүбәкерләр материаль яктан өстенрәк күренәләр. 1975 елда Татар дәүләт академия театры куйган спектакльдә бу парадокс аеруча күзгә бәрелә: Рәшитне алдап кунакка чакырган хуҗалар үзләре чыннан да зиннәтләп бизәлгән бай йортта яшиләр. Талаучылар компаниясендә ике субъект калку булып аерылып тора. Берсе — татлы телле, нәзакәтле, укымышлы нашир Ильяс; икенчесе — сүзендә нык торучы хәйләкәр Әбүбәкер. Болар — бер үк медальнең ике ягы гына, ә асылда буржуаз мещанлык философиясен үзләштергән бер үк тип. Бу типны К. Тинчурин иҗат юлының буеннан-буена игътибар үзәгеннән ычкындырмый һәм «Җилкәнсезләр» комедиясендә классик дәрәҗәгә ирешкән Батырхан образына илтеп тоташтыра. Гадәттән тыш әрсез һәм ифрат яшәүчән тип ул. Аны революция дә экспроприацияли алмый — заводлары да, фабрикалары да юк аларның. Ул, һичшиксез, яңа мохитка җайлашырга тырышачак, күкрәгенә кызыл тасма тагып, яңгыравыклы лозунглар кычкырачак. Ә өендә як-ягына карана-карана (нишетә

күрмәгеннәр) властьны сүгәчәк. Милләтче дигән исем алмас өчен ул кәләпүшне ташлап, эшләпә янсә тагын да садәрәге — кепка кия. Электерергә тырышып кара син аны. Сәләтле кешеме ул, әллә Сәфәргали кебек эшлексез, җилкуармы — күңелендә барыбер ачу һәм көнчелек хисеннән башка һичнәрсәгә урын юк. Тормышта аска тәгәрәп төшү куркынычы тугач, «Йосыф белән Зөләйха» комедиясе герое Сәфәргали Йосыф кыяфәтенә керергә дә риза була һәм гашыйк егет сыйфатында бай карчыкка өйләнеп ала. Ләкин көтелмәгән хәл: йортка керүен керде Сәфәргали, тик берни дә отмады диярлек. Бактың исә, җәмгыятьтә генә түгел, гаилә эчендә дә бар икән ул эксплуатация дигән нәрсә! Карт хатынының боерыкларын үтәп, егет йорт эшләрен дә башкара, кибетләргә дә йөгерә. Хәзер инде хатынга приказчик, дворник, сторож яллап расходланасы да юк. Ә Сәфәргали кибеттә төрле вак-төяк әйбер алганнан калган тиеннәр белән канәгатьләнергә мәҗбүр. Алай да бай карчыгы биргән «сабаклар» бушка китми. Сәфәргали ишеләрне кәкре каенга терәтү ансат эш түгел ул. Озак та үтми, егет бу тормышның үзе өчен бик кулай якларын аңлап ала. Ул җиң сызганып үзеннән көчсезрәкләрне эксплуатацияләү эшенә керешә.

Романтик юнәлешле язучылар гүзәл Йосыф вә Зөләйха турындагы популяр сюжетны драма калыбына салып эшкәртсәләр, К. Тинчурин капиталистик чынбарлык шартларында мәхәббәт гармониясенең уйдырма гына икәнлеген күрсәтә. Әлеге «Йосыф» белән карачкы «Зөләйха» арасындагы никах икеләтә әхлаксыз, чөнки типсә тимер өзәрлек егет фәкыйрь кыз ролендә коллыкка яллана. Ир кешене йорт һәм гаилә башы дип исәпләү — шәрык культы — миф кына булып кала.

Әсәрнең төп герое Сәфәргалидә бөтен нәрсәгә карата ачу, үтә чыккан цинизм тупланып килүен драматург бик оста сурәтли. Революция буржуаз мохитның астын өскә әйләндереп ташлаган. Автор революциянең үзен күрсәтми, аның мещаннар дөньясына тәэсирен генә гәүдәләндерә. Вакыйга үсешендәге бу өзеклек әсәрнең эчке сюжетын тыгызлый, киеренкеләтә. Хәзер инде хәлләр бөтенләй киресенчә: Сәфәргали үзенең хәләл җефетенә «буржуй карчык» исеме таккан, һәм ул, әлбәттә, «изүче сыйныф» вәкиленә рәхим-шәфкать күрсәтми. Сәфәргали болганчык суда күбрәк балык тотып калырга, уңае килгәндә максимум файда алырга тырыша. Иске режим вакытында «җәфа чиккән» кеше буларак, аңа матди өлеш тә чыгарсыннар, портфельле урынга да утыртсыннар. Яңгыравыклы революцион фразеологияне үзләштереп тә өлгергән ул. Күп тә үтмәс, Сәфәргали советлар властен эчтән җимерү теләге белән яшәүче политик аферист Батырханга әверелер. Инде комедиянең 1918 ел башында язылганлыгын әйтеп үтик...

Театр һәм Кәрим Тинчурин — иксез-чиксез тема. Бер мәкаләдә аны өлешчә генә ачу да кыен һәм четерекле эш. Без драматург калдырган мирасның бик аз өлешен генә күздән кичердек. Шушы башлангыч чор әсәрләре дә Тинчуринның үз заманы эстетик ихтыяҗлары һәм таләпләреннән алда баруын раслый. К. Тинчуринны дөнья һәм рус классикасы, А. Чехов әсәрләре җәлеп итә. Моны без «Мәрҗәннәр» исемле автобиографик новеллалар циклыннан да беләбез. Аның колачы гаять тә киң, зәвыге күп нәрсәне сыйдыра, сәнгатьне ул коры эмпиризмнан өстен торган югары поэзия дип аңлый. Тинчуринның матбугаттагы чыгышлары да аның фикер көчен, тирән реалист булуын күрсәтеп торалар. К. Тинчурин әсәрләренең озын гомерлелеге нигезендә «Американ» һәм «Җилкәнсезләр» авторының тарихи сизгерлеге, зирәк акылы ята. Татар культурасының ике дистә ел эчендә үткән юлын гына түгел, бүгенге әдәбият-сәнгать процессын да Тинчурин исеменнән башка күз алдына китерүе кыен. Тинчурин мирасының шифалы йогынтысы башкаручылык сәнгатендә, режиссерлар һәм драматурглар иҗатында ачык сизелә.

**Альберт Яхин,**

филология фәннәре кандидаты



# БЕЗ КАБЫЗГАН УТЛАР

„Сүнмәс алар, сүнмәс алар хәтәр җилләрдә», дип, яңа тормышның яңа кешеләрен яңа сәхнәдә җырлатты Кәрим Тинчурин. Бу җыр беренче тапкыр «Кандыр буе» спектаклендә башкарылды.

Кәрим Тинчурин аеруча күренекле драматургларыбызның берсе. Ул язган җырларны яттан беләбез, пьесаларындагы геройларның исемнәрен онытмыйбыз... Театр өйрәтә, ул оныттырмый. Татар дәүләт академия театрын башта ук рәхмәт белән искә алып узыйк, чөнки Тинчуринның куәтле талант көчен халыкка җиткерүдә иң зур эшне шушы коллектив башкара. Һәр яңа сезонны театр аның «Зәңгәр шәл»е белән ачып җибәрә. Драматургның башка пьесалары да әледән-әле сәхнәләштерелә тора. Театр тарихында бер генә драматург әсәрләре дә Тинчурин пьесалары кебек уйналмаган. Аның пьесаларын сәхнәдә карамаган кеше бар микән?

Бәхеткә каршы, Кәрим Тинчуринны театр аша яхшы беләбез һәм, кызганычка каршы да, башлыча театр аша гына беләбез түгелме...

Кәрим Тинчурин турында ул артист та, драматург та, режиссер да, хикәяче дә, тәнкыйтьче дә булган дип язалар. Дөрес язалар! Ул чыннан да кабатланмас зур талантлы, тынгы белмәс, армый-талмый эшләүче, шат күңелле, көчле кеше булган. Әмма беренче чиратта барыбер драматург булган.

Драматург күбрәк иске татар тормышының негатив якларын — купецлары, мещаннары, руханилары, интеллигенциясе, хәрбиләре турында язды дибез. Кайвакыт, оялып кына, тематикасының тарлыгына киная ясыйбыз. Һәм ялгышабыз. Бер минутка гына татар драматургиясе тарихын Тинчурин пьесаларыннан башка күз алдына китереп карыйк әле. Күз алдына бик тә ярлы,өтек һәм берьяклы тарих килеп басар иде.

Кәрим Тинчурин иҗаты зур тарихи вакыйга һәм чорларны колачлый алды. Аның язган пьесаларын темаларының тарихи хронологиясе буенча күзалласак, татар тормышының берничә социаль катламы язмышын эченә алган төзек система килеп чыга. Социаль катламнарның Бөек Октябрь революциясенә кадәрге, революция елларындагы тормышы һәм илебезнең җиң сызганып социализм төзегән еллардагы халәте — менә шундый эзлекле, төзек компонентлар тезмәсеннән гыйбарәт ул системаның структурасы.

Язучының геройлары зур социаль үзгәрешләр, Бөек Октябрь революциясенең төрле этаплары эчендә яшиләр. Революция Тинчурин пьесаларында һәр хәрәкәттә, һәр репликада сизелеп торган актив катнашучы, төп вакыйга ул. Аның әсәрләрендә тасвирланган конкрет чорның, гадәт буларак, үзенә генә хас конкрет вәкилләре була. Соңгы пьесаларында исә төп геройлар — яңа тормышны төзүчеләр, революция тудырган яңа кешеләр.

Кәрим Тинчурин геройларын социаль катлам төрләренә генә бүлеп чыксак та, дистәдән узып киткән булыр идек. Әмма ул катламнарның һәрберсе эчендә карашлары, абруйлары, дәрәҗәләре һәм бигрәк тә характерлары белән бер-берсеннән аерылып торган бик күп төрле типлар да бар бит әле. Бу исә, үз чиратында, шул заманга хас катлаулы бәйләнешләрне, каршылыкларны зур тарихи дөреслек белән ачарга мөмкинлек биргән.

Мондый очракта гадәттә язучы турында, ул тормышны яхшы белгән, ныклап өйрәнгән, диләр. Әмма Кәрим Тинчурин турында алай дию генә җитми. Үзе язган тормышны нечкәләп ,белү белән бергә драматург вак-төяк күренешләрне әһәмиятле мәгънәви асыллары белән дә бәйли алган. Социаль катлам вәкиленең шул катламга хас характеры, омтылышлары белән генә канәгатьләнмичә, аларны кешеләр итеп тә, шәхес характерлары итеп тә куюга ирешкән. Ул тормышны катлаулы диалектик кар-




*Татар дәүләт академия театрының 1927 елгы гастрольләре өчен әзерләнгән афиша. Беренче рәттә: ишанның беренче хатыны ролендә Нәфига Арапова, Ишан — Зәйни Солтанов; икенче рәттә: Булат — Кәрим Тинчурин, Мәйсәрә — Рокыя Кушловская, Шәйхи бабай — Касыйм Шамил («Зәңгәр шәл»). Өченче рәт: хан — Зәйни Солтанов, Зөһрә — Рокыя Кушловская («Таһир-Зөһрә»). Аскы рәттә: Мисбах Хаҗи — Зәйни Солтанов, Батырхан — Кәрим Тинчурин, хәзрәт — Касыйм Шамил («Җилкәнсезләр»).*

шылыкларына аерып, һәм ул каршылыкларны бергә җыеп, философ буларак күзәтә һәм фикерле белгән язучы. Тинчурин талантының бер көчле ягы шуннан гыйбарәт.

Кәрим Тинчурин символ-образлар белән фикерләргә ярата торган язучы. 1913 елда ук иҗат иткән «Беренче чәчәкләр» драмасында революционер Хәйдәрне үпкә авыруыннан үлеп ятучы Хәмиткә иске тормыш турында сөйләтеп, драматург ул тормышны иске күпер белән тиңләштерә. «Иске күпернең черегән баганалары астына динамитлар куелган. Ут төртер өчен шырпы гына кирәк», — ди. Соңгы әсәрләренең берсе булган «Кандыр буе»нда автор бу символ-образга яңадан әйләнеп кайта. Аңарга әллә ничә мәгънә сала. Ут — яңа тормышның бер почмагы булган «Кызыл йолдыз» колхозына нур, ямь сибүче электр уты да, авыл советы председателе Һилалга җитми торган уяулык уты да. «Ут кирәк миңа, ут! Кулак эргәләрендә калган кортларны кей-

дерергә ут кирәк!» — дип гасабилана аумакай Һилал. Акбирдин өчен ут яңа кешенең яңа туган сыйфаты. Ударник Гөләндәм исә аны тагын да гомумирәк мәгънәдә куллана: «Син ут, Акбирдин, аңлыйсыңмы, ут. ... Ил өчен кирәкле, кадерле ут!» — ди. Ниһаять, әйтерсең лә ут турында барлык әйткәннәренә йомгак ясагандай, язучы аны пьесадагы үзәк җырына төп образ итеп кертә: «Без кабызган утлар сүнмәс алар...»

Шулай итеп, ут драматург иҗатында бер-берсеннән ерак нокталарны, ике очны тоташтыручы җеп ул. Күпер астына Хәйдәр төрткән ут һәм, аның нәтиҗәсе буларак, мәңге сүнмәс яңа тормыш уты...

Тирәннән, ерактан алдырып уйлый белгән Кәрим Тинчурин. Әмма фикерләр никадәрле тирән булмасын, тамашачы бит театрга коры фикер тыңлар өчен генә килми. Кәрим Тинчурин әйтәсе сүзен әсәрләрендә катлаулы хисләрдә, образларга төреп бирә. Хис, кичерешләр тудыру — сәнгатьнең иң серле лабораториясе. Әдәби тәнкыйть өчен иң четерекле, абындыра торган өлкә. Әмма ул лабораториягә керми торып язучының осталыгын да, талантын да, фикеренең тирәнлеген дә аңлатып булмый.

Кәрим Тинчуринның драматург буларак осталыгы турында сөйләгәндә, гадәттә, аның көлдерә белү осталыгын искә алалар. Күренекле драматург, Тинчуринның шәкерте Таҗи Гыйззәт сүзләренә таянып, сюжеты вакыйгаларга куе булмаган урыннарда матур сүзләр, кызыклы эпизодлар белән шомартып, тамашачыны ялыктырмый тотып тору һәвәсе турында язалар.

Кәрим Тинчуринның андый осталыгы да бар. Ләкин тамашачы аның әсәрләрен сүз уйната белгән һәм кызыклы эпизодлар таба белгән өчен генә яратмый. Сәхнәдә артистны үз аягына үзен абындырып та, ыштанынերттырып та, четерекле мәсьәләгә киная ясап та көлке тудырып була. Әмма шундый җиңел ысул белән көлке ясаган спектакльләрне искә төшерик, аларның гомере тәмәке тартучы гомере кебек кыска булды бит. Ә менә Кәрим Тинчурин көлкеләре яши, алар әлек ничек булса, хәзер дә шулай көлдерәләр. Димәк, алар буш түгелләр, димәк, аларның ниндидер серләре бар.

Тамашачыда «Җилкәнсезләр»дәге бай сәүдәгәр Мисбахның һәр сүзе диярлек көлке тудыра. Ул хәйләкәр, үткен, акыллы һәм чиктән тыш саран. Кесәсеннән бер генә тиен дә акча чыгармас өчен әллә нинди көчле дәлилләр, хәйләләр уйлап таба ала. Әсәрнең башыннан ахырына кадәр шул максат өчен көрәшә, ләкин күпме генә хәйләләмәсен, барыбер бирергә мәҗбүр була. Сәүдәгәр буларак, ул саран һәм хәйләкәр. Ләкин ул сәүдәгәр генә түгел шул әле — Советларның кан дошманы да, аңа каршы актив көрәшче дә. «Минем алдымда савит дигән сүзне телгә аласы булмагыз... Алла биреп, богауланган көннәрен бер күрсәм, тиреләрен үтмәс пычак белән, үз кулым белән тунар идем»,— ди ул. Шуның өчен ни тарткалашмасын, акчасын барыбер Советка каршы көрәшер өчен бирергә мәҗбүр була. Мисбахның мондый үз эчендәге конфликты, тамашачыга бер сизелгәч, әсәрнең буеннан буена сузылган бик оста табылган нигезе булып тора. Батырханнар, Нуретдиннар ни турында гына сөйли башласалар да, Мисбах сүзнең барыбер ахыр чиктә акча сорап бетәсен алдан ук абайлап тора. Шуның өчен тегеләр сүз башлау белән үк, бөтенләй башка нәрсә турында сөйләсәләр дә, «бер тиен бирмим» дип, кат-кат бүлдереп тора. Нәтиҗәдә көлке геройның кеше буларак характер үзенчәлеге беренче планга калкып чыга. Үзара талашкан вакытта Батырхан Мисбахның яңагына суккач, бу сыйфат беренче тапкыр күренеп китә. Ул рәнҗетүгә үпкәләү түгел, хәтта Батырханның кулын кысып рәхмәт үк әйтә. Максатының, бар тырышлыгының бөтенләй юкка булып чыгуын, ниһаять, аңлаган Мисбах сугуны үзенең ахмаклыгы өчен җәза итеп кабул итә. Советларга ул хәзер дә кан дошман, нибары Батырхан кебек бушкуыкларга ышанып акчасын биреп бетерүен генә ул ахмаклык дип саный. Әмма шәхес буларак аның хәле аяныч. Соңгы пәрдәдә ашарына беткәч, Мисбах, сату нияте белән, иске читек кунычы күтәреп керә. Язучы бу итек кунычын ике мәртәбә менә дигән итеп уйнатып ала. Һәм ничек кенә итеп уйната әле! Нуретдин бай кунычларның бәясен төшерү өчен яңа башлар сабасы да барлыгын әйткәч, Мисбах карт авыр сулап, бу сүзләргә бөтенләй башка мәгънә сала: «Башлар, яңа башлар кирәк шул»,— дип уфтана. Ә чыгып киткәндә балтырын күрсәтеп үзенең мәшһүр сүзләрен әйтә: «Иһи-һи-һи!.. Заманында болар да кәҗүл булганнар бит...» ди. Җан ачысы белән, үзенең, иске читек балтыры кебек, бер т[illegible]ормаслык үтмәс товарга әйләнүе турында сөйли.

Мисбах бай бу урында да көлке. Сәүдәгәр, дошман буларак көлке. Әмма шул ук вакытта кызганыч та. Мисбах — тарихның үткәне. Без тарихның үзенең үткәне белән көлеп хушлашуын яхшы беләбез. Үтәсе сыйныфның элеккечә батыр булып кылануы тарткалашулары көлке. Һәр сыйныф аерым шәхесләрдән тора. Ә шәхесләр ягыннан, аларның үзләре күзлегеннән караганда, шул ук күренешләр үзләренең трагедиясенә, драмасына әверелә. Мисбахның көлке ягы куәтлерәк булса, шул ук әсәрдә Нуретдин байның олы кызы Рәкыйдә трагедия куәтлерәк. Ул да үзенең сыйныфы белән китәргә тиешле герой. Әмма көрәшеп китми, көрәшер өчен ул бик зәгыйфь, чирле. Өстәвенә, Рәкыя бу көрәшнең, кукыраюларның җирлеге юклыгын сизеп тора. «Милли батырларга» карата үзенең мөнәсәбәтен яшерми, усал итеп, урынлы да, урынсыз да әйтеп тора. Рәкыянең сыйнфый драмасына бөкрелеге, зәгыйфьлеге дә өстәлә. Ул чын мәгънәсендә үз сыйныфы корбаны. Шуңа күрә арада иң кызганыч кеше.

Көлке, кызганыч герой — Тинчуринның үз табышы. Ә драматург табылган яңалыкның кыйммәтен бәяли белгән. Ул аны, беренчедән, әсәрендә тулысынча, барлык потенциаль эстетик мөмкинлекләреннән файдаланырга тырышкан. Икенчедән, башка әсәрендә, башка планда, икенче язмышларга бәйләп кабат файдаланган.

Мисбах белән Рәкыя бер-берсеннән нык аерыла дидек. Алар икесе дә бер үк әсәр геройлары. «Сүнгән йолдызлар»ында Тинчурин Рәкыя кебек үк бөкре, зәгыйфь героен тагын беренче планга чыгара. Ул да көлке дә, кызганыч та. Әмма Надир мәхдүм, Мисбахтан да, Рәкыядән дә аермалы буларак, үзенең кимсетелүен аеруча нечкә тоя белә торган герой. Ямьсез, кызу канлы утыз яшьләрдәге бу мулла малае авылның иң чибәр кызына күз атып йөри. Әйтерсең лә язучы бу типны татар драматургиясендәге иң беренче пьесаларыннан алып үз әсәре эченә кертеп куйган. Мирхәйдәр Фәйзи үзенең «Галиябану»ында андый типны көлке ягыннан арындырып, мәкерле, аяусыз, көчле итеп берьяклы үстергән иде.

Кәрим Тинчурин мәхдүмендә Мирхәйдәр Фәйзидәгечә мәкер һәм көч кенә түгел, ул барыннан да элек көлке образ, һәм шул ук вакытта шәхес буларак мескен дә әле.

Мәхдүмнең Сәрвәрне дәгъвалап йөрүе көлке. Ләкин ул үзенең елаклыгы, эгоистлыгы һәм булдыксызлыгы белән үзенә карата нәфрәт тә тудыра торган герой. Юк, Надирны яратырлык итеп сурәтләмәгән Кәрим Тинчурин. Егетләрне, шулар белән бергә Сәрвәрнең сөйгән егетен дә армиягә алуларын ишеткәч, ул чиктән тыш шатлана: «Сугыш, өһә, сугыш!.. Мин сугышка бармыйм, мин калам. Мин зәгыйфь, мин бөкре. Мин гарбун!..» дип кычкыруын үзе дә сизми кала. Башкаларның бәхетсезлегеннән дә үзенә бәхет эзли торган бәдбәхет кеше ул Надир. Ул хәтта Сәрвәрнең акылдан язуыннан да үзенә файда эзли.

Әмма Надир мәхдүмнең коточкыч тормыш логикасын тудырган сәбәпләр дә бар бит әле. Драматург нәкъ менә шул сәбәпләргә аеруча басым ясый да. Үзен башкалар кебек үк яраттыра, шатлана, аулак өйләрдә уйный ала торган кеше итеп күрсә килгән Надир — кеше бар. Авыл егетләренең сугышка китеп бетүе — мәхдүмнең ялгызы кызлар янында калуы, ниһаять, аңарга да кеше рәтеннән сүз кату өчен шарт тууы диген сүз бит. Сәрвәрнең акылдан шашып, бөкре, ямьсез Надирны үз яныннан куар хәлдә булмавы, мәхдүмгә үзенең сөйгәне янында булу мөмкинлеген бирә. Мәхдүм өчен ул да бәхет. Ул шуңа да канәгать. Шатланганда ул үзенең шул бик кечкенә бәхете өчен шатлана. Шуңа Надир мәхдүм көлке дә, бәдбәхет тә, кызганыч та.

Безнең тәнкыйтьтә әле шундый караш та яшәп килә. Имеш, комедия коры комедия генә булырга тиеш, аңарга драма яки трагедия буяулары кертү кирәкми. Шулай ителсә комедия үзе дә, драма да харап булачак, янәсе. Югыйсә жанрларның үзәра тыгыз мөнәсәбәттә яшәүләре инде күптән кабул ителгән хакыйкать иде булса кирәк. Һәрхәлдә, мондый методология белән Кәрим Тинчурин һәм аның кебек башка талантлы язучылар иҗатын аңлап та, өйрәнеп тә булмаячагы ачык.

Кәрим Тинчуринның катлаулы тойгыларны тамашачыга җиткерү ысуллары хәзергә тәнкыйтьчеләр һәм театр белгечләре алдында торган каты чикләвек әле. Аларны вату Тинчурин иҗатын өйрәнү белән бергә драматургиябезнең бүгенгесе һәм иртәгәсе өчен дә кирәк булачак.

Тинчуринның «матур сүзләре һәм кызыклы эпизодлары» арасында социаль характерда булмаганнары да очрый, әлбәттә. Ләкин язучы тапкан көлкесенә һәр очракта җитди мәгънә һәм ышандыргыч дәлил сала. Әйтик, «Зәңгәр шәл» пьесасында остаби-




*Оренбург татар дәүләт театрының «Зәңгәр шәл» спектакле афишасы. 1930 ел.*

кәләрне кунакка чакырган малай сүзләреннән тамашачы егылып көлә. Ә бит ул нибары сүзләрне бутап кына әйтә: «Әни әйтә, абыстайлар куера, ди, токмачлар килсеннәр...» ди. Мондый сүз уйнатуларны тормышта адым саен очратырга мөмкин. Аларны тыңлыйсың да, онытасың да. Драматургның осталыгы шунда ки, бу сүзләрне бутар өчен психологик нигезне ул алдан ук астыртын гына әзерләп куя. Кунакка чакырылачак абыстайларның саны күп. Алар бар да усаллар, тәрбиясезләр һәм ахмаклар. Әле генә сәхнәдә мәш килеп, юктан сүз куертып үзара җәнҗал куптарып йөргән хатыннарга карата «абыстайлар куера» дип әйтү, гипербола булса да, логик яктан аклана. Малайның ишек ачтыра алмыйча хафалануы һәм өстәвенә хәзрәтнең аны таяк белән

кыйнавы сүз бутау өчен психологик халәт тудыра. Сүз ялгыш буталган. Ялгыш кына абыстайлар сыйфатына тәңгәл килгән. Әмма нигезле һәм ышандыргыч итеп буталган һәм тәңгәл килгән.

Мәшһүр «Американ» комедиясендә Муса җәмәгать хадиме, милләт өчен «үлеп китә торган кеше». Ул икенче пәрдәнең буеннан-буена үзенең милләтчелеге белән мактана. Үзенең һәр кыланышын, кызының һәр һөнәрен, өендәге һәр нәрсәсен, барын да, югын да миллилек белән бәйли. Әмма тора-бара болар мәгънәсезлеккә әверелә башлый. Милли пәрәмәч, милли посу, милли җыр, бию, милли имән бармак, хәтта Шәехмирзаның тазы да милли икән. «Сез милли тазлыгыгыз белән мактанырга тиешсез», — ди аңа Муса. Ниһаять, шулардан соң бүсернең дә миллилеге мәгълүм була. Бүсерле кеше дә үзендә милли сыйфат барлыгы белән горурланырга тиеш булып чыга.

Ә Мусаның «дусты» тәрәккый Габдуллаҗан исә сүз саен үзенең артта калган милләт дәрәҗәсеннән югары икәнлеген тукып тора.

Менә ул хатынын «атасы, сиңа әйтәм» кебек әдәпсез сүзләрне әйтмәскә өйрәтә. «Кайчан шул тупаслыкларыгыздан котылырмын икән инде... Һичбер төрле итеп тәрәккый пәрвәрләндереп булмый үзегезне. Кара аны, Разия ханым, актык мәртәбә әйтәм, әгәр тагы «атасы» дип эндәшкәнеңне ишетсәм, биллаһигазим дип әйтәм, яңагыңнан утлар чыгарырмын!»

«Яңадан шул сиңа әйтәмеңне авызыңнан чыгарсаң, телеңне кадак белән тишәрмен. Гыйбди дисәң гыйбди. Мужик, надан... әнә ашханәдә дөмегеп тор».

Тагы бер мисал... «Алдынгы бай» кызын американга кияүгә чыгарга димли: «Мин, кызым, тупас татар бае түгел.Әгәр дә күңелеңә ошамый икән, мин сине көчләп бирмим. Ә инде минем сүземә каршы килүең өчен яңагыңнан утлар чыгарырмын...»

Геройларның характер логикасын җимермичә, әнә шулай көлдерә белгән Кәрим Тинчурин. Шул ук вакытта ул бер үк төшенчәнең капма-каршы якларын художникларга хас осталык белән тотып ала һәм аларны үзара янәшә куя. Гегель карт әйтмешли, үзара чәкештереп очкын, ут чыгару халәтенә китерә алган ул аларны. Драматург хәтта «алла өчен чукынып китәрмен» кебек өч-дүрт сүздән дә, карчыкның ишанга бозавы турында «Бозау төсле үк — синдәй-миндәй бозау ул, сикерә дә бакыра», дип бер гөнаһсыз акланууыннан да ут чәчрәттергән һәм шул ут яктысында аның үз төшенчәләре, мөнәсәбәтләре, фикерләре ялтырап, балкып торалар. Төптән уйлап, алдан хәстәрләп сәнгать логикасына аз гына да зыян китермичә үзенчәлекле һәм үзгәрүчән шартлар учагында яндырган ул характер каршылыкларын.

Кәрим Тинчуринның әдәби мирасы шактый зур. Ул ел саен диярлек пьеса язган. Кайбер елны икешәр, хәтта өчәрне дә иҗат иткән. Барлык пьесалары да сәхнәдә уйнала килгән. Әмма Тинчурин пьесалары саннарыннан бигрәк сыйфатлары һәм үзләрендәге яңалык, табышлары белән күренекле. Ул табышлар якты учаклар кебек һаман дөрләп, якты биреп торуларында дәвам итәләр.

Үзенең иң соңгы әсәрен Кәрим Тинчурин «Алар өчәү иде» дип атаган. Башка пьесалары кебек үк, аның бу әсәренә дә музыканы якын дусты, иҗатташы Салих Сәйдәшев яза. Бу драматургның Сәйдәшев белән соңгы мәртәбә бергә эшләве була. Бергәләп алар соңгы мәртәбә театрга килгәннәр, соңгы мәртәбә өчесе дә бергә булганнар. Тинчурин, Сәйдәшев һәм театр. Бу өч дус татар сәхнә сәнгатен бөтен илне таң калдырырлык итеп үстергәннәр. Алар өчәү иде... Кәрим Тинчурин фаҗигале рәвештә һәлак булды. Дустының фаҗигасен моңлы Сәйдәшев тә күтәрә алмады...

Татар академия театры исә бу авыр югалтулар белән килешмәде. Ел да сезонын Сәйдәшев музыкасын җырлап, Тинчуринның «Зәңгәр шәле» белән башлап җибәрә торган булды. Быел да шулай итте. Сәйдәшев музыкасы белән кушылган Тинчуринның башка әсәрләре сәхнәдән төшми уйналып киләләр.

Сәхнәдән, радиодан, телевизордан Тинчурин сүзләренә язылган Сәйдәшев җырлары әледән-әле яңгырап тора:

**Без кабызган утлар якты янар,**
**Якты янар хезмәт илләрендә...**

Риза Ишморат

# ДУС һӘМ ОСТАЗ

Әдәбиятыбызга Гафур Коләхметов, Шәриф Камал, Һади Такташ, Шамил Усманов, Гадел Кутуй, Габдрахман Әпсәләмов кебек күренекле әдипләр, шагыйрьләрне биргән Пенза яклары... Гасырыбыз башында Казанга килеп кешеләр күңеленә ут ягып, аларны җылатып та, көлдереп тә, уйландырып, моңландырып та күңелләрен айкар егет — Кәрим Тинчурин да шушы якларда, бик кечкенә бер авылның урта хәлле крестьяны гаиләсендә туып үсә. Казанга килгәч, унеч яшьлек Кәрим, ары сугылып, бире сугылып, озак кына вакыт бәхет эзләп йөри. Үзендәге барлы-юклы бәхетне дә башкалар белән уртаклашырга исәбе юк түгел аның. Ләкин йөрүләр уңышсыз. Табылмый бәхет. Болай да бик сай булган кесә яклары бөтенләй коргаксый. Йөри торгач, бер ашханәгә савыт-саба юучы малай булып эшкә керә. Тамак ялгарлык бераз рәт булса да, авыр һәм газаплы, ал-ялсыз хезмәт. Бәхет табылмый. Укырга омтыла яшь егет. Мең бәлаләр белән «Мөхәммәдия» мәдрәсәсенә керә. Күңеле белән ирекккә, яктылыкка омтылган Кәрим мәдрәсәдә дә бәхет таба алмый, яңалыкны таләп итеп баш күтәргән 87 шәкерт белән бергә мәдрәсәне ташлап чыга. Шәкертләрнең, шулай ук Тинчуринның да дөньяга карашын үстерүдә Хөсәен Ямашевның роле зур була.

Бераз белемгә дә ия булгач, тормышка карашында төплерәк бер фикер дә урнашкач, үзендә башкалар белән уртаклашырлык якты хисләр, уйлар да барлыгын сизенгәч, ул театрга килеп керә. Театр! Менә кайда икән ич аның бәхете!.. Моң, җыр булып, уен, көлке булып һаман үзе белән бергә йөри биргән. Тик ул аны яхшылап белмәгән генә.

— Күңелеңдә яхшылык мул булса, уйларың, хисләрең изге булса, бар театрга, үзеңне дә, эзләгән бәхетеңне дә бәлки шунда табарсың, дигән аңа эчендәге изге тавыш, һәм ул 1910 елны «Сәйяр» труппасына кушыла. Театрның җитәкчесе Г. Кариев аның беренче остазы да, якын дусты да булып китә. Г. Тукай, Г. Камал, Ф. Әмирхан аның фикердәшләренә әверелә. Бик күп тә үтми, Тинчурин талантлы артист та, драматург та булып танылa. Татар яшьләре тормышыннан алынып язылган «Беренче чәчәкләр» драмасы тамашачыны тетрәндерә. Елата, көлдерә, уйландыра, бәхет өчен көрәшкә чакыра. Театрның нинди зур көчкә ия булган сәнгать икәнен Тинчурин бөтен тирәнлеге белән аңлый.

Татар театрын барлыкка китерү, киң иҗтимагый тормыш мәйданына чыгаруда бик күп дәртле йөрәкләр кыю, фидакарь хезмәт күрсәттеләр. Г. Кариев, С. Гыйззәтуллина-Волжская, И. Кудашев-Ашказарский, З. Солтанов, К. Шамил, Ш. Шамильский, Н. Сакаев, Г. Болгарская, Ф. Ильская, Н. Таҗдарова һәм башкаларның исемнәрен без хөрмәт белән телгә алабыз. Кәрим Тинчурин алар арасында да үзенең күпкырлы таланты белән аерылып тора. Ул артист та, режиссер да, драматург та, педагог та һәм яхшы оештыручы да. Тинчуринның әнә шул сыйфатлары революциянең беренче елларыннан ук аңа иң җаваплы бурыч йөкләргә, аны татар совет театрының җитәкчесе итеп билгеләргә мөмкинлек бирде. Менә аның үз кулы белән язылган тәрҗемәи хәленнән бер өзек: «1918 елны Казанда беренче мәртәбә Татар дәүләт труппасы төзелә. Мин аның җитәкчесе һәм режиссеры итеп билгеләнәм. Бер үк вакытта партия губерна комитеты каршында чыгарыла торган «Эш» газетасы өчен баш мәкаләләр һәм фельетоннар язам. Гражданнар сугышы көчәйгәч, бу труппа Үзәк Мөселман хәрби коллегиясенең политик идарәсе каршында эшли башлый. 13 нче номерлы труппа дип йөртелә торган труппаның мин җаваплы җитәкчесе,

режиссеры һәм артисты идем. Егерменче елны Самарада, Заволжский хәрби округының политик бүлеге каршында Татар драма студиясе төзелгәч, анда укытучы һәм баш режиссер булдым. 1921 елны Пролетар труппаның художество эшләре җитәкчесе итеп билгеләндем. 1922 елны Казанда, махсус бинада, Татар дәүләт театры (хәзерге Татар дәүләт академия театры) төзелгәч, мин аның директоры һәм художество эшләре җитәкчесе, режиссеры, артисты һәм шул ук вакытта драматургы да итеп чакырылдым. Хәзерге көндә дә Татар дәүләт академия театрының режиссеры һәм драматургы булып эшләвемне дәвам иттерәм».

Үзенең 1935 елда язган (датасы күрсәтелмәгән — Р. И.) шушы автобиографиясен ул түбәндәге юллар белән тәмамлый:

«Орденлы Татарстанның 15 еллыгы минем иҗат тормышымда тарихи бер момент булып тора. Бу 15 ел эчендә мин 16 пьеса яздым. Иң яхшы пьесаларым шушы чорда язылдылар. Татарстанның 15 еллык юбилее белән Татар дәүләт академия театры сәхнәсендә яңа пьесам куелуы[1] минем иҗат тормышымда шатлыклы һәм бәхетле бер вакыйга. Кыскача тәрҗемәи хәлемне язып, әйтергә теләгәнем шул: мин үземнең иҗатымдагы уңышларым, шатлыкларым өчен Бөек Октябрь революциясенә һәм аның җиңелмәс штабы — Коммунистлар партиясенә бурычлымын».

Кәрим абый белән бергә эшләү, ул иҗат иткән спектакльләрне күрү, аның иҗат процессында катнашу үзе зур бер мәктәп иде. Миңа аның ике әсәрен — «Беренче чәчәкләр» драмасын һәм «Алар өчәү иде» комедиясен сәхнәгә куярга туры килде. «Беренче чәчәкләр» — 1913 елда язылып, заманында зур уңыш белән барган, Г. Кариев, З. Солтанов кебек атаклы осталар тарафыннан сәхнәгә куелган әсәр. Аны бүгенге көнгә җавап бирә алырлык итеп сәхнәләштерү җиңел түгел иде. Минем карашымча, пьесага байтак үзгәреш кертү таләп ителә иде. Дөресен әйтергә кирәк, күренекле остага, мондый фикер белән мөрәҗәгать итәргә бераз уңайсызланып йөрдем. Автор минем белән килешмәсә, бик уңайсыз хәлдә калырмын кебек тоелды. Шулай да сөйләштек. Иң күңеллесе шунда булды, Кәрим абый үзе үк:

— Мин әле әсәрне үзем дә бераз карап, төзәтеп чыгарга кирәктер дип уйлап тора идем,— диде. Минем планны, фикерләремне тыңлагач, күбесе белән килеште. Әсәрнең беренче вариантында алдынгы революцион фикерләр сукыр Суфи авызыннан әйттерелә иде.

Кәрим абый, бу бит тормыш дөреслегеннән ерак тора, дигәч, ул, чын күңелдән елмаеп, мин һич көтмәгәнчә, кызык кына җавап бирде:

«Дөрес, иптәш режиссер, ләкин бит ул фикерләрне мин башка образларга әйтик, шул ук Хәмиткә бирсәм, патша цензоры пьесаны бөтенләй сәхнәгә куйдырмас иде, ә болай, сукыр Суфи әйткәч, үтә,— диде ул.— Сукырга суд юк. Элек-электән шулай...» Мин рәхәтләнеп көлеп җибәрдем. Тагын бер фикер әйттем авторга. Әсәрдә барлык персонажлар да хәят җебен югалткан кешеләр, пессимистлар,— дидем.— Ә бит ул чорда Хөсәен Ямашев кебек революцион рухлы яшьләр дә булган һәм алар шәкертләр арасында да эш алып барганнар, аларны көрәшкә өндәгәннәр, сез үзегез дә...»

«Беләм,— дип җавап бирде Кәрим абый,— пьесама кертсәм, пьеса шулай ук сәхнәгә менмәс иде. Мин әнә шул булган кадәресе белән, бунтарь Кыям, үткен телле, философик табигатьле Суфи образы белән канәгатьләндем. Хәзер инде эш башка. Әсәрне тормыш дөреслегенә туры китереп төзәтеп чыгарга була...»

Атна-ун көннән соң «Беренче чәчәкләр»нең яңа варианты әзер иде инде.

Театр коллективы, аеруча баш рольләрдә уйнаган артистлардан Зәйни Солтанов, Касыйм Шамил, Камал III, Хөсәен Уразиков яңа вариантны хуплап кабул иттеләр. Әсәр зур әзерлек белән сәхнәгә куелды. Спектакль тамашачы тарафыннан, матбугат тарафыннан да җылы каршыланды. Автор үзе дә канәгать иде. «Красная Татария» газетасы хәбәрчесенә болай дигән ул: «Бу сезонда уңышлы спектакльләрнең берсе «Беренче чәчәкләр» булды. Режиссер Ишморатов пьесаны яңадан эшләп чыкты. Аның постановкасы хыялга бай һәм үзенчәлекле иде». («Красная Татария», 1935 ел, 4 апрель саны.) Бу уңай белән бер генә искәрмә ясап китәсем килә. Кәрим абый Тинчурин әсәрнең яңа редакциясендәге үзгәрешләрне ни өчендер минем

---

[1] Сүз шушы юлларны язучы режиссер Риза Ишморат тарафыннан куелган «Алар өчәү иде» пьесасы турында бара.

исемгә генә кайтарып калдыра. Чынында исә алар барысы да авторның үзе тарафыннан язылды.

«Алар өчәү иде» комедиясен сәхнәгә әзерләгән чагымда да Кәрим абый белән тулы контактта эшләдем. Аның сүзләрен, киңәшләрен зур дикъкать белән тыңладым. Ул да минем сүзләремне игътибарсыз калдырмады. Мәсәлән, спектакльдә катнашучы артистлар: Гөлшат белән Равил арасына кереп, аларның мәхәббәтенә комачаулаган өченче геройның кем икәнлеген яхшылап аңламыйбыз; без аңламагач, тамашачы да аңламас, диделәр. Мин Кәрим абыйга пьесада моны берникадәр ачыкларга кирәклеген әйткәч, ул бераз уйланып торды да: «Минемчә, бик аңлашыла кебек тә бит, ярый алайса, коллектив та, режиссер да үтенгәч, анырак язып китерермен»,— диде. Һәм икенче көнне үк өстәмә текст язып китерде. Өченче турында фикер ачыкланды. Татарстанның унбиш еллыгына багышлап әзерләнгән бу спектакльне без яхшы үк уңышлы итеп сәхнәгә чыгардык. Тамашачы да, матбугат та, автор үзе дә хуплап кабул итте.



Бу пьесаларны кую процессында Кәрим Тинчурин миңа үзенең яңа яклары белән ачылды. Театр сәнгатен тирән аңлавы, театрның, драматургиянең спецификасы турында әйткән гаҗәеп кызыклы фикерләре, шуның белән бергә гадилеге, шаянлыгы, башка гүзәл сыйфатлары күңелдә җуелмаслык эз калдырды.

Кәрим Тинчурин белән бер театрда хезмәт итү генә түгел, бу талант иясе белән бергә утырып, яңа әсәр өстендә эшләү бәхете дә насыйп булды миңа.

1932 ел. Җәй. Башымда зур план әйләнә: беренче бишьеллыкның данлы төзелеше саналган Сталинград заводы, аны төзегән һәм хәзер анда эшләүче эшчеләр, инженерлар тормышыннан бер драма әсәре язу уе белән яшим. Сталинградка барып, завод цехларында, эшчеләр урнашкан тулай торакларда айга якын йөреп, чит ил белгечләре белән дә очрашып, материал җыеп кайттым. Эшкә дә утырдым. Материал бай, кызыклы. Ләкин вакыт бик аз. Бөек Октябрь бәйрәменә нибары өч-дүрт ай калган. Сәхнәгә кую, репетицияләр ясау өчен дә күпме вакыт кирәк. Ярый ла, әсәр уңышлы булып чыкса, әгәр барып чыкмаса? Үзем бит әле бәйрәмне шундый-шундый спектакль белән каршыларга ниятебез бар дип җитәкче оешмаларга да әйтеп куйдым. Биргән вәгъдәмне җитәкче иптәшләр дә бик хуплады. Әсәрне өлгертә алмыйча хур булып калуың да бар. Шулай, ниятем изге, зур, ә тәҗрибә аз. Кәч кечкенә. Булган җегәрне җигеп, пьесаның планын төзедем. Яза да башладым. Башладым башлавын, эш акрын бара. Ә бәйрәм, Октябрь, һаман якынлаша. Менә бер көнне театрның директоры шылтырата.

— Хәлләр ничек? Пьеса ничек языла?

— Әкрен языла,— дим.

— Эш бик җаваплы, җитәкче органнарга сүз бирдек, ә вакыт аз, бәлки сиңа ярдәмгә берәр кеше алырга кирәктер?— ди.

— Юк, кирәкми,— дип, тәкъдимен шунда ук кире кагам.

— Син алай кырт кына кисмә әле, Ишморат туган. Бәйрәм җитеп килә. Тема җаваплы. Әгәр икәүләшеп язсагыз, җиңелрәк тә, тизрәк тә, бәлки яхшырак та булыр.

— Кем белән инде ул икәүләшеп?

— Кәрим Тинчурин белән, мәсәлән.

— Тинчурин?..— Мин уйга калдым. Тинчурин драматургиядә дан тоткан оста. Дистәгә якын әсәре сәхнәдә шаулап бара, үзе режиссер да, артист та. Юк, алай гына түгел, мөлаем табигатьле, олы җанлы, шат күңелле өлкән иптәш... Иптәшен иптәш тә, андый шәхес белән каләмдәш, иҗатташ булу ансат эш түгел ул. Шундый уйлар эчендә, икеләнеп кенә ризалыгымны бирдем.

Шул ук көнне театр директоры Тинчурин белән дә сөйләшкән, ул да ризалык биргән. Кәрим абыйның үзе белән очрашып сөйләшү, килешүләрдән соң, бергәләп эшкә тотындык. Вакытның тарлыгын исә алып, пьесаны бер ай эчендә язып бетерергә дигән карарга килдек. Башка барлык эшләребезне ташлап, бөтен көчне бары тик шушы эшкә генә бирүне шарт итеп куйдык. Эш өчен безгә бик уңай шартлар, иҗат атмосферасы, аеруча тын һәм тыныч урын кирәк иде. Аны да җайладык. Кәрим абый Тинчуринның өч бүлмәле фатиры иде бу. Хөрмәтле Зәһидә ханым Тинчуринаны бер айлык «командировкага» озаттык. Әбугалисина белән Әбелхарис бер елга мөгарәдә бикләнеп калган шикелләрәк, без дә үзебезне нәкъ бер айга шушы өйгә



*Рәсемдә: тәнкыйтьче Галимҗан Нигъмәти һәм Кәрим Тинчурин.*

бикләдек. Үзебез дә беркая чыкмыйбыз, өйгә чит кешеләрне дә кертмибез. Тик атнага бер мәртәбә «командировкадан» кайтып, безне азык-төлек белән тәэмин итеп китә торган Заһидә ханымга гына ишегебез ачыла.

Ә иҗатыбыз хәлләре? Әдәбият мәйданында ике кеше бер әсәр язу практикасы юк түгел. Алар ничек яза торгандыр, белмим. Безнең менә ничегрәк булды: иң элек мин күп сәгатьләр буе, бик җентекләп, үземнең Сталинград трактор заводында күргән-белгәннәремне, андагы эшче, инженерларның нинди зур кыенлыклар, каршылыкларны җиңеп эшләүләрен сөйләп чыктым. Газеталарда чыккан материаллар да аз түгел иде. Алар белән дә таныштык. Мин Кәрим абыйны үземнең планым белән дә таныштырдым. Үзем үк, ул планны бөтенләй диярлек игътибарга алмыйча, өр-яңа план төзик дигән тәкъдим керттем. Үзем яхшылап күз алдына китергән, күргән-тойган кайбер персонажларны гына калдырып, пьесага кертелергә тиеш булган персонажларны да яңабаштан билгеләп чыгыйк, дидем. Мин әйткәннәрдән яшь наладчик Азат калды да, аның сөйгән кызы калды. Карчыга исеме белән йөртелә торган эшче, элекке беспризорник калды да, американы инженер мистер Куперзуд калды. Икенче көнне без көнозын пьесаның планын төзү өстендә утырдык. Әсәрдә әйтелергә тиеш булган төп фикерне, төп вакыйганы билгеләү белән берраттән, шул вакыйганы тудыручы персонажларны, аларның характерларын, заводта нинди хезмәт башкаруларын һәм эш процессында туган үзара конфликтларны ачыклап, кәгазьгә сызып куйдык. Барлыгы дүрт пәрдә, сигез картина. Һәркайсыбыз аерым-аерым картина яза. Картина тәмамлангач, аны бергәләп укып тикшерәбез, төзәтмәләр кертәбез. Икебез ике бүлмәдә, ике өстәлдә эшлибез, бер-беребезне күрмибез, сөйләшмибез. Алдан әзерләп куйган планыбыз бар, әлбәттә. Ләкин ул әле эскиз гына. Иҗат ул алдан билгеләнгән планга гына сыймый, билгеле. Аның үз законы. Үз акыллары, үз табигатьләре белән яши торган җанлы кешеләрнең вакыйга барышында әллә нинди хәлләр тудырып куюлары мөмкин. Безнең геройлар да шулай. План ул план белән, ә алар үзләренчә хәрәкәт итә бирәләр.

Дөньяны онытып язып утырганда, Кәрим абый бүлмәсендә кемнәрдер кычкырып сөйләшә, кычкырып көлә кебек булды. Әйе, көлешәләр. Нәрсә бу? Өйгә берәү дә кермәде бит. Әкрен генә килеп, Кәрим абый утырган бүлмәнең ишеген ачам. Карыйм — ул ялгызы. Бүлмәгә керәм. Кәрим абый, гадәтенчә, күзлеген маңгае өстенә күтәреп куйган да шырык-шырык көлеп утыра.

— Вот, шельма! Сөйләш син аның белән,— ди.

— Нәрсә булды? Кемне тиргисең?— дип сорыйм.

— Кемне булсын, әнә шул беспризорник малайны — Карчыганы,— ди.— Һич уйламаганда, теге хөрмәтле инженер, син мактаган мистер Купервудның портсигарын чәлдергән. Шунда ук инде, күз алдында, баш инженер кабинетында. Без аны төзәлеп бара торган, акылга утыра башлаган малай итеп план сызган идек.

— Әйе...

— Ә ул әнә нишли! Тәмәке тартырга теләп, мистер Купервуд кесәсенә тыгылса, портсигары юк. Аптырап китә, бу бер кесәсен капшый, икенчесен... Карчыга моңа карап тора да: «Сез тартырга телисез, ахры, теләсәгез миндә сигарет бар, рәхим итегез»,— ди. Портсигарны ачып, аңа сигарет тәкъдим итә. «Бу минем сигара, портсигары да минеке, каян килеп керде ул сезнең кесәгә?»— ди мистер. «Белмим, үзем дә шуңа аптырап торам әле»,— ди Карчыга. «Юк, сез Карчыга гына түгел, сез күз буучы, сихерче дә икән әле...» «Элек мин, бу заводка килгәнче, урам малае идем. Гади кесә карагы». «Гади... Минем кесәдән портсигарны шулай оста шудыра ала торган булгач, гади генә түгел, син инде беренче классны артист-виртуоз, шулер...»— ди. Шуннан, көлә-көлә ул: «Әгәр син безнең Америкага барсаң...» — дип, Карчыганы котырта башлагач, мин килеп кысылдым. Стоп! Мин әйтәм, артык язмыйм... И куйдым каләмне.

— Кәрим абый,— мин әйтәм,— бу бит безнең алдан төзеп куйган планыбызда юк иде.

— Юк иде шул, ләкин гаеп миндә түгел, Карчыгада һәм мистер Купервудта. Әнә кая алып китмәкче була бит безнең рәтле генә эшче булып килә торган Карчыганы.

— Юк, җибәрмә! Карчыганың монда төзәлеп, чын кеше булып әверелүе кыйммәт.

— Җибәрәмме соң! Шуңа ташладым да каләмне. Уйлашыйк, дидем.

— Ярый, Кәрим абый. Карчыга көтмәгәндә шундый фокус эшләгән икән инде, тимә,— дим,— шул килеш калсын. Тамашачыга бу эпизодны карау да кызыклы булачак. Ә мистер Купервудка йөгәнне бирмә. Үзең нык тот.

Сүз уңаеннан әйтим — кызыклы булды бу эпизод. Театрның сугышта батырларча һәлак булган талантлы артисты Габдулла Сәгыйтов Карчыга ролендә тамашачыларның кайнар мәхәббәтен яулады.

Озын сүзнең кыскасы, төгәл бер ай дигәндә без пьесаны тәмамладык. Исемен беренче көннәрдән үк уйлый башлаган идек. Дистәләрчә исем җыйналды, ләкин берсе дә безне канәгатьләндерерлек түгел. Бер ягы яраса, икенче ягы килеп бетми. Ниһаять, пьесаның караламасы нигездә тәмамланып, акка күчереп чыгасы калгач, Кәрим абый каршыма килеп басты да:

— Хәзер инде тукта, Риза туганкай! Пьесага исем тапмый торып, бер бит түгел, бер генә юл да күчермибез. Ике сәгать, өч сәгать утырабызмы, ике көн, я өч көн утырабызмы, исем табарга тиешбез. Шул исем белән әсәрнең бөтен эчтәлеген күздән кичереп чыгарга, шул исемне әсәргә органик рәвештә бәйләргә тиешбез,— ди.

Исем! Пьесага тәңгәл килгән исем табу иң җаваплы, иң авыр эш ул. Бер француз драматургы әйткән: пьесама төгәл исем, яхшы исем табып биргән кешегә ярты гонорарымны бирергә әзермен, дигән. Пьеса исеме кыска, җыйнак булсын, әсәрнең эчтәлеген дә ачып бирсен, матур, поэтик яңгырашлы, мәгънәле, кызыклы да булсын. Афишага язгач, бераз серлерәк булып, тамашачыны кызыктырып, театрга чакырып та торсын. «Отелло», «Гамлет», «Мәкер вә мәхәббәт», «Зәңгәр шәл», «Җилкәнсезләр», «Ташкыннар»... күп андый исемнәр. Безнең беренче бишьеллыкның беренче гигант төзелеше — Сталинград трактор заводын, аның беренче авыр көннәрен һәм фидакарь хезмәт каһарманнарын чагылдырган драма әсәренә нинди исем кушарга? Килешле исем табу турында уйлап, күп сәгатьләр баш ваттык без. Мин Кәрим абыйга ышанам, ул миңа ышана кебек. Уйланабыз. Утырып та, йөреп тә, ятып та уйланабыз. Мин бер исем әйтсәм, Кәрим абый «юк, ярамый», дип кире кага, ул икенче исем әйтсә, «юк, ярамый», дип мин кире кагам. Кайбер килешлерәк күренгәннәрен ургага салып, төрле яклап тикшереп карыйбыз. Юк, булмый. Менә бәла! Пьесаны язып чыктык, ә бер генә, ике генә сүздән торган исемне таба алмыйбыз. Бермәл

Кәрим абый: «Таптым!» — дип кычкырып җибәрде дә утырган урыныннан сикереп үк торды. Миңа карап елмайды, каршыма килеп басты да:

— Әйтимме?— ди.

— Әйт, әйт, Кәрим абый,— дим түземсезләнеп.

— Юк, әйтмим, я тагын кире кагарсың,— ди ул.

— Яхшы булса, кая инде ул, мин әйтәм, кире кагу...

— Бик яхшы! Шулай да кире кагарсың... аңлап бетмичә.

— Аңлармын, Кәрим абый, әйт кенә.

Кәрим абый арлы-бирле кызу-кызу йөри башлады. Үзе йөри, үзе «Аһ, шәп исем!» дип, үзенә-үзе әйтеп куя.

— Әйт инде, Кәрим абый, азаплама!

— Утыр әле! — диде бу әмер биреп. Утырдым.

— Яхшылап тыңла!

— Бик яхшылап тыңлыйм.

— Безнең пьесаның исеме: «Тургай!» «Тургай...»

— «Тургай?!..» — Мин кычкырып көлеп җибәрдем.

— Әйттем бит, аңламассың,— дидем.

— Тукта әле, Кәрим абый... «Тургай», әлбәттә, бик матур исем. Сайрап тора. Ләкин ул матур кошның безнең пьеса эчтәлегенә ни катнашы бар?

— Нинди катнашымы? Аңлатыйм, алайса. Безнең пьесада сурәтләнгән завод халыкка, колхозларга нәрсә бүләк итә? Тракторлармы? Тракторлар. Алар кая бара? Кырларга. Кайчан? Яз көне, сабан тургайлары сайраган чакта, сабан сөрергә бара. Тургайга якынайдыкмы хәзер? Якынайдык. Икенчедән, яз килүе, коммунизм язы килүе турында хәбәр биреп, гөрли-гөрли барамы ул тракторлар? Әйе, гөрләп бара. Ул гөрелтене, безгә бәхет, шатлык, муллык китерә торган гөрелтене образлы поэтик телгә күчерсәк — «Тургай», «Тургай җыры» булмыймыни? Була. Әйе, әйе, безгә ул яз көннәрендә сайраган иң гүзәл тургай моңы булып ишетелә.

— Дөрес! Менә монысына кул куям! — дидем мин нык өсәрләнеп.

— Әһә! Шулаймы?.. Аннан соң әсәрнең нәкъ әнә шундый эчтәлеген ачкан җыр язабыз! Сәйдәштән «Тургай җыры» дигән музыка яздырабыз. Әсәрнең иң күтәренке урынында аны хор белән җырлатабыз. Шуннан соң инде «Тургай» сүзен безнең пьесадан аерып та ала алмыйсың. Шушыннан да дөресрәк, төгәлрәк, поэтик яңгырашлы исем булуы мөмкин дә түгел!

Кәрим абыйның сүзләре мине тулысынча ышандырды. Тиздән «Тургай җыры» дигән җыр да язылды. Менә ул:

**Тургайлар җырын тыңлыйсы килгән**
**Далага чыксын, күрсен киң җирне.**
**Яз хәбәрчебез кырларга килгән,**
**Матур җырлый ул безнең җиңүне.**
**Безнең тургайлар**
**көчләләр алар,**
**Матур сайрыйлар.**
**Җир актаралар.**

**Безнең тургайлар корычтан алар...**
**Матур сайрыйлар.**
**Ныгыта алар безнең нигезне!**
**Сайра, тургай, сайра!**
**Сайра үткән зарны.**
**Макта, тургай, макта!**
**Макта безнең язны!**

*Пьеса Бөек Октябрьның унбиш еллыгында Татар дәүләт академия театрында сәхнәгә куелды. Режиссеры да үзем булдым. Салих Сәйдәшев музыка язды. Әлбәттә, Кәрим абый бу вакытта да якын киңәшчем булды. Спектакль яхшы ук уңыш белән барды, җәмәгатьчелек һәм матбугат тарафыннан да уңай бәя алды. Шулай да ул театр репертуарында күренекле урын алган озын гомерле әсәр була алмады. Бердән, бик ашыгыч язылды, кыска вакыт эчендә сәхнәгә кую да тиешле художество югарылыгына ирешергә мөмкинлек бирмәде. Аннары башка сәбәпләр өстәлде. Ләкин ни генә булмасын, Кәрим абый Тинчурин белән бергә эшләгән бер ай һәм пьесаны сәхнәләштергән көннәр минем тормышымда онытылмаслык бер чор булып калды. Талантлы драматургның, гүзәл табигатьле кешенең кешелек сыйфатлары, аның зур эрудициясе бу көннәрдә минем алдымда тагын да тулырак ачылды.* Ул көннәрне мин һәр вакыт сагынып искә алам. Пьеса язарга туры килдеме (аеруча пьесага исем эзләгәндә), Кәрим абый искә төшә һәм үзенең акыллы, тапкыр киңәшләре белән миңа ярдәмгә килә кебек.

# БОРЫНГЫ ДА, БҮГЕНГЕ ДӘ

Үткән заманның сәнгать мирасына, традицияләргә мөнәсәбәт мәсьәләсе — бүгенге заман сәнгатендәге җитди проблемаларның берсе. Борынгы сәнгатьне өйрәнүнең төрле яклап әһәмияте бар: беренчедән, ул эстетик кыйммәткә ия, икенчедән, тарихыбызны өйрәнү үткән буыннарның тормыш-көнкүрешен, эчке дөньясын танып-белү чарасы булып хезмәт итә. Халыкларның культура тарихына, этносына кагылышлы кайбер мөһим проблемаларны тикшергәндә галимнәр еш кына борынгы сәнгать әсәрләренә мөрәҗәгать итәләр.

Борынгылар калдырган культура һәм сәнгать хәзинәләре билгеле бер күләмдә һәр чорда диярлек өйрәнелгән. Әмма XIX йөзнең ахыры, XX йөз башларыннан галимнәр һәм художниклар арасында башка халыкларның һәм үз халкының борынгы цивилизацияләре белән кызыксыну аеруча көчәеп китә. Культура тарихын җентекләп тикшерү һәм өйрәнү тора-бара элегрәк чорларның сәнгать казанышларын файдалану, аларның стилен, сурәтләү чараларын кулланып иҗат итүгә омтылыш уята. Мондый тәҗрибәләрне без, мәсәлән, француз художниклары Поль Гоген, борынгыларга ияреп, примитив стильдә ясалган картиналары белән дан казанган Руссо әсәрләрендә очратабыз. Иҗатының халыкчанлыгы белән танылган грузин художнигы Пиросмани әсәрләре дә бу яктан бик кызыклы. Россияне алсак та, шул ук хәлне күрәбез. Ярты-лаш онытылган борынгы рус сәнгатен халыкка кайтарырга, иҗат эшендә файдаланырга омтылыш сизелерлек нәтиҗәләр бирә. Борынгы мәдәниятләр белән кызыксыну хәзерге чорда тагын да үсә төште. Ләкин Көнбатыш Европа илләрендә бу күренеш «сәнгатьтә прогресс — аның элгәргегә кайтуы, башлангыч дәверләрнең сәнгать структурасына йөз тотуы белән билгеләнә, ә сәнгатьнең максаты — табигатькә, ашаешка кайту»[1] дигән тезис белән аңлатылса, совет сәнгатендә прогресс, табигый ки, борынгы заманнарга таба чигенүдә түгел, ә алга таба хәрәкәт итүдә күренә. Эш шунда ки, элгәрге традицияләргә мөрәҗәгать итү, борынгы сурәтләү чараларын тергезү барытик аларны яңа эчтәлек белән баетканда, шул яңа эчтәлекне тирәнрәк итеп ачу өчен яңа формалар эзләнү процессында гына нәтиҗәле була, элеккеге заманнардан бүгенге көн сәнгатенә күпер хезмәтен үти ала.

Татар культурасы тарихына килсәк, мәгълүм ки, ул тамырлары белән Идел буе төркиләре, болгар бабаларыбыз сәнгатенә, безнең заманга кайбер архитектура үрнәкләрендә һәм декоратив-көнкүреш сәнгате әйберләрендә генә сакланып калган матди культурасына барып тоташа.

Урта гасырларда декоратив-көнкүреш сәнгате күбесенчә шартлы характерда булган, билге-символга таянган[2]. Болгар сәнгатенә дә нәкъ шундый сыйфат хас. Сурәт һәм формасы белән ул реалистик, ә гәүдәләндерү ысулы ягыннан шартлы, символик характерда булган. Мәсәлән, кыңгыраулы алка уртасына беркетелгән үрдәк җирнең барлыкка килүе хакындагы легенда символы булып хезмәт итә.

---

[1] К. Долгов. М. Дюфрен эстетикасы. «Теории, школы, концепции» (Критик анализлар) дигән китапта. Мәскәү, 1975 ел, 59 бит.
[2] А. С. Гуревич. Урта гасырлар культурасы категорияләре. Рус телендә. Мәскәү, 1972 ел.

Сәнгатьнең символик формасы борынгы сыйныфсыз җәмгыятьтә барлыкка килә һәм урта гасырларның беренче яртысында үсешен дәвам иттерә. Монгол баскынлыгына кадәрге Болгар дәүләте нәкъ әнә шундый чор кичерә. Символик, шартлы форма аша борынгы художник тормыш күренешләреннән, табигатьнең асылына төшенергә, яшәешнең эчке серләренә үтеп керергә омтылган. Мәҗүсилек чоры сәнгатендә елан яисә ябалак сурәтендәге зирәклек образы, мәсәлән, әнә шуңа мисал була ала. Болгар сәнгатенең дә тотрыклы үз теле, кануннары бар. Табигатьтәге һәр нәрсәнең җаны бар дип карау легендалар һәм мифлар белән бергә, көнкүреш сәнгате өлкәсендә гаҗәеп орнаментлар, бизәк һәм формалар туура да китергән. Борынгы болгар орнаментлары бер очракта теге яки бу кешенең нинди кабиләдән булуын, җәмгыятьтә тоткан урынын белдергән, икенче бер очракта алар табигать күренешләре, үсемлек һәм җәнлекләрнең шартлы билгеләре булып хезмәт иткәннәр. Болгар дәүләтендә рәсми төстә ислам дине кабул ителгәннән соң да, көнкүрештә һәм сәнгатьтә бик озак вакытлар мәҗүсилек карашлары яшәвендә дәвам иткән. Күп кенә сәнгать әйберләре символикага корылып, мәҗүсилек мифологиясе нигезендә эшләнгән. Металл, сөяк һәм кызыл балчыктан ясалган көнкүреш әйберләрендә борынгы кыргый пот-аллаларның образлары — бик нык стильләштерелгән ерткыч җәнлекләр, йорт хайваннары һәм кошлар, төрле фантастик карачкылар сурәтләнә. Орнамент һәм символ XII—XIII йөз болгар сәнгатенең төп үзенчәлекләреннән берсе булып китә.

Гасырлар һәм мең еллар аша үсеп килүче дөнья культурасының бер өлеше булган борынгы болгар сәнгате, шушы ук дәвергә караган рус көнкүреш сәнгате кебек үк, Көнчыгыш Европа территориясендә мәҗүсилек сәнгате үсешен тәгаллли.

Болгарларның сәнгать әйберләрендә һәр орнамент, һәр сызык һәм линия билгеле бер мәгънә алып килә, дидек. Метафоризм, символика куллану «берьюлы берничә төрле фикерне чагылдырырга» [1] мөмкинлек биргән.

Бүгенге заман художниклары алдында да шуңа якын бурычлар тора. Әмма ул бурыч яңа эчтәлекне чагылдыру ихтыяҗы белән билгеләнә. Художниклар да, теоретиклар да үткән чорның сәнгать алымнары, сурәтләү чаралары белән һаман якыннанрак кызыксыналар. Совет сынлы сәнгате олы символик мәгънәдәге образларга башлангыч чорыннан ук мөрәҗәгать итте. В. Мухинаның эшче һәм крестьян дуслыгы символы булган «Эшче һәм колхозчы» скульптурасын, И. Шадрның «Революция» дип аталган һәм эшче, крестьян, солдат бердәмлеген чагылдырган скульптур композициясен яисә Казан художнигы В. Маликовның «Һәлак булганнар истәлегенә» исемле монументаль скульптурасын күз алдына китерик. Нәкыш әсәрләре арасында К. Петров-Водкинның «Комиссарның үлеме», «Мадонна. 1918 ел» һ. б. әсәрләрне мисалга китерергә булыр иде. Бу символлар, әлбәттә, элеккеләрдән күп үзгә, алар безнең заман, безнең җәмгыять кешесенә аңлаешлы һәм якын эчтәлекне алып киләләр. Сәнгатьнең бу формасына мөрәҗәгать итү үткән заманнарның культура мирасы белән кызыксынуның очраклы күренеш булмавын раслый.

XX йөз француз язучысы һәм сәнгать белгече А. Мальро «һәр гасыр үткән заманнан алган мирасын үз «сөзгече аша» үткәрә, яңа заман сәнгате өчен әһәмиятле булган нәрсәләрне сайлап ала, үткән чорларның күп төрле сәнгать хәзинәләре арасыннан заманының сәнгать практикасы белән авазадаш булган кыйммәтләрне эзләп таба» [2], ди. Безнең чор сәнгатендә дә бу процесс өзлексез дәвам итә. Бөтен совет сәнгате казанышларын үзенә сеңдерә барып, үзенчәлекле йөз-рәвешен, милли формасын баета килүче Татарстан сынлы сәнгате өчен бу шулай ук аеруча әһәмиятле мәсьәлә.

Борынгы болгар һәм татар сынлы сәнгате, скульптурасы тәҗрибәсе тотрыклы хәлендә сакланып калмаган. Әмма бу әле алар тарихтан эзсез югалганнар дигән сүз түгел. Рус һәм Европа сәнгате традицияләренә нык таянып үскән татар совет сынлы сәнгате борынгы мираска һаман ешрак мөрәҗәгать итә. Идел буе болгарлары һәм татарларының көнкүреш сәнгате мотивлары, сюжет һәм орнаментлары моңа шактый

---

[1] В. В. Иванов. XX йөз сәнгате һәм культурасында вакыт категориясе. **«Ритм, пространство** и время в литературе и искусстве» исемле китапта. Ленинград, 1974 ел, 54 бит.

[2] С. Моравский. А. Мальроның эстетик концепциясе хакында. «Теории, **школы, концепции»** дигән китапта. Мәскәү, 1975 ел, 137—138 битләр.

зур мөмкинлекләр ача. Борынгы традицияләр сынлы сәнгатьнең кайсы төрләрендә актив файдаланыла һәм бу процессны без бүген ничегрәк күз алдына китерәбез соң?

Традицияләрнең бүгенге сәнгатьтә чагылышы хакында сөйләгәндә, әлбәттә, аларны элекке эчтәлеккә нисбәт итү файдасыз. Сәнгать һәр дәвердә үз чорының рухын чагылдыра.



*Халык батырлары. Е. Киселева эше. В. Зотов фотолары.*

Бүгенге чор татар совет сәнгатен болгар сәнгатеннән гасырлар аерып тора. Сынлы сәнгатебезнең төрләре күп бүген. Нәкыш, скульптура, графика, декоратив-көнкүреш сәнгате өлкәләрендә художниклар һәр елны яңа әсәрләрен иҗат итәләр. Күп кенә биналарның интерьер һәм экстерьерлары монументаль композицияләр белән бизәлә. Хәзер шуларның кайберләренә күз салып үтик.

Казан тимер юл вокзалының шәһәр тирәсе пассажирлары өчен яңа бинасы фасадына ясалган декоратив-монументаль композициягә бик күпләрнең игътибар иткәне бардыр. Ул татар фольклоры мотивларының үзенчәлекле чагылышы рәвешендә эшләнгән дип әйтергә мөмкин (авторлары — С. Бубеннов һәм В. Федоров). Милли киемдәге яшь сылу кыз сынында бүгенге совет Татарстаны гәүдәләндерелә. Кызның җилдә җилфердәгән яулыгына тамбурлы чигү рәвешендә нефть вышкалары, университет һәм Кремль рәсемнәре төшерелгән. Чигүнең бу төре Казан татарларында шулай ук борынгыдан килә. Композициядә без татар орнаменты элементларын да күрәбез.

Казан Химиклар сараеның паркка каршы стенасын бизәгәндә дә художниклар (С. Бубеннов, В. Федоров) шундый ук символик форманы кулланганнар. Смальта мозаикасы техникасыннан файдаланып эшләнгән бу композициядә юан һәм нык агач кәүсәсеннән үсеп чыккан ир кеше сыны гәүдәләндерелә. Ул кулларын чәчәк-кыз иңенә куйган, шушы нәни һәм иркә җан иясен җил-яңгырдан саклый. Яз темасын, тормышның яшәрүе темасын художниклар әнә шулай күрәләр. Аллегорик композиция контрастлыкка корылган, фикер ачык һәм калку бирелә. Шул ук сарайның икенче этажы фойесында чүкеп эшләнгән тагын бер әсәрне очратабыз (художнигы Е. Киселева). Автор халык батырларының явыз көчләргә каршы көрәшен сурәтли, монда ике дәвер — борынгы һәм хәзерге заман очраша. Борынгы батыр яктылык һәм тормыш чыганагы — кояшны кара болыттан саклый, аның янәшәсендә ук реаль тормыштан алынган кызылармеец сурәтләнә, ул да символик төстә яктылыкның караңгылыкны җиңүен раслый.



*Татар ашлары йортының банкет залы стенасы бизәлеше. Фрагмент.*

Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет театры сәхнәсе гипска кисеп ясалган рельефлы орнамент белән уратып алынган (авто-



*Болгарларда кунак каршылау. С. Бубеннов эше. Фрагмент.*

ры — архитектор И. Гайнетдинов). Төгәл симметрияле алтын бизәкләр матур тәэсир калдыра. Геометрик һәм үсемлек орнаментлары бер-берсенә нечкә үрелеп бара. Бу яктан ул Алтын Урда чорларындагы Болгар һәм Урта Азия шәһәрләренең купшы орнаментларын хәтерләтә. «Акчарлак» ресторанны стенасына ясалган композиция (Е. Киселева эше) дә орнаментлар төгәллеге, нечкә симметриясе белән күңелне иркәләрлек. Казандагы «Татар ашлары йорты»ның банкет залы бизәлеше татар халык сәнгате мотивларына якынлыгы белән тагын да аерылыбрак тора (художниклар Н. Артамонов, С. Мостафин, А. Спориус эше). Төрле төсләргә буялган тиреләр кулланып эшләнгән аппликация техникасы ерак тарихыбыздан ук билгеле. Чәмчәле читекләр, бизәкле аяк киемнәре җитештерү Казан татарларында элек-электән киң таралган. «Татарстан» кунак йортын бизәгәндә художник Р. Кильдебеков та шушы ук милли алымны кулланып эш итә. Үсемлек һәм чәчәк орнаментлары анда төгәлләнгән бер композиция тәшкил итәләр.

Алда әйтеп үтелгән монументаль композицияләрдә заманыбызга хас эчтәлек, һәркемгә аңлашыла торган фикер бар. Кызганычка каршы, художникларыбыз иҗат иткән ул композицияләр образларының тирәнлеге, фикер калкулыгы ягыннан канәгатьләндереп җиткермиләр. Аларга эчке киеренкелек җитми, җиңелчә, өстән-өстән башкарылган кебек тәэсир кала. Фикер һәм мәгънә төгәллеге аз сизелә. Әмма аларның тамырлары белән борынгы сәнгать чишмәләренә юнәлгәнлеген тоясың.

Инде тарихи жанр өлкәсендәге тәҗрибәләргә тукталып үтик. «Татарстан» кунак йортының үзәк вестибюлендәге түр стенаны «Болгарда кунак каршылау» (С. Бубеннов эше) исемле мозаика бизи. Кунак каршылаучы мөлаем йөзле карт, борынгы киемнәр кигән яшь кызларның зифа буй-сыннары, борынгы шәһәр диварлары — һәммәсе дә профессиональ эшләнеше, якты төс-бизәкләре белән күңелне җәлеп итә. Шул ук вакытта, аерым детальләрдә тарихи төгәллек җитмәве дә үзен сиздерә.

Нәкыш әсәрләре арасында өлкән рәссамыбыз Бакый Урманченың шушы ук теманы сурәтләгән «Ибн Фадланның Болгарга килүе» исемле картинасын күрсәтеп үтү урынлы булыр. Монда Идел буе Болгарының тарихка кереп калган бер көне тергезелә. Болгар иленең барлык ак сөякләре һәм гади халык Багдад хәлифәсенең илчелеген каршыларга җыелган. Тантана атмосферасын, шау-шудан тынып калган халык төркемен, кояшлы якты көннең барлык төс-бизәкләрен рәссам ачык буяуларда зур дәрт һәм осталык белән тасвир итә. Борынгы сюжетка корылган бу картина бүген дә безне дулкынландырырлык; тирән эчтәлекле тарихи әсәрләрне халыкның тарихын, көнкүрешен, культура һәм сәнгатен яхшы белгән художниклар гына иҗат итә алуы хакында сөйли.

Болгар һәм элгәрге татар сәнгате хакында тирән һәм тәфсилле эшләнгән капиталь хезмәтләрнең булмавы да, Б. Урманче кебек тарихны, төрки телләрне яхшы белүче, югары культура һәм эрудицияле рәссам өчен эштә киртә була алмый, димәк.

Татарстан дәүләт музеенда кырлы пыяла белән инкрустацияләнгән зиннәт әйберләре — муенса, беләзек, колак алкасыннан торган комплект игътибарны җәлеп итә. Художник Р. Альменов аны борынгы болгар осталары техникасын кулланып, шулар стилендә металл чыбыклардан үреп ясаган. Нечкә чылбырлар белән тоташтырылган ромблар гади һәм шул ук вакытта зур зәвыкле композиция хасил итәләр. Бу көнкүреш сәнгате әсәре мисалында да без элгәрге традиция чагылышларын күрәбез. Шушы юнәлешне үстерүдә республикабыз художниклары киләчәктә тагын да кыюрак булырлар, сюжет-композицияләрдә үткәнне иллюстрация төсендә генә чагылдыру, кабатлау белән чикләнмичә, иҗади яктан тагын да катлаулырак бурычларны хәл итәрләр дип ышанырга нигез бар.

Художник, тарихка мөрәҗәгать иткәндә дә, аңа үз заманы күзлегеннән карый. Шуңа күрә элгәрге сәнгать үрнәкләренә беркатлы иярү генә аны канәгатьләндерә алмый да. Гармония һәм гүзәллекне эзләп, ул үткәннән бүгенге тормышка, бүгенгедән киләчәккә эз сала.

Иң мөһим мәсьәлә, әлбәттә, сәнгать әсәрләренә салынган идея, эчтәлек мәсьәләсе. Болгар сәнгате шул дәвер идеологиясеннән аерылгысыз: сихри көчләрне, табигать һәм тышкы дөньяны гәүдәләндерүче җәнлек образлары анык һәм тирән мәгънә белдерә. Бүгенге заман сәнгате социалистик идеологиягә таяна, идея эчтәлеге белән ул безнең бөек идеалларыбызга хезмәт итә. Борынгы сәнгать үрнәкләренә дә без шушы ноктадан чыгып якын килә без. Әлбәттә, үткәнне кабатлау, элгәрге сәнгатьнең төс-бизәкләрен, орнамент һәм образларны күчерү, копия алу теләсә нинди чорда да була торган хәл. Ул элекке мирасны өйрәнү, үзләштерү һәм киләчәк буыннарга җиткерү өчен дә кирәк. Тик шулай да иҗатчы өчен бу — беренче баскыч кына. Ә традицияне дәвам иттерү, үстерү түгел.

Татарстан художникларының югарыда каралган иҗат үрнәкләреннән чыгып, безнеңчә, болгар-татар сәнгате мирасын үзләштерүнең өч яссылыгы һәм төре турында сөйләргә мөмкин. Беренчесе — әле әйтелгәнчә, орнамент үрнәкләрен турыдан-туры күчереп алу, шул юл белән бүгенге сәнгать объектларына этнографик һәм декоратив билге-сыйфатлар өстәү. Икенчесе — тарихи темаларга иҗат ителгән композицияләр һәм картиналар. Алар халыкның үткән тормышын танып-белергә ярдәм итүләре белән дә әһәмиятле. Өченче яссылык исә художникларның элекке чорлар өчен булган сурәтләү чараларыннан (мәсәлән, символик форма, башкару техникасы, алымнар h. б.) файдаланып, яңа эчтәлек алып килүче әсәрләр иҗат итүләрендә чагыла. Нәрсә ул традиция һәм нәрсә традиция түгел дип сорау куйганда, күрәсең, менә шул өченче яссылыкны бүгенге заман сәнгатендә элеккеге мирасның иҗади үстерелүе дип карарга кирәктер. Чөнки сынлы сәнгатьтә якисә көнкүреш сәнгатендә традиция һәм заманнар бәйләнеше, беренче чиратта, орнамент үрнәкләрен, мотив һәм образларны күчерүдән бигрәк, сурәтләү чараларын сайлау принципларын (әйтик, сәнгать телендәге метафоризмны) иҗади үзләштерү аша тормышка ашырыла.

Микельанджело «Давид» скульптурасын, ә В. Мухина исә, мәсәлән, «Икмәк» дигән скульптур композицияне ясаган. Давид — библиядәге мифик герой образы, ә В. Мухина әсәрендә бүгенге тормыш муллыгы чагыла. Икесендә ике төрле эчтәлек, ә сурәтләү алымы исә бер. Традиция менә шунда күренә дә инде. Борынгы болгар һәм хәзерге заман татар сәнгате әсәрләрен чагыштырганда да без шуңа охшашлы күренешкә тап булабыз. Болгарларның декоратив-көнкүреш сәнгатендәге иң камил әйберләрдә үзенчәлекле формада аларның дөньяга карашы чагыла. Кечкенә бер деталь белән дә алар образга зур мәгънә сыйдыра белгәннәр.

Әйткәнебезчә, һәр чорда сәнгать әсәрләренең эчтәлеге шул заманның иҗтимагый идеологиясе, психологиясе, дөньяга караш мәсьәләләре белән аерылгысыз бәйләнгән. Дәверләр үтү белән алар да үзгәреш кичерә. Ә реаль тормышны чагылдыру принциплары исә күп еллар үзгәрми калырга да мөмкин. Сәнгать чаралары белән чынбарлыкны үзләштерүдә нигездә ике художестволы принцип: тормышны аның үз

формалары аша чагылдыру һәм метафорик яисә символик формаларда сурәтләү принциплары яши. Борынгы болгар сәнгатендә без боларның һәр икесенә таянып иҗат ителгән әсәрләрне очратабыз. Социалистик эчтәлекле бүгенге татар совет сынлы сәнгатендә дә кайбер яклары белән символик, аллегорик характердагы әсәрләрне күрергә мөмкин.

Танып-белүнең ленинчыл теориясе буенча, традиция — ул бер яссылыкта өзлексез дәвам итүче линия түгел. Сәнгать үсеше цикллар рәвешендә бара һәм билгеле бер периодтан соң чынбарлыкны сәнгатьчә үзләштерүнең теге яки бу принцибы яңадан кулланылышка әйләнеп кайтырга мөмкин. Тарихи спиральның төрле бормаларында художникларның чынбарлыкка мөнәсәбәте күп кенә яклардан охшаш була, бу хәл ике дәвергә караган сәнгать әсәрләре телендә, чараларында уртак сыйфатларны барлыкка китерә.

Сынлы сәнгать традицияләре бик борынгы заманнардан ук килә. Кешелекнең безгә ирешкән беренче сәнгать төрләреннән берсе — мәгарә стеналарына һәм кыяларга төшерелгән рәсемнәр берьюлы бик күп кешеләргә хезмәт иткән. Бу рәсемнәрдә хәрәкәт киеренкелеге, экспрессия, эчке бер куәт бүген дә сокландыра. Борынгы рус фрескалары яисә Яңарыш чорының бөек рәссамнары калдырган әсәрләр, мексикалы Сикейрос иҗаты һәм күп милләтле совет сәнгате хәзинәләре дә безнә әнә шундый сыйфатлары белән җәлеп итә. Безнең художникларыбызга да, күрәсең, үткән чор сәнгате тәҗрибәсенә һәм совет сәнгатенең иң күркәм үрнәкләренә ешрак мөрәҗәгать итәргә, һәм, шул исәптән, әлбәттә, татар декоратив-гамәли сәнгатендә дәвам итеп килгән традицияләрдән нәтиҗәлерәк файдаланырга кирәктер.

**ДИНӘ ВӘЛИЕВА,**
**сәнгать белгече.**

------------

# ЭЗЛӘСӘҢ – ТАБЫЛА

**Башкортстан татарларының календарь поэзиясе**

*Еш кына, кем әйтмешли, халык иҗаты өлкәсендә эшләп «теше төшкән» өлкән генә агайлардан да шулай дип әйтүчеләр бар:*

*— Син, туган, бераз шыттырмыйсыңмы, бармы соң ул, чыннан да, бездә календарь йола иҗаты? Әгәр бар икән, нигә соң бастырып чыгармыйсың, кайда аграр җырлар, нигә алар, һич югында, журнал битләрендә күренми?*

*Башкортстанда яшәүче татарлар арасында, мәсәлән, йола иҗаты үрнәкләрен шактый күп табарга мөмкин. Күңел биреп, вакытын кызганмый картлар «телен» таба белгән, «тәпи туратка» утырып, авыллар иңләгән кешегә, әйтер идем, әллә күпме табыш очрый. Эзләсәң — табыла. Энҗенең, һәр адымда аунап ятса, кадере булмас иде. Ә бит энҗе бар!*

*Менә шул гүзәл хәзинәнең гаҗәеп үзенчәлекле бер өлкәсе — календарь иҗат үрнәкләре белән танышыйк, кадерле укучылар.*

## Сынамышлар

Хуҗалык итүнең характерына карап һәм борынгыларның табигатьне, тирәлекне танып-белергә омтылулары, күзәтүләре нигезендә, беренче чиратта, халык сынамышлары барлыкка килә. Сынамышлар, барыннан да элек, табигатьтәге үзгәрешләргә (яңгыр яву, кар төшү, ел фасыллары алмашыну, кошлар килү-китү, агачларның яфрак яруы яки коюы һ. б.) бәйле. Мәҗүсилек вакытларында туган бу халык сынамышлары соңрак ислам һәм христиан (керәшеннәрдә) дине карашлары белән аралаша. Календарь йола поэзиясенә алар мәкаль-әйтемнәр, ышанулар, арбаулар, келәүләр рәвешендә килеп керә.

Билгеле булуынча, болгар чорында да әле безнең ата-бабаларыбыз унике иягә табына. Дөресрәге, һәр елның «иясе» (хуҗасы) бар дип инана, шулияләргә ышана. Соңыннан бу ышанулар халык календарена сынамышлар рәвешендә килеп керә, йола иҗатына әверелә. Бу караш буенча, унике ел бер түгәрәк (мәсәл) барлыкка китерә һәм ул түбәндәгечә күзаллана: Тычкан, Сыер, Барыс, Куян, Ләү (келтә балык), Елан, Елкы, Куй, Мичин (маймыл), Тавык, Эт һәм Дуңгыз еллары. Әлеге елларның, халык ышануынча, һәркайсының үз сыйфаты бар. Башкортстанның Шаран районы Алпай авылында яшәүче Нигъмәтҗан бабай Шәйхуллин (1896 елгы) шушы мәсәл буенча

---

Мисалга китерелгән иҗат үрнәкләренең барысын да мәкалә авторы язып алды.

2018 елга кадәр махсус календарь төзегән һәм шуның белән эш итә. Менә аның календаре:

**1971 — 83 — 95 — 2007 — дуңгыз елы,**
**1972 — 84 — 96 — 2008 — тычкан елы,**
**1973 — 85 — 97 — 2009 — сыер елы,**
**1974 — 86 — 98 — 2010 — барыс елы,**
**1975 — 87 — 99 — 2011 — куян елы,**
**1976 — 88 — 2000 — 2012 — ләү елы,**
**1977 — 89 — 2001 — 2013 — елан елы,**
**1978 — 90 — 2002 — 2014 — елкы елы,**
**1979 — 91 — 2003 — 2015 — куй елы,**
**1980 — 92 — 2004 — 2016 — маймыл елы,**
**1981 — 93 — 2005 — 2017 — тавык елы,**
**1982 — 94 — 2006 — 2018 — эт елы.**

Мондый календарь нигезендә туган сынамышларны Башкортстанның кайбер татар авылларында әле дә ишетергә мөмкин. Нигъмәтҗан бабай Шәйхуллин телендә алар болай яңгырый:

**Барыс елы — байлык,**
**Тычкан елы — баллык,**
**Сыер елы — туклык,**
**Куй елы — кытлык,**
**Куян елы — йотлык [1],**
**Балык елы — мал үсәр,**
**Барыс елы — бәр да үсәр һ. б.**

Күрәсез, бу 12 еллык цикл (мәсәл) нигезендә тотемистик ышанулар ятса да, ахыр чиктә алар аграр характерлы, халыкның җир эшкәртү, иген игү, малчылык өлкәсендәге меңәр еллык практик тәҗрибәсенә барып тоташа.

Сынамышлар бик күп төрле һәм гаять катлаулы. Алар хәтта җыр текстларында да очрый. Берничә мисал:

**Күкләр күкрәмәс элек**
**Торналар тор-торласын.**
**Быел еллар туклыкка дип,**
**Күңелләрем җырласын.**

Нигезе: күк күкрәүдән элек торна кычкырса, ел туклыклы була, имеш.

**Шәфәкъләр таңга сузылды, —**
**Яңгыр булуга билге.**
**Кирәк иде, китә идек**
**Җәйгә кергәннән бирле.**

Нигезен әйтеп торасы юк шикелле, тел-текстында ята.

**Соңлап ярды яфракларын**
**Быел һәр җирдә агач.**
**Еллар авыр килер инде,**
**Булмасак иде тик ач.**

Агач яфракларын соңлап ярса, ел авыр килер, дигән халык юравы әлеге җырда чагылыш таба. Мондый мисаллар күп.

## Самаклар [2]

Ел каршылау йоласы — нардуган. Гадәттә ул декабрьның соңгы көннәрендә һәм январь башларында үткәрелә торган була. Дөрес, Башкортстан татарлары бу йоланы нәүрүз (искечә 7 нче март) башында да үткәрә килгәннәр. Шуңа, күрәсең, нардуган самаклары нәүрүз әйтүләр белән бер үк вакытта башкарыла иде, дип сөйлиләр.

[1] Йотлык — ачлык.
[2] Самак — башкортларда һамак — такмазага якын. Тамак төбе белән, кычкырып әйтелә.

Моңа артык гаҗәпләнәсе юк, болгар календаре белән таныш булган һәр укучы беләдер: безнең ата-бабаларыбыз яңа елны кайчандыр нәүрүздә каршылаган. Ягъни һәр ике йола да яңа елны каршы алуга карый, киләчәк уңыш турында, мал-туарның үрчүе хакында, гаилә иминлеге турында борынгыларның хәстәрлеген чагылдыра, магик ышанулы көнкүреш хәрәкәтләреннән тора. Фал ачулар, күрәзәлек итүләр оештырыла, йорттан-йортка йөреп, теләк теләү характерында сый-хөрмәткә җыр-самак әйтелә. Фал ачканда әйтелә торган иҗат, нигездә, сынамыш, ышану яки күрәзәлек итү характерында.

Менә Башкортстанның Шаран районы Алпай авылында язып алынган фал ачу җырлары:

Нардуганым нарына,
Бакма кеше ярына.
Күрше авыл Алпайда
Мулла көтә, картайган.

Бу җыр тигән балдак иясен — яшь кызны, димәк, карт мулла хатынлыкка ала.

Нардуганым нар төсле,
Матур ярлар бар төсле.
Сиңа гына караганы —
Бөкересе бар төсле һ. б.

Самак исә бөтенләй башка. Башкортстанда ул нардуган җыры яки нәүрүз әйтү дип тә йөртелә. Хәзерге телгә күчерсәк, самаклар алар — яңа ел теләге җырлары. Шулардан үрнәкләр:

Нардуган, нардуган,
Нардуган, хуҗалар,
Котлы, мөбарәк булсын,
Тормыш түгәрәк булсын,
Мал-туарыгыз артсын,
Колыннарыгыз чапсын,
Игеннәрегез бик уңсын,
Күкәй кебек тук булсын,
Нардуган, нардуган [1].

Монысы нардуган самагы булды. Инде нәүрүз әйтү дигәнен дә китереп үтик:

Кызыкайлар, дустыкайлар,
Җитте кич нәүрүз айлар,
Эшегезне ташлагыз,
Йон-йомарлам катмагыз,
Орчык шырылдатмагыз.
Кызлар, кызлар, тыңлагыз,
Нәүрүз җитте, уйнагыз,
Казы, күкәй, коймак, май
Әзерләек без давай,
Нәүрүз, нәүрүз!

Бусы яңа ел кичәсендә утырмага җыелган яшь кызларның җыры. Кешесенә карап, нәүрүз әйтүләрнең тексты да үзгәрә:

Нәүрүз килә яшәреп,
Яшәреп тә теш ярып.
Сөләйман абзый, котәмсең,
Табак-савыт бирәмсең!

---

[1] Башкортстанның Ярмәкәй районы, Усман-Ташлы авылында Мирхәйбулла Хәмидуллиннан (1898 елгы) 1973 елда язып алынды. Шул ук самакны Благовар районы, Каргалытамак авылы карчыгы Фатыйма Терегулова (82 яшь) «нәүрүз, «нәүрүз» дип башлый.

**Нәүрүзгә табак кирәк,**
**Табакка кабак кирәк,**
**Май, күкәй, калак кирәк,**
**Сиңа яшь кортка кирәк:**
**Тамагыңны туйдырыр,**
**Күп балалар тудырыр,**
**Иген-икмәк уңдырыр,**
**Күмәчең дә кызганма,**
**Озак яшә, сызланма,**
**Нәүрүз, нәүрүз!**

Самаклар гел бер характерлы түгелләр. Сорау-җавап рәвешендә дә очрыйлар:

**Нәүрүз, нәүрүз!**
**Кайда киттең!**
**— Киттем урам буйлап,**
**Хуҗалардан аш-су юллап.**
**— Нәүрүз, нәүрүз,**
**Моңарчы кайда идең!**
**— Ялан-кырда идем,**
**Инде сезгә килдем.**
**— Нәүрүз, нәүрүз!**
**Ашыкма, китмә,**
**Менә капка-сиртмә,**
**Бу йортта хуҗа —**
**Мулла Йомагуҗа.**
**Илдә ул уңган,**
**Абыстае булган,**
**Атлары юрга,**
**Җефәк бавы кулда,**
**Ярлы юк монда,**
**Кирәек шунда, —**
**Нәүрүз!**

Теләкне ничек тели беләсең бит. Менә ашап-сыйланганнан соң әйтелгәне:

**Урыс капка,**
**Тәрәзәң ялма,**
**Әйтәбез нәүрүз!**
**Ярлыкасын ходай,**
**Еллар килсен уңай,**
**Нардуган бүген,**
**Әбекәй, сөен,**
**Нәүрүз!**

Нәүрүзчеләрне яки нардуганчыларны сыйламаган очракта, ата-анасын кушып тиргәгәне дә, куркытканы да юк түгел. Йоласы шундый — берәү дә үпкәли алмый. Менә «йомшаграк» итеп әйткәне.

**Нәүрүз, абыз түткәем!**
**Бир маең, ипикәең.**
**Бирмәсәң — тартып алырмын,**
**Чүлмәкләрең ярырмын!**
**Нәүрүз!** [1]

---

[1] Нәүрүз әйтүләр һәммәсе дә Башкортстанның Туймазы районы авылларында язып алынды. Яздыручылар җитмештән өстәге карчыклар.

# Сөрән сугулар

Иң олы календарь йолаларның берсе — сөрән. Бу бәйрәм дөньядагы күпчелек халыкларга билгеле. Ел фасылы алмашыну — язга чыгу белән бәйле ул. Явыз рухларны куу, кыштан котылу, язгы кояшны котлауга кайтып кала. Чувашларда — суран, мариларда — сур'ам, керәшеннәрдә — сүрән. Бу көнне төркем-төркем яшьләр, бергылар кычкыртып, өйдән-өйгә кереп, сыйланып йөри, бүләк җыя, сөрән суга (сөрән сала). Хуҗалар сыйламаса, алар үзләре кергән өй учакларын сүндерә, идән-сәке такталарын куптара һ. б. зыяннар эшли торган була. Сөрән сугулар белән нәүрүз әйтүләр дә кайчак үзара бик охшашалар. Ләкин аермалар да юк түгел. Игътибар итик:

Сөрәнчеләр:

**— Әби-бабай, аманмысыз,**
**Аш-тәгамнәр салганмысыз!**

Хуҗалар:

**— Маяшлар әзер, туганнар,**
**Утырыгыз, оланнар!**

Сыйланганнан соң сөрәнчеләр хуҗаларга изге теләкләр белдерәләр, мактау яудыралар:

**Алтын да гынай ишек, көмеш тупса,**
**Атлый да гынай йөгереп без кердек.**
**Әби дә бабай — илнең солтаннары,**
**Табыннарыгызны лай хуп күрдек.**

**Аспары ла йомырка, өсләре май,**
**Тәбәләре телең йотарлык.**
**Кибән-эскертләрегез ишәйсен,**
**Гомерегездә күрмәгез тарлык!**

Сүз дә юк, сөрән сугуларның тел-тексты вакытлар узган саен үзгәреш кичерә, ләкин бер нәрсә даими кала: кереш өлеш (йорт хуҗаларына мөрәҗәгать итү), төп өлеш (бүләк яки аш сорау) һәм традицион бетем (бүләк биргәндә — мактау, бирмәгәндә янау, куркыту).

Шунысы кызыклы, сөрән сугу җырлары аерым очракта турыдан-туры самак (такмаза) формасын ала. Бу, күрәсең, шуның белән аңлатыла: календарь йолаларның барысында да йорттан-йортка йөреп ашамлык һәм бүләк җыю була. Шуңа күрә алар хакында исемнәре үк шуңа ишарә бит: нардуган кычкыру, нәүрүз әйтү, сөрән сугу — барысында да хәбәр салу бар. Менә сөрән сугуларның самак формасында килгәне:

**Сөрән сугып очтан-очка,**
**Килеп җиттек Куанычка [1],**
**Хәтәр, диләр, сырасы,**
**Бирсә ничек чыдасы,**
**Мал-туарлы курасы,**
**Иген тулы бурасы,**
**Улына кәләш кирәк,**
**Сөрәннән киңәш кирәк.**

**Куаныч агай, үгез суй,**
**Өстәп кызыл туның куй.**
**Илдән-илгә йөрербез,**
**Матур кызлар күрербез,**
**Даулап алып бирербез,**
**Яулап алып бирербез!**

---

[1] Куаныч — кеше исеме, типтәр.

**Ә син, абыз түткәем,**
**Бир сөт, май, ипекәең.**
**Бирмәсәң, бирмәсәң,**
**Без әйткәнгә күнмәсәң,**
**Нурлар төшмәс йөзеңә,**
**Хурлар төшәр үзеңә** [1].

## Келәүләр

Келәүләр яки теләүләр календарь иҗатта шактый зур һәм үзенчәлекле урын билиләр һәм бик күп йолаларда актив чагылалар. Мәсәлән, мәҗүсилек чорыннан сакланып калган шундый йолаларны күрсәтергә мөмкин: карга келәве (карга боткасы яки карга туе), балык келәве (балыкның күп булуын сорап үткәрелгән бәйрәм), кыр келәве (яңгыр боткасы яки яңгыр бәйрәме), ызба келәве (яңа өй котлау мәҗлесе) һ. б. Хәтта борынгы җирле календарь буенча махсус келәү ае була, елның алтынчы аена — көз башына туры килә.

Билгеле булуынча, ислам дине үзенең бөтен яшәве дәверендә мәҗүсилеккә каршы каты көрәш алып барган. Ләкин бер генә диннең дә әле киң масса аңыннан мәҗүсилекне соңгы чиккәчә кысрыклап чыгара алганы юк. Бигрәк тә житештеру көчләренең түбән, примитив булуы аркасында киң масса борынгы мәҗүсилекне ташламый. Дөрес, безнең яңа тормыш һәм социализм шартларында һәртөрле мәҗүси табынуларга урын калмый. Ә менә шул чордан килгән иҗат балалар фольклоры, уеннары сыйфатында һаман да очраштыра. Мәсәлән, карга боткасы, яңгыр бәйрәме уздырулар, шул чакларда йомырка тәгәрәтеп уйнаулар, карга булып кычкырулар, тавык булып кыткылдаулар (карга туенда), су сибешүләр (яңгыр туенда) һәм азактан табигатьнең иң гүзәл бер җирендә кумәк аш оештырулар, уеннар уйнау, җырсүздә алышулар — бала-чага өчен, билгеле инде, искиткеч күркәм, хозур тоела. Мәҗүсилек дәвереннән килгән иҗат, шул исәптән келәүләр дә, менә ни өчен бу уеннар (йолалар) белән бергә балалар репертуарына килеп керә, инде аларга хәзер бернинди магик эчтәлек салынмый. Борынгылар исә сүзләр ярдәмендә, мөрәҗәгать итүләр аша киләчәк уңышның, мал-туарның, гаиләнең язмышын хәл итеп була дип уйлаганнар, шуңа омтылганнар. Келәүләрнең безнең көннәргә килеп җиткәннәрендә дә менә шул күзәтелә. Берничә мисал китереп үтик.

Чәчү тәмамланып, игеннәр шытып чыгуга (тамыр җибәрүгә) Башкортстанның Ык буе районнарында борынгылар җир-анага, кояшка табыну, келәү әйтү үткәргәннәр. Шуның келәве:

**Җир атасы — җирән сакал!**
**Җир анасы — асыл бикә!**
**Түбәсенә туклыгын бир,**
**Тамырына ныклыгын бир,**
**Ил өстенә муллыгын бир,**
**Ил эчендә безгә дә бир!**
**Башлыйк теләкне,**
**Күтәрик беләкне, —**
**Кояш, шаһит бул!**

Корылыклы елларда исә кыр келәве (яңгыр боткасы) үткәрелә торган була. Бу очракта шулай ук кояшка (бар нәрсәгә тереклек бирүче символ итеп каралган) һәм болытка, яңгырга мөрәҗәгать иткәннәр, кием белән суга кереп, келәү әйткәннәр. Аерым урыннарда ак алаша, ак үгез, ак сыер, ак балык (ак — иминлек символы) корбан иткәннәр. Дөрес, күбрәк очракта корбанга кара сыер һәм кара сарык куелган. Чөнки, борынгыларның ышануынча, соңгылары яңгыр, кара болыт символы булып күзалланган. Кыр келәвенә мисал:

**Яңгыркаем, яу, яу, яу!**
**Илгә ачлык килмәсен,**

[1] Сөрән сугулар Ярмәкәй районы Шах авылында Шаһгали Хәсәновтан (1889 елгы) 1967 елда язып алынды.

Ачтан халык үлмәсен,
Чума чире йөрмәсен!
Яңгыркаем, яу, яу, яу!
Иген-ашлык күп булсын,
Башаклары тук булсын,
Кибән-эскерт зур булсын!
Яңгыркаем, яу, яу, яу!
Кара сарык суярмын,
Ботын сиңа куярмын,
Сөтле сыер абзарда,
Бар да булыр яуганда,
Яңгыркаем яу, яу, яу!

Уңыш җыеп алганнан соң, тоташ келәү ае уздырылган. Келәү аеннан калган иҗатның аерым чаткылары бүгенге көндә дә очраштыра. Шуңа мисал: урак беткәннән соң, уракчы хатын-кызлар җирдә тәгәрәшеп аунаганнар һәм келәү әйткәннәр:

Җир, җир, көчем бир,
Ябага тайның көчен бир,
Алтын алма төсен бир,
Алты атым куәт бир,
Алтмыш арба арыш бир,
Алтмыш арба бодай бир,
Алтмыш арба борай бир,
Алтмыш арба тары бир,
Бир, бир, барын бир!
Җир! Җир! [1]

## Җар салулар [2]

Формалары һәм төзелешләре ягыннан келәүләргә үтә якын торган иҗат бар: ул җар салулар. Әмма җар салулар, келәүләрдән аермалы буларак, бары тик кыш язга борылган вакытта гына яңгыраганнар һәм келәү йолалары шикелле олылап уздырылмаганнар. Җар салуларның иң яңгыраган ае — нәүрүз, хәзерге календарь буенча март ахыры һәм апрель башы. Бу айда борынгылар, аеруча бала-чага һәм яшьләр, биегрәк урыннардан, йорт, кура башларыннан, тау-түбә өсләреннән торып, кояшны чакырганнар, сүзләр ярдәмендә тизрәк кышны озатырга тырышканнар, камырдан пешерелгән кошлар «очырганнар» (очлы таякларга, колга башларына кадап йөгергәннәр). Бу кошларның очып йөрүләрен күргәннән соң, борынгылар уенча, янәсе кояшны тоткарлап, кышны саклап торучы кара көчләр курка, әркеп кача.

Җар салулар үзләре дә бик күп төрле. Арада бүгенге көндә дә балалар репертуарында шактый популяр булганнары бар:

Эт кояшы, тегеләй кит,
Безнең кояш, болай кил!
Кояш, чык, чык, чык!
Болыт, кач, кач, кач,
Без үйнарбыз җылыткач!
Тәти кашык базарда,
Майлы ботка [3] казанда,
Әти китте базарга,
Кызыл үгез [4] бар анда.
Әти кайткач базардан,
Ботка төшәр казаннан,
Кояш, чык, чык, чык!

---

[1] Китерелгән келәүләр һәммәсе дә Бакалы һәм Шаран районнарында язып алынды.
[2] Җар салулар — оран салу, кычкырып чакырулар.
[3] Ботка — йола ашы.
[4] Кызыл үгез — корбан терлеге, биредә кызыл төс — кояш символы.

Кайсы бер җар салуларда корбан терлекләре турыдан-туры вәгъдә ителә:

**Асыл кояш, болай кил,**
**Эт кояшы, тегеләй кит,**
**Майлы кашык бирермен,**
**Кызыл үгез суярмын,**
**Итен сиңа куярмын,**
**Майлы таба бирермен,**
**Кояш, чык, чык, чык!**

Җар салучылар ярдәмгә кошларны да алалар. Мәсәлән, Башкортстанның Миякә районы Сатый авылында Гани бабай Абдуллиннан (1881 елгы) язып алынган җар салуларның берсендә болай диелә:

**Асыл кояш, кил бире,**
**Кил бире, китмә кире!**
**Кошлар да көтә сине:**
**Тавыклар да кыткылдый,**
**Чыпчыклар да чыркылдый,**
**Ак үрдәкләр бакылдый,**
**Ата казлар каңкылдый,**
**Каргалар да каркылдый.**
**Уйнап йөри кызылтүш,**
**Юлга чыккан сыерчык,**
**Бар да җара [1]: кояш чык!**
**Кызыл әтәч куярбыз.**
**Асыл кояш, җәһәт кил,**
**Яшел җәйне тизләп кил.**

## Җырлар

Халкыбызда элек-электән килгән бер матур йола саклана. Ул — өмәләр үткәрү. Нәкъ менә өмәләр вакытында кайчандыр, хезмәткә ямь, яшәүгә тәм биреп, җырлар яңгыраган һәм хәзер дә яңгырый. Тарихлар төпкеленә киткән саен өмә җырларының тел-тексты да мәҗүсилек эзләрен үз эченә күбрәк ала бара. Бу аңлашыла да. Чөнки, алда әйтелгәнчә, безнең ата-бабаларыбыз хуҗалык итүнең һәммә тармагына сүзләр ярдәмендә йогынты ясарга, әлеге очракта эшне җиңеләйтергә мөмкин дип караганнар. Безнең көннәргә килеп җиткән өмә җырларында турыдан-туры йолачылыкны чагылдыру мотивлары күренми. Халык ышанулары, табынулары бөтенләй диярлек чагылмый. Еш кына аларда семья, никах темасы урын ала. Мондый хәл башка халыкларның календарь мирасында да күзәтелә. Шулай да өмә үткәрү ритуаллары шактый тотрыклы яшәвендә дәвам итә. Мәсәлән, Башкортстанның Чакмагыш, Шаран, Бакалы, Ярмәкәй төбәкләрендә каз өмәләре вакытында борынгыдан калган шундый ритуаллар очрый: а) өмә башлыгы сайлау (беренче булып өмәгә килгән кыз), б) өмәгә бары тик ата-анасы булган кызларны дәшү (казларның нәсел-нәсәбе туктамасын, янәсе), в) йолыкканда каз идәнгә төшәргә тиеш түгел (югыйсә, киләчәктә казлар уңмый), г) су буена җиткәнче каз каурыйларын чәчеп бару һ. б. Җырларда исә болар берсе дә чагылыш тапмый. Игътибар итегез:

**Каз өмәсе, каз өмәсе,**
**Өмә өмәләгәндә,**
**Егетләр мактаган була**
**Теләр-теләмәгәндә.**
**Безнең авыл уртасында**
**Борылып үсә наратлар.**

[1] Бар да җара — барысы да җар (оран) сала.

**Өмәчеләрне хурламас**
**Безнең кебек ир-атлар.**
**Ал да була, гөл дә була**
**Өмәченең куллары.**
**Утка салсаң, уттан чыга**
**Ир-егетнең уңганы.**
**Бу өйләрнең мичләре,**
**Ак икән кирпечләре.**
**Гомергә дә онытмабыз**
**Сездә булган кичләрне.**

Шундый ук хәлне башка төр өмә җырларында да күзәтергә була. Тула өмәсенә бәйле җырларны алып карыйк. Яшьләр хәзер тула басуның ни икәнен дә белмиләр. Ә бит тула басуы җиңелдән булмаган. Көн генә җитмәгән, чыра яктысында озын кышкы кичләрдә (январь, аеруча февраль айларында) эссе су белән станок (куша) артында туктаусыз эш итәргә туры килгән. Бу эш барыннан да элек хатын-кызлар җилкәсенә төшкән.

Дөрес, тула өмәсенең дә үзенә генә хас ритуаллары бар. Ләкин җырларда бу ритуаллар, йола элементлары гомумән чагылыш тапмый дисәк тә хата булмас. Шулай да кайсыбер текстларда күпмедер дәрәҗәдә тула җырларының барсына да уртак моментларны табарга мөмкин. Күз салыйк: гадәттә төшке ялга туктаган чакларда тула өмәсе уздырылган йортның тәрәзәсе янына егетләр җыела. Тулачылар (кызлар) аларны тәрәзә аша тула ашы (коймак) белән сыйлыйлар. Шунда гармунга кушылып җыр-әйтеш булып ала.

Кызлар башлый:

**Басыйк әле туланы,**
**Тулалары буламы!**
**Эч серләрне сөйләшик,**
**Йөрәкләрне бүлешик.**

Күмәк:

**Туласы булам дими,**
**Иясе алам дими.**
**Өзеп бетерик туласын,**
**Башын тотып уласын.**

Кызлар:

**Шәльяулык куе чәчәкле,**
**Ябынышырбыз әле.**
**Гел-гел бергә булалмабыз,**
**Сагынышырбыз әле.**

Күмәк:

**Туласы тулам дими,**
**Хуҗасы алам дими.**
**Өзеп бетерик туласын,**
**Башын тотып уласын!**

Шуннан соң җыр егетләр белән кызлар арасындагы кара-каршы әйтеш формасына күчә:

Егетләр:

**Әй, тула, тула, тула,**
**Тулада кызлар була.**
**Кызлар белән уйнагачтын,**
**Безнең күңелләр була.**

Арадан бер кыз:

**Тәрәзәләрдән карама,**
**Бүрек тышың алама.**

Егет:

**Нигә булсын алама,**
**Кар сыргандыр аңарга.**

Икенче кыз: Алма бирдем — алмадың,
Алларыңа салмадың.
Күкрәгеңне киргән идең, —
Әллә кемне алмадың.

Икенче егет: Аклы ситсы күлмәгеңнең
Әбүркәләре [1] өч рәт.
Безгә ямьсезләр дә ярый, —
Өзелеп сөяргә кирәк.

Сазаган кызлар: [2] Тула басам, тула басам,
Тулам бер дә ырамый.
Кешеләргә кияү килә, —
Безне беркем сорамый.

Кичке ял вакытында һәм эш соңында янә дә уеннар оештырыла, җырлар ишетелә.

Башкортстанның Ык буе регионында өмә җырлары хәтсез табыла. Арада шулай ук печән өмәсенә, урак өмәсенә, орчык өмәсенә, бура өмәсенә караган җырлар еш очрый.

Шулай итеп, татар халкының календарь йола поэзиясе дә, вакытлар сынавын үтеп, безнең көннәргә килеп җитә. Шигъри яктан алар халыкның хуҗалык турында, гаилә иминлеге хакында туктаусыз хәстәрлек күрүе аркасында туган уй-тойгысын, фикерен, кәефен, ни-нәрсәгә табынуын чагылдыра, хезмәт ярдәмендә генә якты хыялны тормышка ашырырга мөмкин дип ышанучыларның иҗат җимеше булып тора. Шуңа күрә дә календарь иҗатның күп кенә төрләреннән (самаклар, келәүләр, фал ачулар, күрәзәлек итүләр, арбаулар һ. б.) иң яхшы үрнәкләр матур әдәбиятта, сәнгатьтә яшәвен дәвам итә.

**РИФ МӨХӘММӘТҖАНОВ,**
Башкорт дәүләт университетының өлкән
укытучысы, филология фәннәре кандидаты.

---

[1] Әбүркә — оборка — бала итәк.
[2] Сазаган кызлар — кияүгә чыга алмый калган кызлар.

Ринат Мөхәммәдиев

# ЮГАЛМАС МИРАС ЭЗЕННӘН

Г. Тукай һәм Г. Ибрагимов, Г. Коләхметов һәм Г. Камал, Ф. Әмирхан һәм Ш. Камал — әдәбиятыбызның күрке булган йолдызлык бу. Беренче рус революциясе тудырган ташкын белән мәйданга чыккан әлеге язучыларның бары бер пары гына да татар әдәбиятының тулы бер дәверен балкытып торыр иде. Ләкин, нур өстенә нур дигәндәй, алар һәммәсе бер чорда туып, бер чорда иҗат иткән һәм бүген дә бергә — туган халкы һәм күп милләтле совет халкы белән бер сафта, горур атлап, алга — коммунистик киләчәккә үтәләр.

XX йөз башы, хаклы рәвештә, әдәбиятыбызның классик дәвере дип санала. Безгә соңгы елларда шушы уңдырышлы һәм бер үк вакытта шактый катлаулы чорның әдәби тәнкыйте — «хәрәкәттәге эстетика»сын җентекләп өйрәнергә туры килде. Вакытлы матбугат сәхифәләреннән чорның үз сулышын бөркеп торган тәнкыйть фикерләре белән танышу Бөек Октябрьга хәзерлек елларындагы татар әдәбияты һәм аның күренекле вәкилләренә булган ихтирам һәм соклану хисләрен тагы да үстерә төште.

Фән әдәбият һәм тәнкыйть тарихларын үзара тыгыз бәйләнештә карауны яклый. Заман югарылыгындагы тәнкыйть юк икән, чорның алдынгы иҗтимагый-политик омтылышларына җавап бирерлек әдәбиятның да булуы икеле. Киресенчә дә шулай ук. XX йөз башы татар әдәбияты да әлеге концепциянең дөреслеген раслый: бу чорның әдәбияты гына түгел, әдәби тынкыйте дә үзенчәлекле талантларга шактый бай булган. Талантлы тәнкыйтьчеләр — кемнәр алар? Иң элек, без тәнкыйть эшчәнлеген әдәби иҗат белән нәтиҗәле чиратлаштыра алган зур әдипләр — Г. Тукай, Ф. Әмирхан һәм Г. Ибраһимовларны күздә тотабыз. Ләкин бу чорда алар белән бер сафка басып, бөтен иҗат энергиясен әдәби тәнкыйтькә генә биргән авторлар — профессиональ тәнкыйтьчеләр булуын күрми китү дә ярамас. Бәхәссез ки, боларның иң күренеклесе Җамал Вәлиди (аның күп кенә тәнкыйть мәкаләләре «Җәләй» псевдонимы белән басылган). Хәер, үз замандашлары да бу исемнең әдәби тәнкыйть мәйданында үзенчәлекле урын алып торуын кат-кат билгеләп үтәләр. Мәсәлән, Г. Ибраһимов 1913 елгы татар әдәби процессына күзәтүендә «бу ел берничә яңа имза туды. Болардан иң беренче гакыллы, мәгънәле, киң алымлы (...) мәкаләләр иясе Җәләй әфәнде...»[1] дип Җ. Вәлидинең беренче тәҗрибәләрен үк уңай яктан билгеләп уза.

Тәнкыйть һәм тәнкыйтьчеләр алдында бөек рус революцион-демократы В. Г. Белинский иҗатын өйрәнүдән чыгып югары таләпләр куйган Г. Ибраһимов Октябрь революциясеннән соң басылган «Әдәбият кануннары» хезмәтендә дә «Бездә иң элекке мөнәкъкыйд Мәрҗани. Хәзерге язучыларыбыз эчендә — Җамалетдин Вәлиди»,[2] — дип язып чыкты.

Күренекле әдәбият галиме Г. Сәгъди дә татар әдәби тәнкыйте тарихын яктырткан беренче хезмәтендә бу тәнкыйтьче иҗатына югары бәя бирә: «Шул вакыттагы татар

[1] «Аң», 1914, 1 сан.
[2] Г. Ибраһимов. Әдәбият кануннары, К., 1918 ел.

әдәби тәнкыйтьчеләре арасында әдәби әсәрләргә бигрәк акыл, мантыйк ноктасыннан торып һәм иҗтимагый-әхлакый якларына күбрәк кагылып анализ ясаучы, аларга бигрәк шул яктан бәя куярга тырышучылардан берсе — Җ. Вәлиди иде. Татар тәнкыйтьчеләре арасында ул вакытта иң сабырлысы, уртача темпераментлысы да шул булды. Үзе «фәлсәфи тәнкыйть» нигезен алган иде»[1].

Җамал Вәлиди конкрет тарихи чор һәм шартларда мәйданга чыккан тәнкыйтьче, шуңа күрә аның иҗатын да шул тарихи чынбарлыктан килеп бәяләү дөрес булыр. Аның өчен үз вакытында шактый мөһим булып тоелган кайбер мәсьәләләр бүген үзләренең әһәмиятләрен югалткан булырга да мөмкин, чөнки бу табигый хәл. Ләкин Җ. Вәлиди тәнкыйте, барыннан да бигрәк, заман әдәбиятының үзәк мәсьәләләрен яктырту һәм хәл итүгә юнәлтелгән объектив һәм принципиаль тәнкыйть. Шуңа күрә анда куелган фикерләр һәм мәсьәләләр, нигездә, үзләренең әһәмиятләрен югалтмады, бүген дә актуаль булып кала бирәләр. Мәсәлән, халыкчанлык һәм тормышчанлык, милли әдәбиятның дөнья әдәбиятларына мөнәсәбәте мәсьәләләре шундыйлардан.

Тәнкыйтьченең татар әдәбиятында халыкчанлык мәсьәләсен яктырткан фикерләре аның Г. Тукай иҗатына мөнәсәбәте белән үзара үрелеп бара. Бу бер дә гаҗәп түгел, гомумән XX йөз башы татар әдәби тәнкыйтендә халыкчанлык турындагы фикер һәм карашлар, нигездә, Тукай поэзиясе тирәсендәге бәхәсләргә кайтып кала иде. Чөнки Г. Тукай шигырьләрендә татар халкының рухи халәте, уй һәм кичерешләре, иҗтимагый-политик омтылышлары аеруча тирән чагылыш тапты.

Җ. Вәлидине, икеләнүсез, тәнкыйтьче һәм әдәбият белгечләребездән беренче тукайчы дип санарга була. Ул әдәби тәнкыйть эшчәнлеген башлаган елларда ук Г. Тукай шигырьләре белән рухланып, аларның татар халкының күңел көзгесе булуын кат-кат билгеләп узды. Мәсәлән, Беренче рус революциясеннән соңгы елларда шагыйрь иҗатының халыкка һәм аның иҗтимагый-политик омтылышларына йогынтысын тәнкыйтьче: «Ул халыкның фикер вә хисенә дулкынга җил, ялкынга керосин тәэсире кеби бер тәэсир бирә иде»[2],— дип искә ала.

Җ. Вәлиди икенче бер мәкаләсендә Тукай иҗатының үзәгендә торган төп идея ул «аның һәр вакыт мәзлүм халык кайгысын чигүе, андагы хәб инсаният (гуманность)»[3], дип күрсәтеп чыга.

Дөрес, XX йөз башында Тукай шигырьләренең халыкчанлыгына хәйран калып, вакытлы матбугат битләрендә үзенең соклануын белдереп чыккан авторлар аз булмый. Ләкин Җ. Вәлиди Тукай иҗатын аңлауда аларның һәркайсыннан күп өстен торды дип әйтергә нигез бар. Тукай поэзиясен ул, күп кенә замандашларыннан аермалы буларак, башыннан ахырына кадәр бер пафос белән язылган дип кабул итеп, аны күккә чөю, идеаллаштыру юлыннан бармады. Шагыйрь язмышы татар халкының үз язмышыдай, ул туган халкының кайгы-шатлыкларын уртаклашып иҗат итте һәм аның иҗтимагый-политик аңы да халыкныкы белән бергә үсә, камилләшә барды дип саный тәнкыйтьче. Мәсәлән, шагыйрьнең Беренче рус революциясе чорындагы иҗаты белән кара реакция һәм яңа революцион күтәрелеш еллары поэзиясе арасындагы аермалыкны ул түбәндәгечә күрсәтеп бирә: «Әвәлдә ул дөньяны өстенә кара ноктадар сибелгән аклык итеп күрә иде. Инде ул хәзер аңа ак нокталар илә бизәлгән каралык итеп күренә башлады»[4]. Тукайның дөньяга карашында булган прогрессны ул шартларда шулай дөрес һәм кыю итеп әйтеп биргән башка берәү булдымы икән?..

Мәгълүм булганча, 1913 нче елда, җитди эзләнүләр чорын кичергән Г. Ибраһимов, «Татар шагыйрьләре» хезмәтен тәмамлап, «бер тәҗрибә» рәвешендә, үзенең әдәби-эстетик принципларын зур аудитория хөкеменә тәкъдим итә.

Ләкин әдәби җәмәгатьчелек аны артык берьяклы гына аңлый. Тәнкыйтьченең талант һәм халыкчанлык мәсьәләләре тирәсендә зур әңгәмә кузгатырга өметләнүе тормышка ашмый кала. Чөнки «Татар шагыйрьләре»ндә Тукай поэзиясе турында әйтелгән күп кенә каршылыклы фикерләр халыкның иң авырткан җиренә килеп кадала. (Тәнкыйтьнең басылып чыгуы, очраклы рәвештә, Тукайның вафаты көннәренә туры килде.) Төрле вакытлы матбугат битләрендә бу хезмәткә каршы бер-бер артлы үтә усал мәкаләләр басыла башлый. Менә шундый кызган атмосферада да Җ. Вәлиди

[1] Г. Сәгъди. Бездә әдәби тәнкыйть. Казан, 1927, 18—19 битләр.
[2] «Вакыт», 1913, 1172 сан.
[3] «Вакыт», 1913, 1258 сан.
[4] «Вакыт», 1914, 1454 сан.

чынбарлыкка үзенең аек карашын югалтмый кала. «Тукаев шигырьне Аполлон вә аның җирдәге табынучылары өчен сөйләми иде. Ул халык илә бергә, халык өчен халык йөрәгеннән сөйли иде... Шуның өчен бәрнечә дистә сәнгатьне сәнгать өчен дип белүчеләргә бервакытта да ул сәнам була алмас»[1], — дип язып, «Татар шагыйрьләре»ндәге фикерләрнең тәнкыйтьченең әдәби-эстетик принципларындагы каршылыкларның чагылышы булуын аңлауда беренче адым ясады. Сүз уңаена әйтергә кирәк, бераз соңрак, Г. Ибраһимов үзе дә «Татар шагыйрьләре» уңаеннан язылганнардан Җ. Вәлиди мәкаләсен аеруча игътибарга лаеклы иде дип билгеләп үтте»[2].

Халык шагыйре Г. Тукай иҗатын аның дөньяга карашы һәм идея-эстетик эволюциясе яктылыгында өйрәнүне Бөек Октябрь революциясеннән соң фәнни нигездә башлап җибәрүче шулай ук Җ. Вәлиди булды. Тәнкыйтьченең 1918 нче елда дөнья күргән «Габдулла Тукаевның мәҗмугаи әсәре» һәм 1923 нче елда «Мәгариф» журналында басылган «Тукайның шагыйрьлеге» хезмәтләре бүген дә шагыйрь иҗатын өйрәнүчеләр өчен җитди чыганак булып кала бирәләр.

«Габдулла Тукаевның мәҗмугаи әсәре»ндә Җ. Вәлиди беренче тапкыр шагыйрь иҗатын чорларга бүлеп, аның үсеш баскычларын күрсәтте, гыйльми биографиясен тудыруга җитди омтылыш ясады. Тәнкыйтьченең Тукай турында Октябрьга кадәрге вакытлы матбугатта чыккан мәкаләләрне күзәтеп чыгуы да үз чоры өчен зур әһәмияткә ия була. Әлеге хезмәттә ул Тукай поэзиясе турындагы сөйләшүне традициягә кереп барган халыкчанлык турында сөйләшү белән генә чикләмичә, аның лирикасына, сатирасына, балалар өчен язылган әсәрләре һәм тәрҗемәләренә аерым тукталып, аларның һәркайсында шагыйрь ирешкән уңыш һәм кимчелекләрне күрсәтеп чыкты. Бу исә тәнкыйтьченең Тукай иҗатын өйрәнүдә тагы бер адым алга атлавы булды.

«Тукайның шагыйрьлеге» мәкаләсендә инде ул халык шагыйрен бөек рус әдәбияты классиклары белән чагыштырып өйрәнү югарылыгына күтәрелә. «Тукай үзенең мирасы белән рус шагыйрьләреннән бигрәк Лермонтовка охшый. Ләкин ул иҗтимагый мәүкыйгы вә иҗтимагый мәсьәләләргә мөнәсәбәте ягыннан Некрасовка охшый төшәдер; ул да Некрасов кебек поэт-гражданиндыр»,— дип язды тәнкыйтьче.

Тукай иҗаты һәм әдәбиятта халыкчанлык төшенчәсе XX йөз башы шартларында турыдан-туры икенче бер әһәмиятле проблема — әдәби тел мәсьәләсенә барып тоташа. Әдәби телебезне халык теле нигезендә формалаштыруда Г. Тукай, Г. Ибраһимов һәм Ф. Әмирханнарның гаять зур эшчәнлеген күрсәтү белән бергә, без бу мәсьәләне хәл итү юлында Җ. Вәлиди эшчәнлеге дә махсус игътибарга лаек дип саныйбыз. (Җ. Вәлиди даими рәвештә эшләп килгән күренекле тел галиме дә, аның татар телен гамәлгә кую өлкәсендәге зур эшчәнлеге махсус өйрәнүчеләр көтә.)

Ул тел турында җитди бәхәсләр барган бер чорда, 1912—1915 нче елларда, яңадан кайтып-кайтып «Тәрҗеман» тәкъдим иткән гомумтөрки телнең үзебезгә һичнинди мөнәсәбәте булмаган чит нәрсә икәнлеген күрсәтеп чыкты. Халык телен, Г. Тукай һәм Г. Ибраһимовлар телен, «печән базары теле», «чабаталы урам теле» дип кимсетергә маташучыларга тыныч һәм дәлилле итеп җавап бирә килде. «Булсын, печән базары әдәбияты булсын,— дип язды тәнкыйтьче мәкаләләренең берсендә,— бу бик табигый эш. Юкса татар теле Невский проспектта яки Солтан Баязит мәйданында эшләнергә тиешме? Печән базары дигәч тә гади бер печән сата торган урын дип уйларга ярамый»[3]. Халыкның уй-кичерешләрен, кайгы-шатлыкларын аның үзенчә, үз теле белән җырлап биргән сандугач — Г. Тукай иде, ул үзенең әсәрләре белән менә шул «печән базары теле»нең нинди зур хәзинә икәнлеген теләсә кемнән матуррак итеп күрсәтә алды. «Минемчә, «Тукаев кем?» соәленә иң мөнасип җавап вә шулай ук Тукаевка иң кыска тәгъриф «Татарча иң матур сүзләр сөйләүче» дигән җөмлә булачакдыр. Шуның өчен телебезнең кадере күтәрелгән саен Тукаев күтәрелә барачак, милли аңыбыз арткан саен Тукаев аңлана барачакдыр»,— кебек нәтиҗәгә килә Җ. Вәлиди. Бүген исә, аның ни дәрәҗәдә хаклы булуы бездә аз гына да шик тудырмый.

Җ. Вәлиди Тукай поэзиясе белән беррәттән XX йөз башы татар әдәбиятының башка күренекле вәкилләре иҗатын да тирәнтен аңлап, аларга үз вакытында төпле бәя бирә килгән тәнкыйтьче. Аның «Вакыт»та басылган беренче тәнкыйть мәкаләсе

[1] «Вакыт», 1913, 1259 сан.
[2] «Йолдыз», 1915, 1532 сан.
[3] «Вакыт», 1914, 1409 сан.

ук әдәбиятыбызның икенче бер классигы Галимҗан Ибраһимовның «Яшь йөрәкләр»е уңае белән язылган. «Әдәбият бигрәк тормышның җилен, дулкынын күрсәтә, шуның өчен тормыш никадәр җилле, дулкынлы булса, аның көзгесе булган әдәбият та шулкадәр рухлы, шулкадәр күренешле була. Әдип, шагыйрь! Болар тормыш дәрьясының уртасына ташланган бер көймәче...» [1] — кебек юллар белән башланып китә ул мәкалә. Тәнкыйтьче Г. Ибраһимовны тормыш дәрьясының уртасында барган көймәчегә охшата һәм бу очраклы рәвештә генә түгел. «Яшь йөрәкләр»дә язучы чынлап та иске татар тормышының бөтен каршылыкларын оста каләм белән тетрәндергеч картиналарда сурәтләп бирде. «Татарның хәзерге тормышы (...) инсан өчен гаять дәрәҗәдә тар, караңгы, яшерен,— дип яза ул әсәр турында уйлануларын дәвам итеп.— Бу хәлгә үзенең инсаният кыйммәтен аңлаган хәсас яшь йөрәк чыдый алмый». Зыя кебек яшь йөрәкләргә нишләргә?.. Бары үләргә генә кала — «аны тормыш кысып үтерә». Тәнкыйтьченең «Яшь йөрәкләр»не һәм аның идея эчтәлеген ни дәрәҗәдә тирән аңлап фикер йөртүенә игътибар итми китү мөмкин түгел.

Әлеге мәкаләдә Җ. Вәлиди, художник буларак, Г. Ибраһимовка аеруча характерлы булган тагы бер үзенчәлекне — аның әсәрләренә хас психологик тирәнлек һәм романтик хикәяләү үзенчәлеген күреп ала. «Галимҗан әфәнде монда шәхси һәм лирик (эчке шагыйрь) булып күренә шикелле. Ул тормышның иң ачык күренеп торган нокталарыннан бигрәк үзенең хыялында ялтыраган йолдызларны күрсәтә»,— дип билгеләп үтә тәнкыйтьче, үзенә генә хас нечкә сиземләү белән.

Ш. Камал иҗатына хас үзенчәлекләрне ачыклауда да Җ. Вәлиди беренче булып җитди уңышка ирешкән тәнкыйтьче. Бу үзенчәлекле язучының киң катлам укучылар тарафыннан яратып укылуы ни белән аңлатыла соң? Шул хакта уйланулардан килеп ул игътибарын язучының әдәби геройларының рухи халәтен күрсәтү осталыгына юнәлдерә. «Шәриф әфәнде үзенең кыска хикәяләрендә,— дип яза тәнкыйтьче,— безгә тормышның бик оригинальный һәм бик характерный булган сәхнәләрен ача вә анда бик нечкә һәм неуловимый нокталарын тотып күрсәтә» [2]. Хикәяләр Җ. Вәлидине үзләренең тормыш дөреслеген бөтен нечкәлекләре белән күрсәтеп, вакыйгаларның гади күзләрдән яшеренгән «төп ягын» яктыртып килүләре белән җәлеп итә. Тәнкыйтьченең үз сүзләре белән әйткәндә: «Ш. Камал вакыйгаларның тышкы барышын, тышкы төзелешен түгел, бәлки эчке ягын — психологический ягын әсас итеп тотадыр». Язучы үзенең хикәяләрендә нинди дә булса бер вакыйганы башыннан ахырына кадәр җентекләп сөйләп чыгу бурычы куймый, «мәгълүм бер халәт рухия (психологический момент)ны эләктереп алып шуны бөтен тулылыгы белән күз алдына китереп бастыра».

Ш. Камал әсәрләренең эчке хасиятен тирәнтен аңлап әйтелгән бу фикерләр бүген дә камиллеккә ирешкән тәнкыйть булып кала бирәләр, бу бер. Икенчедән, Җ. Вәлиди тәнкыйтебездә беренчеләрдән, тормыш дөреслеген чагылдыруны үзенең бурычы санаган әдәбият өчен психологик анализның зур казаныш булуын яхшы аңлап, бу мәсьәләгә әдәби җәмәгатьчелекнең игътибарын юнәлдерде. Тәнкыйтькә психологик анализ төшенчәсенең килеп керүе исә, әдәбиятның реализм юлыннан үсүе өчен яңа мөмкинлекләр тудырды.

*

*   *

Җ. Вәлиди әдәби тәнкыйть мәйданына килгән еллар милли әдәби-эстетик фикернең реализм мәсьәләләрен аңлауда җитди эзләнүләр алып барган, тәнкыйтьнең теоретик фикерләргә һәм фәлсәфи-эстетик принципларга игътибары бермә-бер үсә төшкән чорга туры килә. Ул әдәбият-сәнгатьнең үзәк мәсьәләләрен аңлауда беренче мәкалә һәм хезмәтләре белән ук татар әдәби тәнкыйтенең авангардында баручы Г. Тукай, Ф. Әмирхан һәм Г. Ибраһимовлар сафына кушылды. 1912 нче елда ук дөнья күргән «Татар әдәбиятының барышы» хезмәтендә тәнкыйтьче әдәби хәрәкәтнең иҗтимагый тормыш һәм тарихи чынбарлык белән турыдан-туры бәйләнештә булуына басым ясап, бары тормыш дөреслеген чагылдырган әдәбият кына укучының күңелен били, аңарда эстетик ләззәт тудыру сәләтенә ия була диген нәтиҗәгә килә. Ләкин әдәбият бит чынбарлыкны чагылдыруның үзенчәлекле һәм специфик төре. Ул фәннән

[1] «Вакыт», 1913, 1141 сан.
[2] «Вакыт», 1914, 1622 сан.

өермалы буларак, «хакыйкатьне турыдан-туры түгел, бәлки тәэсир вә тәмсил илә мәйданга куярга тиеш» [1]. Г. Ибраһимов кебек үк Җ. Вәлиди дә әдәбиятның спецификасы мәсьәләләренә зур игътибар бирә, ләкин ул тормышчанлыкка каршы куелмый. Шул уңайдан тәнкыйтьченең «Аң» журналында басылган «Әдәби хәрәкәт» исемле мәкаләләсе игътибарны җәлеп итә. Кешеләр, үзләренең табигате белән, тормышта өч биеклеккә, өч идеалга омтыла дигән фикер белән чыга Җ. Вәлиди: «...боларның берсе хакыйкать, икенчесе фазыйләт [2], өченчесе хәсән (күркәмлек) дер, (...) әдәби иҗат та шул идеалга таба бер хәрәкәттер, адымдыр» [3]. Шул рәвешчә, әдәби әсәрләр язучының хакыйкатькә, фазыйләткә һәм күркәмлеккә омтылышы нәтиҗәсендә иҗат ителергә тиеш дип саный тәнкыйтьче. Бу Җ. Вәлиди тарафыннан тормышчанлык, идеялелек һәм гүзәллекнең әдәбият һәм сәнгать өчен бер дәрәҗәдә әһәмиятле шартлар буларак кабул ителүе турында сөйли иде. Әдәбият һәм сәнгатьнең асылын, аның спецификасын аңлауда бер чиктән икенче чиккә ташлану очраклары кабатланып торган чорда, бу фикерләр аеруча зур әһәмияткә ия булдылар. Дөрес, тәнкыйтьченең әлеге теоретик фикерләренә һәрчак тугрылыклы булып калды дип әйтеп булмый. Вакыты белән ул үзе дә бу өч шартның бөтенлегеннән тайпылып, әдәбият һәм сәнгатьнең теге яки бу үзенчәлегенә басым ясау белән мавыгып киткәләде. Мисал өчен, буржуаз-миллләтче язучы Г. Исхакыйның «Мөгаллимә»се уңае белән язылган тәнкыйтьне алырга була [4]. Бу әсәрнең сыйнфый асылын, Г. Ибраһимов кебек [5], турыдан-туры фаш итә алмаса да, Җ. Вәлиди «Мөгаллимә»не шулай ук кабул итмәде. Пьесаның авторын «чын идеалист» дип, ул да әсәрнең тормыш дөреслеген бозып күрсәтүен һәм иҗтимагый яктан әһәмиятсез булуын күрсәтеп чыга. Ләкин бу сүз уңаена гына. Җ. Вәлиди мәкаләнең теоретик өлешендә, әдәбият һәм сәнгатьнең заман тормышына мөнәсәбәтен дөрес аңлатмыйча, төп игътибарын идеаль матурлык һәм хыял дөньясына юнәлтә. Һәм нәтиҗәдә, әдәбият алдында торган иҗтимагый бурычларны күреп бетермәве белән, ул үз-үзенә каршы килә. Әдәби тәнкыйть мәйданына аяк атлаган елларында ук: «Әдәбият, бигрәк, тормышның җилен, дулкынын күрсәтә»,— дип чыккан тәнкыйтьченең әлеге каршылыклары нәрсә белән аңлатыла соң? Югыйсә, аның өчен әдәбиятның иҗтимагый тормыш мәсьәләләре белән бәйләнештә үсәргә тиешлеге инде күптән кабул ителгән эстетик принцип булып тора иде.

Бу каршылык Җ. Вәлиди тәнкыйтенә очраклы рәвештә һәм вакытлыча гына килеп кермәде. Киресенчә, ул тәнкыйтьченең иҗтимагый-политик позициясе һәм дөньяга карашындагы җитди каршылыкларның чагылышы булды. Җ. Вәлиди — зур талант, югары зәвыклы, сизгер һәм принципиаль тәнкыйтьче булуына карамастан, Октябрь революциясенә кадәрге чорда революцион-демократик идеяләр югарылыгына күтәрелеп җитә алмады. Шул сәбәпле ул аерым очракларда заман тормышының прогрессив көчләрен һәм алар алдында торган зур бурычларны күреп бетерми.

Дөрес, заман тормышы (буржуаз чынбарлык) белән ул үзе дә килешергә теләми, бу ямьсез һәм караңгы тормышның тиз арада нигезеннән үзгәрергә тиешлеген дә сиземли. Ләкин сиземләүдән ерак китми, әдәбият алдында торган бурычларны әледән-әле заман тормышыннан аерып, аны «шомырт вә сирин чәчәкләре илә» генә бизәргә кирәк дигән чакыру белән чыга. «Мондый яшерен, тыныч вә бер төрле тормыш,— дип яза тәнкыйтьче,— даһи сәнгатькярләр өчен тирән идеяле вә зур көрәшле мәүзуглар тудыра алмаган кебек, биллитристлар (гади хикәячеләр) өчен дә киң сәрмая бирә алмыйдыр» [6]. Бу сүзләрнең ике зур революция арасында һәм революцион күтәрелеш елларында әйтелүен дә искә алсак, Җ. Вәлидичең үз чоры иҗтимагый-политик тормышын аңлый алмавы һәм җәмгыятьнең әйдәп баручы көчләрен күрмәве тагы да ачыграк булып күз алдына килеп баса. Тәнкыйтьченең дөньяга карашындагы чикләнгәнлек, әлбәттә, аны әдәби-эстетик фикерләрендә күп кенә каршылыкларга китерде. Ләкин шуңарга да карамастан, Җ. Вәлиди әдәбиятның тормышка мөнәсәбәтен яңача хәл итү һәм аның иҗтимагый ролен күрсәтү юлында, Г. Тукай, Ф. Әмирхан һәм Г. Ибраһимовлар кебек үк, армый-талмый эшләгән тәнкыйтьче иде. Ул

[1] Җ. Вәлиди. Татар әдәбиятының барышы. Оренбург, 1912, 11 бит.
[2] Фазыйләт — яхшы сыйфатлылык, бу очракта — иҗтимагый файда һәм максатлылык мәгънәсендә.
[3] «Аң», 1915 ел, 7 сан, 147 бит.
[4] «Вакыт», 1915, 1674 сан.
[5] Г. Ибраһимов. «Мөгаллимә»нең Уфада уйналуы мөнәсәбәте белән. «Тормыш», 1915, 194—196 саннар.
[6] «Вакыт», 1913, 1141 сан.

1912 елда ук: «Әдәбиятның гомуми иҗтимагия илә мөнәсәбәте бигрәк куәтледер. Шуның өчен боларны берсен икенчесеннән аерып язу мөмкин түгел» [1],— дип чыгып, югарыда искәртелгән кайбер тайпылуларны исәпкә алмаганда, әдәбият һәм сәнгатьнең асылын аңлатуда идеалистлар позициясенә басмады. Тәнкыйтьченең Г. Тукай поэзиясенә мөнәсәбәте моның ачык мисалы булып тора. «Талант» (истигъдад) һәр милләттә, һәр заманда вә урында килергә мөмкин, ләкин аның куәттән фигыльгә чыгуы, җимеш бирүе, шөбһәсез, мохит белән чикләнә» [2], — дигән фикергә нигезләнеп, ул Г. Тукайның 1905 нче ел революциясе тәэсирендә мәйданга килгән талант һәм үз заманының олуг фикер иясе булуын күрсәтеп чыкты.

Тәнкыйтьченең сәнгатьчә гүзәллек (категория прекрасного) кә мөнәсәбәте белән танышып узу да кызыклы булыр. Гүзәллек мәсьәләсен ул мәхәббәт һәм сөю хисләренә бәйләп аңлатты. Бу, бер карашка, гүзәллек мәсьәләсен шактый кечерәйтү, чикләү булып күренә, ләкин нәтиҗә ясарга ашыкмыйк. «Мәхәббәт барлыкны матурлый, бизәкли, бу бөтен тупас матдилеккә бер фәрештәви ямь бирә, дөньяны шагыйрьләндерә (реальный тормышны идеализировать итә)» [3],— дип язды тәнкыйтьче. Шул рәвешчә, ул мәхәббәт төшенчәсен интим хисләргә, яисә реаль чынбарлыктан аерылган илаһи омтылышларга гына кайтарып калдырмый. Сүз көндәлек тормышны һәм җир матурларын идеаллаштыра торган олы хис — мәхәббәт турында бара. Язучының, бигрәк тә шагыйрьнең әдәби әсәрдә тасвирланучы тормышка һәм үзенең геройларына мәхәббәте, безгә калса, табигый күренеш. Аңардан башка чын сәнгать әсәре турында сүз булырга да тиеш түгел. «Шигырь! Бу нәрсә? Мәхәббәт тавышы түгелме?» — кебек уйланулар да бит, тәнкыйтьченең интим поэзияне яклап чыгуы булмыйча, Зыя Ярмәки һәм Сабирҗан Мөлеков кебек яшь каләмләрнең сәнгатьчә гүзәллектән мәхрүм калган дүрт юллыклары уңае белән язылa. Җ. Вәлидинең әлеге шагыйрьләрне Тукайдан үрнәк алырга чакыруы да очраклы түгел. Чөнки Тукай поэзиясе, тәнкыйтьче өчен, Ватанга һәм халыкка булган ярату хисләренең, олы мәхәббәтнең иң ачык мисалы булып торды.

Сәнгатьчә гүзәллекне мәхәббәт һәм сөю хисләренә бәйләп аңлату Н. Г. Чернышевский диссертациясендә дә әһәмиятле урын алып тора. Мәсәлән, ул үз-үзенә: «Дөньяда иң гүзәл әйбер нәрсә? — кебек сорау куеп, аңарга,— кешедә — мәхәббәт һәм матурлык; табигатьтә — ни икәнлеген әйтүе дә кыен, анда матурлыкның чиге юк»,— дип җавап бирә [4].

Җ. Вәлидинең бөек рус шагыйре А. С. Пушкин иҗатына мөнәсәбәте дә әлеге эстетик карашлардан чыгып аңлатыла. Ул Пушкин шигырьләрендә туган илгә, аның табигатенә һәм рус халкына булган бөек яратуның чагылышын күрде. «Пушкиннан рус әдәбиятының яңа дәвере башлана,— дип язды тәнкыйтьче. — Чөнки аңа кадәр анда чын-чын гүзәл вә тугры хөкәмә бирерлек әсәр юк дәрәҗәсендә иде... Ниһаять Пушкин ул дәвернең капкасын бөтенләй ябып рус әдәбиятын икенче дәвергә — табигый һәм хакыйкатькә якын бер гүзәллек дәверенә кертте» [5]. Җ. Вәлиди XX йөз башы татар әдәбиятының да шундый ук «табигый вә хакыйкатькә якын бер гүзәллек дәверенә» таба борылуын яхшы аңлый. Ләкин, шул ук вакытта, ул Г. Ибраһимов кебек ук, тормышны турыдан-туры фотография ысулы белән күрсәткән әдәбиятка, үгет-нәсихәттән гыйбарәт булган поэзиягә каршы чыга. Әдәби әсәрдә чынбарлык язучы һәм шагыйрьнең күңелендә туган тойгылар, хисләр аша тасвирланырга тиеш дигән таләп куя тәнкыйтьче. Әмма аның сәнгатьнең спецификасы мәсьәләләренә зур игътибар бирүе, сәнгатьчә гүзәллекне чынбарлыкка һәм әдәбиятның идеялелегенә каршы куюы дигән сүз түгел. «Фикерсез һәр нәрсә җансыз, җансыз һәр нәрсә бар сурәтендә юктыр... Шигырьдә исә сәнаигъ нәфисәнең башка нуларына караган вакытта да фикер ачык вә аңлаешлы булырга тиеш (...) Шигырьдә фикер тирән, гади яки нечкә вә күркәм булсын» [6],— кебек таләпләр, тагы бер кат, Җ. Вәлидинең гүзәллек мәсьәләсен берьяклы гына аңламыйча, әдәбият һәм сәнгатьнең иҗтимагый бурычы һәм идеялелегенә зур әһәмият бирүе турында сөйли.

---

[1] Җ. Вәлиди. Татар әдәбиятының барышы. Оренбург, 1912, 11 бит.
[2] Җ. Вәлиди. Г. Тукай мәҗмугаи әсәре. К., 1918, 43 бит.
[3] «Вакыт», 1913, 1184 сан.
[4] Н. Г. Чернышевский. Избр. эст. произведения. М., 1974, 162 стр.
[5] Җ. Вәлиди. Татар әдәбиятының барышы. Оренбург, 1912, 83—84 битләр.
[6] «Вакыт», 1913, 1257 сан.

*
* *

Яңарыш һәм кискен борылыш дәверендә милли әдәбиятларның дөнья әдәбиятына игътибары бермә-бер үсеп китүе яңалык түгел. XX йөз башы — татар әдәбияты һәм сәнгате өчен нәкъ менә шундый кискен борылыш һәм яңарыш чоры булды. Мондый шартларда әдәби-эстетик фикер үз кабыгында, милли рамкаларда гына чикләнеп кала алмый. Әдәби җәмәгатьчелек һәм тәнкыйть алдында дөнья әдәбиятының идея-эстетик байлыкларын һәм прогрессив традицияләрен үзләштерү бурычы килеп басты. Ләкин, Җ. Вәлиди билгеләп үткәнчә, XX йөз башларына кадәр дин әһелләре халыкны «безгә остаз булачак халык — әлбәттә, беренче шарт — мөселман булырга кирәк, чөнки мөселман кешегә исламнан тыш гыйлем эзләү, исламнан тыш дин эзләү белән бердер»[1], дип куркытып килделәр. Шул рәвешчә, Көнбатышка мөнәсәбәт дини идеология исеменнән зур гөнаһ саналып, ислам дөньясы — Европага һәм шәрык-гарепкә каршы куелды.

Татар әдәбиятының дөнья әдәбиятына мөнәсәбәте мәсьәләсе шундый шартларда әверуча принципиаль идеологик проблема булып көн тәртибенә килеп басты. Дөнья әдәбиятына мөнәсәбәт турында сүз чыкканда, тәнкыйтьчеләрнең әдәби-эстетик позицияләре генә түгел, дини һәм милли мәсьәләләргә мөнәсәбәтләре дә актив хәрәкәткә килә иде. Мәсәлән, «Дин вә мәгыйшәт»челәр дөнья әдәбияты һәм культурасына мөнәсәбәттә, барыннан да элек, дин һәм шәригать канунлары нарыннан чыгып эш йөртсә, буржуаз-милләтчеләр тик милли рамкаларда гына чикләнеп калуны якладылар.

Җ. Вәлиди исә, замандашлары Г. Тукай, Ф. Әмирхан һәм Г. Ибраһимовлар кебек үк, татар әдәбиятының киләчәген аның Көнбатыш Европа һәм рус әдәбиятларының бай традицияләре белән тыгыз элемтәдә үсүендә күрде. Язучыларны ул кайтып-кайтып гарәп әдәбияты һәм гарәп эстетик фикерен махсус үзләштерергә, «аның эченә керергә, тирәнлегенә төшәргә...» чакырды. «Без Европаны никадәр яхшы белсәк, шул кадәр аның куәтенә, кодрәтенә иманыбыз арта»[2],— дип язды тәнкыйтьче.

Көнбатыш Европа һәм рус әдәбиятлары Җ. Вәлиди өчен, барыннан да элек, үзләренең реалистик традицияләре — тормышчанлыгы һәм халыкчанлыгы белән якын иде. Шуңа күрә милли әдәбиятның уңышларын һәм бурычларын да ул турыдан-туры гарәп әдәбиятлары белән бәйләнештә карап, гарәп эстетик фикере яктылыгында аңлатырга омтылды. «Әдәбиятта гарәпнең тәэсире илә фикеребез, рухыбыз да ул чиксез хыял дәрьясыннан, ул әлеф лилә вә лиләләр галәменнән беркадәр арынды. Ул беркадәр хакыйкатьне дә игътибарга алырга, аның белән дә хисаблашырга мәҗбүрият сизде»,— дип язды Вәлиди, «Әдәби хәрәкәт» дип исемләнгән тәнкыйтендә[3].

«Йолдыз» газетасының 1915 ел, 14 октябрь санында Н. Думави «Бер мөляхәзә» дип исемләнгән мәкалә язып чыга. Анарда Думави дөнья әдәбиятына мөнәсәбәт мәсьәләсен шәрык белән генә чикләп куеп, төп игътибарын татар халкының шәркилеге исбат итүгә юнәлдерде. Вакытлы матбугат битләрендә бу тискәре концепциягә беренче булып отпор бирүче Җ. Вәлиди булды. Думави тарафыннан мәсьәләнең шул рәвешчә өстән генә, иҗтимагый тормыш һәм реаль чынбарлык шартларыннан тулысынча изоляцияләнгән хәлдә аңлатылуын, автор торган позициянең нигезсез булуын күрсәтүче факт дип саный тәнкыйтьче. «Без заман игътибары белән генә түгел, урын игътибары белән дә хәзер чын шәрык халкы түгелбез. Без шәрыкта түгел, бәлки гарәпнең шәрык койрыгында торабыз; безнең мохитыбыз руслыктыр. (...) Безнең хәзерге хәлдә шәрыклы булырга тиешлегебезне исбат өчен канныбызның, чыгышыбызның шәрки булуын дәгъва кылу гына җитми. Минемчә, моның әһәмияте аз. (...) Әһәмият чыгышта, канда түгел, тарихтадыр»[4]. Думавидан аермалы буларак, тәнкыйтьче мәсьәләгә зур принципиальлелек белән һәм материалистик эстетика нормаларыннан чыгып килә. Татар әдәбиятының рус һәм Көнбатыш Европа әдәбиятларыннан үрнәк алып, аларның реалистик традицияләре яктылыгында үсеп баруы, Җ. Вәлиди тарафыннан гаять зур әһәмияткә ия булган прогрессив күренеш һәм иҗтимагый тор-

---

[1] Җ. Вәлиди. Татар әдәбиятының барышы. Оренбург, 1912 ел, 35 бит.
[2] «Вакыт», 1914, 1621 сан.
[3] «Аң», 1915, 3 сан, 59 бит.
[4] «Аң», 1916, 4 сан, 69—70 битләр.

мыш шартларыннан килүче тарихи зарурлык буларак та аңлатыла. Ул әдәбият һәм сәнгатьнең, әдәби-эстетик фикернең гарепкә яки шәрыкка мөнәсәбәтен, нинди дә булса «мода»га иярү яисә кемнең дә булса тырышлыгы белән генә тормышка ашырыла торган күренеш дип санаучылар белән килешми. «...Мөһим вә олуг тарихи яңарыларга «мода» дип карарга ашыгырга ярамый. Аңар тарихи вә иҗтимагый канун тудырган мәҗбүр итеп карарга кирәк» [1],— дип язды тәнкыйтьче. Игътибар итик, Җ. Вәлиди дөнья әдәбиятына мөнәсәбәт проблемасын материалистик эстетиканың методологик принципларыннан чыгып аңлатуны таләп итә — мәкаләдә әдәбият һәм сәнгать мәсьәләләренең иҗтимагый тормыш шартлары белән тыгыз бәйләнештә каралырга тиешлегенә, иҗтимагый шартлылык һәм тарихилыкка җитди әһәмият бирелә.

Тәнкыйтьче үзенең мәкаләләрендә, дөнья әдәбияты дигәндә, иң беренче чиратта, рус әдәбиятын күз алдында тота. Рус әдәбияты аңарда, барыннан да элек үзендә күтәрелгән мәсьәләләрнең тормышыбызга якын торуы белән зур кызыксыну уята иде. Шул ук вакытта ул Көнбатыш Европа әдәбиятлары белән танышуда арадашлык функциясен дә үтәүче әдәбият булып торды. «Руслар безгә Европаны каплый торган пәрдә түгел. Бәлки ачыграк итеп, якынрак китереп күрсәтә торган бер телескоптыр» [2],— дип язган иде Җ. Вәлиди тәнкыйть эшчәнлегенең таңында ук. Ул алга таба да рус әдәбияты классикларын чиксез югары бәяләп, аларны өйрәнүгә даими төстә игътибар биреп килде.

Ләкин Җ. Вәлидинең дөнья әдәбиятына мөнәсәбәт мәсьәләсен хәл итүдә керткән өлешен никадәр генә югары бәяләсәк тә, аның кайбер кимчелекләрдән дә азат булмавын танырга кирәк. Без Н. Думавиның дөнья әдәбияты төшенчәсен шәрык әдәбиятлары белән генә чикләргә омтылуын билгеләп үткән идек инде. Җ. Вәлиди исә, киресенчә, рус һәм Көнбатыш Европа әдәбиятларының ролен гаять югары бәяләп, көнчыгыш әдәбиятларны бөтенләйгә игътибарга алмый дип әйтерлек. XX йөз башы татар әдәбияты һәм әдәби-эстетик фикерләренең хәрәкәт юнәлешен, шәрыктан гарепкә хәрәкәтен берьяклырак кабул итә тәнкыйтьче. Әдәбиятның схоластикадан тормышчанлыкка һәм реализмга таба үсешен турыдан-туры шушы хәрәкәткә бәйләп, ул көнчыгышның уңай традицияләрен аңлап җиткермәде. Шәрык әдәбиятын гарепкә каршы куйганда әйтелгән: «Госманлыларның үзләренә ярамаган тузган, черегән баганаларын үзебезгә нигез итеп утыртыйкмы?» [3] кебек фикер белән килешсәк тә, Җ. Вәлидинең көнчыгыш поэзиясе классикларына онытылганда бер генә мөрәҗәгать итүе бераз гаҗәп тоела.

Мәгълүм булганча, тәрҗемә эше дөнья әдәбиятларына мөнәсәбәт белән турыдан-туры элемтәдә тора. Шуны яхшы аңлап, татар әдәбиятының үз мәнфәгатьләрен кайгыртып, алдынгы әдәбиятлардан үрнәк алуны һәм алардан мөмкин кадәр күбрәк һәм файдалырак әсәрләр тәрҗемә итүне яклап чыгучыларның да берсе Җ. Вәлиди була. «Тәрҗемәсез милләтләрнең фәкать югары вә мөмтаз катлаулары гына танышып бирләшә ала, әмма тәрҗемә аркасында Гюго рус авылларында укыла, Пушкин немец фабрикаларына керә вә Шиллер инглиз шахталарына кадәр нәфүз итәдер» [4]. Шул рәвешчә, ул татар әдәбиятында да тәрҗемә эшенең активлаша баруын күреп чын күңелдән куана һәм моның, барыннан да элек, түбән катлам кешеләре — халык массалары өчен зур әһәмияткә ия булуына басым ясап уза. «Тәрҗемәгә ихтыяҗыбыз чиксез,— дип дәвам итә тәнкыйтьче. — Каршыбыздагы Европа тау кадәр бер гыйлем мөхәзәне, бу һичбер милләткә вә һичбер сыйныф халыкка махсус түгел, бәлки гомуми бер хәзинә». Сүз уңаена искәртеп узыйк, «Европа» дигәндә, автор Көнбатыш Европа әдәбиятларын гына түгел, үзе күрсәткәнчә, иң элек «ватандашларыбыз булган рус әдәбиятын» күздә тота.

Җ. Вәлидинең рус әдәбиятын ни дәрәҗәдә тирән аңлап эш итүен, аның өледәнөлә Пушкин, Некрасов һәм Л. Толстойларга мөрәҗәгать итүеннән дә аңлау читен түгел. Ләкин, артык җәелеп тормастан, бу очракта шуны гына билгеләп үтәсе килә, ул татар вакытлы матбугатында беренчеләрдән булып бөек пролетариат язучысы А. М. Горький турында да язып чыккан тәнкыйтьче. «Рус мөхәррирләренең беренче

---

[1] «Аң», 1916, 4 сан, 72 бит.
[2] Җ. Вәлиди. Татар әдәбиятының барышы, Оренбург, 1912, 32 бит.
[3] «Аң», 1916, 4 сан, 71 бит.
[4] «Вакыт», 1913, 1193 сан.

сафында булган Максим Горький (...) соңра үзе күргән, үзе яшәгән иң әшәке почмакларны һәйбәт тасвир итеп, укучының тәмам күз алдына китереп матбугат мәйданына чыгарган. Аның бар хасияте бәхетсез, гаиләсез вә йортсыз кешеләрнең яхшы якларын, яхшы күңелләрен тасвир итүендәдер. Максим Горький хәзерге исән рус мөхәррирләре эчендә халыктан иң күп хөрмәт күргән, яшьләрнең иң күп ихлас куйганы бер кешедер»[1],— дип, ул пролетариат язучысының әсәрләренә, аның халыкчанлыгына үзенең сокланушн белдерде. Капиталистик чынбарлыкның күп кенә ямьсез якларын фаш иткән, халык массаларының кайгы-хәсрәтләрен тетрәндергеч картиналар аша күрсәтеп биргән реалистик әсәрләрне пропагандалап чыгуы үзе генә дә тәнкыйтьченең зур кыюлыгы турында сөйли.

Дөрес, аерым фактлардан чыгып кына без Җ. Вәлидине заманның иң алдынгы идеологиясен аңлау дәрәҗәсенә күтәрелгән тәнкыйтьче иде дип санарга җыенмыйбыз, аны әле икеләнмичә революцион-демократик карашлар югарылыгыннан торып эш итте дип тә әйтеп булмый. Шулай да әдәбият-сәнгать мәсьәләләренә мөнәсәбәттә, ул, нигездә, Г. Тукай, Ф. Әмирхан һәм Г. Ибраһимовлар позициясендә торды. Моңарга ул иҗтимагый-политик сизгерлегеннән бигрәк, нечкә әдәби-эстетик сиземләве аша килде.

Җ. Вәлиди, барыннан да элек, Октябрьга кадәрге әдәби тәнкыйтебезнең күренекле вәкиле. Шуның белән бергә ул совет власте елларында да әдәбият, культура һәм аеруча халык мәгарифе өлкәләрендә эшләвен актив дәвам итте, тарих, әдәбият һәм тел мәсьәләләренә караган хезмәтләр язды. («Татар теленең аңлатмалы тулы сүзлеге» араларыннан аеруча игътибарга лаеклысы булса кирәк.) Дөрес, аерым очракларда, зур эрудиция һәм нечкә сиземләү белән язылган хезмәтләренә аның һаман да, әлеге дә баягы, иҗтимагый-политик зирәклек җитенкерәмәде. «Татарстан хәбәрләре»нең 1922 елның март саннарында ул, үткәндәге мираска мөнәсәбәттә, Г. Ибраһимов белән принципиаль бәхәскә керә. Менә шул бәхәстә аның ялгышу һәм каршылыклары аермачык чагылыш таптылар[2].

Кыскасы, Җ. Вәлиди 20—30 нчы елларда татар совет әдәбияты белеме һәм әдәби тәнкыйте авангардында барган Г. Ибраһимов, Г. Нигъмәти, Г. Галиләр югарылыгына күтәрелә алмады һәм тора-бара тәнкыйть эшчәнлегеннән читләшергә мәҗбүр булды. Әмма педагог һәм тел галиме буларак гомеренең соңгы елларына кадәр армый-талмый эшләвен дәвам итте: 1921 елда Казанда Көнчыгыш академиясендә укыта башлый; 1921—1925 елларда Татарстан Җир эшләре Халык Комиссариаты каршында мөдир урынбасары һәм терминология комиссиясе председателе булып эшли; 1922—1925 елларда татар рабфагында укыта, 1923—1931 елларда Көнчыгыш педагогия институты доценты.

* * *

Мәкаләдә Җ. Вәлидинең аерым хезмәтләренә тукталып аларны анализлау бурычы куелмады. Шулай да араларыннан берсен һәм, әйтер идек, бәхетле язмышлысын искә алмый үтү мөмкин түгел: Джамал Валидов. Очерк истории образованности и литературы татар (до революции 1917 г.), М.-Пг., Госиздат, 1923. Бу китапның бер нөсхәсе бүген дә В. И. Ленинның Кремльдәге шәхси китапханәсендә әдәбият белеме, әдәбият тарихы һәм тәнкыйть бүлегендә саклана. Даһи Ленинның гомеренең соңгы елларында да татар әдәбияты, аның үткәне һәм бүгенгесе белән якыннан кызыксынуы турында сөйли торган факт бит бу. Кем белә, бәлки юлбашчы шушы китап битләреннән РКП(б)ның X съезды көннәрендә Татарстан делегатлары белән сөйләшүдә искә алган Г. Тукай исемен табып, аның турындагы зур булмаган очерк белән дә танышып чыккандыр. Шушы китаптан Владимир Ильичның Г. Ибраһимов, Ф. Әмирхан, М. Гафури, Г. Камал һәм Ш. Камаллар турында язылган юлларны да кызыксынып укыган булуы мөмкин.

Ничек кенә булмасын, шунысы бәхәссез, китап Ильичның шәхси китапханәсенә очраклы рәвештә генә килеп кермәгән. Чөнки Ленинның үз китапханәсе өчен китап-

[1] «Вакыт», 1914, 1387 сан.
[2] Кара: Г. Халит. Әдәби тәнкыйтьнең югалмас сәхифәләре.— «Совет әдәбияты», 1969, 4 сан.

ларны бик зур таләпчәнлек белән сайлавы мәгълүм. В. В. Бонч-Бруевич «Пометки Ленина на «Книжной летописи» дип исемләнгән хезмәтендә, Ленинның 1918 нче елда чыгачак регистрацияләнгән 5326 китапның 55 е белән генә кызысынуын, ә 1919 елда 3415 тән нибарысы 22 не генә сайлавын билгеләп уза. Ул гына да түгел, әле сайланган китапларның да бер өлешен, үзе танышып чыкканнан соң, ул төрле китапханәләргә җибәрә торган була. Бары шуннан соң гына китапларга инвентарь номеры һәм «библиотека Н. Ленина» дигән штамп сугылган. Җ. Вәлидинең «Очерк истории образованности и литературы татар (до революции 1917 г.)» хезмәте әлеге штампка лаек дип табылган иң бәхетле китаплар исемлегендә 5783 нче номерны йөртә.

*
* *

Әлекке Тәтеш өязе, Апас авылында туган, Иж-Буби мәдрәсәсендә белем алган, соңыннан тәнкыйтьче, тел галиме һәм педагог булып танылган Җ. Вәлидигә шушы елның 13 нче октябрендә 90 яшь тула (1887—1932). Әйе, аның җиң сызганып иҗат иткән елларыннан һаман ераклаша барабыз икән. Мәңге алга чапкан вакыт белән бергә бу әдипнең тәнкыйть һәм фәнни-эстетик мирасы да бездән өзлексез ераклаша бармыймы соң?.. Юк, бу сорауга уңай җавап бирү мөмкин түгел. Аның тәнкыйте һәм эстетик карашлары системасында үзәк урынны биләгән тормышчанлык һәм халыкчанлык, дөнья әдәбиятының алдынгы үрнәкләре белән бәйләныш мәсьәләләре бүген дә үзләренең актуальлекләрен югалтмады, киресенчә, алар күп милләтле совет әдәбияты һәм культурасына аеруча характерлы принциплар буларак һаман да тирәнәя генә баралар. Әдәбият белемебез һәм тәнкыйть тә Г. Тукай, Г. Ибраһимов һәм Ш. Камал кебек күренекле әдипләребез иҗатын өйрәнүдә инде күп кенә уңышларга иреште, менә шушы уңышларда да Җ. Вәлидинең игътибарга лаеклы өлеше бар кебек. Тәнкыйтьченең 90 еллыгы якынлашкан көннәрдә безне әнә шул характердагы уйлар били.

Кыям Миңлебаев

# КАМИЛЛЕККӘ ОМТЫЛУ

Тәрҗемә — төрле әдәбиятлар арасында үзара элемтә урнаштыручы күпер ролен үти. Теге яки бу халыкның милли казанышларын, әдәбият өлкәсендәге уңышларын да башка халыкларга тәрҗемә җиткерә. Күп милләтле Советлар илендә тәрҗемәнең роле аеруча үсте, киң колач алды.

Кат-кат уйланылган, җиде мәртәбә үлчәнеп язылган тасвир гына үзенең художество дәрәслегенә укучыны тулысынча ышандыра, аны факт булырак, вакыйга булырак тетрәндерә ала. Тәрҗемәдәге дөреслек, оригиналга таңгәл килү дә нәкъ әнә шуның сыман. Шулай да тәрҗемә — ул оригиналның һәр сүзен, һәр җөмләсен төкми-чәчми күчереп кую түгел әле. Тәрҗемә әсәре оригиналга үзенең рухы һәм идея эчтәлеге белән, стиле һәм теленең самими байлыгы белән якын килсен, яңгырашы һәм музыкасы белән таңгәл булсын өчен шактый көч сарыф итәргә туры килә.

Эчтәлекне төгәл бирү — хәзерге буын тәрҗемәчеләр өчен проблема булудан туктады шикелле: һәр ике телне җитәрлек дәрәҗәдә белүче тәрҗемәчеләребез инде автор әйтергә теләгән фикерне, автор сурәтләгән картинаны, һич тә хилафлык китермәстән, укучыларыбызга җиткерергә өйрәнделәр дип әйтергә була. Шул сәбәпле тәрҗемә китапларның укучыга тәэсорат көче дә үскәннән-үсә бара. Әдәби әсәрнең кыйммәте аның кайсы телдә иҗат ителгән булу-булмавына бәйләнмәгән, бәлки эчтәлеге һәм формасының бердәм булуына, автор яки тәрҗемәченең сурәтләү чаралары һәм теле ягыннан ни дәрәҗәдә камиллеккә ирешә алуына бәйләнгән. Профессиональ тәрҗемәчеләр кулыннан узган китапны укыганда әсәрнең эчтәлеге турында мәгълүмат алу белән генә чикләнеп калмыйча, авторның тел байлыгын, андагы үзенчәлек-нюансларны, язу стилен тулысынча аңлап, бу хакта җәелеп фикер йөртергә мөмкин.

Бүгенге көндә бәйге тоткан тәрҗемәчеләребез кем җитте аның китабына ябышырга атлыгып тормыйлар, сайлап кына, төпченеп кенә эш итәләр: стиль ягыннан үзләренә якынрак торган, яхшы аңлаешлы, яраткан авторларының китапларын тәрҗемә итүне мәгъкуль күрәләр. Ә бу инде тәрҗемәнең әйбәт чыгачагына гарантия дигән сүз. Чөнки мондый очракта ул иптәш авторның мохитына кереп китә, аның биографиясен, иҗатын мөмкин кадәр тулырак күзалларга тырыша һәм, әлбәттә, оригиналдагы сүз һәм җөмләләрне турыдан-туры тәрҗемә итү белән генә канәгатьләнә алмый, бәлки анда тасвирланган вакыйгаларны үзебезнең әдәбият җирлегенә күчереп куярга, оригиналдагы персонажларга таңгәл килердәй типларны иҗат итәргә омтыла.

Татар теленә тәрҗемә итүчеләргә мәйдан шактый иркен: дөнья классикасы, тугандаш әдәбиятлар, рус классикасы һәм рус совет әдәбияты безнең телгә әле күп күчерелмәгән. Әлбәттә, беренче чиратта, классиканы күбрәк тәрҗемә итәргә кирәк, анысы бәхәссез. Ә инде заман әдәбиятыннан әсәрләр сайлаганда аеруча таләпчән булу кирәк. Тәрҗемәче иң элек: теге яки бу роман, повесть заман сынавын узганмы, оригиналда яратып укыламы? — кебек сорауларга җавап бирергә тиеш.

Заман сынавын узган һәм оригинал хәлендә үзенең укучыларын елдан-ел ишәйткән әсәрне икенче телгә төкми-чәчми күчереп кую ансат башкарыла торган эш түгел. Бердән, оста художник кулы белән язылган китапның теле ифрат үзенчәлекле һәм бай була — тәрҗемәчедән үз ана

телен әйбәт белүне һәм ул байлыктан оста файдалануын сорый; икенчедән, ул бай һәм камил телнең бөтен нечкәлекләрен, нюансларын үз теленә күчерергә, ә моның өчен оригиналга тәңгәл килердәй тәгъбирләр табарга кирәк була; өченчедән, олуг художник ул әсәрен иҗат иткән дәвердә нинди настроениедә яшәгән, аның юл арасына салган бизәк-оттеноклары нидән гыйбарәт — боларның һәммәсен дә ныклап өйрәнү һәм үз телеңдә шуларны мөмкин кадәр тулы, хыянәтсез чагылдыру таләп ителә... Уйлап баксаң, чын-чыннан камил вә гүзәл художество әсәрен тәрҗемә итү шактый гына мәшәкатьле, күп көч сарыф итүне, армый-талмый эшләүне сорый торган нәрсә икән ләбаса!..

Татарстан китап нәшрияты 1976 елда бастырып чыгарган китаплардан рус әдәбияты классигы А. И. Купринның «Атышу» повесте (Р. Даутов тәрҗемәсе), дөнья классикасыннан Д. Лондонның үнлап хикәясе (Ф. Хәсәнов тәрҗемәсе), тугандаш халыклар әдәбиятыннан Ч. Айтматов повестьлары (Я. Халитов тәрҗемәсе) һәм Ә. Мохтарның «Чинар» исемле мәшһүр романы (Л. Хәмидуллин тәрҗемәсе) китап сөючеләребезне инде куандырып та өлгергәннәр. Чөнки ул китаплар, бер яктан, һәр авторның иҗатында үзәк урын тотардай гүзәл әсәрләр булса, икенче яктан, татарча язылган оригинал әсәрләргә тиң итеп эшләнгәннәр, җиңел укылалар.

А. И. Куприн безнең укучыларга яхшы таныш: әле бер ун ел чамасы гына элек Рәис Даутов тәрҗемәсендә аның «Повесть һәм хикәяләр»е дөнья күргән иде. Хәзер шул ук тәрҗемәче шундый ук осталык белән аның «Атышу» (Поединок) дигән повестен татарча эшләп чыгарды.

«Атышу» повестен әгәр дә оригиналы белән чагыштырып карасаң, беренче җөмләсеннән үк тәрҗемәчегә бәйләнергә мөмкин: ул авторның фикеренә үзеннән әллә ниләр өстәп бетергән, күпертә төшкән кебек. Ләкин бу беренче карашка гына шулай тоела икән. Чөнки әле генә без «үзеннән өстәгән» дигән фикер, ныклабрак карасаң, оригиналның шул ук абзацында икән ләбаса...

Китапта нибарысы 2—3 урында гына көйгә зыян китергән җөмлә очрый. Мәсәлән, Куприн үзе җәнлекләрне ифрат ярата һәм өендә гомере буе бер көтү эт асрый, аның хәтта маймылы һәм бер аю баласы да була. 1933 елны, Парижда яшәгән чагында, ул көндәлегенә болай дип язып куя: «Этләр күз алдыбызда кешегә әйләнәләр. Шул ук вакытта безгә кешеләрнең эткә яки чучкага әйләнгәнен дә күргәләргә туры килә». Бер юньсезен автор бу повестенда да «старый и свирепый меделянский пес» дип атый. Ә минә этләр дөньясыннан хәбәре юк тәрҗемәчебез әлеге чагыштыруны йомшарта: юаш холыклы бурзай белән алыштыра һәм үзенең авторын рәнҗетә. Миңа калса, бу очракта «явыз йөнтәс эт танавы» дию урынлырак булыр иде сыман...

Гомумән алганда, Рәис Даутов А. И. Купринны элек-электән олуг художник дип саный, аның таланты алдында баш ия, китапларын ихлас күңелдән яратып укый. Бу авторның хикәя вә повестьларын татарчалаштырганда да тәрҗемәче җөмләне җөмләгә түндереп баруны максат итеп куймый, ул автор сурәтләгән картиналарны, оригиналга мөмкин кадәр якынрак килеп, үзебезнең әдәби телгә күчерүгә омтыла. Язучы үзе татарча белеп, безнең телдә язса, бу фикерләрен ничегрәк итеп әйтер иде икән? Нindирәк сүзләр куллаңыр иде икән? Тәрҗемәче әнә шулай дип баш вата. Һәр аерым очракта сүзләрне авторның табигатенә туры килердәй итеп тезәргә тырыша. Һәм аның эзләнү вә тырышулары сокланырлык нәтиҗә бирә: ул китапның гаять җиңел укылуына, табигыйлегенә, музыкальлегенә ирешә. Моның никадәр көч таләп иткәне, чынчыннан иҗади хезмәт икәнлеге яхшы мәгълүм.

А. Толстой үзенең мәкаләләрендә җөмләне озынга сузмаска, артык сүзләр — чүп сүзләр тутырмаска өнди. Аның үзенең җөмләләре эшләнеше ягыннан хәйран калдыра: из песни слова не выкинешь, дигәндәй, укыган чагында бер генә сүзен дә төшереп калдыра алмыйсың.

Җөмләнең лаконичный булу-булмавы тәрҗемәдә үзен бигрәк тә нык сиздерә. Тәрҗемәнең сыйфатын билгеләү өчен текстны үзгәртеп карарга кирәк. Әгәр дә аны адым саен үзгәртеп була икән, ул тәрҗемәне уңышлы дип әйтеп булмый. Ә инде һәр җөмләсе ныклап уйланган, һәр сүзе урынына куелган икән — андый тәрҗемәне һич тә үзгәртү мөмкин түгел: бәллүр касә бөтен чагында гына чыңлый, аның берәр җире кителсә яки чыртлап ярылса — чыңлаудан туктый. Оста кулы белән эшләнгән тәрҗемә китабында да шулай ук: бер генә сүзен алсаң да — сүтелә, укылмый, җырламый башлый.

Моның шулай икәнлегенә Р. Даутов тәрҗемәсен караганда инанасың.

«От поручика Николаева никто не был?»
«Поручик Николаевлардан килүче-китүче булмадымы?» (27 б.)

Тәрҗемәче биредә һәр сүзен, һәр иҗеген контексттан чыгып яза: сүз Николаевлар өеннән чакыручы-фәлән булу-булмавы турында бара. Шуны күздә тотып, русчасында гәрчә Николаев үзе генә телгә алынса да, тәрҗемәче кыю рәвештә бездә әйтелгәнчә ала: Николаевлар. Күп кеше бу фразаны тәрҗемә иткән чагында: «Килүче булмадымы?» — дип бирер иде. Һәм алай дип бирү мәгънәви яктан дөрес тә булыр иде шикелле. Әмма Рәис Даутов тота да үзеннән бер сүз өстәп җибәрә, һәм шуның белән җөмләнең саф татарча, музыкаль яңгырашына ирешә. Әнә шул өстәлгән сүзне, «артык» сүзне аласың икән — әсәрнең көе, музыкаль тональносте, ритмы юкка чыга.

«Пари было большое — что-то около ста рублей».

«Зурдан бәхәсләшкәннәр — йөз сум акчадан диме» (5 бит).

Оригиналда бәхәснең суммасы якынча гына күрсәтелгән. Русча язганда ул шулай табигый чыга. Ә менә шуны «якынча»лый башласаң, безнең телдә гайре табигый яңгыраячак. Әнә шул хәл тәрҗемәчене уйланырга мәҗбүр иткән дә: тел бистәсе поручик Веткин армия тормышыннан алып сөйләгән мәзәгендә «йөз сум» дип әйтә дә, әйтми дә шикелле, һәрхәлдә, тәгаен өзеп кенә әйтми бугай, шуны татарча ничегрәк әйтер иде икән бу исеркбаш? Әһә, кешедән ишеткәнен сөйли икән ич: шулай булгач, үз өстенә алмастыр, я башкаларга сылтар, я бик үк анык итеп әйтмәстер шикелле: «йөз сум акчадан диме»...

Безнең тәрҗемәләрдә күләмнең чак кына артуына кайбер иптәшләрнең капризы дип карарга һич ярамый: аның сере тирәндәрәк ята. Тәрҗемәчеләребез сабый чактан ук татар әдәбиятының сихри дөньясы белән рухланып үскән, шуның традицияләренә мөкиббән китеп мыек чыгарган кешеләр. Һәм аларның әзмы-күпме тәфсиллебрәк сурәтләргә яратулары табигый хәл.

Шул ук вакытта, җитлеккән сүз осталары булырак, бүгенге көндә бәйге тоткан тәрҗемәчеләребезнең үзләренең иҗади йөзләре, почерклары бар. Әйтик, Рәис Даутов геройның холкын, эчке дөньясын йөрәге аркылы, күңеле аркылы уздыра һәм, әнә шул кичерешне күз алдына аермачык килеш, кирәк чагында җөмлә кысаларын бозып, геройның халәтен үзенчә, телебездәге байлыктан иркенрәк, баерак файдаланып тасвирлый — сүз сайлауда үзен ирекләрәк тота. Әмма бу иркенлек аны һич тә оригиналдан читләштерми, киресенчә, андагы эмоциональ байлыкны, бизәкләрне тулырак чагылдырырга китерә. Бүтәннәрдән дә нәкъ шулай эшләүне, шундый ук нәтиҗәгә ирешүне таләп итү дөрес булмас иде. Чөнки оригиналны һәркем чак кына үзенчәрәк күрә һәм шуңа бәйле рәвештә бизәкләрен үзенчәрәк төшерә.

Сәнгатьтә моңа мисаллар аз түгел. Әйтик, моннан йөз ел элек (1873—1874) Сена буенда, табигать кочагында, күңелләренә хуш килгән бер үк күренешне француз импрессионистлары Огюст Ренуар белән Клод Моне икәүләшеп полотнога төшерәләр. Берсе үзенең эшен «Аржантейдагы җилкәнле көймә» дип, ә икенчесе «Аржантейдагы җилкәнле көймәләр» дип исемли. Картиналар сюжет ягыннан, әлбәттә, бер-берсенә охшаган. Башкача булуы да мөмкин түгел, чөнки алар бер үк вакытта бер үк пейзажны тасвирлыйлар. Әмма бу охшашлык гомуми күренештән узмый, тышкы охшашлык булу белән чикләнә. Бөек рәссамнарның һәркайсы чынлыкта исә үзенең сурәтләү стилен исбатлый, табигатькә үз күзе белән карый. О. Ренуар дөньяга ихлас күңелдән гашыйк булып, һәр детальне аермачык сурәтли: басмадагы кеше дә, төнбоеклар фонындагы үрдәкләр дә, күтәрелгән җилкәннәр дә, якындагы көймә дә һичбер төрле шик тудырмыйлар, һәркемне ышанырга мәҗбүр итәләр, күңелдә мәхәббәт хисе уяталар; тик болар һәммәсе дә билгеле бер мизгелдә тотып алынган. Ә менә К. Моне полотносында шул ук әйберләр хәрәкәттә бирелгән: су өсте дулкынланып тора, күктә болытлар йөзә, җилкәннәр алай ук матур да түгел кебек, әмма аларны җил киергән, алар шуңа тигезләгән җуйган, бер генә буш көймә дә юк — ишкәкчеләр каерылып ишкәк ишәләр; алгы пландагы кешенең көймәгә кереп нелгән чагы туры килгән; төнбоеклар арасындагы үрдәкләр — йөзеп бара. Димәк, рәссамның игътибар үзәгендә хәрәкәт тора.

Әдәби дискуссиядәге чыгышында В. Солоухин Һ. Һейненең бер шигырен ике рус

шагыйре тәрҗемә иткәнлеген әйтеп үтә. Аларның берсе — Ф. И. Тютчев, икенчесе — М. Ю. Лермонтов. Бер үк әйберне ике классик һәркайсы үзенчә язганлыктан, тәрҗемә әсәре ике төрле яңгыраш алган, һәм шуның нәтиҗәсендә укучы икесен ике төрле кабул иткән.

Безнең тәрҗемә практикасында бер үк әйберне төрле чорда төрле кешенең эшләгәне һәм хәттә әле бер китапны, өлешләргә бүлгәләп, берничә кешенең берьюлы башкарганы да булды. Язучының бер үк китапка кергән әсәрләрен төрле кеше тәрҗемә итүгә янарак мисаллар сыйфатында И. С. Тургенев һәм Ч. Айтматов китапларына күз салу урынлы булыр.

Рус әдәбияты классигы И. С. Тургенев повестьларын тәрҗемә иткәндә Фәния Гайнанова да, Вакыйф Зыятдинов та көчләрен кызганмыйча эшләп, шактый гына уңышка ирештеләр. Әмма авторның стилен икесе ике төрлерәк аңлау, һәркайсы үзенчәрәк кабул итү сәбәпле, аларның җитлеккән тәрҗемәче буларак үз йөзе, үз каләме булу сәбәпле, тәрҗемәләр берберсеннән аерылып тора.

Кыргыз халкының мәшһүр язучысы Чыңгыз Айтматов әсәрләрен татар укучысы үз ана телебездә укый. Тик бу авторны бездә моңарчы төрле язучы тәрҗемә итеп килде: Әмирхан Еники, Миркасыйм Усманов, Яхъя Халитов. Ә менә узган ел Ч. Айтматовның повестьлары бер тәрҗемәче кулы белән генә эшләнеп аерым китап булып чыкты. Ул Яхъя Халитов тәрҗемәләре иде.

Яхъя Халитовның тәрҗемәләренә гомумән оригиналга мөмкин кадәр турылыклы булу, авторның тасвирларын, бер дә читкә китмичә, шундагы лексика ярдәмендә чагылдыру хас. Миңа калса, ул кирәгеннән артык җитди эш итә: оригиналдагы ваграк җөмләләрне бергә кушу белән мавыкмый; чамасыз катлаулы, авырлары очраганда исә — аларны бүлгәләми, шул көе саклый; диалогларда автор сүзләрен, нәкъ оригиналдагыча итеп, персонаж сүзләре беткәч кенә терки; мәкаль һәм әйтемнәргә адекват бирми, калька ясый; полутоннардан гомумән качарга тырыша...

Әйтик, атның ял асты дымлы яки тирләгән диясе урынга ул авыз тутырып «юеш» ди (оригиналда: «влажно»); ялан кырда аның героена бераз шикле, хәвефле генә түгел, бәлки «куркыныч» була (оригиналда: «жутковато» һәм, ихтимал, күңелгә шик төшә, дип әйтергә кирәктер).

Калька ясау һәр вакыт матур нәтиҗә бирми:

«...а что кочевка на носу — тебе хоть бы что».

«... күчеп китәр вакыт борынга килеп төртелгән — ә синең исеңдә дә юк» (86 бит).

Чамасыз җитди булу исә еш кына интонацияне югалтуга китерә:

«А ты судишь обо всем раньше времени».

«Ә син бөтен нәрсә турында алдан ук нәтиҗә ясап куясың» (88 бит). Җайдар әйтә моны, Танабайның хатыны. Ләкин ул аңарга төс түгел.

«Да уж припомню как-нибудь крепко, не обрадуешься!»

«Ярар, җае чыккач шундый итеп исеңә төшерермен — үзең дә сөенеп бетә алмассың!» (91 бит).

Мин биредә, Яхъя Халитов ашыккан яисә аннан-моннан гына эшләгән, дип әйтергә һич җыенмыйм. Нык әзерлекле, зур тәҗрибәле бу тәрҗемәченең һәр җөмләне башыннан кичерүе, һәр сүзне бизмәнгә салып кабат-кабат үлчәве һич бәхәс тудырмый. Үзе эшләгән китапларда тәгәллеккә ул әнә шулай ирешә. Минем фәкать, ул лирик планда язылган әсәрләрне тәрҗемә итәргә алынып, бик үк дөрес эшләмидер, диясем килә. Үзенең иҗади йөзен булдырган оста тәрҗемәче, әлбәттә, повестьны әйбәт кенә татарча язып чыга алган. Китап яхшы укыла. Анысы шулай. Әмма тәрҗемәче әсәрне сизелер-сизелмәс кенә авырлаштыра, полутоннар кирәк урында саллы-катгый сүзләр куллана, йөгереклек таләп ителгән җирдә салмак җөмләләр белән эш итә.

«Он на голос чуткий, как нож под рукой...»

«Тавышка шундый сизгер ул — кулга тидереп караган үткен пәке йөзе кебек» (18 бит). Гөлсарының тай вакыты. «Тавышка сизгер» дип Яхъя дөрес әйтә. Әмма аның чагыштыруы уңайсызрак килеп чыккан. Карт көтүченең чагыштыруында сүз чәч пәкесенең үткенлеге турында бармый, бәлки пычакның кулга буйсынуы, кул кушканны үтәве турында бара (ул пычакның алай үк үткен булмавы да ихтимал).

Гөлсарыны ияргә өйрәтәләр, шабыр тиргә батыралар, ә эчәргә бирмиләр, бичаракай төн буе газапланып чыга. Иртән хуҗасы килә дә аның белән ягымлы итеп сөйләшә:

«Я, нәрсә, бик ачыктыңмы, ә? Эчәсең

киләме? Беләм...» (28 бит). Бу диалог Танабайның настроениесенә туры килеп җитмидер шикелле... Мал-туарны яратып, иркәләп сөйләшкәндә ул, һичшиксез: «Шулай булмыйни!..» — дип әйтердер сыман. Гәрчә оригиналда «Знаю...» булса да, бераз нечкәртебрәк бирергә иде.

Дөрес, әллә нигә бер генә Я. Халитов оригиналдан бераз читләшә дә төрле төшенчәләр арасына басма салып ташлый һәм шуның белән татарча табигый яңгыраш булдыра. Әйтик, бер урында интонацияне тулыландыру өчен үзеннән «валлаһи»ны өсти, һәм бу Танабайның халәтенә бигрәк тә тәңгәл килә.

Бер үк персонажның «запомни» дип әйткәнен ул үзе җитәр дип санаганда гападиди «онытма» белән чикләнә, ә инде картларча сөйләшүне укучы ныграк тоемерләсен өчен кирәк тапканда — «хәтереңә салып куй» дип «үзгәртә».

«Если бы тебя увидел сейчас Торгай, перевернулся бы в могиле...»

«Сине хәзер Тургай карт күрсә, гүрендә торып утырыр иде» (29 бит).

Мондый җөмләне һәркемнең җиңелгә санап, русчадагы сүзләрне тәрҗемә итүе ихтимал, ә Я. Халитов аны телдә йөргәнчә, матур итеп яза.

Гәрчә аның всадникны «атлы җайдак» дип әйтүе бераз сәеррәк тоелса да, чабанны «куйчы» дип, табунщикны «йолкынчы» дип алуы уңай тәэсир калдыра. Ат чабышы, Гөлсарының үзенә дан яулавы, Танабайга шөһрәт китерүе сокланырлык итеп тасвирланган.

Тәрҗемәче китапның оригиналга якын булуы һәм татарча яңгырашы, укылуы турында кайгырта, шушы максатка ирешү юлында көчен кызганмый.

Миңа калса, М. Шолохов, В. Лацис кебек художникларның җитди һәм күләмле, тәрҗемә өчен гаҗәеп авыр, саллы романнарын татар укучысына үз ана телебездә укырлык дәрәҗәгә китереп бүләк иткән Яхъя Халитов иҗади осталыкның яңаданяңа үрләрен яулап бара.

Безнең әдәбиятта тугандаш төрки телләрне яхшы гына белеп, шул халыкларның әдәбиятын татарчалаштыру үрнәкләре аз булмады. Бу өлкәдә олуг тәрҗемәчебез Сәрвәр Әдһәмова иң зур уңыш казанды дисәк тә, хата булмас: аның фидакарь хезмәте нәтиҗәсендә безнең укучыларыбыз казакъ язучысы М. Әүэзовның «Абай» дигән гүзәл романын үз ана телебездә уку бәхетенә иреште.

Ә узган ел үзбәк язучысы Әсгать Мохтарның «Чинар» романын Лерон Хәмидуллин оригиналдан эшләп чыгарды.

Тәрҗемәче һәр ике телнең нечкәлекләрен белеп, гаять зур сизгерлек белән эш иткән һәм шуның нәтиҗәсендә китап матур укыла. «Чинар»ны укыганда, Л. Хәмидуллинның лексиконы әдәби телебезгә мул өлеш кертә, баета, аңарга яңа синонимнар, бизәкләр өсти дигән фикергә киләсең.

Тәрҗемәче үзбәк халкының тормышкөнкүреш, милли колорит һәм геройларның настроениесен шактый оста бирүгә ирешкән. Персонаж телендә бу настроение үзен аеруча нык сиздерә: кем, нинди тавыш белән әйтә — ягымлымы аның тавышы, ясалма-ялагаймы, битарафмы, кырысмы, әллә инде бөтенләй янаулымы, гайрәтлеме — романдагы әнә шул оттенокларны Л. Хәмидуллин дөрес чагылдыра алган. Диалоглар аның тәрҗемәсендә лирик бизәкләргә өртелгән.

«— Балаларның мин танымаганнары да бар шикелле?—дип көлеп куйды Ачил баба.

— Вай, өч-дүрт елга бер килгәч булмыйни! — диде Өмидә. — Ешрак кил» (287 бит).

«— Онытмассыңмы минем гозеремне, энем?..

— Юк, юк, Ачил баба, борчылма, эшне бүген үк соратып алырмын...» (194 бит).

Диалоглар әнә шулай табигый агыла — Ачил бабаның ил кайгысын кайгыртуына, гуманистлыгына сокландыра һәм әсәрнең тәэсир көчен бермә-бер үстерә алар.

Мәгәр шунысы кызганыч, татарчага әйләндергәндә тәрҗемәчегә оригиналның йогынтысы чамадан тыш зур була, һәм ул безнең укучыга бик үк аңлашылып җитмәгән «җәдә», «бикәр», «чарчаган» кебек сүзләрне дә вакыт-вакыт үзбәкчә килеш калдыргалый.

Тәрҗемәдә «ул» һәм «бу»ның янәшә килгән чаклары да бар, шулай ук ара-тирә «син» белән «сез» бутала. Аннары тагын синонимнар сайлауда бик үк уңышлы булмаган урыннар очраштыргалый: «сазыга» мәгънәсен Лерон кайчак «уңайлана» яки «төзәлә» дип ала. Иң аянычы — парлы сүзләр тезмәсе. Алар ишләрәк булып киткән һәм китапны һич тә бизәми: «шпиль-манаралар», «ил-мәмләкәт», «костюм-смокинг» һ. б. Тик ул аерым сүзләр бу тәрҗемәнең гомуми тукымасына артык зур зыян китерә алмый. Андый сүзләр очраганда

бераз тукталып каласың да, яңадан онытылып, тәрҗемәнең йөгерек укылуына соклanып, күңеленә хуш килеп өлгергән геройлар дөньясына чумасың...

Рус әдәбияты тарихында гәрчә унлап телне әйбәт белгән һәм Дантеның «Илаһи комедия»сен турыдан-туры итальянчадан эшләгән тәрҗемә даһие М. Лозинский кебекләр күп булмаса да, берничәшәр телне үз ана телләредәй белгән һәм тәрҗемә эшенә күп хезмәт куйган кешеләр байтак очрый. Кызганычка каршы, безнең арада чит телләрне белеп, классик романнарны турыдан-туры оригиналдан тәрҗемә итәргә сәләтле кешеләр әлегә юк. Америка әдәбияты классигы Джек Лондонның хикәяләр җыентыгын рус теле аркылы тәрҗемә итеп чыгаруны әнә шуның белән аңлатырга кирәк. Китапны төзегәндә тәрҗемәче Фатих Хәсәнов язучының зур шөһрәт яулаган хикәяләре арасыннан да иң матурларын, Д. Лондон иҗаты өчен иң характерлыларын сайлап алган. Кереш сүзне дә тәрҗемәче үзе язган. Мәктәп балаларын бу җыентык, һичшиксез, сөендергән булырга тиеш.

Хикәяләр мавыктыргыч һәм җиңел укылалар. Тәрҗемәче халыкның сөйләм телендәге сүзләрне дә кыю гына куллана, гомумән җөмләне җыйнак һәм матур итеп төзи белә:

«Ул инде унөч кояш күргән. Төньякта ел исәбен шулай саныйлар, ник дисәң, һәр кыш саен кояш җирне караңгыда калдыра да үзе төшеп китә, ә икенче елны, кешеләр янә җылынып, бер-берсенең йөзенә карый алсыннар өчен, җир өстенә икенче кояш күтәрелә» («Киш турында хикәят»).

Җөмләләр бер-берсенә менә шулай матур гына бәйләнеп, җай гына агылганда, китапны бер тын белән укып чыгардай буласың.

«Ул көртлекне хәлдән тайдырды, әмма үзе дә тәмам алҗыды. Кошкай авыр сулап кырын ята иде. Юлчы да көртлектән унлап адым гына читтә, аның янына килеп җитә алмыйча, хәлсезләнеп егылды. Юлчы хәл җыйган арада кош та тернәкләнеп өлгерде. Һәм ул комсызланып кулын сузуга, көртлек пырылдап очып китте» («Яшәү теләге»).

Тәрҗемәченең лексиконы бай, хикәяләү манерасы җылы кабул ителә. Мондый җиңел текстны укыганда вакыйганың ничек очлануы, кешенең коточкыч бәладән ни рәвешле котылуы аеруча нык кызыксындыра. «Сакраменто буенда», «Мексикан» һәм күп кенә башка хикәяләр дә укучыда зур кызыксыну, романтика хисе уяталар. Китапның башыннан алып ахырынача кыю һәм тәвәккәл, дөнья гизгән авторны шәйлисең, аның халәтендә яшисең.

Тик ара-тирә бик үк урынлы кулланылмаган сүзләр, бер-берсенә бик үк бәйләнеп җитмәгән җөмләләр очравы гына бераз күңелне рәнҗетә. Гүя син Аляскада берәр исемсез инеш буйлап барган чакны, романтикага бирелеп, хыял диңгезендә йөзгән чакны, кинәт кенә түмгәккә абынып егыласың да аптырап каласың...

«— ...Ул елларны гел шушында эшләп үткәрдеме?

— Тәнәфесләре булгалады булуын» («Качак» хикәясе). «Тәнәфес» сүзе болай үзе начар сүз дә түгел, мәктәп балаларына бик таныш та, әмма ул бүгенге көндә фәкать билгеле бер функцияне үти. Бу урында: китеп тә йөргәләде, дип читләтебрәк әйтергә кирәк булгандыр.

Яки менә «украдкой ложился на нарты» дигәнне «урлап кына чанага ята икән» («Каһарманлык» хикәясе) дип бирү текстның табигый агылышына зыян китерә, аны авырлаштыра.

Әллә тәрҗемәче артык ашыккан, әллә автор сурәтләгән табигатькә биһуш булып, персонажларының батырлыгына сихерләнеп, кирәкле сүзләрне хәтеренә төшерә алмаган — әйтүе кыен, әмма, ул, аерым очракларда, үзенең көчен-сәләтен тулысынча эшкә җикмәгән. Тәрҗемәнең тигез эшләнмәве сәбәпле кайбер хикәяләрнең эмоциональ тәэсире билгеле дәрәҗәдә кими төшкән.

Фатих Хәсәнов, маҗаралы әдәбиятның тәмен белүче һәм хыял дөньясында йөзәргә яратучы кеше буларак, Джек Лондон иҗатын өйрәнүен дәвам итеп, киләчәктә укучыларыбызга фантастика жанры короленең тагы да күләмлерәк китабын бүләк итәр дип ышанырга кала.

Күреп үткәнебезчә, тәрҗемә өлкәсендә уңышларыбыз шактый, әмма киләчәктә җитди уйлануны таләп иткән мәсьәләләр дә аз түгел. Шуларның берсе — чит телләрне яхшы белгән тәрҗемәчеләр тәрбияләү. Әдәбиятка аяк басучы өметле яшьләр бер-ике чит телне белеп, тәрҗемә сәнгатенә өйрәнәләр икән, алар алдында иксез-чиксез мәйдан ачылачак. Тәрҗемә өлкәсендә киләчәктә әнә шундый яшь буын бәйге тотачак.

# ЛАЧЫН КЫЗЛАР

Профсоюзларның XVI съездында сөйләгән речендә Л. И. Брежнев болай дигән иде: «Юбилей елы— һәр вакыт истәлекләр елы, йомгак ясау елы. Ләкин без, коммунистлар, эшләнгән эшләрнең масштаблылыгын, тарихи әһәмиятен законлы горурлану белән билгеләп үтү өчен генә артка борылып карамыйбыз. Без үткәндәгеләрне гаять бай тәҗрибә резервуары итеп, уйлану материалы итеп, үз карарларыбызга һәм хәрәкәтләребезгә тәнкыйть күзлегеннән анализ ясау материалы итеп кабул итәбез. Без үткәндәгедән бүгенге һәм киләчәк эшләр өчен рухлану алабыз».

Әдәбият дөньясына да турыдан-туры карый торган сүзләр бу. Октябрьның 60 еллыгын билгеләп үткәндә, һәр язучы үз иҗатында мәгълүм бер ызан тоя. Ул чикнең бирге ягында — бүгенгәчә башкарылган эшләр, укучыга ирешкән китаплар, аргы ягында — гомер булса, язасы әсәрләр, иҗади планнар...

Прозаик Шамил Рәкыйпов юбилейны зур хезмәтен тәмамлап каршылады, «Кызлар-йолдызлар» повестеның икенче китабын — «Кипарислар җыры»н бастырып чыгарды.[1] Әсәр халкыбызның Бөек Ватан сугышы елларында күрсәткән тиңдәшсез батырлыгын тасвирлауга багышланган. Совет кешеләренең каһарманлык үрнәкләрен автор бу очракта хатын-кызлардан гына торган төнге бомбардировка авиаполкы сугышчылары мисалында күрсәтә.

Октябрь һәм Бөек Ватан сугышы — болар үзара аерылгысыз бәйләнештә торалар. Кешелек тарихында күрелмәгән дәһшәтле сугышта совет халкы социалистик революция казанышларын саклап калды, планетаны фашизм үләтеннән коткарды, дөнья картасында яңа социалистик дәүләтләр барлыкка килүгә юл ачты, милли-азатлык хәрәкәтенең яңа көч белән күтәрелеп китүенә зур йогынты ясады.

Шамил Рәкыйповның ике китаптан торган күләмле повесте геройлары — Октябрь, бөек партиябез, Ленин комсомолы, совет мәктәбе үстергән бөркетләр, ил бәйсезлеген яклап ут өермәсен кичкән батырлар, бүгенге якты һәм мул тормышыбызны тәэмин иткән фидакарьләр. Алар төрле милләт вәкилләре. Кунак каршыларга җыенгән кызларның бик гадәти бер әңгәмәсенә генә колак салыйк.

«— Ит булса, мин бисбармак пешерер идем, — диде Хиваз.

— Мин — пылау...

— Мин — чихохбили...

— Ә мин — галушки...

Кызлар тагын әллә ничаклы милли ашларның исемнәрен телгә алдылар, авыздан сулар килде. Җиңнәрне сызганып, ак алъяпкыч тагып, плитә тирәсендә маташкан тыныч өй тормышын искә төшердек».

Дүртенче һава армиясендә беренчеләрдән булып гвардияче исемен яулаган бу полкның тугыз очучысы — Вера Беликка, Евгения Жигуленкога, Руфина Гашевага, Татьяна Макаровага, Наталья Меклинга, Анастасия Поповага, Екатерина Рябовага, Ирина Себровага һәм Ольга Санфировага берьюлы Советлар Союзы Герое исеме бирелә. Бу исә үзе генә дә төрле милләт кызларының монолит бер көч булып, фашист өерен аяусыз дөмбәсләве турында сөйләүче факт булып тора. Бу полк очучысы Евгения Руднева һәм повестьны хикәяләп баручы Мәгубә Сыртланованың да Советлар Союзы Герое икәнлекләрен әйтергә кирәк. Полкташлардан барлыгы 23 кеше шушы мактаулы исемгә лаек була!

Язучының игътибар үзәгендә башлыча ике образ тора. Алар — татар кызлары — Ольга Санфирова һәм хикәяләүче Мәгубә Сыртланова. Ольга (полкташлары аны Ляля, Ләйлә дип йөртәләр) сугышчан өлкән дустының сөйләве аша ачылса, Мәгубә үзенең полкташларына булган мөнәсәбәте аша күз алдына баса. Баш персонажларның һәр

[1] Кипарислар җыры. Татарстан китап нәшрияты, Казан, 1976.

икесе — катлаулы характер, үзенчәлекле холык өяләре. Автор аларны күпкырлы психология кешеләре буларак сурәтли, җанлы кешеләр итеп күз алдына бастыра. Һәр образ бихисап вакыйга һәм күренешләр һәм кичерешләр ярдәмендә тудырыла.

Гомумән, Шамил Рәкыйпов үз геройларын белеп, яратып яза. Алар йөзендә ул совет кешесенә хас югары мораль сыйфатларны, гуманлыкны, интернационализм хисләрен чагылдырырга омтыла. Шул ук вакытта язучы совет кешеләренең фашизмга чиксез нәфрәтен дә куе буяулар белән сурәтли, повестьта батырлык темасы алгы планга калкып чыга. Полкташлар бу хакта нык уйланалар, фикер алышалар, бәхәсләшәләр, илбасарларга каршы аяусыз сугышта уй-фикерләрен практик төстә гамәлгә ашыралар.

«... Хикмәт батырлыкны ничек аңлауда, аңа ничек хәзерләнүдә,— ди комиссар Рачкевич. — Ягъни үз эшеңә, хәрби бурычыңа мөнәсәбәтеңдә. Санфирова бу мәсьәләне бөтен нечкәлекләре белән аңлый... Кешенең үз бурычларына булган мөнәсәбәте иң киеренке, иң куркыныч моментларда сынала. Мондый чакта ул, иң кадерле нәрсәсен — тормышын куркыныч астына куеп, тәвәккәллеккә бара, туган иле, сугышчан иптәшләре өчен йөрәген, Данко сыман, факел итеп кабыза — үлемсезлеккә атлый...»

Ольганың бөтен тормышы һәм сугышчан юлы — шушы сүзләрне тулысынча аклаган матур бер җыр. Ольга Санфирова һәм аның полкташлары образлары белән язучы төпле, нигезле тагын бер күркәм фикерне раслый: сугыш күпме генә үлем һәм җимереклек китермәсен, күпме генә кан һәм күз яше, толлык һәм ятимлеккә сәбәпче булмасын, кеше булган кешеләрдә, социалистик чынбарлык тәрбияләгән затларда асыл сыйфатлар җуелмый. Сугышчылар саф, нәзакәтле, принципиаль, ярдәмчел һәм тугрылыклы булып калалар. Бу җәһәттән Ләйләнең фикерләрен автор бер ноктага туплап бирә алган: «Комиссар Рачкевич әйткәнчә, азрак баш-күз генә алыйк, матурлык, зәвык турында авыз тутырып сөйләшә башларбыз әле. Затлы, гүзәл халык ич без. Фашистны дөмбәсләп йөреп тупасланырга, күркәмлекне җуярга һич ярамый. Җаныбыз да, тәнебез дә пакь булсын, матур булсын! Утлы давыллар аша узып та таушалмаганнар, сау-сәламәт калганнар дисеннәр».

Шул ук уңайдан Мәгубә Сыртланованың үз сүзләрен дә искә алып узу кызыклы булыр. «... Каһәр төшкән сугыш күпне күрсәтсә дә, без һаман нечкә күңелле хатын-кыз икәнбез әле. Мөгаен, бу — яхшыдыр. Кызгану хисеннән мәхрүм ителгән кешене камил акыллы дип әйтеп булмый», кебек уйлануларга бирелә ул. Лачын кызларның кер чайкау күренешләре, Женя Рудневаның Керчьне бомбага тотар алдыннан Пушкинның Кырымда булуы турында мавыгып сөйләгән сүзләре, Яңа елны каршылау күренешләре — болар бары да җирдә хатын-кыз гүзәллеген корытырлык кара көч юк икәнлеге турында сөйли булса кирәк.

Дошманга каршы нәфрәтнең һәр очучы күңелендә иң изге төшенчәләргә бәйле рәвештә формалашуын автор зур осталык белән күрсәтә алган. Монда оныгы язмышы, аның фаҗигасе өчен үч алырга омтылучы Марфа әбине генә алыйк. Ул әсәрдә гомумиләштерелгән символик образ дәрәҗәсенә күтәрелгән.

«Кызлар-йолдызлар» һәм «Кипарислар җыры» китапларында тагын бер бик мөһим фикер ярылып ята. Бигрәк тә ул әсәрнең соңгы өлешендә ачык тоемлана: бөтен немец та фашист түгел. Бу фикергә язучы безнең экипаж немец җирендә һәлакәткә очраган эпизодта басым ясый.

«... Штурман үз командирына карый алмый, яшьле күзләрен зәңгәр күккә төбәгән. Анда ап-ак бөдрә болытлар йөзә. Читтелдә сөйләшүчеләр өч-дүрт адымда гына инде. Әгәр...

— Ат!..

— Барлык немецлар да фашист түгелләр ич инде!

Пистолет атылмыйча кала. Һәм штурман хаклы булып чыга: немецлар очучы кызларны үзебезнекеләргә илтеп тапшыралар».

Арысландай сугышып, җиңү яулаган кызларның сугыш беткәннән соңгы көннәрен, исән калганнарның бүгенге тормышын хикәяләп автор дөрес эшләгән. Әйтик, без Клава Серебрякованың ике елдан артык госпитальләрдә ятуын, унбишкә якын операция кичерүен, ниһаять, югары уку йортында белем алып, укытучы булуын беләбез. Хиваз Доспанова да педагог икән. Ун биш орден һәм медальләр кавалеры, сугыштан соң озак вакыт комсомолның Казагыстан Үзәк Комитеты секретаре булып эшли. Полк комсоргы Саша Хорошилова Архангельская фәннәр докторы, галим...

Кыскасы, повесть — олы язмышлар турындагы әсәр. Ш. Рәкыйпов моңа кадәр

дә документаль прозаның матур үрнәкләрен биргән иде инде. «Чәчәкләр сөйли беләләр»дә ул татар халкының батыр улы Александр Матросов һәм Газинур Гафиятуллин үлемсезлеген кабатлаган Бари Шәвәлиев образын тудырды, «Кайдан син, Жан?» повестенда Советлар Союзы Герое Иван Константинович Кабушкинның гүзәл тормышы хакында сөйләде, «Таңнар һаман матурмы?» дигән әсәрдә татарлардан беренче Советлар Союзы Герое Гыйльфан Батыршин һәм аның дусты — Советлар Союзы Герое Иван Чернопятко узган сугышчан юлны тасвир кылды. «Кызлар-йолдызлар» повестенда исә язучы документаль проза жанры мөмкинлекләрен тагы да киңәйтеп җибәрә алган. Документальлек һәм язучы фантазиясе аерылгысыз булып үрелгәнгә күрә, әсәр, реаль чынбарлыкның бирелешенә һичбер зыян салмаган хәлдә, сәнгать таләпләренә тулы җавап бирерлек булып җитлеккән. Шуның нәтиҗәсе буларак, повесть психологик тирәнлеккә ия, сюжет җыйнак һәм мавыктыргыч. Бу хәл автор теленә һәм персонажлар сөйләменә дә тәэсир итми калмаган. Бәян итү ысулын сайлаганда, Шамил Рәкыйпов гарәп әкиятләре — «Мең дә бер кичә»дәге алымны кулланган. Бу хакта китапның керешендә ачык әйтелә. Без, укучылар, бу алымны баштан ук кабул итәбез һәм каһарман очучы ханым хикәятләрен ышанып тыңлыйукый башлыйбыз.

«Сүзем юк, — ди Мәгубә Сыртланова, — чибәр Шәһрезадә телгә оста. Тик йомшак паласта аяк бөкләп әкият сөйләп утыру әллә ни шаккатыргыч эш түгел ул. Менә безнең полк сылулары мең дә бер йөз төн очып, үзләре кебек кызларны гына түгел, бөтен кешелекне фашизм коллыгыннан йолып калдылар».

Повестьның төп әйтер сүзе, каймагы шунда булса кирәк. Шул сүзләр, шул фикер художник каләме белән расланганга күрә дә, әсәр, һичшиксез, уңай бәягә лаек.

**БАРЛАС КАМАЛОВ.**

# ӘДӘБИЯТЛАРЫБЫЗ ДУСЛЫГЫ

Милли әдәбиятлар багланышы халыкларыбыз арасында дуслык мөнәсәбәтләрен ныгыта. Бу юлда шактый хезмәтләр басылып чыкты инде. Соңгы елларда төрки телле кардәш халыклар арасындагы әдәби мөнәсәбәтләр дә өйрәнелә башлады. Шундый хезмәтләрнең берсе сыйфатында филология фәннәре кандидаты Бөркет Исхаков чыгарган «Казакъ-татар әдәби мөнәсәбәтләре» исемле китапны күрсәтергә мөмкин [1].

Бу хезмәттә казакъ-татар әдәби мөнәсәбәтләренең тарихы шактый борынгыдан башлап, әтрафлы итеп тикшерелә. Китап бай мәгълүматка нигезләнгән кереш белән йомгактан һәм зур күләмле дүрт бүлектән гыйбарәт.

«Нигез — туганлык» дип аталган беренче бүлектә автор татар һәм казакъларның борынгы чордан ук дус, уртак язмышлы күршеләр һәм, иң мөһиме, якын кардәш халыклар булуын сурәтли. Шушы тирән тамырлы, үзара үрелеп үскән әдәби һәм мәдәни мөнәсәбәтләр нәтиҗәсендә бу ике халыкның рухи яктан бер-берсен аңлап яшәгән булулары ышандырырлык итеп тасвирлана.

Урта гасырларда, төгәлрәк әйткәндә, казакъларда Нугайлы дәвере дип аталган Алтын Урда чорында, һәр ике халык та бер дәүләт составында яши. Шушы конкрет шартларда формалашкан бу ике халыкның рухи дөньялары бер җирлектә, уртак тамырдан туенган куш ботак кебек бергә үсә. Менә шуңа күрә аларның халык иҗатлары күп очракта игезәк кебек охшаш. Орхон-Енисей чоры төрки язмалар, Мәхмүд Кашгарый сүзлегендә теркәлгән фольклор әсәрләре, «Кодекус Куманикус» кебек кыйммәтле истәлекләр, Кадыйргали бәкнең «Җәмигъ әт-тәварих» китабы, ниһаять, Корбангали Халидинең «Тәварихы Хәмсәи Шәркыя» исемле хезмәте һәм тагын башка бик күп истәлекләр безнең ике халык өчен дә уртак мирас булып исәпләнә. Шушы көннәргә кадәр телдә яшәп килгән, һәр ике халык өчен дә аңлаешлы булган мәкаль-әйтемнәр, чәчән сүзләр, әкият һәм риваятьләр, җыр-такмак һәм табышмаклар бу кардәшлекне, бу тарихи уртаклыкны тулысынча раслый.

Элек күчмә тормышта яшәгән казакълар үзләреннән күпкә алда утрак тормышка күчеп шәһәрләр салган, борынгылыкта ук бай рухи мәдәният һәм әдәбият тудырган татарлар белән тыгыз мөнәсәбәттә то-

[1] Б. Ысқақов. Қазақъ-татар әдәби байланысы (қазақъ телендә). Алма-Ата. 1976.

рып, алар тудырган байлыктан да киң файдалана. Автор боларны тарихи дөрес фактлар ярдәмендә тулы яктырта.

Шул рәвешчә, халыкларыбыз арасындагы дуслыкның тирән тамырлы булуы хакында бөек шагыйрь Габдулла Тукай әйткән сүзләр тагы бер кат гыйльми нигездә раслана.

«Яңадан кавышу» исемле икенче бүлекнең үзәгенә Россиядә промышленность үсеп, сәүдә эшләре киң канат җәю нәтиҗәсендә, төгәлрәк әйткәндә, XIX йөз дәвамында, казакъ-татар иҗтимагый мөнәсәбәтләренең тагы да җанлана төшү мәсьәләләре куела. Күп санлы казакъ яшьләренең «Галия» мәдрәсәсендә һәм башка татар уку йортларында тәрбияләнүе, шулай ук Казан нәшриятларында басылып чыккан татарча һәм казакъча китапларның сахра халкы арасында киң таралуы казакъ дөньясында да китап укучыларның саны ишәюгә китерә. Бу мөнәсәбәт белән автор ике халык өчен дә электән үк уртак булган, яки соңгы дәвердә китап ярдәмендә уртаклашып киткән дастаннар, тарихи җырлар хакында төрле-төрле мәгълүматларны тикшерә.

Автор шагыйрь Акмулла, күренекле мәгърифәтчеләрдән Шиһабетдин Мәрҗани, Каюм Насыйриларның казакъ зыялылары арасында да зур абруйга ия булуларын бәхәссез фактлар ярдәмендә күрсәтә. Шулай ук казакъ мәгърифәтчесе И. Алтынсарин, шагыйрьләрдән А. Кунанбаев, Акансире, М. Сиралин һәм башкаларның дөньяга карашлары формалашуда татар демократик иҗтимагый фикеренең зур әһәмияткә ия булуын да галим дөрес күрсәтә.

Халыкларыбыз арасындагы мәдәни мөнәсәбәтләрнең шундый бай традицияле булуы яңа дәвер багланышларының тагы да көчлерәк, тагы да нәтиҗәлерәк булуына китерә. Мөнәсәбәтләр күп кырлы һәм эчтәлеклерәк булуга таба йөз тота. Шуңарга мисал итеп яңа дәвер татар әдипләреннән Галимҗан Ибраһимов, Фәтхи Бурнашларның үз әсәрләрендә казакъ тормышына мөрәҗәгать итүләрен күрсәтеп узарга мөмкин. Икенче яктан, бу фактлар татар язучыларының иҗтимагый җәһәттә активлаша башлаган якын кардәшләренә, ягъни казакъларга, теләктәш булуын, алар тормышы белән якыннан кызыксынуын исбатлый.

Соңгы елларда гына да Ә. Айдарның «Ташбай» романы, Г. Әпсәләмовның «Казакъ егете» очеркы, И. Сәләховның «Күкчәтау» романы һәм тагы башка бик күп шигырьләр, җырлар, хикәяләр дөнья күрде. Болар бары да хәзерге татар әдипләренең кунакчыл казакъ сахралары, кардәш казакъ халкы белән кызыксынуы үскәннән-үсә баруын күрсәтеп торалар.

Монографиянең «Уртак аваз, охшаш сыйфат» исемле өченче бүлеге тарихи мәгълүматларга аерата бай. Анда XX гасыр башы татар-казакъ мөнәсәбәтләренең элгәрге чорларга караганда киңрәк колач җәеп, тагы да тирәнрәк тамыр җибәрүе сурәтләнә. Гасыр башында ачылган яңа татар нәшриятларында казакъ халкы тарихына, әдәбиятына, теленә караган күп санлы китаплар, гыйльми хезмәтләр басыла.

Үзенең формалашу чорын кичергән яңа казакъ әдәбиятына, аның идея-эстетик осталык һәм форма җәһәтләреннән дә камилләшә баруына рус әдәбияты белән бергә татар әдәбияты да гаять көчле тәэсир ясый. Кайбер казакъ язучылары турыдан-туры татар әдипләреннән өйрәнеп иҗат итәләр. Шул рәвешчә дөньяга чыккан роман һәм повестьлардан Т. Җомартбаевның «Кыз күрү», Б. Иржановның «Уку мәктәбе», С. Күбәевнең «Калым малы», М. Кашимовның «Моңлы Мәрьям», С. Турайгыровның «Камәр сылу» исемле әсәрләрен казакъ прозасының беренче карлыгачлары дип әйтергә мөмкин.

Бу дәвер казакъ укымышлылары татар телен, татар әдәбиятын бик әйбәт белгәннәр. Моның шулай икәнлеген күренекле казакъ әдипләреннән М. Сиралин, Б. Майлин, Җ. Сыздыков, М. Дәүләтбаев, С. Машаков һәм башкаларның бик күп татарча шигырь һәм хикәяләрне казакъчага турыдан-туры тәрҗемә итүләреннән күрергә мөмкин. Үзләре дә оригинал әсәрләрен иҗат итүдә татар әдәбияты тәҗрибәсенә таяналар.

Яңа дәвер казакъ-татар әдәби мөнәсәбәтләре хакында сөйләгән чакта, Дәрдмәнд һәм Шәехзада Бабич иҗатларына махсус тукталу зарури икән. Чөнки татар әдәбиятында эз калдырган Дәрдмәнд һәм Бабич иҗатларында казакъ теленең, казакъ фольклорының тәэсире нык сизелә — казакъча канатлы гыйбарәләр, образлы сүзләр аларның шигырьләрендә органик рәвештә үрелеп бирелә. Шулай ук күренекле казакъ шагыйрьләреннән Солтанмәхмүт Турайгыров һәм Сабит Дунәнтаев әсәрләрендә дә татар теле тәэсире ярылып ята.

«Бер сафта, бер максатка» дип аталган

дүртенче бүлектә автор социалистик чордагы әдәби бәйләнешләр хакында яза. Бөек Октябрь революциясеннән соң ирешелгән казанышлар һәм ленинчыл Коммунистлар партиясе әдәбиятларыбызга яңа юл күрсәтеп, алар алдына яңа бурычлар куйды. Тугандаш халыкларның социалистик әдәбиятларын тудыручы язучыларыбыз яңа чынбарлыкны ныгытуга хезмәт итә торган, беренче бишьеллыкларның бөек төзелешендә олы җиңүләргә чакыра торган югары рухлы әдәби әсәрләр иҗат иттеләр. Тормыш максатлары уртак, илһам чишмәләре бер булган кебек әдәби әсәрләрдә дә уртак сыйфатлар, рухи авыздашлык барлыкка килде. Шуңа күрә казакъ шагыйрьләреннән С. Сәйфуллин, И. Җансөгеров, А. Тукмагамбәтов, Т. Җароковлар язган җырлар белән татар шагыйрьләре Мәҗит Гафури, Һади Такташ, Фәтхи Бурнаш иҗат иткән әсәрләр арасында рухи уртаклык бик зур.

Яшь совет әдәбиятына Максим Горький ни дәрәҗәдә бәрәкәтле юлбашчылык иткән булса, казакъ һәм кыргыз, үзбәк һәм төрекмән әдәбиятларына да Галимҗан Ибраһимов шундый ук дәрәҗәдә рухи җитәкче, танылган остаз иде. Аның аерым әсәрләре дә, хәтта бөтен иҗаты да безнең әдәбиятларыбыз өчен бәхәссез үрнәк булып хезмәт итте. Әдипнең «Казакъ кызы», «Тирән тамырлар», «Безнең көннәр» һәм башка зур әсәрләре, «Алмачуар» кебек хикәяләре казакъ теленә тәрҗемә ителеп, кат-кат басылып чыктылар. Аларны казакъ укучылары җылы кабул итте, әле дә яратып, үз ана телендә иҗат ителгән әсәрләрдәй якын итеп укый. Г. Ибраһимовның якты истәлеге һаман казакъ укучыларының күңел түрендә саклана.

Тарихи олы дуслыкның гүзәл бер сыйфаты туган илне яклау өчен барган сугышларда аеруча ачылды. Татар шагыйре Муса Җәлилнең дошманның үз өнендә аңа каршы көрәш оештыруы, бу юлда соңгы сулышка кадәр үз Ватанына, олы гаделлеккә турылыклы булып калуы һәммәбезгә мәгълүм. Җәлил җитәкчелек иткән оешмада бер төркем казагыстанлылар да актив катнаша. Мисалга Г. Курмашев, А. Аднашев, Р. Хисаметдинов, Ф. Сәйфелмелековларны күрсәтергә мөмкин. Җәлилнең Ватанны олылап, азат тормышны мактап, ирeклеккә өндәп язылган көр рухлы җырлары аның иптәшләрен көрәшкә дәртләндерде, соңгы минутка кадәр туган илләренә тугрылык сакларга ярдәм итте. Әмма Б. Исхаков бу мәгълүматларны факт сыйфатында гына китерми, бәлки фронт тылында яшәп тә, дәртле җырлары белән ил улларын көрәшкә чакыручы аксакал акын Җамбул җырларында да, утлы көрәш мәйданында сүз кылычын айкаган Җәлил шигырьләрендә дә уртак сыйфатны — бер максатка хезмәт итү сыйфатын күрә, шуны укучыларга да җиткерергә тырыша. Күрәсең, менә шушы сыйфат Җәлил язган «Алтынчәч» либреттосының казакъ укучылары каршында киң популярлык казануын тәэмин иткәндер. 1953 елны ук казакъчага тәрҗемә ителгән «Моабит дәфтәре» дә казакъ укучылары тарафыннан үз итеп кабул кылындылар.

Яңа дәвер шагыйрьләреннән Абай Кунанбаев һәм Габдулла Тукай, язучылардан Галимҗан Ибраһимов һәм Баембәт Майлиннар башлап җибәргән әдәби дуслык традицияләре сугыштан соңгы елларда тагы да көчәеп, куәтләнеп китте. Әдәби очрашулар истәлекле бәйрәмгә, дуслык бәйрәмендәге чын тантанага әверелде. Язучылар, әдипләр арасындагы шәхси мөнәсәбәтләр дә үскәннән-үсә бара, дәвам итә.

Абай хакындагы романны татар укучылары җылы каршылаган кебек, Тукай турындагы романны да казакъ китап сөючеләре үз ана телендә укып ләззәтләнәләр.

Татар җыры, татар көе, татар музыкасы киң казакъ җәмәгатьчелеге өчен дә таныш. «Татар хикәяләре», «Татар әкиятләре», «Татар җырлары» кебек җыентыклар Казагыстанда әледән-әле басыла һәм халык арасында тарала тора. Бүгенге казакъ язучылары, казакъ шагыйрьләренең әсәрләре дә татар укучыларына үз ана телләрендә тәкъдим ителә. Кыскасы, тирән тамырлы, бай тарихлы әдәби мөнәсәбәтләребез тагы да төрләнә, тагы да баеый бара.

Җыеп әйткәндә, Бөркет Исхаковның «Казакъ-татар әдәби мөнәсәбәтләре» дип аталган яңа хезмәте ике кардәш халык арасындагы тарихи дуслык һәм туганлыкны тирән итеп, әтрафлы итеп бәян кыла, бу бай тарихның төп дәверләрен дөрес билгеләп, фактларны мул китерә. Шуңа күрә аны Бөек Октябрь революциясенең 60 еллык бәйрәме мөнәсәбәте белән китап сөючe киң җәмәгатьчелегебезгә тәкъдим ителгән файдалы хезмәт, матур бүләк дип бәяләргә мөмкин.

**Елубәк БАЙТУКОВ,**
**М. Әуэзов исемендәге әдәбият һәм сәнгать институты гыйльми хезмәткәре.**

# СУЛХАН-САБА ОРБЕЛИАНИ

*1658—1725*

*Грузин язучысы һәм политик эшлекле. Судья семьясында туа Иран баскыннарына каршы сугышларда катнаша. Бернчә ел монах соңыннан, Вахтанг VI патшалык иткән елларда, культура эшләр башлыгы була. Грузиягә ярдәм сорап, Европага яшерен диплома булып бара. 1724 елда Вахтанг белән бергә Россиягә күчеп килә һәм Мәскәүдә үлә. Грузин теленең аңлатмалы сүзлеген төзи, «Калила һәм Димна» исемле мәсәлләр җыентыгының грузинчага тәрҗемәсе эшкәртә. «Ялганның акыллылыгы яки уйдырманың дөреслеге» кита бында феодаль җәмгыятьнең әхлакый кимчелекләрен фаш итә, тиран патшаларны гаепли, ялагайлары булган ахмак судьялардан, әләкче ләрдән, динчеләрдән көлә.*

## Саран ярлы

Бер нәрсәсе дә булмаган бер ярлы кеше яшәгән дөньяда Төннәрнең берендә ул төш күрә икән: имеш, аның алтмыш сарыгы бар һәм ул базарда шуларны сатарга тели. Кемде берәү килә дә аңа һәр сарык өчен бишәр кирменнули[1] түлим ди әйтә. Хуҗа исә алтышарны сорый. Шулай сатулашкан арада тег ярлы уяна да бик үкенеп уйлана башлый. Аннары ул күзен яңадан йома һәм сәүдәгәргә кул суза:

— Икешәр кирменнули бир — һәм минем сарыклар синеке булачак

...Әмма аңа кем көмеш бирсен икән дә һәм ул кемгә нәрсә сата ал ди? Тик төштә генә күргәннәр барысы да буш нәрсә бит...

## Иләк белән эшләүче кеше

Бер кеше елга ярында утыра. Кулына иләк тоткан. Иләкн суга батыра да, ул тулгач, үзалдына үзе кычкырып сөйлән икән:

— Әгәр ходай кемгә дә булса бирим дисә, менә шулай бирә ул.

Иләкне өскә күтәргәч һәм аннан су агып беткәч исә бүтәнне ка батлый:

— Кемнән дә булса тартып алыйм дисә, менә шулай ала ул.

[1] Көмеш вак акча.

Бик күп явызлыклар эшләгән, шул ук вакытта җаны-тәне белән динче булган бер кеше яшәгән дөньяда. Урлашып һәм алдашып йөрүдән буш арада ул бертуктаусыз гыйбадәт кыла һәм елый икән. Шуның каршына бер фәрештә килеп баса да әйтә бер чакны:

— Ходай тәгалә сине җәннәткә явызлыгың өчен кертмәде, әмма син шундый көчле динчесең бит — тәңре сиңа моның өчен, җәннәттән кала, үзең сораган теләсә нәрсәне бирә алачак.

Шунда әйтә икән теге кеше.

— Әгәр мин җәннәттә булырга тиеш түгелмен һәм әгәр сезгә минем теләсә нинди үтенечемне канәгатьләндерергә мөмкин икән, ходай тәгалә мине җәннәткә миннән башка беркем дә сыя алмаслык пәһлеван итсен икән!

Ходай тәгалә моны эшли алмый һәм бу кешене җәннәткә юллый.

## Карт кеше һәм аның оныгы

Тешләре төшеп беткән бер карт һәм аның оныгы бергә ашап утыралар икән. Кинәт алар икесе берьюлы елый башлый. Кемдер килә дә сорый карттан:

— Ник елыйсың?

Карт әйтә:

— Тешләрем юк минем, ризык чәйни алмыйм. Менә бу бала ни барын ашап бетерде, ә мин ач калдым.

— Ә син ник елыйсың?

— Мин чәйнәгән арада ул ризык кисәкләрен рәттән йота барды һәм мин ач калдым.

Аларның кайсы хаклы икәнен, әлбәттә, һәркем белә, әмма гаепне алар берсенә-берсе әнә шулай тагалар.

## Иң татлысы һәм иң ачысы

Ниндидер бер патша үз вәзирләренә әмер бирә:

— Бар, син миңа шундый ризык табып китер — аннан да татлы нәрсә җирдә дә һәм диңгез төбендә дә була алмасын.

Вәзир китә дә тел сатып ала, кайта да шуны кыздырып бирә. Патшага бик ошый азык.

Ә икенче юлы исә патша бүтәнне боера:

— Бар, син миңа шундый ачы ризык табып китер — аннан да ачырак нәрсә дөньяда була алмасын.

Вәзир тагын китә дә тагын тел ала һәм патшаны шуның белән сыйлый.

Патша әйтә:

— Мин татлыны сорадым — син миңа тел куйдың, мин ачыны бирдем — син шул ук телне китердең.

Вәзир әйтә:

— Синең башың белән антлар итеп әйтәмен ки, чөнки җир йөзендә телдән дә татлы һәм телдән дә ачы бернәрсә дә юк бит.

Эт белән этәч дуслаша.

— Әйдә, бер авыл салыйк әле бергәләп!

Эт әйтә икән этәчкә:

— Без аны ничек салырбыз соң?

Әтәч әйтә:

— Син өреп торасың, ә мин кикрикүк дип кычкырам — менә шулай салына инде ул авыл.

Алар икәүләп урманга китәләр. Эт өреп тора-тора да йокыга китә. Әтәч агач башына менеп ала да кычкырыпмы-кычкыра икән. Шуны төлке ишетә һәм сорый әтәчтән:

— Нишлисең анда син?

— Авыл салабыз.

— Бирегә тиз генә төш тә шул авылда минем йортым өчен дә мәйдан бүлеп бир әле син.

Әтәч әйтә:

— Әнә тегендә башлык ята, шуны уят син һәм ул сиңа мәйдан үлчәп бирер.

Әтәч ите авыз итәсе килүдән башы әйләнеп фикере чуалган төлке эт янына килә. Эт исә сикереп тора да төлкене ботарламак була, койрыгы өзелгән, яраланып беткән төлке көчкә качып котыла һәм, бер үргә менеп җиткәч, артына борылып кычкыра икән:

— Мин, әлбәттә, үз юләрлегем аркасында бәлага тардым. Ә менә сез бары тик шулай эшләп авыл сала алырсызмы икән — анысын күз күрер әле!

## ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫ ИДАРӘСЕНДӘ

Идарәнең июнь аенда үткәрелгән утырышында шигырь бәйрәме йомгаклары, республика яшь иҗат көчләренең V семинары йомгагы, яшьләр белән эшләү комиссиясенең эше, Казанда РСФСР Язучылар союзының проза буенча Советы күчмә утырышын үткәрү һәм СССР Язучылар союзына яңа членнар кабул итү турындагы мәсьәләләр каралды.

Яшьләр белән эшләү комиссиясенең яңа составы расланды. Аңа Ш. Галиев (председатель), М. Вәлиев (секретарь), И. Юзеев, М. Скороходов, М. Шабаев, Ш. Маннур, Ә. Баянов, Г. Рәхим, Т. Миннуллин һәм А. Гыйләҗев иптәшләр кертелде.

## ӘДИПЛӘРЕБЕЗНЕҢ ӘСӘРЛӘРЕ БАШКА ТЕЛЛӘРДӘ

•

•   •

Язучы Шамил Бикчуринның «Каты торым» романы Чехословакиянең Словенску нәшриятында, словак телендә басылып чыкты. Тәрҗемәчесе — Вера Крнова. Тиражы 14 мең. Китапка сүз башында




Ш. Бикчуринның иҗади эшчәнлегенә югары бәя бирелә, романның кыскача эчтәлеге һәм әһәмияте турында әйтелә. Авторга чехословак дуслардан, китаплары белән бергә, котлау хаты да килде.

•

•   •

Мәскәүдәге «Молодая гвардия» нәшриятында филология фәннәре докторы, профессор Ибраһим Нуруллинның «Тукай» дигән китабы «Күренекле кешеләр тормышы» сериясендә басылып чыкты. Бу китап — татар халык шагыйренең тормышы, иҗаты турында художестволы биография.

Әсәрне рус теленә Радий Фиш тәрҗемә иткән.

•

•   •

Тува музыкаль драма театры бөтенсоюз милли драматургия фестивалендә татар совет шагыйре һәм драматургы И. Юзеевның «Сандугачлар килгән безгә» дигән әсәре буенча эшләнгән спектакль күрсәтте. Спектакльнең режиссеры — В. Л. Шкляр. Җәмәгатьчелек татар драматургы әсәрен җылы каршылады, өлкә газетасы «Тувинская правда» зур рецензия белән чыкты.

Бу әсәр моннан алда М. Гафури исемендәге Башкорт дәүләт драма һәм Мари музыкаль драма театрларында да куелган иде.

## ИГЪТИБАР ҮЗӘГЕНДӘ — ЯШЬЛӘР ИҖАТЫ

Апас ягы элек-электән үзенең язучылары һәм әдәбият белгечләре белән билгеле. Өлкәннәр традициясен дәвам иттереп, мәйданга яшьләр килә. Сигезьеллык һәм урта мәктәпләрнең күбесендә әдәби түгәрәкләр, район газетасы редакциясе каршында «Тамчылар» әдәби берләшмәсе эшли. Хәзер берләшмәнең 30 дан артык члены бар.

КПСС Үзәк Комитетының «Иҗат яшьләре белән эшләү турында»гы карарын үтәү йөзеннән монда яшь әдәбиятчыларның беренче район конференциясе үткәрелде. Анда «Тамчылар» әдәби берләшмәсе һәм мәктәпләрнең әдәби түгәрәк членнары катнашты.

Конференцияне котлау сүзе белән КПСС райкомы секретаре К. Филиппова ачты. Яшь әдәбиятчыларны Татарстан Язучылар союзы партоешмасы секретаре язучы В. Нуруллин һәм ВЛКСМ райкомы секретаре Ф. Фәтхуллин котлады. Конференциядә катнашучылар «Тамчылар» әдәби берләшмәсе эше турында доклад тыңладылар. Әдәбият укытучысы Н. Вәлиева мәктәптәге әдәби түгәрәкнең эш тәҗрибәсе белән уртаклашты. Филология фәннәре кандидаты тәнкыйтьче Флүн Мусин «Фән-техника революциясе һәм хәзерге авылның әдәбиятта чагылышы» дигән темага доклад сөйләде. Союзның яшьләр белән эшләү комиссиясе председателе шагыйрь Шәүкәт Галиев, шагыйрь һәм драматург Илдар Юзеев Апасның яшь әдәбиятчылары белән фикер уртаклаштылар, иҗат яшьләре алдында торган бурычларны аңлаттылар.

Аннары яшь әдәбиятчыларның проза һәм поэзия секцияләре эшләде. Вакыйф Нуруллин, Илдар Юзеев, Шәүкәт Галиев, Аяз Гыйләҗев, Абдулла Шәрәфи, Хәкимҗан Халиков башлап язучыларның иҗатын тик-

шерделәр, кайбер әсәрләргә рецензияләр бирделәр. Секцияләрдә уңай бәя алган әсәрләр өлкә матбугатына тәкъдим ителде.

*
* *

Шагыйрьләр секциясе Р. Хәлиуллина һәм М. Галиевның кульязма шигырь китапларын укып тикшерде. Фикер алышуларда катнашып, өлкән шагыйрь С. Хәким, шагыйрьләр М. Шабаев, Р. Мингалимов, Р. Фәйзуллин, Р. Батуллин һ. б. иптәшләр яшь язучыларга күп кенә файдалы киңәшләр бирделәр. Ике авторның да кульязмалары, китап итеп чыгару өчен, Татарстан китап нәшриятына тәкъдим ителде.

*
* *

Азнакай әдәби берләшмәсендә яшь авторларның иҗат активлыгы турында сөйләшү булды. Татарстан Язучылары союзының Әлмәт бүлеге җаваплы секретаре Ә. Маликов яңа басылып чыккан әсәрләргә тукталды, бүлекнең перспектив планнары турында сөйләде. «Маяк» газетасы редакторы Әхәт Мөхәмәтшин газета битләрендә очерк, зарисовка һәм мәкаләләр белән актив катнашкан, конкурста җиңеп чыккан авторларга бүләкләр тапшырды. Җыелышта язучы Мәхмүт Хәсәнов, яшь язучылар Нур Әхмәдиев, Ирек Бәдретдинов һ. б. катнашты.

Яшьләрнең иҗат активлыгына багышланган җыелыш шулай ук Лениногорск әдәби берләшмәсендә дә үткәрелде. Ә. Маликов, Ш. Бикчурин, яшь язучылардан Рәшит Бәшәров, Әсрар Галиев һ. б. чыгыш ясады.

*
* *

Шагыйрә Сажидә Сөләйманова Чаллыдагы «Ләйсән» әдәби берләшмәсе члennары белән очрашты, аларның яңа әсәрләрен тикшерүдә катнашты. Яшь шагыйрьләрнең аерым шигырьләре республика матбугатына тәкъдим итү өчен сайлап алынды.

*
* *

Казан дәүләт университетындагы «Әллүки» әдәби берләшмәсенең чираттагы утырышында яшь шагыйрьләр иҗаты тикшерелде. Анда Илдар Юзеев катнашты.

*
* *

Арча районы газетасы каршындагы «Тукай якташы» исемле әдәби берләшмәнең (җитәкчесе Радик Фаизов) май аенда үткәрелгән утырышында Язучылар союзының әдәби консультанты Илдар Юзеев һәм Яшь авторлар белән эшләү комиссиясе председателе Шәүкәт Галиев катнаштылар.

## СОЮЗНЫҢ ӘЛМӘТ БҮЛЕГЕНДӘ

*
* *

Бүлекнең чираттагы утырышында язучы Мәхмүт Хәсәновның «Шөгеровлар» дип исемләнгән яңа романын тикшерү булды. Әсәр нефть чыгаручылар турында, аның геройлары итеп гомерләрен нефтькә багышлаган Шөгеровлар династиясе алына. Ә. Маликов, Г. Афзал, Ш. Бикчурин, Х. Хәйруллин, Ю. Әминов, Җ. Рәхимов, С. Кальметов һәм Р. Бәшәровлар яңа әсәр турында үз фикерләрен һәм әдипкә теләкләрен әйттеләр.

*
* *

Бөек Октябрь революциясенең 60 еллыгы уңае белән Бөгелмә шәһәрендә әдәби кичәләр үткәрелде. Язучылардан Ш. Бикчурин, Э. Касыймов Техника йортында чыгыш ясадылар. Кичәдә катнашучылар бу авторларның Мәскәүдә «Современник» нәшриятында русча басылып чыккан, «Каты токым» һәм «Чулман — оныклар елгасы» дигән романнары турында сөйләделәр, язучыларга күп кенә сораулар бирделәр.

*
* *

Лениногорск районы Чыршылы авылында үткәрелгән әдәби-музыкаль кичәдә колхозчылар һәм мәктәп балалары язучы Ш. Бикчурин, яшь язучылар Альберт Хәсәнов, Разим Вәлиуллин, Шарига Таһирова һәм әдәби берләшмә члennарының чыгышларын кызыксынып тыңладылар. Ахырдан үзешчәннәр көче белән концерт бирелде.

*
* *

Әлмәт әдәби берләшмәсе утырышында Татарстанның халык артисткасы, Бөек Ватан сугышы ветераны Зәкия Туишеваның «Сугышның бер мизгеле» исемле әдәби язмалары тикшерелде. Гамил Афзал, Сажидә Сөләйманова, яшь язучы Газиз Кашапов һ. б. иптәшләр әсәргә уңай бәя бирделәр, аерым кимчелекләрен күрсәттеләр.

*
* *

Җәлил нефтьчеләр поселогының Техника йортында «Сарман таңнары» әдәби берләшмәсе члennары белән очрашу булды. Берләшмә җитәкчесе язучы Хәниф Хәйруллин татар әдәбиятындагы яңалыклар белән таныштырды, яшь авторлар үзләренең әсәрләрен укыдылар. Кичәдә элек Сарман урта мәктәбен тәмамлаган шагыйрә Клара Булатова шигырь сөйләде.

## ОЧРАШУЛАР, ӘДӘБИ КИЧӘЛӘР

*
* *

Язучы Миргазиян Юныска 50 яшь тулды. Аның иҗат бәйрәменә багышланган тантаналы кичә әдипнең туган авылы Исәргәптә уздырылды. Юбилярны Баулы район хезмәт ияләре исеменнән райком секретаре Х. З. Заһидуллин, Язучылар

союзы исеменнән Мөсәгыйть Хәбибуллин, колхоз, мәктәп житәкчеләре һәм язучының авылдашлары котлады. Кичәдә язучы М. Мәһдиев һәм яшь шагыйрь Мөдәррис Әгъләмовлар катнашты.

*
* *

Шагыйрь С. Хәким һәм И. Юзеев Казан дәүләт педагогия институты студентлары, укытучылары белән очраштылар. Сүз Бөек Октябрьның 60 еллыгы һәм бүгенге татар совет әдәбияты турында барды. Шагыйрьләр бөек юбилейга багышланган әсәрләрен укыдылар, сорауларга җаваплар бирделәр.

*
* *

Язучы Гомәр Бәширов һәм Татарстан китап нәшрияты директоры Г. Шәрәфетдинов Баулы районының китапханә работниклары белән очраштылар. Сүз бүгенге татар әдәбияты һәм китап нәшриятының эшчәнлеге, планнары турында барды. Г. Бәширов һәм Г. Шәрәфетдинов районның Ленин исемендәге колхозында (Шалты авылы) булып укучылар конференциясендә дә чыгыш ясадылар. Һәр ике очрашуда да КПССның Баулы район комитеты секретаре Х. З. Заһидуллин, район культура бүлеге мөдире И. Камалетдинов һәм район газетасы редакторы К. Әхмәтжановлар катнашты.

*
* *

Драматург Р. Ишморат, язучы Р. Ишморатова, шагыйрь Р. Гәрәй, Язучылар союзының пропаганда бюросы мөдире Э. Гаделов, баянчы З. Гыйбадуллин һәм яшь җырчы К. Хәйретдинова Саба районында колхозчылар, урман хуҗалыгы эшчеләре, укучылар белән очраштылар.

*
* *

Һәр елның июнь аенда туганлаш Мари республикасында милли бәйрәм — Чәчәк бәйрәме уздырыла. Традиция буларак, анда шагыйрьләр дә катнаша, шигъри митинг, әдәби очрашулар була. Йошкар-Ола шәһәре янында яшел урман аланында узган быелгы шигъри митингка Казаннан кунак булып шагыйрь Рәдиф Гатауллин барды. Мәскәү, удмурт, мари шагыйрьләре белән берлектә үзенең шигырьләрен укыды, татар әдәбияты яңалыклары белән таныштырды.

*
* *

Композитор Фасил Әхмәтов һәм шагыйрь Илдар Юзеев Казан медицина училищесы студентлары, язучы Мәҗит Рафиков Казанның 109 нчы мәктәп укучылары белән очрашуларда катнаштылар.

*
* *

Тукай-Кырлай мемориаль музеенда Татарстан китап нәшрияты работниклары белән очрашу булды. Нәшрият директоры Г. Шәрәфетдинов, редакция мөдирләре язучылар Ш. Рәкыйпов, И. Низамов һәм өлкән редакторлардан К. Миңлебаев, М. Зарецкий, Р. Вәлиевалар колхозчылар һәм авыл интеллигенциясен үзләренең иҗади эшләре, нәшриятның киләчәккә планнары белән таныштырдылар.

*
* *

Татарстан китап нәшрияты директоры Гарәф Шәрәфетдинов, баш редактор урынбасары Нурулла Габитов, редакция мөдирләре Шәүкәт Галиев, Шамил Рәкыйпов һәм Илдар Низамовлар Казан мәктәпләренең татар теле һәм әдәбияты укытучылары белән очраштылар. Очрашуда әдәбият дәреслекләре бастыру һәм әдәбият укытуны яхшырту турында эшлекле сөйләшү булды.

## ФӘННИ КОНФЕРЕНЦИЯ

Мәскәүдә В. И. Ленин исемендәге СССР Дәүләт китапханәсендә, Бөек Октябрьның данлы юбилеена багышлап, «Совет китабына — 60 ел» дигән III Бөтенсоюз фәнни конференциясе булып үтте. СССР Фәннәр академиясе, В. И. Ленин исемендәге СССР Дәүләт китапханәсе, Бөтенсоюз китап палатасы һәм китап сөючеләрнең Бөтенсоюз ирекле җәмгыяте оештырган конференциянең пленар утырышларында китап басуның һәм таратуның, гомуман китап белеменең актуаль проблемаларына багышланган 100 дән артык доклад ясалды. СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалы Г. Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм тарих институты галиме Ә. Кәримуллин, Казан авыл хуҗалыгы институтының КПСС тарихы кафедрасы мөдире Т. Насыйров, Казан культура институтының педагогия фәннәре кандидатлары Т. Дунаева, Т. Корбангалиева иптәшләрнең чыгышлары тыңлаучыларда зур кызыксыну уятты.

## ҮЗЕШЧӘН ТЕАТРЛАР ЯРЫШЫ

Республикабыз профсоюзларының үзешчән сәнгать театрларына традицион смотр-конкурсларның унберенчесе төгәлләнде. Анда Казан, Чаллы, Түбән Кама, Әлмәт, Зеленодольск һ. б. районнардан 17 татар һәм 13 рус театр коллективлары катнашты.

Халык театрлары арасыннан «Яз-77» лауреаты исеменә Ш. Хөсәеновның «Әни килде» пьесасы буенча куелган «Әниемнең ак күлмәге» спектакле өчен (режиссеры Н. Нуретдинов) Түбән Камадан М. Горький исемендәге клуб коллективы лаек булды. «Мехчы» культура сараеның «Игезәкләр» спектакле (авторы Ә. Атнабаев, режиссеры Р. Ибатов) — I дәрәҗә диплом алды. Рус халык театрлары коллективларыннан лауреат исеме Саидгалиев исемен-

дәге культура сарае коллективына (Г. Паушкинның «Танайка» пьесасын В. Кременчуцкий сәхнәләштергән) бирелде.

Драма коллективлары арасыннан Әлмәттән М. Горький исемендәге клуб, Чаллыдан «Энергетик» культура сарае театр студияләре коллективлары җинүче дип табылды.

## АЛАБУГАДА КҮРГӘЗМӘ

Бирегә Татарстан рәссамнары әсәрләреннән күргәзмә эшли башлады. ТАССР Художниклар союзы һәм Сынлы сәнгать музее оештырган бу күргәзмәгә республикабыз рәссамнарының иң яхшы әсәрләре сайлап алынган. Күргәзмә залларын аларның 57 хезмәте бизәп тора. Күп районнарда күрсәтеләчәк бу үзенчәлекле күргәзмә Татарстан художникларының республикабыз хезмәт ияләре алдындагы иҗат отчеты да.

## МУЗЕЙ ПРОПАГАНДИСТЛАРЫ

ТАССР дәүләт музееның бер төркем работниклары Чаллыда булып кайтты. Алар КамАЗның барлык заводларында «Барысы да Октябрьның 60 еллыгы хөрмәтенә», «Халык бәхете өчен көрәшчеләр», «Татарстанда Октябрь», «Синең комсомол билетың» дигән һәм татар әдәбияты классиклары Г. Тукай, М. Җәлил турында лекцияләр укыдылар.

## ГАСТРОЛЬЛӘР ҖӘЕ

*
* *

Татар дәүләт академия театрының быелгы җәйге гастрольләре республикабызның нефть районнарында, КамАЗда чыгыш ясаулар белән башланып киткән иде. Театр коллективы булган һәр район үзәгендә тамашачылар конференциясе үткәрелде, сәхнә осталары үзешчән сәнгать түгәрәкләренә, агитколлективларга иҗади ярдәм күрсәттеләр. Астраханьда бер ай дәвамында спектакльләр куйганнан соң, театрыбыз җәйге гастрольләрен Әзербәйҗан ССРның башкаласы Бакуда йомгаклады.

*
* *

Июнь аенда Г. Камал исемендәге Татар академия театры бинасында М. Гафури исемендәге Башкорт дәүләт академия театры спектакльләр күрсәтте. Казан тамашачылары тугандаш Башкортстан артистларының чыгышын зур кызыксыну белән һәм бик яратып карадылар. Шул ук көннәрдә Уфада исә Татар дәүләт республика күчмә театрының җәйге гастрольләре барды. Театр коллективы башкорт дусларга үзенең 11 спектаклен тәкъдим итте.

*
* *

Республикабыз тамашачылары июнь-июль айларында шулай ук М. В. Ломоносов исемендәге Архангельск драма театры һәм Мәскәүнең Пушкин исемендәге драма театры, Әлмәт татар дәүләт драма театры, (Казанда) һәм Киров исемендәге Астрахань драма театры (Чаллы, Түбән Кама, Зәй, Әлмәт, Лениногорск һәм Баулыда) коллективларының чыгышлары белән таныштылар.

## МАКТАУЛЫ ИСЕМНӘР

Совет музыка сәнгате өлкәсендәге хезмәтләре өчен Казан дәүләт консерваториясенең фәнни эш буенча проректоры, доцент **Чулпан Нәкыйповна Бәхтияровага**, Казан дәүләт консерваториясе кафедрасы мөдире **Алевтина Евгеньевна Миркинага Татарстан АССРның атказанган сәнгать эшлеклесе** дигән мактаулы исемнәр бирелде.

*
* *

Совет матбугаты өлкәсендәге хезмәтләре өчен «Коммунист Татарии» журналы редакциясенең философия һәм фәнни коммунизм бүлеге мөдире **Валерий Николаевич Русаковка Татарстан АССРның атказанган культура работнигы** дигән мактаулы исем бирелде.

## КОНКУРСТА КАТНАШЫГЫЗ!

Центрсоюз идарәсе органы «Советская потребительская кооперация» журналы редакциясе авыл кооператорлары — сатучылар, товар белгечләре, пешекчеләр, автолавка йөртүчеләр, хәзерләү работниклары, икмәк пешерүчеләр — авыл хезмәт ияләренең ихтыяҗларын канәгатьләндерү хакына тырышып эшләүчеләр турында язылган иң яхшы хикәя, очерк һәм фоторәсемгә конкурс игълан итте.

Конкурста җиңүчеләр өчен түбәндәге премияләр билгеләнгән:

Хикәя өчен: беренче бүләк — 350 сум, ике икенче бүләк — 250 шәр сум, өч өченче бүләк — 150 шәр сум. Очерк өчен: беренче бүләк — 200 сум, ике икенче бүләк — 150 шәр сум, өч өченче бүләк — 100 әр сум. Шулай ук кызыксындыру премияләре дә бар.


Хикәяләрнең күләме 16 биттән артмаска тиеш. Конкурска кульъязмаларны җибәрү срогы 1977 елның 1 декабренә кадәр. Адрес: Москва, ул. Студенческая, дом 35, редакция журнала «Советская потребительская кооперация».


# СОВЕТ СОЦИАЛИСТИК РЕСПУБЛИКАЛАР СОЮЗЫ ГИМНЫ

С. МИХАЛКОВ, Г. ЭЛЬ-РЕГИСТАН
тексты

А. В. АЛЕКСАНДРОВ
музыкасы

ӘХМӘТ ИСХАК, НУРИ АРСЛАНОВ
тәржемәсе



## Хөрмәтле укучыбыз!

Сезне журналыбызның 10 нчы саны белән таныштырабыз.

Бу сан Илдар Юзеевның «Өзелмәс кыллар» дигән яңа поэмасы белән ачылачак.

Әхәт Гаффарның «Кашан җыры» исемле повесте һәм Мәгъсүм Хуҗинның бергә тупланган өч хикәясе бирелә.

Поэзия бүлеге бай гына. Сезнең игътибарга Саҗидә Сөләйманованың «Казан — күңелем һәйкәлләре иле» дигән шигырьләр бәйләмен һәм Роза Хәлиуллинаның «Каенана» поэмасын да тәкъдим итә.

Бөек Октябрьның 60 еллыгы уңае белән күп кенә материаллар урнаштырыла. Филология фәннәре галиме Мөхәммәт Гайнуллин, язучы Габдрахман Әпсәләмов, драматург Риза Ишморат, язучы Атилла Расих үзләренең язмышларына, иҗатларына Бөек Октябрьның тәэсире турындагы фикерләре белән уртаклашалар. Х. Хәйруллинның «Бригадир Зөфәр», В. Белокопытовның «Яшәү хакына», Ә. Галиевнең «Давыллы еллар аша» дигән очерк һәм язмалары да Октябрь революциясе, кеше һәм ил язмышы турында сөйли.

Үзешчән сәнгать түгәрәкләрендә уйнар өчен Сәет Шәкүровның «Кыз бирү» пьесасы басыла.

Әдәбият тарихына материаллар, яңа китапларга рецензияләр, әдәби публицистика, юмор-сатира әсәрләре, әдәбият һәм сәнгать яңалыклары турында белешмәләр журналыбызның эчтәлеген тулыландырып, баетып торалар.

Хөрмәтле укучыбыз!

Журналыбызның киләсе елдагы кайбер планнары белән сезне таныштырган идек инде. Редакциягә яңа повесть һәм хикәяләр, шигырь һәм поэмалар, очерклар һ. б. материаллар килү дәвам итә. Аларның иң яхшылары сезнең игътибарга тәкъдим ителәчәк.

**1978 ел өчен газета-журналларга язылу дәвам итә. Алдагы елда да сезне журналыбызның актив укучысы булырсыз дип өметләнәбез.**

**«Почет билгесе» орденлы «Казан утлары» журналына Советлар Союзының барлык элемтә бүлекләрендә язылырга мөмкин. Язылу бәясе бер елга 6 сум. Журналыбызның индексы 73210.**

Бәясе 50 тиен
Цена 50 коп.

# КАЗАН УТЛАРЫ (ОГНИ КАЗАНИ)

Ежемесячный литературно-художественный и общественно-политический журнал

ОРГАН СОЮЗА ПИСАТЕЛЕЙ ТАТАРИИ

ИНДЕКС 73210